

# Казан утлары

4. 1986



Шагыйрьнең исеме В. И. Ленинга да билгеле булган. 1921 елда РКП(б)ның X съездына Татарстаннан килгән делегатлар белән әңгәмә вакытында Владимир Ильич сорау бирде:

— ...Сүз уңаенда әйтегез әле: сезнең татар әдәбияты белән эш ничек тора? Әлеге ...ни атлы соң... мулла улы... Пушкин, Лермонтов әсәрләрен туган теленә тәрҗемә иткән... Габдулла, Габдулла...

Мин:

— Тукаев! — дип әйтеп куйдым.

— Шагыйрьнең эшен лаеклы дәвам иттерүчеләр бармы соң?..

Мин, кечкенә куен дәфтәре белән карандашны кесәмә яшерә-яшерә, берничә яшь татар язучыларының исемен әйттем.

— Димәк, базда дары бетмәгән әле! — диде Ильич, елмаеп.

*В. М. Бахметьев.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

4

1986

## *Бу санда*

АПРЕЛЬ — В. И. ЛЕНИН ТУГАН АЙ

Ә. МӨЭМИНОВА. Үз даһие санап... *Шигырь* . . 3

Г. ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

М. ХӘСӘНОВ. Тукайның бөеклеге . . . . . . 4
С. ХӘКИМ. Тукай дәфтәреннән . . . . . . . 17
Бер сорауга — бер җавап (20, 27, 29) . . . . . 20
Н. НӘҖМИ. Шигърият йолдызы . . . . . . . 21
Э. ОГНЕЦВЕТ. Рухи кардәшлек . . . . . . . 26
Б. ВАҺАБЗАДӘ. Сабир һәм Тукай . . . . . . 28
В. КОЧЕТКОВ. Шигъри причалда. *Шигырь* . . 30
С. СЕИТОВ. Тукай турында уйланулар. *Шигырь* . 31
К. МОСТАФИН. Белсә иде, белсә иде! *Шигырь* . 32
Р. ГАТАУЛЛИН. Тукай сагындыра. *Шигырь* . . 33
Х. ӘЮПОВ. Бер индәге... *Шигырь* . . . . . . 34
РӨСТӘМ ВӘЛИЕВ. Дөнья гаме. . . . . . . . . 35
Р. БОХАРАЕВ. Тукай тирәсендә. *Драматик повестьтан өзек* . . . . . . . . . . . . . 97
М. МӘҺДИЕВ. Кырлай . . . . . . . . . . . 105
Х. ЗӘБИРОВ. Казанда Тукай урыннары . . . . 106
З. РӘСҮЛЕВА. Тукай шәҗәрәсе . . . . . . . . 109

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

М. ГЫЙЛӘҖЕВ. КамАЗ куенында *(Тукай районы)* 112

Г. ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Г. ТАҺИР, И. НАДИРОВ. Бәрәкәтле хәрәкәт . . 115
Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премияләре лауреатлары . . . . . 123
М. ПЛИСЕЦКАЯ. Гүзәл һәйкәл . . . . . . . 127
Р. НИЗАМИЕВ. Матурлыкның яшәр урыны. *Повесть* . . . . . . . . . . . . . . . . 130
К. ХӨСНУЛЛИН, Р. ӘХМӘТОВ. «Җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле» . . . . . . . . . 172
Г. ӘХӘТОВ. Сүз эчендә энҗе бар... . . . . . 176
Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы . . . . 178
Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . 189
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

22 апреля — день рождения Ленина: стихи Э. МУЭМИНОВОЙ.
Этот номер посвящается столетию Г. Тукая.
Статья первого заместителя Председателя Совета Министров ТАССР, председателя республиканской комиссии по проведению юбилея Г. Тукая М. Х. ХАСАНОВА — «Величие Тукая».
Отрывки из романа Рустема ВАЛЕЕВА «Земные заботы» (о Тукае).
Повесть Р. НИЗАМИЕВА «Шурәле» о композиторе Ф. Яруллине.
Драматическая повесть Р. БУХАРАЕВА «Вокруг Тукая».
Стихи С. ХАКИМА, В. КОЧЕТКОВА (Москва), С. СЕИТОВА (Алма-Ата), К. МУСТАФИНА, Р. ГАТАУЛЛИНА, Х. АЮПОВА.

Статьи: М. ПЛИСЕЦКОЙ (Москва) — «Величественный памятник», Н. НАДЖМИ (Уфа) — «Яркая звезда», Э. ОГНЕЦВЕТ (Минск) — «Духовное родство», Б. ВАГАБЗАДЕ (Баку) — «Сабир и Тукай».
Х. ЗАБИРОВ — «Тукаевские места в Казани», З. РАСУЛЕВА — «Родословная Тукая». Зарисовка М. МАГДИЕВА «Кырлай».
В рубрике «Татарстан — родной мой край» статья первого секретаря Тукаевского райкома КПСС М. В. ГИЛЯЗЕВА.
Интервью И. НАДИРОВА с преподавателем тюркских языков Хельсинского университета, председателем «Общество Тукая в Финляндии» Г. ТАГИРОМ.
Список лауреатов премии имени Габдуллы Тукая (1958—1985 гг.)
К. ХУСНУЛЛИН, Р. АХМАТОВ о песнях на слова Тукая.
Хроника жизни и творчества Тукая.
Дневник культуры.
На наших обложках: творчество художника М. Хайрутдинова.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова, Ч. Фәтхуллина.*

Производствога бирелде 7.02.1986 ел. Басарга кул куелды 28.03.1986 ел. ПФ 05119. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы $70 \times 108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 62749. Заказ В-51. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

## Энже Мөэминова

### Үз даhие санап...

Аллаларны ижат иткэн халык,
«Пэйгамбэрлэр» килеп киткэннэр:
Аз булмаган үзен «халык өчен
Хезмэт итүче», дип йөрткэннэр.

Тэхет каршысында баш идереп,
Иң зур көчкэ санап алтынны,
Кем казанган халык ихтирамын,
Көчлэү-буйсындыру аркылы?!

Адым саен йозак-тозак корып,
Богау салып аяк-кулларга,
Кем казанган халык ихтирамын,
Киртэ корып барыр юлларга?!

Алдау, хэйлэ белэн ышандырып,
Боерык арты боерык үтэтеп,
Кем казанган халык ихтирамын,
Ялган гуманлылык күрсэтеп?!

Кан кардэшен кан дошманы ясап,
Төрмэ-зинданнарга утыртып,
Кем казанган халык ихтирамын,
Бер-берсенэ каршы котыртып?!

Бер чынлыкны исбат итэ килгэн
Яшәешнең бөек законы:
Ирексезлэү арта барган саен,
Арта барган аңа каршылык.

Үз даhие килүен көткэн халык.
Көткэн еллар, көткэн гасырлар.
Һэм ул килгэн!—
Килгэн Ленин булып!
Җирнең үзэгенэ елышкан күк,
Дөнья халкы аңа тартылган —
Үзе телэп,
юлбашчысы итеп,
Җитэкчесе санап тартылган!

**Мансур Хәсәнов,**

ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары, Г. Тукайның 100 еллыгын уздыру буенча республика юбилей комиссиясе председателе.

# ТУКАЙНЫҢ БӨЕКЛЕГЕ

Совет кешеләре, бөтен прогрессив кешелек бу көннәрдә Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXVII съездында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш М. С. Горбачев ясаган Политик доклад, партия съездының тарихи карарлары, социализм төзү һәм җирдә тынычлык өчен көрәш программасын тормышка ашыру юнәлешендәге яңа фидакарьлекләр белән рухланып яши. Партия һәм халкыбыз социаль һәм рухи тормышның һәр өлкәсендә зур яңару, кискен борылышларга йөз тоткан бу әлеге яңа чор — кояшлы һәм нурлы апрель иртәседәй йөрәкләргә бетмәс-төкәнмәс егәр һәм ышаныч биреп тора.

«Без күп милләтле совет социалистик культурасының казанышлары белән нигезле горурланабыз. Милли формалар һәм бизәкләр байлыгын үзенә туплый барып, ул дөнья культурасында уникаль күренешкә әверелә»,— диде М. С. Горбачев үзенең докладында әдәбият һәм сәнгатьнең җәмгыятебез тормышында тоткан мөһим ролен билгеләп. Габдулла Тукайның бер гасырлык юбилее әнә шундый, чын мәгънәсендә тарихи көннәргә туры килде.

Кыя-тау никадәр биек булса, аның зурлыгын, мәһабәт матурлыгын тулырак күрү өчен дә шулкадәр читкәрәк, ераккарак китеп карарга кирәк, диләр. Күп милләтле уртак Ватанда яшәүче халыкларның революцион көрәш, иҗтимагый прогресс, әдәбият һәм культурасы тарихында да, әнә шул рәвешле, мәһабәт кыяларны хәтерләткән зур шәхесләр бар. Аларның исемнәре һәм кылган эшләре, В. Г. Белинский сүзләре белән әйткәндә, «мәңге яши һәм хәрәкәт итә торган күренешләрдән саналалар, алар гомерләрен үлем өзгән ноктада тукталып калмыйлар, ә бәлки җәмгыятьнең аңында алга таба үсүләрен дәвам иттерәләр».

Татар халкының бөек шагыйре, күренекле фикер иясе һәм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Тукай әнә шундый кыя-тауларның берсе. Бер гасырлык юбилее көннәрендә без ерак еллар аша янә бер кабат аның яшендәй яшьнәп кенә узган кыска гомер юлын, ул калдырган иҗади мирасны, Туры Тукайның яшәү үрнәген күз алдыннан уздырып, соклану һәм горурлану хисләре кичерәбез.

Габдулла Тукай... Ул Яз хәбәрчесе сыман. Язда туган һәм егерме җиденче язында ук китеп тә барган. Туган халкы һәм Ватаны кырларына киләчәк язга сусап, социаль тигезсезлекләрне, һәммә кимсетүләрне юкка чыгарачак язның килеренә ышанып, шул идеаллар хакына үз-үзен аямый көрәшеп янган, якты йолдыз булып күккә ашкан Яз хәбәрчесе Габдулла Тукай.

Тукай хакында сүз чыктымы, еш кына күңелгә бер сорау килә: ничек итеп гади генә бер авыл ятиме санаулы еллар эчендә күпгасырлык бай тарихы булган татар әдәбияты күгендә балкыр йолдызга әверелгән? Ничек итеп ул замандашларын һәм килер буыннарны, якташларын һәм илебез халыкларын үзенә берьюлы җәлеп итә алган? Каян шундый көч һәм бетмәс-төкәнмәс җегәр табылган? Бу сораулар безне еракка, халык рухы һәм халык аңының нигезләренә китереп чыгара. Борын-борыннан татар халкы азатлык сөючән идеал һәм якты, хөр омтылышларга йөз тотып яшәгән. Бу исә, барыннан да бигрәк, халык авыз иҗаты әсәрләрендә киң һәм тулы чагылыш тапкан. Әлеге бай рухи мирасның кайсы гына тармагын һәм кайсы гына үрнәген алсак та, без анда гади халык массаларының элек-электән азатлыкка омтылып, иминлекне бар нәрсәдән өстенрәк күреп яшәгәнлеген тоябыз. Дөрес, безгә бу сәламәт рух һәм якты идеалларның социаль тигезсезлек пәрдәсе аша саркып чыга алган өлеше генә килеп җиткән. Шулай да халык күңелендәге сәламәт һәм аек рух бар нәрсәдән көчлерәк! Ул әле шагыйрь Кол Галинең иҗади һәм гражданлык батырлыгы сурәте булган мәшһүр «Кыйссаи Иосыф» әсәре булып ташып чыга, әле Пугачев генералы Бәхтияр Канкаев артыннан царизмга каршы күтәрелгән крестьян массаларының якты өмет чаткыларында чагыла, яисә XIX гасырның мәгърифәт маяклары булып калыккан Г. Курсави, Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйрилар эшчәнлегендә балкып кабына.

Әйе, биек кыялар текә таулар иңендә калкып торганы кебек, бөек шагыйрьләр һәм фикер ияләре дә буш урында гына тумый. Аларны гасырлар дәвамында җыелып туплана килгән халыкчан рух, зур социаль һәм милли күтәрелеш дәверләре тудыра. XX йөз башы — Тукай шәхес һәм шагыйрь булып формалашкан, җитлеккән еллар нәкъ менә шундый. Беренче Рус революциясе байтак заманнар буе йокымсырарга мәҗбүр ителгән халыкларның, шул исәптән татарларның, социаль һәм милли үзаңын уятып, кинәт хәрәкәтләндереп җибәрә. Татар халкының алдынгы фикер ияләре алдында кинәт киң офыклар ачылып киткәндәй була, аларны гомумроссия һәм дөнья халыкларының рухи казанышлары җәлеп итә. Һәм, нәтиҗәдә, бу еллар татар әдәбияты, культурасы һәм иҗтимагый фикере өчен, Европа халыкларының Яңарыш дәверен хәтерләткән, кискен борылыш һәм җитди яңарыш чоры булды. Татарның бөтен иҗтимагый-рухи тормышы җанлана, активлашып китә, һәм бу үзгәрешләр, беренче чиратта, әдәбият һәм культура өлкәләрендә аеруча киң чагылыш таба. Милли матбугат формалаша. Матбугат исә, алдынгы иҗтимагый-политик фикерләрнең формалашуы, әдәби тәнкыйть һәм милли журналистиканың үсүе өчен мәйдан була. Иҗтимагый һәм рухи чынбарлыкның әһәмиятле факторы буларак, татар театры барлыкка килә. Мәйданга революцион хәрәкәт, әдәбият һәм культура күгендә тулы бер йолдызлыкны тәшкил иткән, халык күңелендә «мөбарәк тәсбихны» хәтерләтеп, озак еллар яшәячәк талант ияләре килә: Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Мәҗит Гафури, Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимов, Гафур Коләхметов... Санаулы еллар эчендә алар милли большевистик матбугат, реализм һәм халыкчанлык принципларына нигезләнгән яңа әдәбиятның проза, поэзия, драматургия, публицистика һәм әдәби тәнкыйть жанрларын тудырдылар, тарих һәм тел белеме фәннәрен нигезләделәр. Һәм шулар арасында егерме яшьлек Тукай төп җаваплылыкны үз өстенә ала, әлеге хәрәкәтнең әйдәүчесе була. Нәкъ менә Г. Тукай иҗаты һәм эшчәнлегендә халык массаларының күп гасырлар дәвамында туплана килеп тә, әлегәчә мәйданга чыга алмый килгән рухи тәҗрибәсе, зур потенциаль мөмкинлекләре чын мәгънәсендә гәүдәләнеш тапты, тормышка ашты ул елларда.

Шул рәвешле, гомум җанлану һәм яңарыш дәверендә яшәгән Тукай, үз чоры өчен генә түгел, татар әдәбиятының киләчәк үсеш юлларына да маяк булып кабына. Тулы мәгънәсендәге «милли әдәбият» төшенчәсе үзе дә тууы белән Г. Тукай иҗатыннан, Г. Тукай эшчәнлегеннән башлана. Менә шуңа күрә дә ул тарихка критик реализм принципларына нигезләнгән яңа татар әдәбиятын нигезләүче, яңа чорның милли әдәби телен тудыручы буларак керде.

Тукайның бөеклеге аның чынбарлыкны танып белүдә һәм тасвирлауда карашлары киңлеге, үз чорының аеруча әһәмиятле демократик һәм прогрессив идеяләрен тирәнтен аңлап, шулар югарылыгыннан торып иҗат итүе белән аңлатыла. Иҗатында тарихилык принципларына тугры булып калган хәлендә, ул — заман сулышын, гади халык массалары күңелендә бөреләнеп тә яфрак яра алмый торган изге омтылышларны чагылдыруы, чын халыкчанлыгы белән матурлыкны тою һәм әдәби зәвыгы нечкәлеге белән кабатланмас художник. Бөек шагыйрьнең таланты күпгасырлык бай традицияләре булган татар поэзиясен кинәт яшәртеп җибәрде, халык күңелендә шигъри сүзнең, әдәбиятның абруен бермә-бер үстерде. Илаһи матурлыкны җырлауга гына кайтып кала язган шигърияткә яңа чор сулышын алып керде. Чөнки ул — яңа чор шагыйре, ул —1905 ел җилләре белән мәйданга чыккан, якынлашып килгән тарихи язның сулышын тойган, шуңарга омтылган тынгысыз зат. Тукай шагыйрьлек талантын көрәшче кыюлыгы, гражданлык батырлыгы, җәмәгать эшлеклесе каһарманлыгы белән аерылгысыз рәвештә бергә куша, гомерен тулысы белән халык бәхете өчен көрәшкә багышлый. Каләмдәше һәм замандашы С. Рәмиевка язган хатларының берсендә: «Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә»,— дигән мәгълүм юллар бар. Җаваплылык хисе һәм шул олы җаваплылыкны тоюдан билгеле бер дәрәҗәдә горурлану хисе дә кичереп язылган әлеге юллар һич кенә очраклы түгел. Шагыйрьнең бөтен гомере, иҗат эшчәнлеге аларның ни дәрәҗәдә дөрес һәм урынлы булуын раслап килә.

Чынлап та, XX йөз башы татар чынбарлыгында булган һәммә үзгәрешләр һәм яңалыклар Тукай бәгыре аша узган. Иҗтимагый-политик һәм әдәби-мәдәни тормышның бер генә тармагында да Тукай игътибарыннан читтә калган мәсьәлә юктыр сыман, ул шагыйрь һәм гражданин буларак, заманның «шылт» иткән авазына да колак сала, барлык принципиаль мәсьәләләр буенча да кичектергесез рәвештә туры сүзен әйтә килә. Шул чор татар тормышындагы феодаль торгынлык һәм теләсә нинди прогрессив үзгәрешләргә киртә булып басарга омтылган иске карашлы дин әһелләренә каршы иң элек көрәшкә күтәрелүче кем? Тукай! Хатын-кыз азатлыгын, яшьләрнең җәмгыятьтәге урынын яклап, көн-төн матбугатта чаң кагучы да — Тукай. Халык мәгарифе, мәктәпләрдә әдәбият дәресләрен укыту, тарих мәсьәләләре, халык авыз иҗаты һәм аны җыю, пропагандалау, үткәндәге әдәби мираска заман күзлегеннән чыгып бәя бирү, музыка һәм башкаручылар, театр һәм беренче артистлар — боларның һәркайсы язмышы өчен дә Тукай җаваплы хис итә үзен, үз-үзен аямый мавыгып һәм янып иҗат итә, бәхәсләшә, көрәшә. Җыеп кына әйткәндә, Тукай иҗатын һәм эшчәнлеген XX йөз башы татар тормышының үзенчәлекле энциклопедиясе дип бәяләү дә һич арттыру булмас. Ләкин, шул ук вакытта ул теркәп, искә алып баручы гына да түгел, бу мәсьәләләрнең һәркайсының асылына үтеп керергә омтылып, аларны ил һәм дөньяда барган прогресс яктылыгында бәяләп, үсеш юлларын ачыкларга омтылып янып яши.

Югарыда искәртелгәнчә, Тукай үзен тулысынча халыкка хезмәт итүгә багышлады. Халык язмышы, халык мәнфәгатьләрен кайгыртып

яшәү — аның өчен бар нәрсәдән дә югарырак критерий. Үзе кече яшьтән үк татып өлгергән тормыш авырлыгына битараф була алмый шагыйрь. Шуңа да төннәрен күзенә йокы керми шагыйрьнең. Әйтерсең, бар дөньяны җылытырга теләгәндәй, ул юрганын тартыбрак куя, шундый төннәрдә һәм күңеленнән генә җирләр, күкләр белән сөйләшә, шәһәр һәм авылларда ачлы-туклы көн күргән якташлары язмышын уртаклаша:

Күзгә төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый;
Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.

— Иң сөекле эшче әүладым быел ач калды,— дип,
Изге, шәфкатьле анабыз — мәрхәмәтле җир җылый...

Ә шул ук вакытта, икенче берәүләрнең шушы ачлыкка югарыдан торып кына караш ташлавы, черек тешләренә алтын куйдырып йөрүләре... күз алдыннан китми шагыйрьнең. Шуларны чагыштырып күз алдына китергәндә, җил түгел, әйтерсең лә, шагыйрь үзе җылый, шагыйрьнең үз җаны тыпырчынып өзгәләнәдер сыман тоела.

Әмма шагыйрь халыкның көченә, аның матур һәм якты киләчәгенә ышанычын бервакытта да җуймый. Хезмәт кешесе, һичшиксез, канатларын киң җилпеп, кимсетү һәм түбәнлекләрдән югары күтәреләчәк, үз язмышын үзе хәл итә башлаячак. Моңарга ышаныч, аның «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул, әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә, бу күренештә йөри...» — кебек мәгълүм сүзләреннән дә ачык күренеп тора. Менә шул ышаныч Тукайны, халык өстенә төшкән бүгенге кыенлыклар, җәбер-золым, авыр язмыш хакында гына җырлаудан арынып, туган як табигате, анда яшәүче кешеләрнең матурлыгы һәм рухи байлыгына сокланып та иҗат итәргә рухландыра. Бу ышаныч шагыйрь өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы:

Җәй көнен яздым бераз; язый әле кыш, көзләрен.
Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле кызларын.
Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабаны туйларын
Язмыймын куркып, еракларга китәр дип уйларым...
Тукта, мин юлдин адашканмын икән бит, күр әле;
Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит: «Шүрәле».
Аз гына сабр ит әле, и кариэм! хәзер язам;
Уйласам аулымны, гакълымнан да мин хәзер язам.

Тукай поэзиясен, шул рәвешле, тулаем туган җиргә, туган халкына мәхәббәт хисләре сугарып тора. Бу мәхәббәттә татар поэзиясенең борынгыдан дәвам итеп килгән иң тотрыклы традицияләреннән берсе чагыла. Шагыйрьнең гүзәл лирикасы һәм сокландыргыч нечкә табигать бизәкләре белән чигелгән «Шүрәле» поэмасы да шул хакта сөйли. Аларда туган якларның җанлы картинасы тудырыла, урман һәм күлләре белән генә түгел, борынгыдан килгән йолалары, гореф-гадәтләре белән дә кабатланмас серле шигъри дөнья тасвирлана. Һәр образ, һәр төс һәм хәрәкәтне шагыйрь туган якларына мәхәббәте, якташларына ихлас хөрмәт тойгылары белән иңдерә кебек. Бу уңайдан табигать лирикасының гүзәл үрнәге саналырга лаек «Җәйге таң хатирәсе»н аерым искә алмый үтү мөмкин түгел:

Каршыларга иң сәза чак, иң матур чак җәйге таң;
Шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам, уйласаң.

Туган як табигате, шул рәвешле, шагыйрь күңеленә бетмәс-төкәнмәс рухи җегәр бирә, авырлыклар каршында баш имәскә, нык булырга өйрәтә. Шушы мәхәббәт аның тарихи оптимизмына нигез булып ята, төп эстетик концепциясен тәшкил итә. Халык рухының теренлегенә ышаныч аның әйләнә-тирәгә, яшәп килүче җәмгыятькә тәнкыйди

мөнәсәбәтен ныгыта, иҗатындагы сугышчан пафоска көч-куәт бирә. Ул әсәрләрендә, кемнең кем булуы белән дә хисаплашмыйча, ике-йөзлеләрнең битлеген салдыра, сатлык патша чиновникларының кемлеген күрсәтә, буржуаз милләтче һәм шовинистларны кеше көлкесе итә, зур булмаган милләтләрне рәнҗетүче империалистларны фаш итә.

Тукай сатирасы милли тормышның караңгы якларын да яшен яктысында көйдереп ала. Ишан һәм муллаларга көн күрсәтми, консервативлык һәм дини фанатизм, саранлык һәм дорфалык сыйфатларын конкрет мисаллары аша мәсхәрә итә. Гомумән, Тукайның социаль стройның бозыклыгын, тормыштагы һәммә консервативлыкларны фаш иткән үткен эпиграммалары, сатирик шигырьләре тиз арада киң яңгыраш ала. Бу җәһәттән «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасы аеруча зур уңыш казана. Тулы бер галереяны тәшкил иткән үткен сатирик персонажлар тудырыла әлеге поэмада. Анда шул заманның кара көчләре, конкрет прототипларыерактан танылып торган образлар гыйбрәт өчен хурлык баганасына бастырылалар. Борынгы сюжетка ияреп, пародияләштереп, татарлардагы дини фанатизмның мескенлегеннән, феодализм калдыкларының кызганычлыгыннан көлә ул. Тукай сатирасы дәһшәтле көчкә ия, чөнки аның адресы төгәл, максатлары ачык, ул хезмәт халкын турыдантуры һәртөрле социаль тигезсезлекләр һәм эксплуатациягә каршы көрәшкә чакыра.

Шул ук вакытта Тукай татарлар арасыннан да халык мәнфәгатьләрен яклап көрәшкә күтәрелерлек, әлеге көрәшнең авангардында барырлык ир-егетләр үсеп чыгачагына өметен өзми, чын күңеленнән ышана. «Безнең милләт тә, башка милләтләрдәге кеби, ...фәкыйрь вә эшче халыкның файдаларына тырышучы, биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алмаштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егетләргә мохтаҗ»,— дип язды ул «Хиссияте миллия» мәкаләсендә.

Дөрес, баштарак әле замананың әлегедәй геройларын кайдан эзләргә икәнлеген ул үзе дә ачык кына күз алдына китерә алмый иде. Ул аларны берара шәкертләр арасыннан эзләде, әмма соңыннан революционерлар арасыннан тапты. Мондый фикри эволюциягә, әлбәттә, аны алдынгы эшчеләр хәрәкәтенә якынаюы һәм бу хәрәкәтнең авангарды булып торган социал-демократларның яшерен оешмалары белән элемтәгә керүе алып килә. Һәр яңалыкка һәм прогрессив хәрәкәткә игътибарлы булган һәм табигате белән яктылыкка тартылып торган Г. Тукай әдәбиятчы замандашларыннан да иң элек социал-демократлар эшчәнлегенә игътибарын юнәлтә. Әле Уральск чорында ук аның инде эшчеләр хәрәкәтенең авангардында торган шәхесләр белән элемтәдә булуы мәгълүм. «Фикер» газетасы, «Әлгасрел җәдид» һәм «Уклар» журналларында актив язышу белән генә чикләнмичә, шагыйрь инде шул чорда ук социал-демократик фикерләрне алга сөреп, Россиядәге эшчеләрнең яшәү һәм хезмәт шартлары, әлеге шартлар белән алга таба инде артык канәгатьләнү мөмкин түгеллеген ачыктан-ачык язып чыккан рус газеталары «Уралец» һәм «Уральский дневник» белән дә иҗади мөнәсәбәтләр урнаштыра. Ул шул көннәрдә иҗади рухлану кичереп, социаль тигезсезлекнең капитализм шартларында табигый җирлеген, шул тигезсезлекләрнең экономик сәбәпләрен марксистик позицияләрдән торып яктырткан хезмәт А. Н. Бахның «Ачлык-патша» брошюрасының дүрт бүлеген тәрҗемә итеп бастыра.

Революцион-демократик идеяләргә тартылу шундук шагыйрьнең оригинал әсәрләрендә дә чагылыш таба. Мәсәлән, аның дөньяга карашындагы кискен борылышны шул көннәрдә иҗат ителгән, гомумән, Тукай иҗатында килешмәүчәнлек, сугышчанлык җәһәтләреннән үрнәк әсәрләрнең берсе — «Сорыкортларга» ачык чагылдырып килә.

«...җанымны чын юлда бирәм мең кәррә, кызганмыйм,
Минем чөн мәсләгем — юлым бөтенләй социаллардай»,—

дип, турыдан яра, яшерми-нитми әйтеп сала ул үзенең нинди юл сайлавы хакында, ике төрле фикер йөртергә урын калдырмыйча. Һәм шул ук 1906 елда «Мөселман иттифакы» партиясенә һәм аның җитәкчеләренә адресланган «Шартлар» исемле памфлетында ул: «Капиталистический строй бетеп, дөньяга социалистический тормыш чыкмыйча, капиталның һәр хакыйкатькә пәрдә булып торуы бетмичә, мин үзебезне мөселман дип йөрүдә бер мәгънә дә тапмыйм»,— дип игълан итә. Бу юлларны җентекләп укыганда, шагыйрьнең әлеге идеяләргә җитди инанганлыгын аңлау кыенлык тудырмас. Ләкин игътибарлырак булсак, аларның бер үк вакытта бөтен татар хезмәт ияләренә мөрәҗәгать, ачыктан-ачык революцион күтәрелешкә чакыру икәнлеген дә тану кирәктер.

Менә шуңа күрә дә Тукайның бөтен күңеле белән үз иткән иң якын дусларыннан берсе ялкынлы большевик-ленинчы Хөсәен Ямашев була. Әлбәттә, бу әле Тукай революцион көрәш тарихында Х. Ямашевның эшчәнлеген тулысынча күзаллаган дигән сүз түгел. Тормышның төрле шартлары аңар чын мәгънәсендә әлеге көрәшнең үзәгендә кайнарга ирек бирми. Шулай да халыкка, Ватанга тугрылыклы хезмәт итү үрнәге — ул Х. Ямашевныкы кебек соңгы сулышынача революцион көрәшкә бирелгән гомер дип саный. Шуңа да хөрмәт итә, шуңа да соклана һәм махсус шигырь-мәрсия багышлый ул Хөсәен Ямашев истәлегенә.

Көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кеби,
Ул иде өстен вә кул җитмәс кеше, йолдыз кеби,—

дигән юллар белән башланган мәшһүр «Хөрмәтле Хөсәен ядкаре» — бу татар поэзиясендә чын большевик-революционерларга багышланып иҗат ителгән иң беренче шигъри әсәр иде. Бүген без әдәбиятыбызның тарихи-революцион теманы үзләштерүдәге казанышлары хакында горурланып сөйлибез икән, әлеге традициянең дә чишмә башы Тукайдан булуын онытырга хакыбыз юк.

Халык шагыйре Г. Тукайның социал-демократик хәрәкәт белән элемтәләре, мәгълүм булганча, Казанга килгәч тә өзелеп калмаган. Татарстан Үзәк Дәүләт архивындагы тарихи документлар революцион хәрәкәттә катнашучыларга Тукай һәм аның иптәшләренең актив булышканлыгы турында сөйли. Аларның «Шәрык» клубында кичәләр уздырудан җыелган акчаны политик сөргендә булучыларга җибәргәнлеге, революция фондына күчергәнлеге ачыкланды. Бу уңайдан әле шушы елның башында үзәк һәм республика матбугат органнарында күренгән ТАСС хәбәре дә игътибарга лаек: «1911 елның ноябрендә РСДРПның VI Бөтенроссия (Прага) конференциясенә Казан большевикларыннан делегат, тугрылыклы ленинчы В. Догадовка «Шәрык» клубыннан акча бирелгән. Бу хәл бөек шагыйрь тормышында һәм иҗатында күркәм бер вакыйга булып тора»,— диелә анда.

Чын халыкчан шагыйрь булган тәкъдирдә, Тукай бөек интернационалист та иде. Аның бетмәс-төкәнмәс патриотизмы һәм Ватанга бирелгәнлеге нәкъ менә шул киң дәрьядан көч һәм гайрәт ала. Шагыйрьнең милли горурлык хисләре белән аның халыклар дуслыгы мәсьәләләрен аңлауда чын интернационалист булуы бер-берен тулыландырып киләләр, җиңелмәс рух рәвешендә иҗат юлына якты нур сирпеп торалар. Рус халкы белән бер дәүләт булып яшәүне ул бер язмыш, бер максат һәм уртак борчулар белән үрелгән табигый бергәлек буларак кабул итә. Ә инде халыклар арасында милли аерымлану һәм язмышлар башкалыгы идеяләре чәчәргә газапланган

шовинистларга һәм пантюркистларга ул беренче булып, күзләренә карап, туры җавап бирергә дә курыкмый. Туган халкын монда чит-ят санап Төркиягә җибәрергә димләгән карагруһчыларга аның җавабы ачык һәм бернинди икеләнүләргә урын калдырмый торган — «Китмибез!».

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне таңребез (гыйззе вә җәл).
Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт — хөр Русия!
Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе ру сияһ!

Халыклар арасындагы эчкерсез дуслыкка дан җырлаучыга әверелә шагыйрь. Ә инде рус һәм татар халыкларының максатлары, язмышлары уртаклыгына ул аеруча кат-кат басым ясап узуны кирәк саный:

Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, легать, гадәт вә әхлак алмашып.
...Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? —
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.

Тукай иҗатында халыклар дуслыгының бар нәрсәдән дә көчлерәк булуына инанганлык татар поэзиясендә һәм, гомумән, төрки халыкларда әлегәчә күрелмәгән югарылыкта яңгыраш ала. Һәм ул гомеренең соңгы сәгатьләренәчә бер иман — изелгән милләтләрнең хезмәт ияләре бары бердәм булган тәкъдирдә генә иң бөек максатларына — социаль азатлыкка ирешәчәк дигән ныклы ышаныч белән яшәде. Шундый ышаныч белән ул, капитализм кояшы батып, илдә социалистик җәмгыять урнашкан тарихи көн турында хыялланды.

Халыклар дуслыгы идеяләрен пропагандалауның һәрвакыт зур мөмкинлекләр ачучы юлы — ул әдәби багланышлар. Тукай чын интернационалист буларак рус һәм дөнья әдәбиятларының прогрессив традицияләренә мөрәҗәгать итүне милли әдәбият һәм әдәби-эстетик фикернең үсеше өчен кирәк булган иң әһәмиятле зарурлык дип саный. Дөнья халыклары әдәбиятының ул Көнчыгыштан Хафиз, Низами, Фирдәүси, Хәйям, Көнбатыштан Шекспир, Байрон, Гете, Шиллер, Гейне кебек мәшһүр фикер ияләре һәм шагыйрьләрен укып өйрәнә. Әдәби иҗатында булсын, тәнкыйть эшчәнлегендә булсын, ул казанышлардан файдалануны һәм бигрәк тә аларның идея-эстетик үзенчәлекләрен киң катлам укучыларга җиткерүне үзенең гражданлык бурычы дип саный шагыйрь. Рус әдәбиятына, рус халкының рухын чагылдыруга ирешкән зур талант ияләренә аның хөрмәте аеруча зур. Тукай хөрмәт иткән һәм Тукай өйрәнгән рус әдипләренең исемнәрен санап чыгу гына да күп нәрсә хакында сөйли. Пушкин һәм Лермонтов, Грибоедов һәм Толстой, Крылов һәм Некрасов, Тургенев һәм Никитин, Кольцов һәм Плещеев, Белинский һәм Писарев, ниһаять, М. Горький... Кыскасы, рус әдәбиятыннан аерым талант ияләренә генә соклану түгел шагыйрьнең бу мөнәсәбәте, ул аны, тулаем күзаллап, гигант зур дәрьяга охшатып колачларга омтылган. Һәм, әйтергә кирәк, шагыйрь буларак кына түгел, фикер иясе һәм тәнкыйтьче буларак та гаять зур уңышка ирешкән Тукай. Аның шигъри тәрҗемәләре һәм тәнкыйть мәкаләләре татар укучысын Жуковскийдан алып Горькийгача дистәләгән рус әдипләре иҗаты белән таныштыра.

Тукайның аеруча үз иткән һәм җентекләп өйрәнгән кумирлары — Пушкин һәм Лермонтов, Толстой һәм Горький. Тукай Пушкин поэзиясенең гуманизмын, азатлык сөючәнлеген һәм тормышны раслаучан рухын үзләштерә; Лермонтов шигырьләренең романтик киңлеген һәм бунтарьлыгын югары бәяли. Рус әдәбияты тарихында Пушкин һәм Лермонтов нинди урын алып торган булса, татар әдәбиятында үзе шундый биеклеккә күтәрелү турында хыяллана, шуңарга омтылып иҗат итә. Халык рухына тугрылыкта, аның мәнфәгатьләре белән

яныш яшәү һәм иҗат итүдә ул Лев Толстой һәм Максим Горькийга тиң булырга омтыла. Нәкъ менә шуңа күрә дә ул үз халкын алар иҗаты белән генә таныштырып калмый, бәлки алдынгы рус язучыларының иҗатына хас идеяләрне һәм образларны татар әдәбиятына алып керә, туган халкына җиткерә.

Гомумән, рус әдәбияты Тукайның дөньяга карашы һәм идея-эстетик принциплары формалашуга гаять бәрәкәтле йогынты ясый. Мәгълүм булганча, Г. Тукай татар әдәби тәнкыйть фикеренең нигез ташларын салуда, аның иҗтимагый тормыш һәм әдәби процесстагы урынын билгеләүдә зур урын тоткан фикер иясе дә. Бу уңайдан аның татар әдәби тәнкыйть тарихында программ хезмәт буларак мәгълүм «Тәнкыйть кирәкле шәйдер» мәкаләсен генә искә алу да күп нәрсә турында сөйли. Тукай әдәби тәнкыйть эшчәнлеген үзенең иң җаваплы бурычларыннан санаган һәм XX йөз башы татар әдәбиятының принципиаль проблемаларын күтәргән әдәби тәнкыйть мәкаләләре, әдәби процесста вакыйга булырлык әдәби әсәрләргә заман югарылыгыннан бәя биргән рецензияләре белән даими чыгыш ясап килгән. Әдәбиятта халыкчанлык һәм тормышчанлык, милли әдәбиятның дөнья әдәбиятларына мөнәсәбәте, әдәби осталык һәм идеялелек — боларның һәркайсы ул елларда беренче булып Тукай тәнкыйтендә күтәрелгән проблемалар. Һәм аларның алдынгы революцион-демократик карашлар югарылыгыннан торып хәл ителүендә шулай ук Тукайның өлеше зур. Без бүген татар әдәбияты Бөек Октябрьне иҗтимагый фикернең мөстәкыйль бер тармагы булган, принципиаль мәсьәләләрне заман югарылыгыннан торып хәл иткән әдәби тәнкыйть белән каршылады дип әйтәбез икән, монда шулай ук Тукайның зур өлеше булуы хакында онытмаска тиешлебез.

Үзенең әдәби-тәнкыйть һәм эстетик фикер өлкәсендәге эшчәнлегендә Тукай рус революцион-демократик тәнкыйте казанышларына, һәм беренче чиратта, Белинский, Добролюбов иҗатларына йөз тота. Аның җәмгыять тормышында әдәбиятның урыны һәм бурычлары турындагы фикерләре бер дә очраклы рәвештә генә бөек рус тәнкыйтьчеләренең мәгълүм хезмәтләрен хәтерләтми. Тукай да, Белинский кебек үк, әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә әдәбиятның чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәте, халык тормышы белән бәйләнешләре, дөреслек һәм реализм хакында фикер йөртә, үзенең замандашлары иҗатына да нәкъ менә шул критерийлардан торып анализ ясый, бәя бирә.

Тукайның шагыйрь һәм җәмгыять, иҗади шәхеснең иҗтимагый-әхлакый йөзе турындагы даими уйланулары да очраклы гына түгел. Һәм бу юнәлештә дә ул идеал эзләп ерак китми, ә Белинский һәм башка рус революцион-демократик тәнкыйтьчеләре иҗатында киң анализланган Пушкин һәм Лермонтовка мөрәҗәгать итә. Алар мирасыннан үзенең күңелендә йөргән, тынгылык бирми йөдәткән уй һәм хисләргә якынлык, аваздашлык эзли.

Халыкчанлык һәм гражданлылык юнәлешендәге даими эзләнүләр тора-бара табигый рәвештә Тукайны икенче бер бөек рус шагыйре, реализм һәм халыкчанлык җәһәтләреннән Тукайга тагы якынрак һәм аңлаешлырак булган Некрасовка алып чыга. Чөнки ул да, Некрасов кебек үк, шигъри сүзнең бәясен һәм кыйммәтен, иң элек, аның тормышчанлыгы һәм халык мәнфәгатьләренә якынлыгы белән үлчәргә күнеккән. Шулай итеп аның поэзиясендә гади халык тормышының кырыс реализмы торган саен киңрәк чагылыш таба бара, хезмәт ияләренең авыр язмышы тетрәндергеч дәрәҗәдә тормышчан картиналарда сурәтләнә. Мисал өчен, аның 1911 елда Идел буйлап пароходта Астраханьга сәяхәте нәтиҗәсендә язылган «Көзге җилләр» шигырен искә алырга мөмкин. Корылык нәтиҗәсендә туган ачлык елдагы тормышның бөтен чынбарлыгын ачуга ирешә анда Тукай. Һәм бу әсәр-

нең беркадәр Некрасовның «Размышления у парадного подъезда»сына идея-эстетик якынлыгын да абайламау мөмкин түгел. Хезмәт ияләре, крестьяннарның авыр язмышы гаять реалистик детальләр аша тетрәндергеч итеп сурәтләнә әлеге әсәрләрдә.

Тукай өчен рус әдәбияты бер үк вакытта дөнья, аерым алганда, Көнбатыш Европа әдәбиятларына тәрәзә дә булып тора. Гомумән, XX йөз башы татар әдәбиятын җентекләп күздән уздырганда рус әдәбияты үзе зур мәктәп булу белән бергә, аның дөнья әдәбиятлары белән тоташтырып торган күпер булуына да игътибар ителә. Тукай әлеге бәрәкәтле бәйләнештән дә урынлы һәм оста файдалана, Европа халыкларының идея-эстетик казанышларын зур кызыксыну белән өйрәнергә керешә. Аның тәнкыйть хезмәтләрендә әледән-әле Байрон, Гете, Шиллер һәм Гейнеларны искә алып, аларның иҗат принциплары хакында уйланулары очраклы түгел. Әмма шул ук вакытта бу уңайдан принципиаль ачыклык кертеп узу да зыян итмәс. Чөнки кайбер тикшеренүләрдә Тукайның Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятлары һәм эстетикасы белән кызыксынуын Көнчыгыштан йөз чөерергә омтылыш итеп тә аңлатырга теләүчеләр булды. Әлбәттә, хакыйкатьтә алай түгел иде — иҗатының кайсы гына чорында булмасын, Тукай классик Көнчыгыш поэзиясе һәм фәлсәфи фикеренең кыйммәтен киметеп күрсәтмәде. Хафиз, Хәйям, Нәваи, Низами иҗатлары, борынгы болгар-татар поэзиясенең классик үрнәкләре кебек үк (мисал өчен, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы) аның өчен, чын мәгънәсендә, гуманизм һәм шигъри осталык мәктәбе булып торды. Алай гына да түгел, шәрык поэзиясенең традицияләрен үзләштерүдә Тукай һәм аның кайбер замандашлары яңа баскычка күтәрелделәр, кешегә, аның акыл һәм рух көченә, матурлыгына дан җырлаган бу шигърият дөньясын яңа шартларда заман ихтыяҗларына җавап йөзеннән тагы да киңрәк колачлый алдылар. Нәтиҗәдә, Г. Тукай иҗатында Шәрык, рус һәм Европа әдәбиятларының иң яхшы традицияләре бергә кушылып, борынгы төрки-татар поэзиясе казанышларына нигезләнгән, сыйфат ягыннан яңа шигъри дөнья туды. Бу исә реализм һәм халыкчанлык юлыннан үсәчәк яңа татар әдәбиятына ышанычлы һәм ныклы нигез салыну дигән сүз иде. Тукай иҗатының дөньякүләм әһәмияте нәкъ менә шул үзенчәлекләре — моңарчы гасырлар дәвамына бер-береннән изоляцияләнгән, аерым үсештә булган көнчыгыш һәм көнбатыш поэзияләренең традицияләрен органик төстә үзенә сеңдереп, милли нигездә үстереп җибәрүе белән аңлатыла.

«Казан — ике дөньяның көрешкән һәм очрашкан төбәге»,— дип сокланып язган үз вакытында безнең якларга килеп чыккан бөек рус революционеры А. И. Герцен. Тукай үзенең шигъри иҗатында әлеге күзәтүләрнең тормышчанлыгын шигърият мисалында тагы бер кат исбат итте. Гомумән, иҗтимагый һәм рухи тормышның һәммә тармакларына да хас иде бу прогрессив үзгәрешләр. 1905—1907 еллар революциясе нәтиҗәсендә татар халкы тизләтелгән адымнар белән дөньяда һәм Россиядә барган шаулы тарихи процесска йөз тотты, колониаль артталык һәм милли чикләнгәнлек богауларыннан арына барып, зур прогрессив хәрәкәткә килеп кушылды. Шул елларда татарлар арасында көчәеп киткән милли-азатлык хәрәкәте һәм тарихи-революцион күтәрелеш моның характерлы мисалы булып тора.

Яңалык өчен көрәштә иҗтимагый-политик тормышның һәр тармагында кайнап торган яңалыкка омтылышны чагылдыра-чагылдыра, үз чиратында әдәбият та сыйфат җәһәтеннән принципиаль сикереш ясый. Әдәбият инде милли ихтыяҗларны кайгырткан мәйдан гына булып калмыйча, иҗтимагый-политик көрәш аренасына, халык тормышын һәрьяклап яңа югарылыкка күтәрүне алга сөргән зур көчкә әверелә. Әдәби образлар һәм сурәтләү чаралары, бер яктан

яңа тарихи тәҗрибә йогынтысы астында байый барса, икенчедән, дөнья әдәбиятларының прогрессив казанышлары тәэсирендә үсүен дәвам итә. Бер сүз белән әйткәндә, татар әдәбияты дөнья әдәбиятларының магистраль үсеш юлына килеп кушыла. Һәм нәкъ менә шуңа күрә дә Тукай иҗаты беренче карлыгач иде — татар әдәбиятының бөтенкешелек культурасына зур өлеш булып кергән карлыгачы.

Көнбатыш Европа һәм рус культурасы казанышларын тиз арада иҗади үзләштерүе нәтиҗәсендә Г. Тукай бер үк вакытта үзе күп кенә тугандаш милли әдәбиятлар өчен әлеге бай тәҗрибәгә чыгу юлында арадашчы ролен үти. Тукай поэзиясенең интернациональ характеры, алдынгы һәм дөньяви идеяләр белән сугарылган булуы әле Октябрьгә кадәр үк төрки телле әдәбиятлар үсешенә җитди йогынты ясый. Шагыйрьнең һәр китабы диярлек әле үзе исән чагында ук Россиянең иң ерак төбәкләренә барып җитә, азатлык сөючән, кешелекле, югары гражданлык хисләренә бай булуы белән укучыларны һәм шагыйрьләрне үзенә җәлеп итә. Тукай шигырьләре татарлар арасында гына түгел, казах, кыргыз, үзбәк, төркмән, каракалпак, уйгур, кумык, таҗик һәм башка күп кенә тугандаш халыкларга милли-азатлык идеяләрен, прогрессив рус әдәбиятыннан күчкән яңа революцион көрәш рухын тарата. Нәтиҗәдә әлеге тугандаш әдәбиятларның заман тормышы, халык тормышы һәм реаль чынбарлыкка игътибары бермә-бер активлаша. Шулай итеп, Тукайның шигъри мәктәбе татар әдәбияты даирәсе белән генә чикләнми, ә күп кенә тугандаш халыкларның сүз осталарын да үз эченә ала. Башкорт шагыйрьләре Д. Юлтый һәм С. Кудаш, үзбәк халкының бөек уллары Хәмзә һәм Г. Голәм, казах совет әдәбиятына нигез салучылардан С. Сәйфуллин һәм Б. Майлин, таҗик әдәбияты классигы С. Айни, күренекле төркмән әдибе Б. Кербабаев — һәркайсы үзен Тукай мәктәбе шәкерте дип санады. Әлбәттә, бу исемлекне әле тагы да дәвам итү мөмкин булыр иде. Казах совет язучысы академик С. Моканов Тукайны, күрәмсең, бер дә очраклы рәвештә генә «Шәрык поэзиясенең титаны» дип атамагандыр.

Татар шагыйре иҗатының әлеге популярлыгы, әлбәттә, патша самодержавиесе тарафыннан бер дәрәҗә изелгән тугандаш халыкларның язмыш уртаклыгы белән дә аңлатыла. Әмма, шул ук вакытта, феодаль торгынлыкка, дини фанатизмга каршы чыгу, милли һәм социаль тигезсезлекләрнең тамырын юкка чыгару турындагы шигъри сүз шәрык дөньясы өчен чын мәгънәсендә зур кыюлык һәм новаторлык иде. XX йөз башы шартларында мондый проблемаларны кискен рәвештә күтәргән иҗатка, гомумән, битараф калу мөмкин булмагандыр.

Беренче Рус революциясе көннәреннән үк Тукай татар культурасының революцион-демократик канатын җитәкләүгә алына. Бу аеруча зур иҗтимагый-политик җаваплылык өсти шагыйрь шәхесенә. Шул ук вакытта әле шагыйрьнең һәр яңа әсәре тугандаш халыкларда да зур кызыксыну уята килүне искә алсак, интернационалист шагыйрь өстенә төшкән әлеге җаваплылыкның масштабын аңлау зур кыенлык тудырмаса кирәк. Тукайның революцион-демократик ялкын белән иҗат ителгән сугышчан шигърияте һәм иҗтимагый, әдәби процессларның иң четерекле проблемаларына багышланган публицистик чыгышлары, әдәби тәнкыйть мәкаләләре Казахстан, Урта Азия һәм Кавказда яшәүче күпсанлы укучылары өчен дә җитди әһәмияткә ия була.

Милли көндәлек матбугат органнарының шул чордагы тарихын өйрәнүчеләр ул елларда шагыйрь иҗаты тудырган зур резонанска махсус игътибар итүне кирәк саныйлар. Татар шагыйренең үлеме дә бөтен төркиләрнең уртак югалтуына әверелә. Бер ай дәвамына диярлек милли траур игълан иткән татар газеталары хакында сөйләп тору да артык булса кирәк, алар ул чорда бертавыштан халыкның

иң сөекле җырчысын, рухи юлбашчысын югалту хакында яза. Бу очракта нибарысы бер мисалга — Бакуда чыккан «Каспий»ның 1913 ел, 20 апрель санына игътибар итик: «Сабир һәм Г. Тукай кебек милли талантларның арабыздан китүе, интеллигенциядән бигрәк, гади хезмәт ияләрен тирән кайгыга салды... Халык массалары хәзер җанына үз булган күп нәрсәгә башкача карарга өйрәнде... Тамырдан үзгәреш бара дөньяда, һәм моңарга бернинди киртәләр дә каршы тора алмас»,— дип язылa анда. Тукайның үлеме шундый яңгыраш ала. Һәм бу патша чиновникларын чын мәгънәсендә куркуга сала.

Шагыйрь иҗатының зур идея-тәрбия әһәмияте тугандаш республикаларда Бөек Октябрьдән соң да югары бәяләнә. Мәсәлән, Үзбәкстанда чыгучы «Иштиракиюн» («Коммунист») газетасы «Шәрык шагыйре иптәш Габдулла Тукай» (15 апрель, 1920 ел) дип исемләнгән мәкаләдә болай дип язды: «Көнчыгышның Мәгарри, Хафиз, Хәйям, Сәгъди, Нәваи кебек бөек шагыйрьләре арасында Габдулла Тукай дәрәҗәле урын алып тора. Ул үзенең иҗаты белән төрки-татар дөньясы хезмәт ияләрен Россиядәге Бөек революциягә әзерләде».

Конкрет шартлар һәм көн тәртибендә торган иҗтимагый-культура мәсьәләләренә мөнәсәбәтле рәвештә шәрык халыклары Тукай иҗатына төрле чорда төрлечә идея һәм эстетик кызыксыну белән мөрәҗәгать итеп килделәр. Әйтик, унынчы елларда Казахстанда, Урта Азиядә, Кавказда һәм Дагстанда аның дөньяга карашы мәсьәләләренә һәм иҗатының революцион-демократик юнәлгәнлегенә зур игътибар бирелгән булса, 20-30 елларда исә Тукайның сатирасы махсус өйрәнү объектына әверелә. Тугандаш халыкларның С. Донентаев, С. Торайгыров, Б. Кербабаев, Х. Х. Ниязи, Ш. Туктаргази, Аткай кебек күренекле сатирикларына аеруча зур йогынты ясый шагыйрьнең сатирасы. Әинде Бөек Ватан сугышы елларында төрки телле әдәбиятлар аеруча Тукайның азатлык сөючән хөр рухына, халыклар дуслыгы һәм патриотизм идеяләрен олылаган әсәрләренә игътибар юнәлтәләр.

Шагыйрьнең 80 һәм 90 еллык юбилейларын уздырган чорда тагы бер мәртәбә Тукай иҗатының интернациональ рухы гаять югары бәягә лаек булды. Казанда һәм Мәскәүдә үткәрелгән бәйрәм кичәләрендә һәм гыйльми конференцияләрдә, илебезнең үзәк һәм җирле матбугатында ясалган чыгышларда шагыйрьнең интернациональлеге иҗатының илкүләм әһәмияткә ия булуын тәэмин иткән үзенчәлек буларак ассызыклап бәяләнде. Тугандаш төрки телле әдәбиятлар вәкилләре тагы бер тапкыр Тукай иҗатының бөек рус культурасы белән үзләре өчен арадашлыгын аерым хөрмәт белән искә алдылар. Мисал өчен, Ч. Айтматов чыгышыннан нибарысы бер фрагментны искә алыйк: «Төрки телле халыкларга Тукай иҗатының тәэсире җуелырлык кына булмады, әле бүген дә без аның җылылыгын үзебездә тоеп яшибез. Безнең Урта Азия республикаларында Тукай әсәрләрен укып, кайчан да булса бер рухланмаган кеше, гомумән, юктыр дип уйлыйм. Чөнки Тукай, әле безнең халыклар бөек рус әдәбиятының тәэсирен, йогынтысын тоя башлаганга кадәр үк, үзенең әсәрләре белән рус һәм Европа әдәбиятларының игелекле җилен алып килде безнең төбәкләргә. Үзбәкстан башкаласы Ташкентның үзәк урамнарыннан берсенең Г. Тукай исемен йөртүе дә әлеге хөрмәт билгесе булса кирәк. Һәм ул киң, матур урамның Алишер Нәваи проспекты белән кисешүе — очрашып кул кысышуы да — халыклар дуслыгын символлаштырган тирән мәгънәгә ия.

Г. Тукай хакында бөек революция юлбашчысы даһи В. И. Ленин да ишетеп белгән һәм аның талантын югары бәяләгән. 1921 елның мартында РКП(б)ның X съездына килгән Казан делегатлары белән очрашкач, татар әдәбиятының хәле белән кызыксына юлбашчы, Г. Тукай башлаган эшнең лаеклы дәвам иттерүчеләре бармы, дип сорый. Уңай җавап ишеткәч В. И. Ленин елмаеп ук җибәрә һәм:

«Димәк, базда дары бетмәгән икән!» — дип куя. Без бүген, куаныч белән, даһи юлбашчының әлеге ышанычы акланды дип әйтә алабыз. Бөек Тукай иҗатының лаеклы дәвамы булды, ул башлаган җаваплы эшнең киләчәге зур дип раслый алабыз. Тукай бөтен рухы һәм хыялы белән омтылган социализм җәмгыятендә ул чәчкән орлыкларның тишелеп чыгуы һәм мул уңыш китерүе өчен шартлар уңай булды. Әлеге шытымнар турында сөйләгәндә, без беренче булып ялкынлы шагыйрь, Тукай варисы, ул күтәргән гражданлык һәм сугышчанлык байрагын югары тотып иҗат иткән Һ. Такташны искә алабыз. Бөек Ватан сугышы каһарманы, бүген дөнья поэзиясе күгендә Ватанга бирелгәнлек һәм чын геройлыкның символы буларак кабул ителгән мәшһүр М. Җәлилне искә алып горурланабыз. Бигрәк тә шунысы куанычлы, әлегедәй якты йолдызлары булган шигъриятебез һич саекмый, бүген дә аның күгендә Тукай варислары булган яңа йолдызлар кабына тора.

Тукай шәхесе, Тукай иҗатының әһәмиятен бер поэзия һәм әдәбият белән генә чикләп карау да аны күпкә кечерәйтү булыр иде. Бүген Совет Татарстанында гөрләп үскән культура һәм профессиональ сәнгатьнең һәр тармагында без Тукай чәчкән орлыкларның үсеп чыгуын һәм гөрләп чәчәк атуын күрәбез. Шул ук вакытта, Тукай шәхесе, Тукай иҗаты үзе яңадан-яңа талантлы әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең нигезенә алына, Тукай чишмәсе бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы буларак шаулап агуында дәвам итә.

Тукай традицияләре... Ул әдәбиятыбызның үткән юлында ирешелгән биеклекләр, бүгенге иҗат газаплары һәм эзләнүләр, киләчәккә төбәлгән зур өметләр дигән сүз. Тукай мирасындагы һәм аның гражданлык йөзендәге сыйфатлар — гуманизм һәм хөрлек хисе, фәлсәфи оптимизм һәм халыкка тирән мәхәббәт, Ватанны сөю һәм интернационализм — болар һәммәсе бүген дә безнең күңелләрне, бөтен кешелекне борчып торган проблемалар. Димәк, Тукай — актуаль дигән сүз бу! Бүген бөтен кешелек алдында «Яшәүме, һәлакәтме?» дигән Гамлет соравы эленеп торганда, әдәбият һәм сәнгать эшлекләре Тукай батырлыгын, Тукайның килешмәүчән һәм сугышчан рухын һич оныта алмый. Җир язмышын бизмәнгә салып, атом-төш коралы, «йолдызлар сугышы» белән көн-төн янап торган сугыш чукмарлары барында Тукайның бу традицияләре тынгысызлыкка, чорның глобаль проблемаларын колачлап иҗат итүгә чакыра.

Безнең бүгенге һәм иртәгәсе көнгә планнарыбызның нигезенә үк тыныч хезмәт идеясе, кеше бәхете хакына иҗат итү идеясе салынган. Ә бу — илебезне экономик һәм социаль үстерү бурычлары КПСС-ның халыкара стратегиясен дә билгели дигән сүз. Аның төп максаты бик ачык — совет халкына ныклы тынычлык һәм ирек шартларында хезмәт итү мөмкинлеген тәэмин итү.

КПСС бу йөзьеллык ахырына кадәр массакүләм юк итү коралын тулысынча бетерүнең бөтенлекле программасын тәкъдим итте. Масштаблары һәм әһәмияте ягыннан ул — тарихи программа. Партиянең XXVII съезды трибунасыннан халыкара иминлекнең тулы системасын булдыру турында яңа тәкъдим яңгырады, мондый системаның принципиаль Нигезләре бәян ителде.

Кешелек тарихының бөек фикер ияләре гасырлар дәвамына көрәш алып барган әлегедәй колачлы һәм әһәмиятле гуманистик проблемаларны бай әдәби мирас һәм әдәбият классикларының күпкырлы идея-эстетик казанышларына нигезләнеп кенә хәл итү мөмкин булачак. Чөнки, гасырлар дәвамына тупланып кристаллашкан классик мирасга кешелекнең иң якты хыяллары, акыл һәм рух җегәре чагылыш таба. Татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай иҗаты әнә шул гомумкешелек мирасының аерылмас өлеше, бер буыны булып тора. Тукай иҗатының бәрәкәтле орлыклары безнең күңелләрдә урын алып, безнең

акылда, безнең интеллектта яшәвен дәвам итә. Ул безнең тормыш һәм җәмгыять белән бергә киләчәккә уза, яшәрә, халык рухының тирән тамырларына тоташкан хәлендә яңа җиңүләргә рухландыра. Тукай бүген дә дөньяда барган иң олы көрәш — Җирне һәм кешелекне саклау өчен барган көрәшнең үзәгендә, кыл уртасында.

---

ЛУИ АРАГОН, француз язучысы.

*...Тукай үзенең бер шигырендә болай ди:*

*Килде тоткынлык, түбәнләнде уемның куллары,*
*Хөр заман ак кул белән күкләрдә йолдыз чүпләдем.*
*...Ул түгел күңлем эшеннән, тик ялан кулның эше,*
*Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылган чүпләрем.*

*Әнә шундый кырыс башлангыч, Тукай һәм Мәҗит Гафури поэзиясе, Галимҗан Ибраһимовның типографиядә конфискацияләнгән романнары Татарстан республикасы язучыларына юл әзерләде.*

МОСТАЙ КӘРИМ, Башкортстанның халык шагыйре.

*...Сәгыйть Агишның бер әсәрендә мактанчык шундый бер персонаж бар. Ул элек извозчик булып эшләгән һәм Габдулла Тукайны бик якыннан белгән, аны күп тапкырлар утыртып йөрткән мактанып сөйли. Карттан: «Тукай нинди иде?»— дип сорасалар, теге кызып ук китә.*

*— Тукайны да белмисезме? Тукаймы? Тукай ул... Мыеклары колак артына җитеп тора иде аның. Басса, түбәтәе түшәмгә тия иде. Күкрәгенә колач җитәрлек түгел. Ике учына ике пәһлеванны утыртып күтәрә иде ул. Ә сез...*

*Бу әсәрнең кулъязмасын укыганда Баязит Бикбай шундый сүзләр әйтте:*

*— Тукай ике кулы белән ике кешене генә түгел, йөзләгән язучылары булган ике әдәбиятны, татар һәм башкорт әдәбиятларын берьюлы күтәрде.*

*Бу хак сүз иде.*

---

## Сибгат Хәким

# ТУКАЙ ДӘФТӘРЕННӘН

*Тукай миңа бик иртә кергән. Ана сөте белән. Халык моңнарын тоя башлагач та. Татар халкы бар җирдә Тукай булган. Кайчан дигән сорауга халык сулышы белән дип кенә җавап бирә алам. Шулай булмаса, язарга мин «Пар ат»тан тотынмас идем. Миннән аның беркайчан да чыкканы да юк. Хәтта Дугада да... Сугышлар да мине аннан биздерә алмады. Нигә ул миннән чыкмый? Аңлатуы читен. Татарда Тукай туганы өчен куанам. Рухымның Тукай белән очрашуына куанам. Олыгайган саен, күңелгә бер курку урнаша бара. Мин аннан бик авыр аерылырмын шикелле...*

*«Шагыйрь кем?» дигән сорауга җавапны җитмеш өч яшемә җиткәндә Тукайдан таптым. Шагыйрьлекне шагыйрь үзе яшәгән җәмгыятькә керткән рухи көченең микъдары белән үлчәгәнлеген Тукайны укып аңладым. «Бетте көч, сынды кылыч.— Шул булды эш» менә кайчан әйтелә икән. Тукай миндә үзенең милли рухы белән яши. Шул яздыра, шул эчке энергиягә әйләнде. Яшь чакта алга-артка карамый ярыша-ярыша чапкан киләчәк шагыйрьләре дә, минем шикелле картая төшкәч, әлеге сорауга җавапны барыбер Тукайдан эзләячәкләр. «Шагыйрь кем?» Такташ, Туфан, Җәлил дип килерләр дә Тукайда тукталырлар. Шуңа бик нык инандым. Ә шагыйрьгә җавап табарга кирәк икән. Кыскасы, икенче заманда яшәсәм дә, дөньяга ике катлы тәрәзә аша карап яшәдем — Тукай аша. Бөтенесен теоретик нигезли алсам, мин шагыйрь дә булмас идем. Тукай — борчу. Тукайдан аерыласым килми...*

## Тукайга кайтам...

Сөйләшеп ЮНЕСКО белән,
Эчкә, сүз юллыгына
Үтеп хәерле сәгатьтә,
Тукай йөз еллыгына
Килгәндә дөнья, шушында
Булдым кинәт туктарга,
Мин кайтырга булдым, дуслар,
Үткәнемә — Тукайга.
Нинди сәяхәт турында
Җиткәндә җитмеш бишең,
Хыялланасың син, юләр,
Соң инде, җитми көчең.
Юк синең Кимедән чыгып,
Казанда таң атканын
Каршылый торган ут яллы
Әвәлге «Пар ат»ларың.
Әйтерсең, узган тормышым
Ике ялкын арасы,
Ара ераклашкан саен
Килде якынаясы.
Шушы хис кебек борчулы
Күңелнең кайсы хисе?
Ара ераклашкан саен
Көчәйде кайту хисе.
Әй, милли горурлык, сине
Мөмкинме томаларга!
Үлмәде ул хис кереп тә
Куркыныч Дугаларга.
Өстемә ажгырып килгән
Ярты Европа белән
Ул хис капланыр күк иде.
Дошман — яу уты белән
Күмелер күк иде ул хис,
Көнгә ничә кат давыл!
Шул хискә өяләр кебек
Җирнең бөтен катлавын.

Өяләр, туфрактан солдат
Калыккан кебек, йөрәк
Калка, тагын да нык сыкрап,
Тагын да әрнебрәк.

Кайтам бик хәтәр елларның
Борылып чатларыннан,
Шушы хис изге булганга,
Күрәсең, сакланылган.

*1985*

## Бик сагынган чаклар була сине

Бик сагынган чаклар була сине,
Тугры Тукай, тугры Габдулла,
Ай күрде дә кояш алды сине,
Мәңге янар өчен халкыңа.

Үзем өчен түгел, синең өчен
Үз бакчамда саклыйм бер гөлне.
Ай күрде дә кояш алды сине,
Булдың бигрәк кыска гомерле.

Исемең синең искә төшермәгән
Минутларым минем бик сирәк.
Мин үзем дә белмим, ни өчендер
Бу җаныма көн дә син кирәк.

*1985*

## Төртелсә язганда каләм...

Төртелсә язганда каләм,
Килми торса илһамым,
Шкафтан үрелеп кенә
Алам Тукай китабын,
Чумам Тукай дөньясына,
Моңлы, хәсрәтле Тукай,
Шул Тукай, мине яшәткән
Бөек хәзрәти Тукай.
Яңара язмыш һәм тарих,
Яңара татар бергә,
Шул Тукай булыр телемдә
Кергәнче тар кабергә.
Тукай юк чакта «Болгар»ның
Кырыгынчы номерын
Мин биләп тордым, әйтерсең,
Шунда узды гомерем.
Бирдем халыкка үзеннән
Калган бар хәзинәсен.
Иҗатым — йөрәгем аша
Кичердем фаҗигасен.
Киткәндә җирдән өстемә
Төшкән ай нурын күтәм,
Шул Тукай белән газаплы
Аерылу көнен көтәм.

*1 февраль, 1984.*

## Йөргәнең бардыр болында...

Йөргәнең бардыр болында,
Тугай бармы тургайсыз?
Шул туган-үскән җиреңдә
Бер йорт бармы Тукайсыз?

Килделәр телгә чәчәкләр,
Басќам ялгыш, уңайсыз.
Дәштеләр алар да миңа:
Үсмәдек, дип, Тукайсыз.

Таң алды, йоклый табигать,
Ул нинди саф, тузансыз.
Ул тулы булмас шикелле
Миңа, никтер, Тукайсыз.

И, гашыйк җаннар, хәятне
Сез бизәргә тугансыз.
Ул нинди бөек мәхәббәт —
Ай, кояшсыз, Тукайсыз?!

*Август, 1985.*

## Бүлмәдә шкаф, кулъязма...

*«Татар әдәбияты тарихы»н укыгач...*

Башласаң иде бу узган
Гомерне яңа баштан.
Утырдым бүлмәмдә ялгыз,
Кайда дип замандашлар?
Юк замандашларым, мин дә
Көннәрем санап яшим.
Ишетелде аваз: мин исән,
Мин синең замандашың.
Бүлмәмдә шкаф, кулъязма,
Кил, актар, кара шуннан...
Ишетелде аваз борынгы
Китаплар арасыннан.
Тавышында коръән мәкаме,
Тавышыннан таныйм сыман,
Татар әдәбиятының
Мең еллык тарихыннан
Ул үзе чыкты, Кол Гали,
Тотып кулына «Кыйсса»ны.
Сорыйм: бу ничәнче басма?
Бу дим ничәнче саны?
Чыкты Мөхәммәдъяр аннан,
«Нуры содур» — Мөхәммәдъяр.
Каршымда Болгар һәм Идел,
Каршымда мәһабәт яр.
Чыкты Утыз-Имәниләр,
Утызы утыз имән.

Ут, җылы, якты шулардан.
Ни мәгънә утсыз өйдән.
Мин бераз каушап калганмын,
Кулымнан каләм төшкән.
Чыкты уртага яшь Тукай
Кап-кара кәләпүштән.
Була бит шундый вакытлар,
Кинәт бер айный торган.
Ике алмаз бораү белән
Җанны бораулый торган
Карашы белән очраштым...
Көнләшә бирсен ятлар:
Сез барда мин бар, бар данлы
Тарихым, бөек затлар!

*Декабрь, 1985*

## БЕР СОРАУГА ? БЕР ҖАВАП

СОРАУ:

— Тукайның кыска гына гомере һәм үлемсез иҗаты. Иҗатта үлемсезлек мәсьәләсе. Бу мөнәсәбәттән нинди уйларыгыз бар?

ТАССРның Г. Тукай премиясе лауреаты, шагыйрь РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН.

— Үлемсезлек дигән сүз — үзе бөек сүз. Ул, мөгаен, кешелек хыялының иң биек ноктасыдыр. Әмма бу хакта теләсә кем турында һәм теләсә нинди уңай белән сөйләү кыен. Ә менә Тукайның шәхесе һәм иҗаты бу хакта иркенләп сөйләргә нигез бирә.

Үлемсезлек юлын беркем дә кистереп күрсәтә алмас. Юкса, әкиятләрдә мәңгелек суын эзләмәсләр, Фаустлар алданмас, фидакарьләр утларга ташланмас иде... Шулай да, без аңлаган асылында, бу юлның кайбер төп нигез принциплары бар: заманның чын мәгънәсендәге гадел һәм зирәк улы була алу, ягъни, дәвереңнең төп проблемаларын чишү үзәгендә булу, үз халкыңның мәнфәгатьләрен кайгырту (Вакыт галиҗәнапләре көзгесендә һәр халыкның үз хәлләре), киләчәкне анык күрә алу... Тукай — минемчә, бу принципларның һәммәсенә дә туры килә торган шагыйрь.

Халык күңеленең тагын бер ягын онытмыйк: дөньялыктан пәйгамбәрләрчә яшьли янып китү — мәңгелеккә баруның тәгаен бер ышанычлы юлы. Безнең халык яшьли фаҗигале үлемгә дучар булган кызга яки егеткә тикмәгә генә җыр-бәетләр чыгармаган. Тукай бу яктан да Үлемсезлек кодексына бик туры килә.

Һәм, ниһаять, һәр бөек затны таныр, бәяләр өчен чорына лаек замандашлары булу, илаһи рухны киләчәктә дә саклап, олылап бару өчен зирәк оныклары — яңа буыннар булу кирәк. Сандугач тавышын аерыр өчен бихисап кош сайравын белү кирәк... Бу җәһәттән дә Тукай бәхетле шәхес. Чөнки аның иҗат чоры гаҗәеп дәвергә — 1905 еллардагы бөек күтәрелеш чорына туры килә. Халык бөеклегенең рухи маякларын төгәл ачыклау, барлау заманы. Аннан соңрак дәвер буыннары рухи бөеклекне тану, бәяләү буенча тагын да зирәгрәк булдылар — Тукайны бөек итеп танып, киләчәккә илттеләр.

Әлбәттә, ни генә димик, бу очракта бөеклекнең төп сәбәпчесе — Тукай үзе, гаҗәеп иҗаты. XX йөз башында Россия киңлекләрендә берләнбер диярлек уникаль шәхес. Ятим үсеп, дәүләт уку йортлары күрмичә тәрбияләнеп, бик аз гомер яшәп, ятимлек һәм ялгызлык кичереп, биш-алты томлык үлмәс әсәрләр язган кеше дип ул чорда тагын кемне атап була соң?

**Нажар Нәҗми,**
РСФСРның М. Горький исемендәге, Башкортстанның С. Юлаев исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты.

# ШИГЪРИЯТ ЙОЛДЫЗЫ

Дөньябызның бөек уллары төрле заманнарда, төрле илләрдә, төрле телләрдә үзләренең сынын кешелек алдында мәңгеләштерә алырлык сүзләр әйтеп калдырганнар.

«Эврика!» — «Таптым!»— дигән бөек галим үзенең иң шатлыклы һәм бәхетле минутында. Ул сүз грек телендә әйтелгән, аның иясе Архимед.

«О күз ачып йомган ара, син гүзәлсең, туктасана!»— дип эндәшкән бөек шагыйрь. Ул немец телендә әйтелгән. Сүзләрнең авторы Иоганн Вольфганг Гете.

«Мәрхәмәтле тойгыларны уяттым мин лирам белән»— дигән икенче бер бөек шагыйрь. Өченче бөеге: «Хуш, юылмаган Россия!»— дигән. Бу сүзләр рус телендә әйтелгәннәр. Шагыйрьләрнең исеме Александр Пушкин, Михаил Лермонтов икәнлеген әйтеп тору да артык.

Егерменче гасыр башларында бүтән бер бөек шагыйрь: «Очты дөнья читлегеннән тарсынып, күңлем кошы»,— дигән канатлы сүзләрне дөньяга очырган. Алар татар телендә әйтелгәннәр, димәк, Габдулла Тукай әйткән дигән сүз.

Мин монда берничә бөек исемне генә искә алдым, ләкин һәр халыкның үз Тукае бар, алар үз халыкларының поэтик сыннарына әйләнгәннәр. Тукайның Лев Толстой вафат булгач язган мәкаләсендәге поэтик образны файдаланып шуны әйтмәк булам: Байрон, Бернс, Беранже, Петефи, Мицкевич, Шевченко, Бараташвили, Туманян, Ахундов, Абай, Райнис «вә гайре, вә гайре, бөтен Русиянең мөхтәрәм мөхәррирләреннән тезелгән мөбәрәк тәсбих»тә Тукай — нурлар чәчеп торган төймәләрдән берсе.

Тукай — бөек шагыйрь, ләкин, шул ук вакытта, Тукай табигать тарафыннан язылган үзе бер бөек шигырь, буыннан-буынга җырлана торган шигырь, буыннан-буынга серләре ачыла барган шигырь, шат шигырь, кайгы-хәсрәтле шигырь, тугрылыклы, зур вөҗданлы шигырь, дошманнарына аяусыз, көрәшче шигырь.

Тукай — без Тукайсыз яши алмавыбыз өчен туган. Аның тууы һәм яшәве татар халкының рухи тормышын икегә бүлеп үткән сихри агым кебек һәм без: «Тукайга кадәрге дөнья һәм аннан соңгы»,— дип билгеләп, авыз тутырып әйтә алабыз. Без, аның туган көнен билгеләүчеләр, бездән соң да, аның тууын бәйрәм итүчеләр, әнә шул агымның Тукайлы ярында яшәвебез белән бәхетлебез. Ул бәхет безгә җиңел бирелмәде, ягъни Тукайга гомер һәм шагыйрьлек җиңел килмәде. Дөрес, шагыйрьлек бәхете һәркемгә дә җиңел бирелми, ләкин шагыйрь булганчы, адәм баласы, табигать тарафыннан бирелгән таланты чәчәк атып, җимешләр биргәнче, туып үсәргә тиеш. Тукайның бала чакта үлми калуы безнең бәхетебез өчен булгандыр. Бу бәхет өчен кайдадыр тирәндә безнең һәркайсыбызда рәхмәт сүзе дә ята.

Аны кемнәргә әйтергә? Әнисенәме яки атасынамы? Кыш көннәрендә үксез ятим баланың ишек ача алмый, аяклары бозга ябышып катканчы ишек төбендә туңып торганда, яки чәчәк белән каты авырган чагында: «Ичмасам чәнчелсә, бер тамак кимер иде»,— дип үлемен теләгән чакларда исән калган җанынамы, тәненәме рәхмәт әйтергә, я булмаса үги әбисеннән яшереп кенә сөйгән, иркәләгән һәм ашаткан Сәҗидә апасынамы, әллә, Казанга алып килгәч, «асрарга бала бирәм, кем

ала?» — дип Печән базарында кычкырып йөргән ямщиккамы, я булмаса шул рәхмәт сүзен базардан өйләренә алып кайткан Мөхәммәтвәли белән Газизәгәме?

Кемгә әйтергә? Сабый Тукай кем өендә торса, шуңа эти, ди, я булмаса әни, ди, ә шуларның берсе дә ана да, ата да түгел. Кемгә рәхмәт әйтергә? Кимсетүләрдән, ачлыклардан, авырулардан саклап алып калган минутларгамы, сәгатьләргәме, көннәргәме, айлар, елларгамы? Бәлки... Бәлки!.. Безне Тукайсыз калдырмаган өчен без кемгәдер, нәрсәгәдер рәхмәт әйтергә тиешбез.

Тукай язмышы — үтә сирәк очрый торган язмыш. Моннан күп еллар элек, сугыштан соң, ГДРның Веймар шәһәрендә, Гете йорты-сараеның бүлмәләренә, залларына кереп йөргәндә, чагыштырмача яшь булгангамы, ни өчендер Тукай үскән йортлар, ул яшәгән кысан бүлмәләр белән чагыштырып карау башыма килмәгән. Ә бит уйлап карасаң, Тукайның шигырьләрдән башка бер нәрсәсе дә юк. Ә менә күптән түгел, Ленинград янындагы элекке «Царское село»да булганда, алтынланган сарайлар, Пушкин укыган лицей эченә кереп йөргәндә инде Тукайның бала һәм үсмер чаклары, аның тормышы, язмышы күз алдымнан китмәде. Дөрес, алтын сарайлар гына шагыйрь тудырмый, шагыйрь итми. Пушкин заманында да бер бөеккә күпмедер дистә булдыксыз туры килгән, соңыннан да шулай булган. Безнең көннәрдә дә шулай.

Сер түгел, Тукайга охшаш язмышлы язучыларны башка илләрдә, заманнарда һәм милләтләрдә дә табарга мөмкиндер. Ләкин Тукай шикелле үк булмас, чөнки ул «чакырылмаган кунактан да яманрак» булып күренгән заманга туры килүе белән дә аерылып тора. Ирексез милләтнең ирекле шагыйре булып яшәве, әлбәттә, икеләтә авыр.

Тукайга бик катлаулы чор туры килде. Бер яклап, 1905 елгы революциядән соңгы буржуаз-демократик һәм милли хәрәкәт шагыйрь күңеленең хәрәкәте, җанлануы өчен рухи ризык булса, шул ук революциядән соңгы реакция елларындагы өзәрлекләүләр, фикерләр коллыгы шагыйрьне күңелсез борчылуларга салды, уйланырга мәҗбүр итте. Шулай да уянган рухны кабат йоклатуы, хәрәкәтне туктатуы мөмкин түгел иде.

Буржуаз-демократик хәрәкәтнең җанлануы Тукай иҗаты өчен, аның эшчәнлеге өчен, әйткәнемчә, бәрәкәтле туфрак була. Аның иң элек шигырьләренең берсе «Ник йоклыйсың, мужик?»— дип башланып китүе, хак сүз әйтеп, гади халыкның күзен ачарга һәм:

Хак сүзне әйткәнгә
Киң күңлең тарайса,
Урыныңнан кузгалма,
Йоклый күр, алайса,—

дип чеметүе юкка түгел. Шушы «Мужик йокысы» дигән шигыреннән башлап, иң соңгыларыннан берсе:

Ут, төтен, фабрик-завод берлә һаман кайный Казан;—
Имгәтеп ташлап савын, сау эшчеләр сайлый Казан,—

дигән ике юллык кына шигыренә кадәр, Габдулла Тукай зур сиземле, үзен җәмгыятьнең барометры итеп хис иткән шәхес булып кала. Ул бер дустына язган билгеле хатында болай ди: «Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә».

Бу инде Тукайны Тукай иткән, гомумән зур шагыйрьләрне шагыйрь иткән төп сыйфатларның берседер. Әйе, аның күзе күпне күрә, колагы күпне ишетә. Күпне күрү һәм ишетү бер хәл, вә ләкин күпне күрә белү һәм ишетә белү икенче мәсьәлә. Әнә шул белүдә, димәк, ничегрәк күрүдә һәм ничегрәк ишетүдә бөеклекнең бер кечкенә сере, хикмәте ята да.

Тукай — исәпсез вә хисапсыз кыллардан торган сихри вә шигъри бер саз. Аның һәрбер кылы тартылган, көйләнгән. Скрипка кылына берәр чебен кунып очып киткәндә, скрипка шыңгырап калган шикелле, Габдулла Тукайның сазына дөньяның сизелер-сизелмәс җилләре кагылганда да аның кыллары чеңләми калмаган. Габдулла Тукай — шигырь өчен туып, шигырьдә яшәп, шигырьдә үлгән җан. Тукай һәм шигырь — ул аерылгысыз бер бөтенлек, бер дөнья. Әгәр дә Максим Горький Сергей Есенин хакында: «...Кеше булудан бигрәк, табигать тарафыннан шигърият өчен генә яратылган орган»,— дигән икән, Тукай турында да шундый сүзне күптән әйтергә мөмкин иде. Монда минем ике халыкның төрле чор-

ларда яшәгән һәм язган, берсен-берсе белмәгән ике бөек шагыйренең исемнәрен янәшә куюымның хикмәте шунда ки, аларны аваздашлык, ихласлык берләштерә һәм берләштерүнең чыганаклары һичшиксез Пушкиннан һәм Лермонтовтан килә. Пушкиннан һәм Лермонтовтан соң яшәгән рус язучылары һәм шагыйрьләре өчен алардан өйрәнү, аларны үзләренең остазлары итү — сулаган һава, искән җил кебек табигый, ә менә мәдрәсә шәкертенең, уналты-унҗиде яшьлек татар егетенең «күп яттык без мәдрәсәдә, аңламадык бер нәрсә дә» дигән шигъри юлларындагы хакыйкатьне дә искә алганда, ул уку йортларында, әлбәттә, Пушкин һәм Лермонтов шигырьләренең эзе дә булмагандыр. Әмма ләкин Тукай шигърияткә кармаланып түгел, ә бөтен бөекләргә хас булган сыйфатта, зур әзерлек белән килә. Пушкинлык, ягъни шагыйрьлек Тукай табигатенә, йөрәгенә салынып куелганга күрә, аларның шигъри кан группалары бер булганлыгы да ярылып ята. Габдулла Тукайның Байрон, Гете, Пушкин, Лермонтов һәм башка бөек шагыйрьләр иҗаты нигезендә үзенә-үзе рух һәм шигърият университеты булдырганлыгы һәм аның шунда көн-төн укыганлыгын һәм өйрәнгәнлеген бөтен иҗатында күреп була.

> Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов әгәр булса кояш,
> Ай кеби, нурны алардан икътибас иткән бу баш,—

дип әйтүе дә юкка түгел.

Бөек кешеләрнең өйрәнүләре дә бөек. Хәтта аның «Пушкиннан», «Лермонтовтан», «Байроннан»,— дип куелган шигырьләре дә бөтенләй үзенеке, Тукайча булып яңгырый. Монда мине шелтәләүләре мөмкин. Тукай, үз халкының улы буларак, татарның бөтен борынгы истәлекләрен, шәрык әдәбиятын белгәнлеге, хак иҗатын җентекләп өйрәнгәнлеге һәм алар нигезендә шедеврлар тудыруы кайсыбызга билгеле түгел? Дөнья әдәбиятына, аның бөек исемнәренә мөрәҗәгать итүе шагыйрьнең таләп дәрәҗәсеннән, күңел аваздашлыгыннан килә. Миңа калса, Тукайның поэтик рухында, җанының, күңеленең хәрәкәтендә күбрәк Лермонтов рухы бар, дияр идем. Хәтта аларның адәми язмышларында, ничектер, охшашлык бар: алар үлем сәгатьләре белән яшьтәшләр, икесенә дә нибары егерме җиде яшь була, икесе дә сабый чактан ук анасыз, атасыз калалар, замандашларының истәлекләренә карaганда, икесе дә кыска буйлы, аннан соң икесе дә өйләнә алмый үләләр... Кабатлыйм, бу тышкы охшашлык, ә рухи яктан?..

Габдулла Тукай иҗатында да күпме изгелек һәм дөреслек, күпме кыюлык һәм аяусызлык, күпме ачыну, күпме оптимизм һәм шул ук вакытта ниндидер өметсезлек тә бар — Тукай тормыш шикелле катлаулы, шул катлаулылык аның шигырьләрендә дә, публицистик мәкаләләрендә дә, шулай ук әдәбият, әдәби осталык турындагы язмаларында, бигрәк тә памфлетларында әлеге шул «коеп куйган поэт» түгеллеге аңкып тора.

Бөтен мәрхәмәтлелеккә, яхшылыкка Тукай мәрхәмәтле, бөтен кара көчләргә, руханиларга карата аяусыз.

Дөнья шагыйрьләренең кайберләре үз заманындагы җәмгыять төзелешенә каршы чыкканлыклары өчен җирләреннән куылганын да, үз-үзләренең иманнарына тугры буларак, үз ирекләре белән ерак илләргә китеп, яуларда һәлак булганнарын да беләбез, ләкин хөкем сөргән рухка каршы баш күтәрүнең ни белән тәмамланганлыгы да билгеле. Бу яклап Тукайның кыюлыгына исең китмәле, чөнки бу тәкъдирдә Тукай ялгыз түгел, өстә әйтеп киткәнемчә, демократик көчләрнең хәрәкәте, аларның уянып, җанлануы руханиларның төп көч булудан мәхрүм итәләшлаулары. Тукай кебек акыл ияләренә кыю фикер йөртергә, чагыштырмача күп мөмкинлекләр бирә, хәтта Пушкиннар, Лермонтовлар заманында гына да мондый эшчәнлек өчен әзербайҗан шагыйре Нәсимине җәзалаган кебек, тереләй тунамасалар да, җир йөзеннән ничек тә булса юк итәрләр иде.

Тукай шулай ук әдәбият дөньясында да бөтен яхшылыкка мәрхәмәтле булу белән бергә, бөтен мөтәшагыйрьләргә, ягъни шигырь язып маташучыларга, шагыйрь булырга тырышучыларга да (аның «Мөтәшагыйрьгә» дигән шигыре дә бар) бик аяусыз. Әдәбиятка, иҗатка дөнья әдәбияты бөеклегеннән карап, зур таләпләр куеп, бөтен булдыксызларга каршы көрәш ача. Бу да бөеклекнең бер миссиясе. Мондый миссиягә әдәбият һәрвакыт, һәр заманда мохтаҗ булган. Ә хәзер? Хәзер бигрәк тә! Безнең әдәбиятларда әлеге шул мөтәшагыйрьлек, аталанмаган, субтиль, рухи җенессез шигырьләр үрчеп барганда, җитмәсә, шундый әсәрләрнең авторлары үзләренә-үзләре әдәбият һәм поэзия хакында җәмгыять фикере тудырырга маташканда, әдәбиятта Тукайларның булмавы, Тукай дөреслеге булмавы үтә кызганыч.

Безнең күпләребез, безнең үсүебезгә комачаулаган үтә җитди җитешсезлекләр белән көрәшкәндә Тукайлыктан, ягъни кыюлыктан ваз кичеп барабыз. Ә бит Тукай һич нәрсәдән, дошманы эттән күбәйсә дә, курыкмаган.

Шигъре Лермонтов вә Пушкин — олугъ саф диңгез ул,
Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул.
...Барчы, эт, гомрең буе шул күктә өч йолдызга өр!—

дип «Җавап» бирергә мәҗбүр булган. «Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул!» Бөекләр генә үз бөеклекләрен тоеп яшәгәннәр, иҗат иткәннәр, көрәшкәннәр, шигырьләре белән яу ачканнар, сугышканнар. Тукай да шундый! Үзен җиңелгәнгә исәпләгәндә дә дөреслеккә туры караган.

Кайтмады уч, бетте көч, сынды кылыч,— шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым,—

дисә дә, аның керләнүендә дә нинди пакьлек!

Тукай турындагы сүзләремдә бернинди дә яңа фикерләргә дәгъва итмичә (Тукай турында яңалык әйтүе читен), бары тик байтак еллар үз телемдә шигырьне аңлаган кеше буларак кына, кайсыбер тойгыларым белән генә бүлешмәкче булдым. Ә Тукай исә хәзерге гыйльми-техник терминнарны кулланып әйткәндә, шигъри реактор кебек, андагы шигъри энергия мәңгелек һәм ул әллә ничаклы фән кандидатлары, докторлары тудырырга җитәр әле.

Әйе, мин үз тойгыларымны бүлешмәкче булдым. Ләкин шулай да, шулай да шигырьләрнең нинди йөрәк каны белән язылганын азмы-күпме, нининдидер дәрәҗәдә татыганга күрә, Тукайның:

И мөкатдәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз ахрысы.
Очты дөнья читлегеннән тарсынып, күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы,—

дигән юлларын һәм әнкәсенә мөрәҗәгать итеп:

«Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы.
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!—

дигән сүзләр белән тәмамланган бөек шигырен искә алмый китә алмыйм.

Нәрсә соң бу! Җанның өзгәләнүеме, я булмаса җан ачуымы? Әйтүе авыр. Хәзер һәркем яшен яшьнәп, күк күкрәүләрнең ничек хасил булганын белә. Бу шигырь дә йөрәкнең бер яшьнәп күкрәве кебек кенә, ләкин нинди кодрәт белән яшьнәп, күкрәвен — язылганын аңлатуы мөмкин түгел. Баналь булса да шуны әйтер идем: «Шүрәле»не, «Су анасы»н, «Яңа Кисекбаш»ларны язмыйча, менә шушы бер шигырьне язганда да Тукай — Тукай булып калыр иде.

Кешелек дөньясы исең китәрлек ачышлар ясады. Адәм баласының фәнни фикерләү куәсе фәнни законлылыкка корылган. Мәсәлән, җирнең тарту көчен Ньютон ачмаса, башка берәү мотлак ачар иде, диде бер галим. Әдәбиятта, сәнгатьтә мондый законлылык юк. Пушкин язганны фәкать Пушкин гына, Лермонтов язганны фәкать Лермонтов кына яза ала. Тукай язганны Тукайдан башка беркем дә яза алмый. Әдәбиятта һәм сәнгатьтә алмаштырыла торган нәрсә юк, хәтта мөтәшагыйрь язган да аныкы гына булып кала. Өстә искә алынып кителгән шигырьне башкалар, хәтта аннан бөекләр язган тәкъдирдә дә алмаштырып булмый. Тукай бөеклеге башка бөеклекләргә охшамаган. Менә нинди ул Тукай!

Һәр халыкның үз бөек шагыйрьләре барлыгын беләбез. Аларның илләрендә булып, шул ил телендә сөйләшә алмау сәбәпле, теге яки бу бөек шагыйрьнең үз халкы йөрәгендә ничек яшәгәнлеген тәрҗемә китаплар, тикшеренүләр аша гына белгәнгә күрә, бөтен күңел нечкәлекләре белән тоюы кыен. Үз халкының йөрәгендә Тукай шикелле яшәгән шагыйрьне дә җир йөзендә очрату авырдыр. Кайда барма, Тукай — хәтта кабер ташларында Тукай сүзләре. Халкы йөрәгендә ул шул кадәр тамыр җәйгән ки, әгәр дә берәр явыз көч, явыз рух Тукайны тартып алырга теләсә, аны, җире һәм халкы-ние белән, хәтта кабер ташлары белән бергә суырып алырга туры килер иде, ләкин бу мөмкин булмаган хәл! Менә нинди ул Тукай! Тукай — чын мәгънәсендәге халык шагыйре!

Мин сүз башымны төрле телләрдә әйтелгән данлы сүзләрне искә алып башлаган идем, шулар белән сүземне дә очларга уйлыйм.

Әгәр дә Архимед «Эврика!» — дип шатланып, кычкырып җибәргән булса, шагыйрьнең дә шундый шатланып, кычкырып җибәргән минутлары була, чөнки чын шагыйрь гомере дә табышлардан, ачышлардан тора. Шагыйрьнең ачышлары

да, табышлары да аның хосусый милке булып калмый, алар халык ачышына, байлыгына әйләнә. Шагыйрь ачышлары, шулай ук, үз халкын, халкының рухын ача, дөньяга чыгара. Шуның белән ул халкының вәкиленә, илчесенә дә әйләнә. Тукайның: «...Мин — дипломат...» — дигән сүзен һич тә безнең арада әйтелеп йөртелгән яраштыручы, ярачы мәгънәсендә түгел, ә халык вәкиле, халык илчесе мәгънәсендә итеп аңлыйсы килә. Тукайның башка төрле дипломат булуы аның бар табигатенә каршы.

Тукайның бөтен иҗаты, дөнья һәм милләт язмышы турында уйлап, ачынуларга, борчылуларга тулы булуга карамастан, оптимизм белән сугарылган. «Мәрхәмәтле тойгыларны уяттым мин лирам белән»— дигән сүзләр Тукайга да кайтып кала.

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
«Без китәбез, сез каласыз!»— дип җырлармын,
Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә,—

дип юкка әйтмәгән. Бу үзе генә дә бер бөеклек! Әгәр дә икенче бер остазы: «Хуш, юылмаган Россия!— дип ачынса, Тукай исә әнә шул юыла башлаган «хөр мәмләкәт — хөр Русия»дә «рус белән тормыш кичердек сайрашып, тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып»— дип үз халкы белән дә, рус халкы белән дә горурлана һәм бу горурлану аның фикерләү масштабының нинди киңлектә булуы турында сөйли. Ә күңел төшенкелегенә бирелгән шагыйрьләр мондый масштабтан мәхрүмнәр.

Ничек кенә булмасын, шагыйрь өчен, барыбер, ул тормыш тар булып тоелды һәм «Очты дөнья читлегеннән тарсынып, күңлем кошы»— дип әйтергә мәҗбүр итте. Тукай вафат булып, берничә ел гына үткәннән соң «хөр мәмләкәт — хөр Русия» дөнья читлекләрен ертып, халыкларга революцион азатлык һәм киңлекләр китерде. Шагыйрьнең күңел кошлары бу киңлекләрне айкый-айкый халыклар күңелендә оя корды. Шагыйрь өчен моннан да зур бәхет юк!

Тукайның гомере аның кыска булуы белән дә, нибары сигез ел гына язып калуы белән дә «бер күз ачып йомган ара» кебек кенә. Ул мизгел, әлбәттә, гүзәл һәм аның тукталмавы табигый, чөнки туктала калса, гүзәл дә булмас иде. Бу гүзәллек үсә, үзеннән соң яшәгән кешеләрнең йөрәгендә дәвам итә, ул мәңгелек хәрәкәттә, ул үлемсез!

---

**ЖОВАННИ ЖЕРМАНЕТТО**, итальян шагыйре.

*Казанга беренче килүемдә үк мин атаклы халык шагыйре Габдулла Тукай турында ишеттем. Аның турында безгә профессиональ язучылар белән журналистлар гына түгел, бәлки заводлардагы һәм төзелешләрдәге эшчеләр дә, студентлар һәм мәктәп балалары да сөйләде. Татар халкының бу бөек улына укучыларның мәхәббәте нинди самими булганын, күп гасырлардан бирле дәвам итеп килгән бай культура традициясе һәм совет эпохасында шул тикле уңышлы үсә барган бу халыкның поэзияне шундый нык яратуын мин ачык аңладым һәм бөтен йөрәгем белән сиздем.*

---

ПАВЕЛ РАДИМОВ, рус язучысы.

*«Нинди зур шагыйрь!— дигән Сергей Есенин Тукай турында. Есенин да, Тукай да — икесе дә зур халык шагыйрьләре, дөньядан алар бик иртә киттеләр, ләкин тугандаш әдәбиятларда, рус һәм татар әдәбиятларында алар зур эз калдырдылар.*

**Эди Огнецвет,**
Белоруссия шагыйрәсе

# РУХИ КАРДӘШЛЕК

Габдулла Тукай шигъриятенең шифалы яктылыгы минем күңелгә дәһшәтле сугыш елларында үтеп керде.

Ул истәлекләр Ташкентка бәйле. Без — эвакуациядә. Үзгә шартлар, урнашу-танышулар, яңа дуслар. Әңгәмәләр. Бу сөйләшүләрне мин ифрат файдалы тормыш сабагыннан саныйм. Белоруссиянең халык шагыйре Якуб Коласның сөйләгәннәре күңелгә аеруча тирән уелган. Аның якын дусты һәм фикердәше Янка Купала ул чорда Казан ягындагы Печище авылында яши иде. Берсендә, Янка Купала турындагы әңгәмәсеннән соң, Якуб Колас: «Сезнең Габдулла Тукай шигырьләрен укыганыгыз бармы?» — дип сорады.— Ул Купала белән минем яшьтәш кебек. Дүрт яшькә генә кечерәк ул бездән. Безнең үсмерлек елларына туры килгән хәлләр аны чиксез борчыган. Аңардагы көчле рух таң калдыра! Искиткеч фидакарь шагыйрь! Ничек тә эзләп табарга тырышыгыз, укыгыз сез аның шигырьләрен!..»

Остазымның бу сүзләрен һич онытасым юк.

Соңыннан, Тукай шигырьләренең русчага тәрҗемәләре белән танышкач, яшьяшь егетнең шул дәрәҗәдә җитлеккән, кыю фикерле булуы, хисләренең саф чишмәдәй бәреп торуы мине чын мәгънәсендә тетрәндерде. (Хәзер без ул яшьтәге шагыйрьләргә өйрәнчек итеп кенә карыйбыз бит...)

Тукайның 1906 елда язган «Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә» исемле шигырен генә искә төшерик:

Беләсезме, бу дөнья нинди дөнья?
Бу дөнья — һәр ике дөньяда бәхетнең башы.
Бу юлны, зинһар, мәңге ташламагыз,
Чөнки бу — милләтне алга илтүче юл.

Аның «Пушкинә» шигырен укырга тотынсам, мин Якуб Колас сүзләрен ишетәм кебек. Пушкинның тууына 150 ел тулган көннәрдә, «Кешелекнең якын дусты» исемле мәкалә язып, Колас төрле халыкларның бөек шагыйрьләрен телгә ала, аларның Пушкин даһилыгы белән бәйләнгән булуларына туктала.

Т. Шевченко, Л. Украинка, И. Франко, И. Чавчавадзе, О. Туманян... Мәкаләдә әзербайҗан классигы Мирза Фатали Ахундов тарафыннан 1837 елда иҗат ителгән «А. С. Пушкинның үлеменә» исемле поэмага туктала һәм шунда ук: «Ахундовның шигъри юллары татар әдәбияты классигы Габдулла Тукай шигыре белән аваздаш»,— дип яза.

...Нәзыйрсыз шагыйрь улдың (афәрин), Пушкин Александр!
Бәнем дә дәрде шәүкым һәм сәнең дәрдеңлә якъсандыр.

Якуб Коласның ул мәкаләсе 1949 елның 4 июнендә «Литературная газета» битләрендә басылып чыкты.

Габдулла Тукайның шигърияте 1905 елгы революция ялкыннарында чыныккан Янка Купала һәм Якуб Колас иҗатлары белән аваздаш. Бу иҗатларның рухи кардәшлеген мин нәкъ әнә шунда күрәм.

Тукай шигырьләре укып туймаслык. Кайнарланып язылган революцион яңгырашлы әсәрләр һәм нәфис лирика, тирән фәлсәфи мәсьәләләр һәм сабый балаларга язылган әкиятләр. Илле табак чамасы прозасы да бар Тукайның. Гете, Гейне, Шиллер кебек талант ияләренең кайбер әсәрләре дә, Тукай тарафыннан тәрҗемә ителеп, татар әдәбиятының бәяләп бетергесез байлыгына әйләнгәннәр. Тукай талантының һичнинди чик-чамаларын белми!

Каршымда — Тукайның фоторәсеме. Саф күңелле яшүсмер йөзе. Тирән мәгънәле, якты омтылышлы карашлар. Алар Белоруссиянең классик шагыйре Максим Богданович күзләрен хәтерләтәләр. Бу ике шагыйрьнең язмышларында да уртаклык бар. Богданович якты дөньяда нибары егерме алты ел гына яшәгән һәм, туберкулездан терелә алмыйча, 1917 елның маенда ук дөньядан кичкән. Бу бөек демократ шагыйрь иҗатына, аның гаҗәеп лирикасына, тәрҗемәләренә тулы бәя бирүне өстемә алмыйм. Бер нәрсәгә генә, бу ике бөек шәхес — белорус һәм татар шагыйрьләре иҗатындагы рухи якынлыкка, кардәшлеккә игътибарны юнәлтәсем килә. Аларның икесе дә, шул дәвернең алдынгы фикерле кешеләре буларак, үз әсәрләрендә халык теләкләрен һәм омтылышларын күрсәтергә, шигърияттә дөнья культурасы биеклегенә ирешергә тырышканнар.

Үз иҗатым, нигездә, балаларга багышлангангадыр, мөгаен, миңа Тукайның балалар өчен язганнары аеруча якын: «Фатыйма белән Сандугач», «Ак бабай», «Кәҗә белән сарык хикәяте», «Карлыгач», «Бишектәге бала», «Кечкенә музыкант». Гаҗәп бит: үзе биш яшендә ятим калган шагыйрьнең күңелендә — балаларга карата никадәр наз!

Тукай булган, Тукай бар, Тукай булачак! Шуның өчен мең рәхмәт аңа!

Нурын сибеп җирдәге һәр күңелгә —
Балкысын Тукай йолдызы мәңгегә!

**БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП**

СОРАУ:

— Г. Тукайның тормышын һәм иҗатын өйрәнү буенча хәзер безнең алда нинди бурычлар тора?

Тукай әсәрләренең басма томнарын әзерләгән РАШАТ ГАЙНАНОВ:

— Тукай иҗаты бездә иң күп һәм иң тирән өйрәнелгән өлкә. Тукай хакында китаплар, мәкаләләр күп. Ләкин кайда аның бөтен язма мирасының шигъриятен һәрьяклап, җентекләп, киң һәм тирән итеп иңләп алган, күрсәтеп биргән хезмәтләр, монографияләр? «Оп-олы Тукайны» нәкъ менә «оп-олы шагыйрь» итеп күрсәтү, таныту — көн тәртибеннән төшмәс бурыч булып кала.

Тукайның «үзе», шәхси тормышы турында да монография дөнья күрде. Әмма бары тик документларга таянып кына, фантазия-хыял катыштырмыйча язылган тирән фәнни биографик хезмәтнең әлегә туганы юк. Бу, минемчә, нәкъ менә бүгенге һәм беренче бурычлардан.

1906 елдан башлап чыккан беренче тәнкыйть фикереннән соң Тукай тормышына һәм иҗатына карата бик күп тәнкыйть мәкаләләре басылып чыккан. Аларның зур күпчелеге гарәп графикасында. Шуларның иң кыйммәтлеләрен туплап, тиешле бәясен биреп, саллы бер җыентык чыгару — югарыда әйтелгән бурычларны үтәү юлында кирәкле бер эш. Хәзер әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть мәйданына байтак сәләтле яшьләр килде һәм килә. Тик алар гарәп язулы материалларга тиз генә кереп китә алмыйлар. (Бу университетта гарәп, фарсы телләрен артык академик рәвештә укытудан, гамәл-практика белән тыгыз бәйләнмәвеннән килсә кирәк.) Әлеге җыентык сәләтле яшьләргә Тукайны өйрәнү-тикшерүдә традицияне үзләштерү һәм дәвам итү өчен әйбәт чыганак-кулланма да булыр иде.

Җыйнап әйткәндә, бөек Тукайны өйрәнү һәм күрсәтү кебек изге эштә яңа этап башлана.

**Бәхтияр Ваһабзадә,**
Әзербайҗан халык шагыйре, СССР
һәм Әзербайҗан ССР Дәүләт премияләре
лауреаты

# САБИР ҺӘМ ТУКАЙ

Бөек шагыйребез, революцион-сатирик әдип Мирза Алекпер Сабир әсәрләрен кайчан гына укысам да, хәтеремә татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай килә. Мөгаен, бу — аларның идея, уй юнәлеше, яшәгән еллары һәм язмышларының уртаклыгыннандыр...

1905 елгы революциядән соң бөек әзербайҗан демократ язучысы Җәлил Мәмәдкулизадә чыгара башлаган «Мелла Насретдин» журналы Сабир иҗатында да текә борылышка сәбәп булды: Сабир үзенең революцион сатирасы белән яңа юл ачып, шигъриятебездә яңа мәктәпкә нигез салды дибез.

Бөек Сабир 1911 елда бавыр авыруыннан вафат булды. Аның алты ел эчендә иҗат иткән әсәрләре әзербайҗан шигъриятенең — иҗтимагый һәм политик лириканың чын биеклегенә әверелде. Һәм бик яшьли үпкә авыруы белән дөньядан киткән Габдулла Тукай да үзенең 8—9 еллык иҗат гомерендә, безнең әдәбият өчен Сабир башкарган олы миссияне иңнәренә алып, халкы алдында бурычын үтәргә өлгерде...

Һәр ике шагыйрь, рухи һәм фикри бик якын булган хәлдә, үзләренең зур көрәшендә бер үк дошманнар белән көрәштеләр: мәсәлән, Тукайның атаклы «Мулланың зары»н тәрҗемә итүе очраклы хәл түгел иде. Шуңа күрә дә, Тукайны Сабирыбызның аваздашы, фикердәше, көрәштәше итеп санаган «Мелла Насретдин» журналы үзенең 1913 ел, 13 санында басылган некрологында «безнең дә милли шагыйребез саналган Габдулла Тукаевның вакытсыз үлүе уңае белән татар халкының тирән кайгысын уртаклашуын» язды.

Һәр ике әдип үз йөрәген якты чыраг итеп, ирек һәм ватан бәхете хакына караңгыны җиңәргә омтылдылар. Алар өчен Ватан һәм халык, аның өметләре һәм мәнфәгатеннән башка зуррак максат юк иде. Ватан — аларның изге михрабына, халыкны тәрәккый иттерү — иң олы идеалга әверелде һәм бу юлда ахыргача балкып янып, алар чын бөеклек яулый алдылар да...

Мин Г. Тукай шигырьләре белән яшьтән үк танышмын. Бакуда яшәүче, Тукайның ерак туганнарыннан берсе, һөнәре буенча табибә — Һава ханым миңа шагыйрьнең татарча китабын бүләк иткән иде. Оригиналны бик үк әйбәт аңламаганлыктан, Һава ханым миңа ярдәмгә килде: шигырьләрне кычкырып укып, миңа мәгънәләрен аңлатты. Шул чакта мин үзем өчен татарча күп сүзләрнең тамыры безнең белән бер үк булып, әйтелеше генә башка икәнлеген, шуның төп мәгънәне аңларга комачаулавына төшендем... Әйе, Һава ханым ярдәме белән мин бөек татар шагыйрен үз халкым шагыйре кебек яраттым һәм аңа мәхәббәтем еллар узган саен арта гына бара... Бүген дә Тукай — минем өчен, Сабир шикелле үк, кан кардәшем һәм рухи якын туганым...

Һәрбер кеше тик бер генә кабат туа һәм һәр бөек улы туган сәгатьтә, гүяки, халыклар да өр-яңадан туа кебек. Бөек уллары халкын үз-үзенә башка күзләр белән — үзләренчә карарга өйрәтә, һәм яңача күрергә өйрәнгән, күзләре тагын да киңрәк ачылган халыклар яңара, байый бара. Татар халкының шундый улы булган Тукай үзе дә халкына бурычы турында аз язмады! Чөнки ул үзе үк халкының аһзарыннан яралган иде. Һәм мондый шагыйрьләр, гадәттә, бу аһ-зарлардан котылу юлларын да эзлиләр һәм табалар...

Инглиз халкын — бөек Шекспирсыз, рус халкын — Пушкинсыз, алманнарны — Гетесыз һәм әзербайҗан халкын Сабирсыз күз алдына китереп булмаган шикелле, татар халкын да Тукайдан башка аңлавы мөмкин түгел. Чөнки бу алыплар һәркайсы үз халкының рухына, символ-эмблемасына әверелә алган. Үз халкының горурлыгы, даны була алган бу олуг затлар — бар халыклар өчен дә кадерле, якын исемнәр. Шуның өчен дә без бүген Тукайны татар халкының бөек улы итеп кенә түгел, ә бәлки бөтен кешелекнең даһие дип тә саныйбыз.

Сүземне шагыйрьнең бөеклегенә багышланган бер шигырь белән тәмамлыйсым килде.

Яшьнәдең яшендәй һәм куа алдың төнне
юлыңда син,
Дөньяны, чорың төсен — идеалың
уты аша күрдең.
Мең гасырлар һәм гомерләрдән
калган зур йөкне алып,
Ил күгенә «Халкым!» дип янган бер
йолдыз булып кердең!
Үз вакытында яндың, әмма
иртә сүнеп, киттең бездән.
Ә халкыңның көткән бер йолдызы —
чын улы идең!
Фәкать синдәй улы белән кабат
туды, гүя — бөек, моңлы халкың синең!

*1985, Баку.* *(Рәдиф Гатауллин тәрҗемәсе.)*

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

СОРАУ:

— Г. Тукайның тормышын һәм иҗатын өйрәнү буенча хәзер безнең алда нинди бурычлар тора?

ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, филология фәннәре докторы, профессор ИБРАҺИМ НУРУЛЛИН.

— Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты, үзе әйтмешли, «анасеннән җебенә кадәр» өйрәнелеп җиткән тәкъдирдә дә әдәбият белеме кул кушырып утыра алмас иде. Чөнки теләсә кайсы бөек шагыйрь кебек үк, Тукай да һәр чорда ниндидер яңа ягы, яңа сыйфатлары белән ачылып китә. Өйрәнелеп бетү турында сүз йөртергә бик тә, бик тә иртә әле. Биографиясендә «ак таплар» байтак булган кебек, иҗаты да ачылып җитмәгән.

Тукайны чын мәгънәсендә гыйльми рәвештә, дөрес методологиягә нигезләнеп өйрәнү һәм фәнгә кагылышсыз исәп-хисаптан чыгып өстәлгән чүп-чардан арындыру бурычы тора. Дөньяда булмаган ниндидер Тукай уйлап чыгармыйк, ничек булганынча (натурализмга бирелмичә, әлбәттә, реалистик итеп) күрсәтик, алдан уйланган нәтиҗәгә яраштырып фактлар чүпләмичә, фактлардан чыгып нәтиҗә ясыйк.

Әдәбият белеменең игътибары Тукайның шигъриятенә юнәлергә тиеш. Чөнки — сәер тоелса да, әйтергә туры килә — без аны шагыйрь итеп начар беләбез. Фәнни әйләнештә — күп булса ике-өч дистә шигыре һәм бер-ике поэмасы. Минә күңелгә килгән беренче шигыре:

Бик югартын күз салырга башладык әхлакка без,
Көр күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без.

Тик хәзер йөз сумны урлап килгүче угры кеби,
Күз салабыз чын сүз әйтердән әлек як-якка без.

Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга,
Гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без.

Кемнең, әйтик, шушы әсәрне җентекләгәне, тирән мәгънәсен һәм сәнгатьчә матурлыгын ачып биргәне бар? Мондый шигырьләр исә Тукайда аз түгел.

Әхлак дигәннән, бу тема Тукай иҗатында зур урын тота. Партия социаль гаделлек, дереслек һәм әхлак мәсьәләсен бөтен кискенлеге белән куйган бер заманда Тукай поэзиясен кемдер әнә шул тема яктылыгында өйрәнеп чыкса, зарар булмас иде.

## Виктор Кочетков,
рус шагыйре.

# Шигъри причалда

Урта Рәсәй күзе узып бара,
«Шевченко» һәм «Пушкин» затонда
Кышкы ялга туктап гәпләшәләр
Җыр хакында,
Дөнья хакында.

Әйләнгәннәр ерак диңгезләрне,
Шуңа бугай, алар уйчан да...
Шигъри юлга хисап ясый алар.
Маңгайларын терәп причалга.

Утлар яна,
Күзге кичке утлар —
Алар уйландырыр ут сыман.
Әнә «Пушкин»
Шигъри диңгездәге
Туганнарын эзләп юксына.

Печорада «Крылов» йөзеп йөри,
Днепрдан түбән — «Гоголь» бар —
Бүгенгеләр, бәлки, алар йөргән
Киңлекләргә бер юл алырлар.

Ока елгасында «Есенин» бар
Ә түбәндә — «Янка Купала».
Шигърият зур —
Су юллары кебек,
Киләчәге барлар юл таба.

Яңалардан кемне атыйк бүген?
Кемне чорга лаек дисеннәр?
Россия ул бары үзе кебек
Мәшһүрләргә бирә исемнәр.

«Пушкин» сүзләренә башын кага
Юлдаш, чордаш, кордаш булып чын —
Бер үк причалның яктысында
Ялга кайткан дусты «Шевченко».

Әнә шулай гәпләшәләр алар,
Җыр хакында, дөнья хакында...
Сөенәләр күреп: илләр гизеп,
«Тукай» кереп килә затонга.

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ** тәрҗемәсе.

## Сагынгали Сеитов,

казах шагыйре.

# Тукай турында уйланулар

Тукай туды — илнең сирәк баласы,
Зарыгып көтеп алган кирәк баласы.

Татар җанын аңлатыр, аңлар шәп ир
Кирәк иде илгә — бөек бер шагыйрь.

Тукай туды тулгагыннан тарихның,
Тукай туды моң-зарыннан тарихның.

Туды йомылып калмас өчен ояда,
Туды очар өчен биек кыяга.

Ачты аңа ак канатын җәеп таң,
Күтәрелде шоңкар ерак Җаектан.

Җаек, Җаек... Өйрәтте дулкыннарда
Иртә үсеп, ил турында уйларга.

Халык белән баш күтәреп җиңәргә —
Җыр җилкәне горур акты җилләрдә.

Тайпылмады бар дип упкын, үр алда,
Давыл шавы күтәрелде Уралда.

Аны ишетте Үләнте, Болдырты[1], —
Казахларның җырга комар киң йорты.

Шуңа, шуңа якыны ул казахның,
Шуңа, шуңа акыны ул казахның.

Тукай, Абай бер сын миңа, бер рәсем:
Кадерлимен аталарның мирасын.

Оран салган, давылланган акынны
Серле Казан, моңлы Казан чакырды.

Акын дәррәү җиктерде дә пар атны,
Йөзен нурлы Казанына каратты.

Тукай кайтты чаптырып пар атларда,
Курай моңы чыңлады наратларда.

Утырды зур шагыйрь татар түрендә,
Кояш булып балкыды ул күгендә.

Язмыш аңа шундый өлеш сайлады,—
Яныл төште күктән... көлгә калмады,

---

[1] Үләнте, Болдырты — Урал өлкәсендәге елгалар исеме.

Куктән атылып төште... җиргә ятмады,
Кояш булып чыкты, ләкин батмады.

Ул мәңгелек татар җаны шикелле,
Ул мәңгелек татар даны шикелле.

Ул мәңгелек татар теле шикелле,
Ул мәңгелек татар иле шикелле.

**Нури АРСЛАНОВ** тәрҗемәсе.

# Камил Мостафин

## Белсә иде, белсә иде!..

Иске «Болгар» номерлары,
бик караңгы почмаклары,—
өйсезләрнең үги өе,
ятимнәрнең «оҗмахлары»...

Тәрәзәдән ай караган,
ак күлмәкле ябык егет
нидер яза ак кәгазьгә,
уйчанланып, кайчак — көлеп.

Хәрефләре нинди җитез:
берсен-берсе эләктереп,
ашыгалар,— нәкъ аныңча,
сагышланып яки көлеп.

Сукыр лампа — өстәлендә...
Урамнар тын. Казан йоклый.
Бер-ике эт өреп куя
(Каракларны гына тотмый!).

Авыр дөнья! Гаҗәп дөнья!
Моңнарын да, зарларын да,
ах, абзыйлар сата мәллә
күрше Печән базарында?!

Аһәңнәрен саклап калган,
аклап калган татар теле,
шушы телнең яңа серен
көйли мәллә Кабан күле?!.

Тын булса да төнге дөнья,
барсы ишетелә кебек...
Бүлмәсенең почмакларын
инде күрә, күрә егет!

...Караңгыда пәйда була
урман халкы, сәер затлар.

(Я алар алдар егетне,
я аларны егет алдар!)

Тузган чәчле әбекәйләр
тәрәз шактый, ялт-йолт карап.
Сискәндереп йолдызларны
һәм пошкырып, килә пар ат...

Әллә кемнәр йөгереп чыга,
кәлә, каршы ала инде,—
кем исемле, кайсы яктан —
белсәң иде, белсәң иде!..

## Рәдиф Гатауллин

Тукай сагындыра...
Юккамыни
Зәукы «сусап китсә», берәүләр:
— Әнә, диләр, тавышын ишетәбез,
Хәбәр бирә яңа пәйгамбәр,—
Күренәчәк тиздән... Әль-сәламе
Белән килә: горур, дәгъвалы...
Яңа Тукай, шиксез! Көр тавышы
Ничек яңгырый!
Бөтен галәмне
Шаккаттырыр тагын татар җыры...
Тукайдандыр мирас каләме...
Күреп калыйк!

...— Тукта!— дип кем әйтер
Тукай исеме белән уйнаган
Бәгъзеләргә?!— Тукай үзе булып
Килгән ләса? Кемдер булмаган...
Аның рухы белән тиңлик, дисәк,
Мохитына аның куярга
Кирәкмиме яңа дәгъвачыны?—
Кыл күперләр белән сынарга...
Рухта бәлки кабат туу кирәк,
Табу өчен дөрес кәгъбәне...
Булды алар — үзен Тукай итеп
Санаганнар — ялган вәгъдәле...

— Мин Тукайдан соңгы җыр рәсүле,—
Дип белдерде азмы килгәннәр —
Чордан «вәхи ала» белгәннәр...

...Ә булганмы пәйгамбәр, «Мин» дигән?—
Ялганнары булган, йөргәннәр...

Пәйгамбәр дип алдап танытканны
Беләм, элек... Иблис, дигәннәр.
Элек тә ахры таный белгәннәр!

# Харрас Әюпов

*Тукайның өстәл тартмасында*
*коръән белән бергә револьвер*
*саклanган.*

Бер иңдәге ике фәрештә кук —
Бер тартмада коръән, револьвер:
Бер ук җанны икәү сагалаган...
Мәрхәмәт бир берүк, иман бир!

Револьверга кагылмаган шагыйрь...
Тик әле дә тора яңгырап:
Дошманына төбәп аткан сүзе
Кургаштан да булган саллырак.

Өметләре өзелеп калган чакта
Ничә тапкыр кискен уй керде;
Тартма почмагында ятты шәүлә
Бөгәрләнгән елан шикелле.

Кара еллар буган сулышыңны
Коръән генә ничек сакласын —
«Ходаң» үзе килеп тартса синең
Язмышыңның кара чакмасын?!

Бер ук җанны икәү сагалаган:
Я сынасы син, я чыдасы;
Кара нокта куясыдыр берсе,
Икенчесе — ясин чыгасы.

Баш бирмәде шагыйрь берсенә дә,
Кагылырга хәтта чирканды:
Китеп барды бер тартмага ябып
Револьверы белән коръәнне...

# Рөстәм Вәлиев

*Рөстәм Шәвәли улы Вәлиев Троицк шәһәрендә 1936 елда укытучы гаиләсендә туа. Гаскәри хезмәтен тәмамлаганнан соң, ул Магнитогорск металлургия комбинатында эшли. Хәзер Чиләбе каласында яши.*

*Язучы — Чиләбе, Новосибирск, Мәскәү нәшриятларында басылып чыккан унбишләп проза китабы авторы. «Шәһәрләр җире» романы «Новый мир» журналында басылып чыкты, кайбер әсәрләре чит илләрдә швед һәм дари телләрендә дә дөнья күрде.*

*Рөстәм Вәлиевнең «Дөнья гаме» дигән яңа романы Габдулла Тукайга багышланган. Ул рус телендә «Урал» журналында басылды, быел Мәскәүдә «Советский писатель» китап нәшриятында чыга. Без шул әсәрнең аерым бүлекләрен бөек шагыйребезнең юбилее уңаеннан укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез.*

## ДӨНЬЯ ГАМЕ



Карт дәрвиш Җаек каласында бу юлы да әллә ни үзгәреш тапмады. Кырый урамдагы балчык алачыклар, читән коймалар, үзәктәге асты таш, өсте бүрәнә йортлар, татар бистәсе Мәгъмүриянең яшел түбәле өйләре, башына ай менеп кунаклаган нәфис маналы мәчетләре — барысы, барысы да интектергеч кызуда элеккечә үк җәйрәп ята иде. «Мотыйгыя» мәдрәсәсенең биек тирәкләр ышыгындагы ишегалды да янарыш кичермәгән сыман. Әмма карт дәрвиш монысына сөенде генә — аулак күләгәдә сулыш алулары урамдагыдан күпкә җиңелрәк һәм рәхәтрәк иде.

Киндер чаршауны як-якка аерып, ишек уемыннан килеп чыккан озынча йөзле, малай гына дип әйтерлек кара-коңгырт чәчле яшүсмер, кунакны күреп алуга, күңелле җанланып каршысына атлады һәм, кулларын сузып, оялчан гына күреште. Карт аның ябык, сары суккан йөзенә карап:

— Намазга бармагансың икән, Габдулла шәкерт. Әллә чирләп киттеңме? — дип сорады.

— Мин гыйбадәтне ялгызым кылырга яратам.

Яшүсмер кызарынган йөзен түбән иде. Аның кунакка чынлап та авыруын, әле һаман хәлсезлеген сиздерәсе килми иде. Соңгы очрашудан соң бик әз үзгәрүе, быелгы язда унсигезен тутырса да, әле һаман ябык һәм карсак буйлы булып калуы да уңайсызландыра иде аны. Шулай да ул үзен бик тиз кулга алды һәм ишек чаршавын ашыга-ашыга күтәреп:

— Әйдәгез, суфый бабай, узыгыз! — дип кунакны хөҗрәсенә чакырды.

Карт әчкә керүгә сәкедә урнашып, җепкә тезелгән хөрмә төшләре шикелле үк кара-кучкыл озынча бармаклары белән тәсбихен тарта башлады.

— Мин самавыр куйыйм әле. Шәкертләр барысы да таралышып бетте инде, безгә хәзер берәү дә комачауламас.

Ул шулай диде дә ишегалдына чыгып китте. Анда бераз югалып торгач, кызгылт күмерләре чыжлап торган самавырны хөҗрәсенә алып керде һәм чәй пешерде. Аннары сәкегә җаймә җәеп, шуңа нәни киндер капчыгыннан күзикмәк һәм бавырсак шикелле йомарлап киптерелгән корт бушатты. Аннары касәгә чәй ясап, кунагы алдына куйды.

— Шикәрем беткән чак туры килде бу юлы,— диде ул.— Өченче елымны шушында яшим инде, суфый бабай. Балык тотам, бай малайларына сабак өйрәтәм, кайчак коръән укырга баргалыйм — тукланам шулай. Мәҗлесләрне, ярминкәләрне генә яратмыйм. Шау-шуы, ыгы-зыгысы биздерә.

— Хәмелгә, мәет күмешергә йөрмисеңме?

— Йөрмим. Йолаларыбыз кырыс, күз яше чыгарырга ярамый ич. Хатын-кызларыбыз кайгыдан кара көйсә көя, әмма иңрәми, ир-атларыбыз инде таштан яралган шикелле.

— Хәсрәт сабыр кичерелергә тиеш,— диде карт.— Безнең тәнебез тузаннан яратылган, тузанга әйләнер дә. Шагыйрь:

Газиз җаным юл табалмый яхшыга,
Гаҗизләнеп әҗәленә ашыга,

— дигән. «Әл-Мәгарри. Ярлы дәрвиш бу юлларны кайдан откан икән?»

— Заманында шөһрәтегез еракларга таралган булгандыр сезнең, суфый бабай?

— Элек мин нәҗес тазартучылардан да фәкыйрьрәк идем,— дип җавап бирде карт.— Хәзер инде үз байлыгымны алтын кантарына да тиңләмим. Бергә сәяхәткә чыгып китсәк, үзең дә борынгы китапларда тупланган зирәклекнең сәүдәгәрләр йөгеннән дә мулрак икәнен күрерсең.

— Сәяхәткәме? — дип сорады яшүсмер.— Тынычлап гыйбадәт кылыр өчен кешеләрдән ераклашыргамы?

— Юк, углым, рухыбызны танып-белер, аны ирекле итәр өчен.

— Без бүтәннәр бәхете хакына яшәмибезмени?

— Ә син әүвәл үз рухыңны бает, аннары ул бүтәннәргә дә күчәр.

— Рухыбыз нинди хакыйкатькә якыная ала соң?

— Дөнья мәгънәле һәм камил яратылган, аның һәр нәрсәсе бер-берсенә бәйләнгән, ләкин могҗизалары исәпсез-хисапсыз. Хакыйкать менә шунда.

— Җиһанда яманлык нигә бу кадәр күп икән?

— Дөньяда яманы да, яхшысы да җитәрлек. Боҗраның иң түбәнге ноктасыннан баксаң, аның югарыгы ноктасында бүтән, син хис иткәннең капма-каршысы да бар. Һәммә нәрсә үсештә үзенең иң югары ноктасына күтәрелә дә түбән тәгәри, боҗра буенча сиңа, Искәндәргә, Әфләтүн яки Аксак Тимергә алмашка башкалар килә. Бөтен яшәеш әйләнә буенча кабатлана, фәкать кеше гомере генә туры юлдан ук сыман узып китә. Син, углым, теге игелекле җәйне генә хәтерлә!

— Мин аны онытмадым.

Алар бер җәйдә шәһәрдән шәһәргә, авылдан авылга сәяхәт иттеләр, көтү-көтү маллары белән казакълар күчеп йөргән далалардан кыдырып уздылар, карт дәрвиш аңа менә шул сәфәрдә озын-озак гомерендә күргәннәрен төннәрката әңгәмә кылды. Аһ, нинди рәхәт булган иде шул чакларда!

Габдулла тышта көпчәкләр шыгырдавын, ат пошкыруын, тояк тавышларын ишетте һәм, тиз генә аягына басып, ишеккә юнәлде. Капка төбендә берәү иплән кенә атын тынычландырып маташа иде.

Яшүсмер ишегалдына йөгереп чыккач, камчысы белән юл буендагы куакларга сыдыргалап килүче хәлфәсе Камилне күреп алды.

— Мөхтәрәм шәкерт әфәнде,— диде ул ваемсыз кыяфәттә,— сез әле, мөгаен, шушы сәгатькәчә йокы симертеп ятасыздыр?

— Шаулама, кунагым бар минем.
— Кем соң ул?
— Дәрвиш бабай.
— Һә-ә-әй! — Камил, чыраен сытып, болдырга үзе башлап килеп керде. Дәрвишкә юрамалый юашланып, итагатьле рәвештә олылап баш иде. Карт исә аңа: «Вәгаләйкем»,— дип шактый коры җавап кайтарды. Камил шикелле ыспай, көяз бәндәләргә ул элек-электән кырын карый иде. Егетнең янып торган кабартма яңаклары, мәгънәле сикергәләгән куе калын кашлары, дәү туры борыны — җиңү яулаган сугышчыныкыдай бөтен кыяфәте тук тормыш турында сөйли иде. Киемнәре дә харап: буй-буй сызыклы голланд күлмәге, тар балаклы чалбар, штиблетлар, яшел атлас чапан. Кереп җитмәс борын Габдуллага «әйдә, карт мосафирыңны ташла инде» дигән сыман ишарәләр ясый башлады.

...Су буена килгәч, Камил җанланып:
— Син берни дә белмисең ич әле, валлаһи! — диде.— Шәрипов завод хуҗасы Ибнәминевкә: «Фәлән җиргә фәлән сәгатьтә мең тәңкә илтеп куймасаң, башың китәчәк», — дип язу җибәргән.
— Шул кадәр акча Шәриповка ни өчен кирәк икән?
— Экспроприация... Минемчә, революция хаҗәтләренә. Күн заводында да кемнәрдер куйган бомба тапканнар ди. Берни ишетмисең син, ә? Дәрвиш әкиятләреннән башканы тыңламыйсың да ахры. Әле Мәскәү, Питербурларда, Көньяк заводларынданиләр генә кыйланмыйлар икән!..
— Сугышны туктатсыннар иде алар.
— «Сугышны, сугышны»,— дип куйды Камил.— Анысы тиз генә бетмәс инде аның. Ляоян тирәсендә меңләгән җан һәлак булган, Порт-Артур да кыл өстендә генә тора икән... Тик дошман Порт-Артурны шартласа да ала алмас!
— Бу очракта сиңа Ибнәминев тә каршы килмәс, сүзләреңнән хәзрәт тә көфер нәрсә тапмас иде.
— Шушы да булдымы инде мулла малаеның җавабы?
— Менә, менә! Без шундый ватанпәрвәрләр ки, үзебезнең үткәнебезне дә, хәзергебезне дә хурлаудан тыелырга тиеш. Изге нәрсәләргә кагылу зарарлы, янәсе. Яшь түгәргә булса — рәхим ит, мөмкин. Искергәнне, сөрсегәнне көлкегә калдырудан исә алла сакласын, милләтебезгә күләгә төшүе бар!
— Моның куркырлыгы юк,— диде Камил беркатлы рәвештә.— Без бары үз халкыбызны, аның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен сөябез.
— Әмма мәхәббәтебезне назлы сүзләргә генә кайтарып калдыру килешми. Мәхәббәтебез ачы ич безнең. Шәриповның матур телләренә кызлар гына сокланса сокланыр... Менә син үзең нишләргә җыенасың: китап язаргамы, җырларга, балалар укытырга яки революционер булыргамы?
— Мин, мөгаен, барысына да өлгерермен кебек. Тукта әле, менә хәзер үзең исемә төшердең,— диде Камил илтифатсыз гына.— Бүген пайтәхеттән хат алдым, «Бәхетле Мәрьям»ымны Питербурда басачаклар икән.
— Ху-уш, котлыйм!

Барысына да көче җитәчәгенә чынлап та ышана иде ахры ул. Дөньяда нидер бара, нидер какшый һәм җимерелә, яңа катламнар өскә калка, иске тормыш бернигә дә ярамый, яшәп килгән тәртипләрне нәкъ менә алар үзгәртергә тиеш, дип ышанган нindидер яңа кешеләр пәйда булды. Әллә соң Камил шуларның берсеме? Татар әдәбиятында «Бичара кыз», «Рәдде бичара кыз», «Бәхетсез егет» кебек мелодрамалар болай да күп, андыйлар урынына нигә соң әле ул әнә шул яңарышны күрсәтмәскә тиеш? Моңарчы язганнары тормыштан, әйтик, хәтта үз чынбарлыгыннан да бик ерак, билгеле. Атасы сәүдәгәр кызына өйләнергә тәкъдим иткәч, нинди тузынган иде. Ләкин барыбер өйләнде, бер елдан исә шатланып һәм җилкенеп Истанбулга, аннан Каһирәгә үк укырга китеп барды. «Әл-

Әзһәр»не тәмамлап кайткач, тыңлаучан хатынының үзенә тышау булмаячагына тагын бер кат ышанып, тәмам тынычланды. Атасы мәдрәсәсендә мөгаллим булып мантыйк, мөселман хокукы, коръән сабакларын бирә башлады, әдәби әсәрләр язарга һәм Фламарионны укып рәхәтләнергә керешге. Төннәрен чормага менеп, уклау сыман күзәтү торбасы аша чардактан күк җисемнәрен барлый, Акбүзат, Вега, Көянтә, Сириус кебек серле атамаларны дулкынланып һәм рухланып кабатлый, шул чак үзен дә аерым бер илаһи дөньяга килеп эләккәндәй хис итә иде. Җаны түземсезлектән чыңлый, дәрте тышка да бәреп чыга — иртәләрен манара башына менә дә азан әйтә — Мәгъмүриянең тын урамнары өстендә моңлы һәм көчле яшь авазлар яңгырый башлый иде...

Шәһәргә кайтып килгәндә Камил:

— Әйдә безгә кичке ашка,— дип чакырды.— Әткәй синең килеп йөрүеңне хуп күрә.

— Рәхмәт,— дип җавап бирде Габдулла,— хәзрәткә сәлам әйт, мин бүген кереп тормыйм инде.

Әмма үзе бу чакыруны кире каккач, күңелсезләнә калды. Мотыйгулла хәзрәт Габдулланы малай чагыннан ук иләштерде, үз көтепханәсеннән Хафиз, Әл-Мәгарри, Сәгъди мәҗмугаларын биреп торды, аннары классик шигырь төзелеше гарузны өйрәтте, үз өендә җыела торган яшьләргә Габдулланы зирәк шәкерт, китап сөюче итеп таныгты. Хорафатлардан азат кеше буларак, үз балаларын заманча тәрбияләргә тырышты. Камил инде яңалыкларның нәкъ уртасында кайный. Габдулла аларның барысын да үзенчә ярата, әмма өйләренә еш барудан тайчана, ыгы-зыгылы мәҗлесләрдән кыенсына иде.

Яңа пешкән икмәк сыман җылы һәм хуш исле сары көннәре, йолдызлы караңгы төннәре белән сентябрь килде. Җәйге озын тәнәфестән соң шәкертләр дә җыела башлады. Берәүләр ата-анасы янында кунак булган, икенчеләр ярминкәләрдә йомышка яраган, далада балалар укыткан яки Гурьев балык промыселларында тир түккән иде.

Габдулланың «Гайния» мәдрәсәсендәге дуслары Миңлебай белән Сираҗи быелгы җәйне Эрбет ярминкәсендә уздырганнар икән. Тәэсирләре дөнья, акча да эшләп алганнар, Сираҗи шунда гашыйк тотарга да өлгергән.

— Шаклар катарсың,— диде Сираҗи назлы елмаеп,— мин шуңа аптырыйм әле, Апуш, ярминкәдә артист даны казануын дустыбыз телгә дә алмый лабаса...

— Бәйләнмә әле,— диде Миңлебай уңайсызланып.

— Юк, чыннан да, Апуш,— дип үзенекен бөгә бирде Сираҗи,— дустыбыз анда һәр кичне гармун уйнап, җырлап, Сакаев ресторанын ду китерде.

— Әмма маяны синнән әзрәк тупладым,— диде Миңлебай кызарып.— Ләкин ярар, хикмәт акчада гына түгел лә. Мин, Апуш, беләсеңме, җырлавыма үзем дә сөендем әле. Бәхет кошын тоттыммыни!

— Әйбәт булган,— диде Габдулла,— тик син бу хакта хәлфәләр алдында ычкындыра күрмә инде. Ә безнең Сираҗи ни кыйратты соң?

— Трактирда аш-су өләшеп тордым,— диде Сираҗи гади генә.— Башлап җибәргәндә ярыйсы инде. Хәзер менә яңа эш табу да зыян итмәс иде. Фронтта сәүдә итү төшемле диләр дә, мин тотынганчы сугышның бетеп куюы бар. Бәлки, биш олау кизәк сатып алырга да ваклап сәүдә итәргәдер? Хәзер кизәк тә бәяле. Элек юл төзегәндә генә шулай була торган иде.

Чынлап сөйли идеме ул моны, шаяртыпмы — алла белсен. Әмма юантык шәкертнең хәйләкәр елмаюы, күңелле авыз еруы күз алдында иде.

— Ай-һай, хыялларың!

— Укуны өзсәм, ни белән шөгыльләнергә? Алайса үзегез әйтегез.

Мәдрәсәне ташлау яки, анда тагын алты-җиде ел буе гыйлем өстәп, мәхәллә мулласы булу турында алар соңгы вакытта әз баш ватмады инде. Ташласаң, кая китәргә? Сираҗи приказчиклыкка яллана, вакыты җиткәч, үз кибетләрендә атасын алыштыра алыр. Әмма сәүдә эше дә хәзер дөньяви белемнәр таләп итә. Рус-татар мәктәбенә керерләр иде — хурлыгы чамасыз: анда синең мәдәниятеңне түбәнсетәләр, ата-бабаң диненә күләгә төшерәләр. Хәер, кайберәүләр икеләнеп тормый, тәвәккәлләп шунда белем ала, бәлки Сираҗига да зыяны тимәс иде аның.

Ә Миңлебайга нишләргә? Ул артист булырга тели ләбаса. Бу шулкадәр яңа, кыю һәм хәвефле бер эш ки, олыларның яклавына исәп итәсе дә юк. Укымышлы остазлар моңлы мәкам белән коръән укуны гына таный. Нигезе нык, әшнәләре күп Камил дә иҗат дәртен азан әйтеп кенә баскан бер дәвердә, ни акчасы, ни йогынтылы туганнары юк егеткә артистлык турында хыяллану үзе бер акылсызлык!

Мәдрәсә ишегалдында алар, күңелсез уйларга чумып, тынып калдылар. Яшьрәк шәкертләр килеп: «Габдулла абый, әкият сөйлә әле?» — дип ялынса да, ул җавап бирмәде. Өлкәнрәк иптәшләре аш пешерергә җыенгач та урыныннан кузгалмады. Анда катнашасың икән, уртак казанга ит салырга кирәк. Тик аның инде күптән ит сатып алганы юк.

— Һәй, бөтенләй онытканмын да ич! — дип кинәт телгә килде Миңлебай.— Бүләк алып кайттым әле мин сиңа.

Ул шатлана-шатлана киндер биштәреннән бер калын китап тартып чыгарды. «Каюм Насыйри. Фәвакиһелҗөләса».

— Әллә бу чынлап та миңамы? — диде Габдулла аптырап.

— Сиңа инде, сиңа. Моннан мавыктыргыч тарихлар укып, галимнәрнең фикерләре һәм җырларыбыз белән дә танышырга мөмкин.

— Беләм, заманында бер укыган идем мин аны. Тик үземә булдыруны хыяллана да алмаган идем. Бик кыйбаттыр ләбаса ул?

— Араны киләчәктә өзәрбез. Тагын бер китап бар ич әле сиңа: Пушкин.

— Рәхмәт яусын үзеңә! Мин хәзер бу китапларны гына җыеп куйыйм да... Көтеп торыгыз, мин хәзер. Берәр аулак җиргә барырбыз да...

Әмма дуслары остазларына сәлам биреп чыгарга җыенганлыктан, Габдулла Пушкин бакчасына ялгызы гына барырга мәҗбүр булды. «Фәвакиһелҗөләса» томын хөҗрәсендә калдырып, ул үзе белән Пушкин китабын алды. Түзмәде, аны аяк өсте үк караштырды, үзенә электән таныш шигырьләрне дә күреп шатланды.

«Рус классы» укытучысы Әхмәтша абыйсы шушы бакчаны утыртырга алып килгәндә аңа әле унөч кенә яшь иде. Шагыйрьнең йөз еллыгы хөрмәтенә барлыкка китерелде ул. Ак каүсәле каеннар, яфраклары саргая башлаган чаганнар. Габдулла әле дә хәтерли: нәни үрентеләрнең яфракларына кагылганда ул бик дулкынланган, кулларының җиңелчә калтыравын баса алмый аптыраган, эченнән шагыйрьнең «Для вас, души моей царицы, красавицы, для вас одних» дигән юлларын кабатлаган иде.

Бакча әйбәт кенә үсеп китте.

Ә хәзер — көз, яфраклар саргая, яфраклар коела...

...Кышкы сарай мәйданында тыныч демонстрацияне ату, дистәләгән гөнаһсыз җанның салкын карга авып һәлак булуы, байтак хатын-кызлар һәм балаларның яралануы турында Җаекка да хәбәрләр килеп җитте. Кешеләр, яманлыкны бөтенләй күздә тотмастан, галиҗәнап хәзрәтләре хозурына барып тез чүгәргә генә теләгән, ә ул, озаграк мыштырдап, халыкка каршы чыгарга өлгермәгән, шул чак канга сусаган залим жандармнар ата башлаган, имеш. Корбаннар гына түгел, аларның язмышына ачынган патша үзе дә кызганыч, имеш.

Габдулла бу хәбәрләрнең дөрес үк түгеллеген, артык беркатлы икәнлеген чамалый иде. Әмма чынлыкта хәлләрнең ничегрәк булуын һич тә

күзаллый алмый, акылының чикле, хисләренең салкын булуына кыйнала иде. Мотыйгулла хәзрәт пәйгамбәрләрчә ваем һәм олпатлык белән:

— Киләчәктә нәрсә көткәнен беләм мин,— ди иде.— Әле күптән түгел генә какшамас тоелган барлык нәрсә көлгә әйләнәчәк. Моңа кадәр үзара дошманлашуны уйлап та карамаган үз халкыбыз язмышы гына томанлы миңа...

Габдулла бу сүзләргә дулкынланып колак сала. Нишләргә икән аңа? Кайсы юлны сайларга? Ул төне буе китаплар дөньясын гизә, капма-каршы фикердәге фәлсәфәчеләр, тарихчылар, каләм даһилары белән таныша, әмма үзе шуларның берсенә өстенлек бирергә — «әйе, мин дә нәкъ сезнеңчә уйлыйм», — дип әйтергә кыенсына. Ул тормышны бераз белә, ләкин аның чын асылын төшенә микән соң?

Миңа яшәешемне үзгәртергә кирәк, дип уйлый иде ул. Ләкин нәрсәдән башларга? Кем белән? Үз язмышларын кискен үзгәрткән Шәрипов белән Хикмәт аңа үрнәк була аламы соң?

Мәдрәсәдә укулар бетүгә, Габдулла китап сатучы дусты янына йөгерә иде. Китап тутырылган капчыкны аркага салалар да бергәләп шәһәр кырыендагы бистәгә элдертәләр. Беренче тукталышлары — кое яны. Суга килгән яшь-җилкенчәк тә, эштән соң өйләренә кайтып баручы өлкәннәр дә китапны бик сирәк сатып ала. Әмма һәр өйдә аларны ачык йөз белән каршылыйлар, каклаган балык, бәрәңге, чәй белән сыйлыйлар.

Алар еш кына күнче Юныс өендә куна калалар иде. Озын буйлы, киң җилкәле, әмма ябык, юка гәүдәле хуҗа сакал-мыексыз, рус һөнәрчесе кебек һәрвакыт картуз киеп, теш арасына кыска челем кыстырып йөрүе, әллә нинди кырыс көч сизелеп торган бөтен кыяфәте, ятрак гадәтләре белән башкалардан нык аерыла иде.

Кунаклар янында ул әкренләп эри, китапмы, гәзитме, әлифба яки теләсә нинди рәсми кәгазьме — ташка басылганны тыңларга гомумән ярата, улының иҗекләп китап укый башлавын могҗиза сыман күзәтә иде.

Бервакыт ул сүзен:

— Шәһәргә корылык китерде мине,— дип башлады.— Уңыш тамырда утырган хәлдә сабагына кадәр көеп бетте. Калага кит, дип боерды әти, шунда юкка чыкмасаң, яшәрсең. Барам шәһәргә таба, барам, әмма аңа тагын күпме ара калуын, аның нинди икәнлеген һәм анда нишләячәгемне һич тә белмим. Бер заман юл буенда тегермән күренде, арыш тарталар. Ә мин инде өч көн ризык валчыгы капмаган. Инәләм — бирмиләр. Бөтен мохтаҗларга кайдан җиткермәк кирәк. Бүрегемне салдым да биш уч он тутырып алдым. Шул чак кемдер муен тамырыма тондырмасынмы? Ниндидер тимерләр өстенә килеп төшеп, кабыргамны чатнаттым, әмма, шөкер, барыбер сау калдым.

Калага килгәч, бер якташым аш өләшүче итеп трактирга урнаштырды. Тамак туя башлады монда, анысы хак, әмма көн дә сүгеш ишетү, көн дә йодрык тату һәм шуңа бил бөгү белән генә җавап бирү туйдырды. Тәлинкә тотып йөгереп йөргәнче, авыррак булса да, бүтән эшкә күчәсе иде дип уйлап баш ватканда, тагын әлеге якташым ярдәмгә килде. Заводка урнаштырды, хәзер шунда егерменче елым. Ә шәһәрдә җәмгысе егерме бишенче кышым. Кара әле, Сәрби, шаккатырсың, валлаһи: калада егерме бишенче елым икән бит!

Аның аркылыга җәелгән, әмма бик тере, хәрәкәтчән хатыны почмак ягыннан:

— Дөрес, атасы,— дип аваз бирде.— Гаҗәпләнәсе юк, без бергә кушылып яши башлаганга да унҗиденче ел ич инде. Әй, Надыйр, Гали, сез нәрсә шул кадәр дөнья кубарасыз?

Балаларының барысы да ир затыннан, барысы да шуклар, тавышлары бөтен өйгә яңгырап тора иде. Ун яшендә асрамага алган Нәфисә исемле кызлары да бар. Хәзер инде ул ундүрткә чыккан, нәзберек, зифа буйлы, балалыктан тәмам арынып килә иде. Сәрби апа аңа матур күл-

мәкләр, купшы башмаклар алып кидертә, батист кулъяулыкларын кызыкай тар җиңенә кыстырып йөртә иде.

Кызыкай мадам Веденяпина остаханәсендә чигәргә өйрәнә: ханым ясаган бизәкләрне тукымага төшерә һәм аларны ефәк җеп белән чигә. Шуннан кайтканда ул ара-тирә китап сатучыларга да очрый, калган юлны бергә дәвам итә иде. Кичләрен шәкерт абыйларының китап укуын тыңлап утыра. Габдулла аңа күз салмый, күптән таныш дастанны аеруча бар илһам белән яттан сиптерә:

> Кара болыт башымнан китәр көнем булырмы?
> Карагайлы кара урман үтәр көнем булырмы?
> Кайгыларның башымнан китәр кенем булырмы?
> Михнәт бетеп, рәхәтлек җитәр кенем булырмы?

Хикмәт, иптәше кулындагы китапны көлә-көлә тартып алып, аннан бөтенләй башка рухтагы юлларны эзләп таба да, Нәфисәгә мәгънәле караш ташлап, укып китә:

> Төшемдә ярым җырлап эзлә, диде,
> Тапмасмын, дип өметең өзмә, диде.
> Яраткан алла безне ни кылса да,
> Вәгъдәңне үлсәң дәген бозма, диде.

Мондый минутларда Юныс абзый рәхәтләнеп көлеп җибәрә. Ул укыганны тыңларга ярата, ләкин тыныч, гыйбрәтле кыйссаларны хубрак күрә. Ул кыйссалар аны фәлсәфи уйларга батыра иде. Ләкин үзе шул арада Хикмәтне заводка күчәргә үгетләүне дә онытып бетерми.

— Эше авыр, юанычы эз, әмма барыбер уйлап кара әле син моны,— ди.

— Андый эшкә ни дип күчим инде мин?

— Кибетчедә йомышка йөгереп йөрү шәбрәкмени?

— Аның караvы, тамак туя,— дип үрти аны Хикмәт.

— Туя?! — дип кычкырып җибәрә Юныс.— Ә билең ничәгә бөгелә соң? Туклыктанмы, ярарга тырышуданмы? Ә мин менә төз атлап йөрим, төп-төз! Заводмы... юк, син аның нәрсә икәнен белмисең...

Хикмәт көлә, ләкин иртә белән калага кайтып барганда Габдуллага:

— Ә бәлки Юныс абыйны тыңларга кирәктер? — ди.

Аннары ул татлы хыялга бирелә башлый.

— Кайчан да булса мин дә шундый саман йорт корырмын әле, Габдулла. Кәҗә сатып алырмын да балаларым рәхәтләнеп сөт эчәр. Ә кызым Нәфисә кебек чибәр булып үсәр!

Язга таба Хикмәт чынлап та кибетен ташлады һәм заводка эшкә керде.

Кышны Габдулла мәдрәсәдә уздырды. Сабак хәзер аның ни акылына, ни хисләренә азык бирми иде. Камил белән анда-санда тәнәфесләрдә күрешкәли, яшь мөдәррис дәресләрне сирәгәйткән, күбрәк әллә кайларга барып, төрле түрәләрнең бусагасын таптау белән мәшгуль иде. Апрель азагындагы көннәрнең берсендә ул мәдрәсә торагына йөгереп керде дә, Габдулла хөҗрәсенә ташланып, шатлыклы кайнар хис белән:

— Тиздән безнең үз гәзитебез, хәтта үз журналыбыз да булыр! — дип кычкырып җибәрде.— Бәхет бит бу, малай! Нәрсә дәшмисең, әйдә урамга, иркенгә, төне буе бәйрәм итик әле... Мин булачак хезмәткәрләр исемлеген дә төзеп куйдым инде. Син анда — беренче.

Алар әле карлы аклыгын җуймаган урамда ярты төнгә кадәр арлыбирле йөрделәр, хыялландылар, төрле-төрле план кордылар. Камил узган елны Җаектагы бөтен түрәләрне күреп чыккан, аннары үтенечен пайтәхеткә юллаган иде. Кире кактылар. 1905 елның башында ул кабат

Петербургка мөрәҗәгать итте. Кардәшләре инде аның бу адымын артык тәвәккәл, хәтәр санап, дәрәҗәле түрәләрнең аңа коткычы дип каравыннан шикләнә башлаган иде. Менә хәзер югарыдан җавап килеп төште. Билгеле, бусы да кыеклатып кире кагу төсендә иде. Әмма Камил хәзер инде эшнең уңасына өметләнә башлады. Чөнки ул җавапта, газета чыгарыр өчен кайбер гарантияләр, әйтик, хуҗаның мөлкәтле, матди базага ия булуы хаҗәт икәнлеге, шулар булганда мәсьәләгә кире әйләнеп кайту мөмкинлеге аңлатылган иде.

Бәхете басып, шул чак «Уралец» газетасы һәм аның типографиясе сатылачагы ачыкланды. Камил, тимерне кызуында сугып, көтмәгәндә әнә шул мөлкәтнең хуҗасына әйләнде дә куйды.

Габдулла барлык бу көннәрне Камил белән уздыруына сөенде дә, кыенсынды да. Чөнки иптәше, типография сатып алганчы гына түгел, соңрак та бик зур эш майтаргандай гайрәтләнүен дәвам итте, әмма хәзер инде аның шатлыгына хәтсез масаю, үз шәхесенә соклану хисләре дә кушылган иде. Шуңлыктан Габдулла тагын Хикмәткә, гади һәм тыйнак тормыш белән яшәүче бистә кешеләренә тартыла башлады.

Ул бервакыт су буена баргач, балык тотып маташучы эшчеләргә листовкалар таратып йөргән Хикмәтне күреп алды. Иптәше хәтәр шөгылен яшереп кала алмады:

— Мондый эш өчен, беләсеңме, башың Себер китәргә мөмкин,— дип егетләнде.

Үзенең киләчәк тормышын сурәтләгәндә Хикмәт балкып китеп, бәхеткә ирешәчәк кешедәй кыяфәткә керде. Алтын таулары белән нишләсен ул? Сәүдәгәрләргә дә төкерә генә, бомбалар ясап ятарлык бер саман йортка да риза ул, вакыты җитәр, һәр төрле кабахәтләргә каршы хәлиткеч көрәшкә ташланыр...

Хикмәт Чаган елгасы буенда йөргәндә Габдуллага үзенең нинди кешеләр белән дуслашуын, ничек итеп ышаныч казануын сөйләде. Бер көнне ач яңаклы, түгәрәк бөдрә сакаллы ир-атны күрсәтеп:

— Механигыбыз Моргулис,— дип пышылдады.— Сормово заводыннан бүре билеты белән куып чыгарганнар. Андагы вакыйгаларны ишеткән булгансыздыр ич?

— Ибнәминев ничек алды соң аны?

— Безнекеләр, эшне шәп белә, дип үгетләде.— Хикмәт көлеп өстәде: — Менә шундый эшләр, агай-эне...

Иптәшеннән аерылгач, Габдулла, сыра эчәргә дип, Казан мәйданындагы хәрчәүнәгә кагылды. Кеше әз иде, шуңа күрә ул «Уралец» газетасы редакторы Ядринцевны бик тиз күреп алды.

— Китәм, туганкаем, китәм Җаектан,— диде Ядринцев кызмача кыяфәттә.— Ә сез нигә бу кадәр сагышлы әле? Әйдә, бергәләп сарматларны искә төшерикче...— Аннары костюм кесәсеннән сары тышлы бер китап тартып чыгарды.— Истәлеккә миннән берәр нәрсә алып каласызмы? Әйтик, менә шушыны, ә?..

Габдулла бүләк китапны өенә кайткач кына актарып карады. «Ачлык-патша. Икътисадый очерклар». Димәк, истәлеккә...

Типографиягә алар Камил белән бергә килделәр. Караңгы баскычтан аскы катка төшеп барганда Габдулла балачак иптәше Саша Гладышевны очратты. Таныш кеше булгач, Габдулланы хәреф җыю һөнәренә өйрәтү дә аңа тапшырылды.

Инде икенче көнне үк, дәресләр тәмамлануга, ул типографиягә йөгерде. Шуннан соң инде мондый ашыгу, ашкынулар бөтенләй гадәткә кереп китте. Хәреф җыю да, монда эшләүчеләр үзләре дә аңа бик ошый иде. Элек кайдадыр ишеткән яңалыкларны Габдулла бик тиз оныта, бернигә дә гаҗәпләнми, балачак шуклыклары шикелле, күбесе күңелдә эз калдырмый узып китә иде. Байтак еллар узып, байтак сулар агып, менә хәзер йөзгә-йөз очрашкач кына, ул Сашканың абыйсы Мукден тирәсендә һәлак булуын, малайның шуннан соң Винклер заводында слесарь,

Наумов тимерчелегендә ярдәмче вазифаларын башкаруын, хәзер менә типографиядә кургашын тузаны йота-йота хәреф җыюын белеп алды. Картайган әнисен, инде күптән таушалган әбисен тәрбияләүне дә кайгыртырга мәҗбүр икән ул. Гаилә терәге. Мондый егеткә сабыр, тыңлаучан булу кирәк иде. Әмма яшьли төрле хезмәттә ватылган, сәламәтлеген дә какшатырга өлгергән Сашка үзен авызлыклап тота алмый, мастерга кайнарланып кирәкмәгәнне дә ычкындыра, аны «сателлит» дип атый иде.

Габдулла цехтан кәнсәгә менгәли, «Уралец» редакторы юкта, алар Камил белән гәп корып алалар.

— Мин әле һаман үземне малай-шалай итеп тоям,— ди ул, иптәшен бүлеп.— Ә яшьтәшләрем бер сынык ипине кайгыртудан гаҗиз, шул гамь аларны түбәнсетә, вакытыннан элек картайта икән. Алар шушы караңгы подвалда иске машиналар дөбердәвен тыңлаудан, сасысын иснәүдән һәм сөремен үпкәгә утыртудан бүтәнгә лаек түгел микәнни?

— Шартлары начар, билгеле, монда да искене яңартасы бар. Әнә, Ибнәминев яңа җиһаз кайтартып, заводын үзгәртеп кора икән. Син барып карап кайтсаң да ярар иде. Күз алдында милли промышленностебыз тернәкләнә ләбаса. Без бу турыда язып та чыгарбыз әле. Һичшиксез!..

Ул иртәгесен үк әлеге заводка юнәлде. Шакшы ишегалды, җиргә чүккән озын һәм тәбәнәк саман корылмалар, сасы тире төялгән шыгырдавык арбалар — монда барысы да элеккечә үк иде. Хикмәтне эзләп тапкач, ул иптәшенең үзенә гаҗәпләнгән һәм өнәмәгән караш ташлавын абайлады. Шулай да дусты, тачкасын җиргә куеп, шырпылы төстә: «Сәйран чигүләр күңеллеме соң?» — дип эндәште. Шул минутта ук мастеры кычкырып кисәтү ясагач, ул ачу белән: «Ярар, гәп корырга бүтән вакыт табарбыз әле»,— дип өстәде дә үз юлыннан китеп барды.

Хикмәт иптәшләре белән тачкада тире ташый, аларны киң чандагы сасы, пычрак известь сыекчасына бушата иде. Икенче чокырдан инде берничә көн эремәдә яткан тиреләрне сөйрәп чыгаралар да цехка алып барып, салкын суда чайкыйлар, тирене ярысыннан арындыралар иде... Хуҗаның заводны яңартасына һәм шул яңарту йөзләгән михнәт чигүче эшченең хәлен кискен җиңеләйтәчәгенә Камил чынлап ышана микәнни соң?

...Җаек елгасы буендагы Хан куаклыгында, кала халкы чәйләр кайнатып ял итәргә, күңел ачарга яраткан җирдә, маевка уздыру билгеләнгән иде. Габдулла төшкә таба шунда очрашу хакында Хикмәт белән алдан ук вәгъдәләшеп куйды. Шуңа күрә иртән бик ашыкмады — тынычта әйбәт языла иде.

Бер дә көтмәгәндә Камил килеп керде. Дулкынланган, баскан җирендә тик кенә тора алмый.

— Урамда мәхшәр. Бөтен шәһәр Олы Михайловская урамына агыла.

— Аю биетәләрме әллә?

— Шул гына булса иде,— дип көрсенде Камил.— Кара әле, бүген полицейский кермәдеме монда?

— Юк. Тиеш идемени?

Камил, кичә атасы янына жандарм килеп, шәкертләрне фетнәчеләр җыенына барудан тыярга киңәш итүен сөйләп бирде. Тәртипсезлек чыгарулары мөмкин, имеш. Типография хуҗасы буларак аны да кисәткәннәр икән.

— Әллә нинди буталыш шунда,— диде Камил өметсезлеккә бирелеп.— Урамда — казаклар. Типография эшчеләре өйдә генә утырмаячак инде, әлбәттә, ә җавабын миңа тотарга туры киләчәк. Эшчеләр фетнә күтәрергә маташса, тәртип урнаштырачакбыз, дип талчукчылар яный тагын.

Алар урамга чыккач ук, бер якка таба гына агылучы шау-шулы чуар төркемнәргә тап булдылар. Ука белән чигелгән камзуллы, түбәтәйле берәү юлдашларына:

— Җәмәгать, тыныч җыен ясау, сүз дә юк, кирәк кирәген. Әмма мөселманнарга аны аерым уздыру фарыз,— дип мәш килә иде. Чатта басып торган городовой акаеп карауга, ул ашыга-кабалана пышылдауга күчте...

Халык арасыннан «Хезмәт бәйрәме — Беренче май яшәсен!» дигән язулы комач күтәрделәр. Төркемнәр бер-беренә кушылып һаман зурая, ыгы-зыгы тагын да көчәя төште. Ул да түгел, халык билгеле бер тәртипкә килеп атлый башлады. Юксыллар шигаре язылган комачлар янә күтәрелеп, алар артыннан саф-саф механика заводы эшчеләре, мехчылар, күнчеләр, депо, типография һөнәрчеләре куаклыкка таба юнәлде.

...Габдулла аланга барып җиткәндә митинг башланган иде инде. Ул, ары-бире сугылып, тыгыз сафлар эченнән Камилне эзләде, әмма врач Шәриповка очраса да, иптәшен таба алмады. Аңа Моргулисның: «Үгетләп тә, көч кулланып та эшчеләрнең гадел һәм катгый таләпләрен кире кагу барып чыкмас... Матди дәгъвалардан тыш сәяси...»— дип кайнарланып сөйләгән нотыгы түгел, «Тормышыбыз хәсрәт эчендә үтә. Без ул хәсрәт, газапларга шулкадәр күнектек»...— дип башланган чыгыш ныграк тәэсир итте. Чөнки аны Юныс абыйсы сөйләде. Башта ул үз колагына, үз үзенә үзе ышанмый торды. Аннары: «Их, Камил ишетсә иде бу эшченең сүзләрен»,— дип уйлады.

Аның хезмәттәше Саша һәм тагын берничә егет исә митингтагыларга листовкалар таратып йөри иде. Габдулла саргаеп кипкән былтыргы үләннәр өстеннән атлый-атлый каенлыктан сөзәк яр буена килеп чыкты. Өенә кайтып җиткәч, бер ятты, бер кире торып утырды, әмма нигәдер башына юньле фикер килмәде. Кичен, әле һаман тынычлана алмаган хәлдә, Камилләргә китте. Иптәше үз бүлмәсендә ялгызы гына чәй эчеп, тәмәке тартып утыра иде.

— Әткәй чирләп түшәккә егылды, хатын-кызларыбыз чигү чигеп маташа. Ә мин менә күрәсең ич...— диде ул.— Син теге җыенга чыктыңмы?

— Әйе. Миңа да чәй яса әле.

— Майда элек мондый эсселәр булуын хәтерләмим,— диде ул тулы касәне Габдулла алдына куеп.— Мине бүген Мортаза бай шаккаттырды әле. Күпердә этеш-төртеш, ыгы-зыгы башланганда гына яныма килде дә киңәшләшкән төсле сөйләнә башлады: «Сугыш-талашлар да чыгарырлар ахры. Юләр Котбый да иректә йөри икән, әләм-әтрәкләргә бәйләнер өчен сез сылтау бирмәссез лә инде, иншалла»,— дигән була.

— Акчам янмагае, дип куркадыр, әҗәткә керден ич үзенә.

— Миңа ул, бичара, халыкны кызгана, өметебезнең эшкә ашуын кайгырта сыман тоелган иде.

— Төкерә ул безнең мәнфәгатькә.

— Әйе шул, син хаклы.— Камил ялагайланган шикелле ашыгып Габдулланы җөпләде.— Алар минем алда күз буяудан, хәйләләүдән башканы белмиләр дә ич.

...Октябрь уртасы, урамда тузан, коры суык. Күңелсез чак. Әмма шәһәр, бәйрәм җиткәндәй, шау-гөр килә. Шәхес кагылгысызлыгына нигезләнгән чын хөррият, шуны игълан иткән патша манифесты турында төрле-төрле гәпләр яңгырый. Манифестта Дәүләт думасын чакыру турында да игълан ителгән иде. Галиҗанап хәзрәтләренең бүтән фәтвалары кебек, бу манифест та халыкка ихтирам һәм өмет, шатлык һәм яңалыгы йөрәккә бераз шом салган кызыксыну хисләре уятты. Хәтта большевиклар листовкасы да бу вакыйганы революциянең җиңүе дип таныды.

Октябрь азагында Камил Казаннан хәрефләр алып кайтты... Ноябрьдә шуннан ук хәреф җыючы Сафи белән матбагачы Гариф күчеп

килде. Матбагачы өлкән яшьтә, бөкре, русча киенгән, әмма башына түбәтәй чәпегән, йөткерә һәм өзлексез тәмәке тарта торган, сүзгә саран бер кеше иде. Яшь-яшь, ялтырап торган зур күзле, аксыл чырайлы, шат күңелле һәм аралашырга һәвәс тәвәккәл Сафи беренче көнне үк барлык эшчеләр белән танышып бетте. Җанланып Казан хәлләрен сөйли башлагач, Камил аны йомшак кына тыеп:

— Житәр, житәр, халыкны әгъвалама,— диде.

— Сыйныфташларының ничек көрәшүләрен белсеннәр әле.

— Көрәшеп туйганнардыр инде.

Чыннан да, хәзерге хисләр бәрелеше хөррият китергән давылның соңгы талпынуы шикелле тоела иде.

...Үз газеталары басылган төнне алар Камил белән редакциядән кайтып та тормадылар. Ядринцевтан калган кабинетта өстәлгә таянып черем итеп утырган иртәдә Сафи дөбер-шатыр йөгереп газетаны китереп тоттырды. Күнегелгән буяу, кургашын, керосин — тулаем типография исләре борынны ярып керде дә бөтен нерв очларын рәхәт-рәхәт кытыклады, бер-берсенә үрелеп ак кәгазьгә төшерелгән кара хәрефләр сокланырлык матур күренде. Габдулла, Камил җилкәсе өстеннән сузылып, беренче мәртәбә газетада басылган үз шигырен укыды:

Кайда китте цензурлык,  
Коллык, тарлык, ким-хурлык?  
Артка карасак борлып,  
Ерак анлар калдыя...

Беренче санны әзерләгәндә Камил үзләре сайлаган мәсләкне, тоткан юлны белдерә торган үткен бер нәрсә җитмәвенә борсаланган иде. Әгәр беренче битнең уңъяк почмагына Габдулла шундыйрак бер шигырь язып куйса иде... Язды Габдулла. Бу газетаның чыгуы һәм, гомумән, быелгы вакыйгалар аны да дулкынландырган, хәлләр яхшыга үзгәрер ахры, дигән өмет аның күңелендә дә канатлана башлаган иде. «Күп яшь егетләр үлде, Мәетләр дөнья тулды, Шәкерт, студент — бары, Дарга асылганнары,— Сез бу арысланнарый Онытмагыз тидия». Хөррият намына күпме кыю йөрәкләр, күпме якты башлар корбан булды. Бушкамыни болар барысы да?

Экспедитор килеп җитүен генә көтеп алдылар да, аңа бөтен тиражны язылучыларга җибәрергә кушып, өйгә кайтып китәргә килештеләр.

— Йокларга. Йокларга! — диде Камил исерекләрчә татлы елмаеп.— Без әйбәт кенә эшләп алдык сыман. Кичен Нәбиулла ресторанында җыйналырбыз, үзем сыйлаячакмын. Анда музыка да уйный диләр. Менә шул. Ә хәзер — йокларга. Йокларга!

Кичен Камил, Габдулла, Сиражи һәм Миңлебай, извозчик яллап, Мәгъмүриягә киттеләр. Нәбиулла ресторанының икенче катына менгәндә баскычтан ук күңелле «Әпипә» ишетелде. Кара сөякләрнең садә генә көе күтәренке марш кебек яңгырый иде.

— Уһу, монда бөтен Җаек каласының каймагы җыелган икән ләбаса,— дип куйды Камил залга килеп кергәч.— Әйтерсең лә манифис байларга музыка тыңлауны йөкләгән.

Нәбиулла нәшир Камил Мотыйгыйны һәм аның иптәшләрен үзе каршы алды. Музыкантлар яңа көй уйный башлады.

Каз канаты кат-кат була,  
Ир канаты ат була.  
Чит җирләрдә күп йөресәң,  
Туган илең ят була.

Миңлебай, иптәшләренә ишетелерлек итеп, әнә шулай музыкантларга кушылды. Габдулла аны үсендереп, ягымлы караш ташлады. Ул арада өстәлгә пылау килде, мәҗлес торган саен күңеллерәк була барды. Әмма Миңлебайның һаман үз кайгысы кайгы иде.

— Җәмагать,— дип мөрәҗәгать итте ул,— безнең мәдрәсәдә ятуыбыз моңсу, эчпошыргыч бер нәрсә түгелмени? Ләкин бүтән кая барыйк соң? Бәлки безнең өчен дә ниләрдер үзгәрер, ә? Элек менә мөселманнарга беркайда да уйнау, җырлау рөхсәт ителми иде ич. Бәлки ходаның ярдәме белән кайчан да булса үз театрыбыз да барлыкка килер? Аһ, сәхнәдә уйнар өчен мин теләсә нинди корбан бирер, хәтта мәңгелек фәкыйрьлеккә дә ризалашыр идем!

Ул арада ресторанның калкурак түренә Нәбиулла хуҗа үзе күтәрелде. Нотык сөйләргә иде ахры исәбе.

— Җәмагать! Күп михнәтләр чиккән милләтебезнең хакын даулауда олуг тырышлыклар куйган өчен, сезне ихлас сәламләргә, сезгә рәхмәтләр яудырырга рөхсәт итегез. Хөрриятнең тамчысы да озак еллар тоткынлыкта боегып гомер сөрүдән артыграк, җыр — күз яшьләреннән... Шушы җиңү, шушы шатлыкларыбыз шәрәфенә... Менә хәзер без мөселманнар да Аурупа ханәләреннән калышмаслык үз милли рестораныбызга ия. Ур-ра, җәмагать!

— Мөхтәрәм Нәбиулла әфәндегә ур-ра! Милләтебезнең шанлы улларына ура! Ходай тәгалә, патша хәзрәтләре вә тәхет варисы шәрәфенә шампан ширбәте... Бөек Болгар намына!

Бу кичәдә дә, башка көннәрдә дә Габдулла торган саен үзен били барган алдану хисеннән арына алмый аптырады. Мондый ваклыкны һәм этлекне ул хәтта каешланып беткән сәүдәгәрләрдән дә көтмәгән иде. Манифест, хөррият һәм Нәбиулланың харчәүнә ачуы... Тфү! «Кайда китте цензурлык, Коллык, тарлык, ким-хурлык? Артка карасак борлып, Ерак анлар калдыя»... Шушы юлларны әле бер атна элек кенә Габдулла үзе язды лабаса.

...Торак караңгылыгыннан, кар баскан урамнар караңгылыгыннан — типографиягә, керосин сөреме чыккан, хәреф кассаларына лампа яктысы төшкән бүлмәгә!

Ул кулына алган хәрефләр тиешле урынына тезеп куйганчы җылынып өлгерә һәм, уч төбендә тармакланган сызыкларны хәтерләтеп, үрмә рәсем хасил итә иде. Сүзләргә җыйналгач ул шулай ук язмыш турында сөйли иде. «Безнең милләт үлгән үкме, әллә йоклаган гынамы? Үлмәгән дә, йокламаган да, фәкать һушы китеп егылган. Аны һушына китерү өчен, милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, газитә җилпәзәләре илә йомшак җил истерик һәм авызына берләшеп эшләү сулары салыйк; җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик, тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын». Ул язудан күзен ала да үзалдына елмаеп куя, аннары моңсулана. «Бәянелхак» карагруһлары моңа ачулы мәкалә белән җавап бирми калмас инде.

Газета аңа бер генә минутка да тынгылык бирми иде: әле заводка бара, әле сәүдә клубына йөгерә, әле ятимнәр йортына яки җәмгыяте хәйрия көтепханәсенә ташлана, аннан бушаган чакларда кәнсәгә күтәрелә дә газетага диген язмаларны басмага әзерли башлый. Хатлар да муеннан: җәмгыяте хәйрияләр, байларның юмартлыгы турында дисеңме, кызлар гимназиясе ачу яки җәмгыятьтәге хатын-кызлар хәленә багышланган трактатлар, милләтпәрвәр рухтагы шигырь, такмазалар, реклама... Кайбер хатлар фельетонга менә диген азык бирерлек. Мәсәлән, Хисаметдин исемле берәүнең фирмасы «Исмәгыйль Гаспринский» исемле хушбуй һәм сабын житештерә башлаган. Бакчасарай эшлеклесе үз исеме белән сабынчылар сәүдә итүен беләме икән? Ә менә бер акыллы баш сабынга, «шәригать буенча кайнатылды» диген язу төшерүне тәкъдим итә, югыйсә ул аны сатып алмаячак!

...Көн туа. Лампа исә һаман яна, тик аның яктысы торган саен зәгыйфьләнә бара сыман. Ә менә аның куык эчендәге ялкыны куера башлый — кич җитә, буранлы эңгердә урам буйлап йөгерергә, өйгә кайтып чәй эчәргә дә киез түшәлгән сәкегә авып, минуты белән йокыга

китәргә вакыт. Сөенечле мәшәкатьләре аны тулысынча биләп ала, ял итәргә дә, төрле мәҗлесләрдә катнашырга да мөмкинлеге калмый, тик ул моңа һич тә сыкранмый иде. Мотыйгулла хәзрәтне ул элеккечә үк хөрмәт итә һәм ярата, ләкин аның хәлен белешергә дә бик сирәк кагыла. Карт мөдәррис шәкертенең үзеннән ерагая, ятсына баруын тоя, әмма Габдулла килеп кергән чакларда үпкәләвен горур рәвештә үз эченә яшереп калырга тырыша. Җанланып китә дә шаярта, хәлләрен сорашырга тотына.

— Искечә яшим, хәзрәт. Типографиягә барып яңа һөнәрләр өйрәнәм.

— Һәйбәт,— ди ул тыныч кына,— егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

Габдулла шунда язылып, чишелеп китә: үзенең инде күптән мөстәкыйль хәреф җыюын, басучыны да алыштыруын, кәнсә эшләрен дә алып баруын, һәр санга мәкаләләр дә язуын сөйли. Камил аның айлыгын күтәрүен, хәзер сигез урынына унике тәңкә алганлыктан, хәленең җиңеләюен дә белдерә.

Карт мөдәррис йөзен чытыбрак:

— Кара әле, сиңа күпме түләргә кирәклеген мин Камилгә төгәлләп әйткән идем ләбаса,— ди.

— Юк, юк, миңа җитә, хәзрәт,— ди Габдулла елмаеп.

Дөнья мәшәкатьләренә чуму дамеллага әллә ничек килешеп бетми иде. Әдәпле җитдилеге, мәһабәтлеге аңардан күңел азыгы булырлык бирәр зирәк, гыйбрәтле сүз ишетү теләге уята, шуңа ымсындыра иде. Хәер, менә шундыйрак өметне акларга теләгәндәй, бервакыт Габдулланың соравына Әл-Мәгарри сүзләре белән:

> Укыганда дөнья гаме биләсә,
> Зиһеннәрен кечеңең һәм өлкәннең,
> Әнә шул гамь очкын чәчеп дөрләсә,
> Икеләнми ябып куйыйк корьәнне,—

дип җавап бирде. Аннары ул, мәхәллә халкының китап сүзен җай белән миенә сеңдерүенә күнеккәнлектән, сүзләрен салмак һәм уйланып кына дәвам итте: — Адәм баласына чыдамлык һәм тырышлык кирәк, шул чакта раббыбыз байлык та иңдерер. Миңа менә шуны һәрвакыт тукырга кирәктер, бәлки. Син менә яшәешеңнең мөстәкыйль юлына аяк бастың, улым. Үз мавыгуларыңның колына әйләнмә, намусың һәм абруең турында ешрак уйла. Мин белгәннәремне сиңа өйрәтергә тырыштым. Хәзер инде...— Ул уйга чумып тәрәзәгә — зәңгәрсуланып баеган кызгылт шәфәкъка, хәзрәте Гали каны төсе кергән карлы урамнарга, изге догаларга мохтаҗ җиһанга текәлеп тынып калды.

Карт белән сөйләшүләр күңелдә нинди дер әрнү калдыра, әмма аның бу хистән арынасы килми иде. Мондый сәгатьләрдә күп язылмый, язылган кадәресе сагышлы килеп чыга, әмма шул юлларны соңыннан тынычрак халәттә бизмәнләгәндә, яхшы ләбаса бу, дигән фикергә килә иде. Кайчак аңа үзе дә, бөтен язмышы да кызганыч тоела, тик бу тойгыдан бер генә шигырь юлы да тумый иде. Үзен кызгану хисе аңа беркайчан да ярдәм итмәде, ул моны искиткеч серле иҗат шатлыгын татыганчы ук ачыклаган иде инде. Шул хакыйкать аны башка хисләргә бирелергә, бүтән борчулар, бүтән хәсрәтләргә чумып яшәргә этәрмәде микән?

Типография эшчеләре хәвефле әңгәмәләр алып бара башладылар. Тик хәзер инде ерактагы вакыйгалар турында гына түгел, үз хәлләренә нәфрәтләнеп. Типография хуҗасыннан айлыкны арттыруны, сигез сәгатьле эш көне кертүне һәм елына ике атналык түләүле ял бирүне таләп итәргә булдылар. Моны кәгазьгә яздылар да туп-туры хуҗага мөрәҗәгать итәргәме, әллә забастовка ясаргамы дип киңәштеләр. Кыюраклар Винклер заводы һәм депо эшчеләренә кушылып баш күтәрергә

өндәде. Саграклары, бәлки ул хуҗа белән сөйләшсә, һәммәсе дә җайлы гына хәл кылыныр дип, Габдуллага мөрәҗәгать итте.

Ул ризалык бирде. Әмма Габдулла иптәшләре гозерен әйтүгә, Камил чыгырыннан чыкты:

— Син... син миңа эшкә кергәндә сигез тәңкә генә ала идең, ә хәзер егермене ләбаса! Мин сиңа айлыкны гел арттыра килдем түгелмени?

Габдулла, теле кычытып торса да, «мин әүвәл хәреф җыючы гына идем, ә хәзер кәнсә хезмәткәре дә, экспедитор, корректор һәм каләм иясе дә» дип аңлатып маташмады.

— Гафу ит,— диде ул сабыр гына,— мин үзем турында түгел ләбаса. Эшчеләр көненә уникешәр сәгать кургашын тузанын йота, ярым караңгыда күз нурын түгә, ләкин шуның өчен тиеннәр генә ала.

— Бәлки алар баш күтәрергә җыенадыр? — диде Камил буылабуыла.— Әй, шайтаныма олаксыннар ла. Алар минем милләт өчен эшләвемнең, безнең бергәләп шуның намына тырышуларыбызның кадерен беләмени? Ә син үзең, гафу ит, алар алдында әйле-шәйлерәк телеңә салынмадыңмы икән?

Габдулла, ләм-мим эндәшми, бүлмәдән тышка чыгып китте...

Ниһаять, ишелеп-ишелеп кар яуды — шәһәрнең барлык шакшысы, чуар шаламалары ак җаймә астында калды. Ямьсез һавалы көзнең холыксыз җилләре бары шуннан соң гына ак мамыктай кырларга ятып тынычланды.

Табигатьтәге мондый күптән көтелгән үзгәрешләр кешеләргә дә сәер һәм кискен йогынты ясый, ничек тотынырга, дип баш ватып, өркеп яки иренеп һаман кичектерә килгән эшләренә алар хәзер җиңел генә алынып, сөенә-сөенә бер сулыштан башкарып куялар. Аларның да шулай булды. Тыштан карга батып кергән Миңлебай тәвәккәл төстә: «Бүген кунакханәгә күченәбез, сау бул инде, мәдрәсәкәй, көенечле оябыз!» — дип кычкырып җибәрде.

Шушы минутта ук барлы-юклы милкен алып, кунакханәгәме, бүтән берәр җиргәме күчеп китәргә үзе дә әзер Габдулла:

— Ә нигә нәкъ менә бүген? — дип гаҗәпләнде.

— Тышта бар тараф ак,— дип елмайды Миңлебай.— Кар ява, күңелне әллә нәрсә җилкендерә, рәхәт. Сиражи да шулай юләрләнә. Я, бер, ике, өч!

Дәррәү тегене-моны эләктерделәр дә урамга чыктылар. Кибетләр яныннан, кар яткан киң мәйдан кырыеннан узып — бөтен шәһәрне кичеп, аның Бохара очында әле күпән түгел генә ачылган «Казан» кунакханәсенә килеп җиттеләр. Сизелер-сизелмәс зәңгәрлек өретелгән якты көн күзләрдә чагыла, чәнечкеле салкын саф һава күкрәккә тулып, йөрәкне дәртлерәк тибәргә мәҗбүр итә иде.

Кунакханәнең маңгаена беркетелгән зур-зур хәрефле «Казан» дигән язу әллә кайдан балкып, үзенә чакырып тора. Әнекәй генәчем, син дә, салкын кояш та, бала-чага шау-гөре дә бар икән ләбаса бу мәшәкатьле дөньяда! Бер абзыкай тротуарны себереп маташа. Көртләр өстеннән зәңгәрсу очкыннар йөгерешә, алар әлеге абзый күләгәсендә дә сүнеп бетми, азрак карала да барыбер көндезге ялтыравы белән күз явын ала. Кардан тазартылган такыр юл слюда сыман саргылт пыялалы ишекләргә кадәр алып бара.

Кизү торучы үсмерләрне өске катка ияртеп менде. Сиражи белән Миңлебай — икесе бергә, Габдулла исә аерым бүлмәгә урнашты.

— Монда сезгә тыныч, әйбәт булачак,— диде кизү.— Гыйнварда Гурьевтан олаучылар килеп, бераз шау-гөр чыгарып, типтереп алыр, шуннан соң мосафирханәбез янә аулак калачак.

Габдулла аның сүзләренә колак та элмәстән, бүлмәне караштырды. Иң кирәге — өстәл бар икән, аны тәрәзә буенарак күчерү яхшы. Хөҗрәсендә калган китап-кәгазьләрен дә алып килсә, нәрсәсе ярамаган?

йокларга караваты, утырырга урындыклары бар лабаса. Бүлмәсе хәйран җылы икән. Әле һаман чишенмәстән, икә бүлмә аша күршедә урнашкан дуеларына йөгереп керде. Сиражи белән Миңлебай шундук таралып ятакка ауганнар, төшкә кадәр ял итәчәкләрен, бары кичен генә, ихтимал, урамга чыгачакларын белдерделәр.

— Ятыгыз алайса. Ә мин һавага чыгам әле.

Ул Олы Михайловская урамына таба атлады. Бернинди йомышсыз, көне шундый әйбәт булганга гына!

...Күн заводы эшчеләре менә икенче көн инде эшкә чыкмый, диган хәбәрләр ишетелде. Тегермәндә һәм Винклер заводында да шундый ук тәртипсезлекләр имеш. Әмма типографияне берәү дә алай телгә алмаган иде. Шуңа күрә матбагачылар забастовкасын берәү дә көтми иде. Очраклы рәвештәме, юкмы — аларның баш күтәрүе Винклер механиклары һәм депо эшчеләренеке белән бер көнгә туры килде.

Габдулла бу көнне, ниһаять, «Ачлык-патша»ны тәрҗемә итеп бетергән һәм аны Камилгә укытырга теләгән иде... Әмма хуҗа кәнсәгә ачулы хәлдә килеп керде. Тирләгән, күзләре очкынланган, туны җилбәгәй җибәрелгән, бүреге бер якка кыйшайган.

— Син инде беләсеңме?.. Оятсызлар! — диде ул һаман тынычлана алмыйча.

— Берни белмим, бары чамаласам гына инде.

— Уйлавымча, син миңа караганда күбрәкне чамаларга тиеш.

— Ихтимал.

Шулчак ишек шакып, бүлмәгә типография эшчеләре Сафи белән Сластин килеп керде. Кыяфәтләре тантаналы, йөзләре кырыс.

— Без сезгә петиция китердек,— диде Сафи.— Аңа кул куймаучыларның забастовкага катнашы юк.

— Бирегез соң, нәрсә таптанып торасыз? — диде Камил көлемсерәп.

Сафи вәкарь белән якынлашты да кәгазен өстәлгә куйды. Аны алыр өчен Камилгә урындыгыннан кубарга кирәк иде. Ләкин ул кузгалырга уйламады да. Бераз карап торгач, нык тавыш белән:

— Кызганыч, мөхтәрәм әфәнделәр, мин ул таләпләрегезне канәгатьләндерә алмыйм. Башка сүзем юк! — диде.

Сафи белән Сластин мыштым гына чыгып киткәннән соң, Габдулла кәгазьне үзенәрәк тартып укып чыкты да:

— Мин бу таләпләрдә акылга сыймаслык берни дә күрмим,— диде.

— Алар ялгыз баш күтәрми,— диде Камил карлыккан тавыш белән.— Винклерныкылар... депоныкылар да... сүз берләшкәннәр, таләпләре дә уртак, петицияләрен укымасам да, беләм ул юньсезләрне.

Алар текә баскычтан цехка төштеләр. Эшчеләр, бергә укмашып, Сластинны тыңлый иде. Хуҗа күренгәндә генә алар шаулашып көлеп җибәрделәр.

— Я сез кичекми эшкә тотынасыз!..— дип кычкырды Камил,— яки котыртучыларның барысы да шушы минуттан эштән чыгарыла!

Ул кискен борылды да, ишекне шапылдатып, цехтан чыгып китте.

Габдулла кәнсәгә әйләнеп кергәндә, Камил диванда утыра иде. Туны белән бүреге дә шунда гына салып куелган. Ул иптәшенә эчкә баткан күзләре белән карап:

— Син алар белән сөйләштеңме? — дип сорады.

— Камил,— диде Габдулла йомшак кына,— аларның таләпләрен канәгатьләндерергә туры килер. Әзне генә, кирәген генә үтенәләр лабаса.

Камил тиз генә җавап бирмәде. Аннары нәрсәнедер искә төшергән рәвештә тигез тавыш белән:

— Беренче тапкыр ишеткәч, минем исем китте,— диде.— Әллә куркудан гына шулай тоеламы дип торам. Хәзер аңладым инде, юк икән.

«Уралец»та халыкның яртысы сайлау хокукыннан мәхрүм, ителүе, советларның вакытлы революцион хөкүмәт вазифаларын башкара алуы турында язып чыккач, мин инде эзәрләүгә, яла ягуга һәм хәтта кулга алуга да әзер, бернидән дә курыкмас хәлгә килгән идем. Ә хәзер мине «саттылар» дигән фикер таң калдырды. Рус эшчеләре эш ташлавын аңлыйм мин, әмма үзебезнекеләрне...— Ул тынып калды, аннары сагыш, хәсрәт эчендә өстәде: — Безне хыянәт үтерәчәк!

— Бернинди хыянәт юк,— диде Габдулла.— Чөнки бай белән ярлы бергә була да алмый, изелүчеләр белән...

— Аңлатма,— диде Камил чыраен сытып.— Занһар дәвам итмә. Алдандым мин, хыянәт...

— Юк ла инде! — диде Габдулла үзсүзләнеп.— Хыянәт чыкмады, чөнки син күзаллаган бердәмлекнең булганы да юк. Нишләп әле син шуны аңларга теләмисең? — һәм ул ягымлы, хәтта җылы кайгыртучанлык белән дәвам итте: — Ышан, безгә болай да кыен чакта мин һич тә моның хәзер булуын теләмәгән идем. Әллә эшчеләр белән сөйләшеп карыйммы? Алар мине тыңлар, эшкә тотынырбыз. Ул таләпләрне без соңрак кузгатырбыз.

— Соңрак? Шуны укмы? Син дә «без» дип авыз ачасыңмыни инде? — Камил яман да рухы төшеп һәм үпкәләп, үзен-үзе белештерми: — Кирәкми ярдәмең! Башка җирдә теләсәң нишлә, тик монда, миндә — кирәкми! — дип кычкырып җибәрде.

Габдулла авыз күтәреп бүтән бер сүз әйтмәде, шунда ук торып киенә башлады. Кесәсеннән килеп төшкән «Ачлык-патша» кулъязмасын идәннән иелеп алды да кәнсәдән чыгып китте.

...Ишек шакыган тавыштан сискәнеп, ул язулы кәгазьләрен өстәл тартмасына сыпырып төшерде һәм канәгатьсез караш белән бүлмәсенә килеп кергән Миңлебайга төбәлде.

— Берәр нәрсә булдымы әллә?

— Камилне... нәширлек хокукыннан мәхрүм иткәннәр.

— Тикшерү бетмәгән иде ич әле. Ничек җөрьәт кылдылар икән? Син Камилне күрдеңме соң?

— Юк. Хәзер аның кайгысы миндә түгелдер әле.

Камил белән Миңлебай бәйләнешләрен өзмәгәннәр иде. Бу Габдулланың эчен дә пошыра, әллә ничек сөендерә дә: яхшы күңелле сабыр Миңлебай әле аларны тоташтырып тора, бәлки шушы буын дуслыкны тәмам җуеп бетермәскә булышыр?

Нишләргә соң? Миңлебай тиз генә Камилне күрергә йөгерсен әле, хәлләрне җентекләп сорашсын, бәлки берәр ничек булышырга мөмкиндер? Их, әгәр аның акчасы, бик күп акчасы булса иде...

— Камилне эзләп тап әле син,— диде ул дустына.

— Өендә юк, Мортаза байларга киткән. Ашыгыч төстә типографиясен һәм газитләрен сата икән.

— Сата?

— Нәширлеккә хокукы калмагач, нишләсен инде алар белән?

— Әмма... Мортаза Гобәйдуллингә генә димәгәндер ич? Әлбәттә, юк! Ул акча сорап торадыр. Бәлки вице-президентны майлап котылырга мөмкиндер?

— Белмим.

...Үз хәлләре дә торган саен авырая барды. Февраль азагында кесәсе тәмам такырайды, хәзер инде көндезге аштан да тыелып, ипи белән чәйгә генә күчтеләр. Миңлебай ара-тирә кунакханәдән юкка чыга һәм бер таңкә-таңкә ярым керем ясап кайткалый иде. Бай йортларда коръән укуын ул бары соңрак кына танырга мәҗбүр булды.

— Әйтәсем килмәгән иде моны,— диде ул дустына.— Синең җенләнүең дә мөмкин ич.

Габдулла шаярган төсле:

— Булачак артистны репетиция ясаудан ничек тыясың инде? — дип кенә көлемсерәде.

Мартта ул Оренбурдан, нәшир Кәримидән үз журналларына язышуны тәкъдим иткән хат алды. Җаекта газета белән журнал бастыру тукталмады, әмма, я хода! — андагы һәр язманы Мортаза әфәнде үзе карап чыга, әгәр берәр четерекле нәрсә күрсә, язмаларның теләсә кайсын кире бора иде. Типографияне сатып алуына үкенә дә башлаган имеш. Сәүдәгәрләрнең барысы да шундый: меценат булып бераз кылана да бик тиз куләгәгә посалар.

Минлебайдан башка хет тәгәрәп үл! Ул үзенә тагын бер һөнәр — китаплар сатуны өстәде. Камилнең китап кибете дә бар иде. Хакимнәр аны да япкач, Камил үзенең элекке шәкертеннән калган китапларны уртагыннан сатып бирүне үтенде. Миңлебай көн саен бистәгә, базарга теркелди, әмма китапка бик ябырылмыйлар, шулай да чәйлек-шикәрлек мая җыйнала иде.

Камилне тикшерүнең очы-кырые күренми иде. Әйтүләренчә, гаделлек эзләп, ул әле Казанга, әле хөкем палатасы урнашкан Саратовка сәфәр чыга иде.

Габдулла төннәрен эшләп, көндезен йоклый, аннары тиз генә урамга чыгып керә дә тагын язу-сызуына утыра. Кыска, тонык көннәр бербер артлы уза тора, салкын төннәрне исә ул абайламый да кала иде. Март азагында көрт өемнәре утырды, хәтта эреп юкка да чыкты, ләкин урамнар әлегә пычрак, изрәгән юлларны җайдаклар һәм җәяүлеләр тәмам эштән чыгарып бетергән иде. Төшкә таба язгы кояш юмартланыбрак елтырый, даладан саф җылы җилләр исә. Кичләрен әле шулай да салкынча һәм дымлы, аяк асты да туңа, пычрак куера, кайчак уалган боз тавышлары яңгырап китә иде.

...Әнә шундый кичләрнең берсендә Габдулла бистәгә, Юныс абыйларына юнәлде. Бу юлы ул хуҗаны шактый ябыккан һәм хәлсез, чирле кыяфәттә урын өстендә очратты.

— Ибнәминев локаут игълан итте,— диде ул яңалыкларны тезеп.— Завод ике атна эшләмәде. Күпләр аны үзләре ташлап чыкты, мин дә уйлаган идем дә... Кая инде хәзер. Бәлки, язын терелермен... Әгәр яшьрәк булсам, каладан ук китеп барыр идем әле.

— Мин дә китәргә телим моннан, Юныс абый. Казанга.

— Кит,— диде хуҗа гади генә.— Монда син артык күзгә бәреләсең, артык ялгыз тыпырчынасың.

Габдулла елмаеп:

— Качып киткәнгә охшар инде бу,— диде.

— Тагын да хәвефлерәк җиргә китмәсәң, шулай да тоелыр иде.

— Мин куркак түгел,— диде Габдулла.— Әмма җитдирәк эшкә ярыйммы, белмим әле.

— Син кеше хәсрәтен уртаклашырга һәвәс. Их, улым, кыенлыкларның олысы алда әле.

— Беләм. Тик сез минем өчен уфтанмагыз.

Чәйле чынаяклар тотып Сәрби апасы керде, табынга шикәр һәм хәтта май да куйды.

— Майны Нәфисә алып килгән иде әле. Кызыбыз, аллага шөкер, әйбәт урнашты,— диде, мондый байлыкны аңлатырга кирәк санап.

Кияүгә киткән! Габдулла, йөрәге чәнчеп куйса да, тыштан берни сиздермәде. Хәер, аның хисләрен өлкәннәр, гомумән, бар дип тә белмәде ич.

...Нәфисәне ул моннан соң беркайчан да күрмәде. Көннәр бер-бер артлы уза торды, табигать көзгә керергә әзерләнде — инде август азагы килеп җиткән иде. Габдулла исә әле һаман юк-юк та Нәфисәне уйлап өзгәләнде. Бичара, аны бит сайлау хокукыннан гына түгел, гаделсез-

леккә кайгыру хисеннән дә мәхрүм иткәннәр, чөнки ул үз язмышыннан газапланмый, тормышында бүтән юл булу ихтималын асла белми!

Китәргә интегеп йөргән көннәренең берсендә ул Казанга, нәшир Шәрәфкә хат язып салган һәм аңардан, өметле җавап белән бергә, илле сум аванс та алган иде. Монысы юлга дип карар итте ул. Әле берәр эше эшләнеп бетмәгән шикелле, аны нидер һаман Җаекта тота иде. Зарыгудан, икеләнүдән бөтен ихтыяр көчен җуеп, Габдулла үз-үзен авыру сыман тойды.

Их, тизрәк Кырлайга барып җитәргә иде аңа. Менә кайда әби-сәбиләр әллә нинди тылсымлы, мәзәк әфсеннәр белә, шуларны ишетү белән, ихтыярсыз көлеп җибәрәчәксең һәм үзеңне тап-таза кеше итеп хис итә башлаячаксың...

Ул быел язын, әнә китәм, менә китәм, дип саташып йөргәндә чыгарган бер шигырен исенә төшерде.

Хуш, гомер иткән шәһәр! Инде еракта калдыгыз,
Аһ! Таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз...

Бер тавыш килде колакка, яңгырады бер заман:
«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдымызда бит Казан»...

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан:
И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!

Шушы шигыре тәэсиреннән шатланган, күңеле әллә кайларда гизеп рәхәтләнгән бәхетле иртәдә аның бүлмәсенә кинәт Миңлебай килеп керде һәм күтәренке күңел белән:

— Танышырга рөхсәт итегез: «Сәйяр» труппасының артисты Габдулла Кариев,— дип кулын сузды.

— Чынлапмы, Миңлебай?

— Ярар, синең өчен мин Миңлебай булып калырмын инде. Ә башкалар өчен моннан соң мәңгегә — Габдулла Кариев. Синең хөрмәткә исемеңне алам, Габдулла. Фатиханы бир, башка сорар кешем юк ич минем...— ул яшьле йөзен аның иңбашына иде...— Рәхмәт, киттем мин, яңа юллар ачылуына шулкадәр куандым, көлкегә калудан гына шүрлим...

Габдулла ике көннән соң дустын күчмә труппа оешып яткан Казан каласына озатты. «Сәйяр»ның ни акчасы, ни даими бинасы булмаганлыктан, «күчмә» мәгънәсен белдергән исеме җисеменә бик туры килә иде.

...Хәзер инде менә чират аңа да килеп җитте. Габдулла, дога укыган кебек, эченнән: «И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!» — дип пышылдады.

...Вокзалдан ул җәяү атларга булды, әмма бик тиз адашып, ыгы-зыгыда каушап калгач, бер «барабыз»ны туктатты да «Йолдыз» редакциясе урнашкан урамга алып баруын үтенде. Анда Сәгыйть Рәмиев — туган әдәбиятында каләм кыштырдатучылар арасында шигырьләренең шомлы горурлыгы, байрончалыгы, хыялыйлыгы һәм тормышны көтелмәгәнчә искиткеч образлы гәүдәләндерүе белән аерылып торган һәм Габдулла хөрмәт иткән бердәнбер шагыйрь эшли иде. Пушкинның «Пәйгамбәр»ен тәрҗемә итүе аны шулай ук күңелгә якынайта иде. Халык төркемен ерып, бүтән экипажларны һәм хәтта трамвайны узып тарантаста барганда да ул шагыйрьнең юаш татар дөньясын тетрәндергән кыю, тәвәккәл юлларын кабатлады:

Масайма син, раббым! Кодрәтеңә,
Тартып алып ни бар бәхетемне...
Булыр бер көн: ватар, көл итәрмен
Гарше көрси, сәмаң, тәхетеңне!..

Кич җитеп килә, редакциядә ялгыз каравылчы гына торып калган иде. Ул Сәгыйть әфәндене «Болгар» кунакханәсендә табарга мөмкин икәнлеген әйтте. Шунда юл тотты Габдулла. Ишегән шакып килеп кергәч, караңгы коридордан соң бу бүлмә шактый якты тоелды. Төз буйлы, тар җилкәле, дулкынланып торган озын чәчле, киң маңгайлы хуҗа аңа ятсынып карап тора иде. Габдулла исәнләшеп:

— Сәгыйть әфәнде, мин сезгә Җаектан Камил Мотыйгый сәламен алып килдем,— диде.

— Ху-уш, сез аның шәкертеме?

— Дөресе, шәкерте дә, хәлфәсе дә. Мин сездән бер нәрсә белешмәкче идем. «Ачлык-патша» дигән бер тәрҗемәне күптән салган булсам да, сез аны басмадыгыз, җавап та бирмәдегез.

— Гафу, соң сез кем буласыз?

— Тукаев мин, хәтерләмисезмени?

— Соң, кергәч үк сүзне шуннан башласагыз ни була? Кашки элек очрашкан булсак... каршы алу да башкача булыр иде. Әй, Тукаев, Тукаев, без менә хәзер чәй янында иплән...

— Юк, юк,— диде ул,— мин тук, валлаһи, белешәм дә китәм.

Хуҗа ул арада лампа кабызды. Тәрәзә шунда ук тоныкланды, караңгы төшүе ачыграк сизелә башлады. Кая барып төртелер, төнне кайда уздырыр икән инде ул?

— Юләр сатмагыз,— дип көлде кырыс хуҗа.— Ерак юлдан туры монда килүегезне күреп торам ич мин. Барыр җирегез дә юктыр әле.

Җанланып китсә дә, Сәгыйть әфәнденең чәй ясаганда нидер уйлап торуы ачык сизелә иде.

— Мин бүген өйдә кунасымны үзем дә юньләп белми идем әле...

— Нәрсә, кулга алулар барамы? — дип сорады Габдулла гади генә.

— Сез дә мондагы хәлләрне ишеттегезмени?

— Ишетүен ишетмәдем.

Хуҗаның хәвефләнүе һәм нидер көтүе йөзенә бәреп чыккан иде. Шуңа күрә кунак, монда да тынычлык юк икән, дип уйлап куйды.

Казан тормышының өченче көнендә үк аны Миңлебай эзләп тапты. Җаекта аерылышуларына әле кайчан гына, ләкин никадәр үзгәреш. Пөхтә кара сюртук аны озын зифа буйлы күрсәтә, йөзе сулыккан, кыяфәтеннән олпатлык, илаһи яну, үз-үзенә ышану рухы бөркелеп тора. Узган айларны ул гастрольдә йөргән — Саратов, Самара, Әстерханда, Урал буенда һәм аннан да арырак Томскида булган.

— Менә шул соңгысында Камилгә килеп очрамыйммы!— диде ул.— Ышанасыңмы, ул да гастрольдә йөри икән. Җырчы! Концертларын губернатор тыйган. Җырчыбыз нишләргә мәҗбүр булган дип уйлыйсың? Кайтыр юлга акча юнәтер өчен өйдән өйгә йөреп коръән укый башлаган.

— Камил... Хафиз ролендәме? Юк, юк, мин бүтән нәрсә сорашырга теләгәм идем. Театр турында сөйләсәң, мөгаен, яхшырак булыр.

— Безнең труппа — мәңгелек сәйях. Берәр җиргә килеп җитәсең дә патша чиновникларының бусагасын таптый башлыйсың. Әүвәл рөхсәт аласың, аннары зал эзләргә тотынасың. Кайчак шундый хак билгелиләр — көчкә түләп бетерәбез. Казанда да хәлләр мактанырлык түгел. Гыйззәтуллина спектакльдән соң кайтып барганда, бер кичне каршысына Печән базары каһарманнары килеп чыга. Ярый әле якында гына будочник табыла. Әмма ничек кенә булмасын, театрыбыз яши! Их! Габдулла, безнең өчен гадәттән тышрак, «Шүрәле» кебек хыялыйрак берәр пьеса язсаң икән син. Башбаштак сәүдәгәр, әрсез приказчик, бичара кызларны — җыен көнкүреш драмаларын уйнау туйдырды инде.

— Галиәсгардән үтенегез, менә дигән драматург, хикмәт иясе.

— Кайвакыт миңа сәхнәдә бер генә рольне уйнау әз күренә. Бары шигырьләрдән яки поэмадан торган бөтен бер спектакль турында хыял-

лана башлыйм. Мин инде акренләп программа әзерли дә башладым, синнән дә әсәрләр көтәм.

— Белмим шул. Хәер, Кольцовтан тәрҗемә иткән «Мужик йокысы» бар ич әле минем, хәтерлисеңме?

— Юк инде, Габдулла, миңа бүтән берәр нәрсә кирәк. Сәгыйть әфәнденең яңа шигырен укыдыңмы әле син? «Мин»не!

«Мин!» димен мин, «мин» дидисәм,
Миңа бер зур көч керә,
Аллалар, шаплар, канУннар
Булалар бер чүп кенә...

Миңлебай, эчендәге ялкынны сакларга омтылгандай, ашыгып саубуллашты да бусагадан чыкканда:

— Репетициягә...— дип кычкырып, театрына чыгып йөгерде.

...Бертуган Шәрәфләр аның белән аеруча эшлекле бәйләныш урнаштырырга тырышты. Габдулла нәширләрне биздермәде, әмма ашыгып та төшмәде.

— Фарсы телен ничә айда өйрәнеп була? — дип сорады ул Борһаннан.

— Айда дисеңме? Шәрык телләре факультетында аны биш ел өйрәнәләр.

Габдулла кыенсынып, әмма бирешергә теләмәстән:

— Анысын беләм лә,— диде.— Әгәр мин ныграк тырышсам? Үзлегеннән тизрәк үзләштерүчеләр дә була ич.

— Андыйлар бик әз очрый.

Икенче юлы инде Габдулла мәсьәләне Борһан алдына кабыргасы белән куйды:

— Таныш профессорың белән күрештермәссеңме икән?

— Тел галиме эзлисеңме? Фатих белән киңәшергә кирәк аны. Мәдрәсәне ташлагач, ул Казанга сөрелгән социал-демократ Гассардан сабак алган иде.

— Миңа кемлеге барыбер. Җаекта чакта социал-демократларны үзем дә белә идем,— диде ул эре генә.— Гассарны кайдан таба алырмын икән соң?

— Аны былтыр кулга алдылар. Һәрхәлдә, хәзер Казанда түгелдер инде.

— Бик кызганыч! Без монда ни дип кагаеп торабыз соң әле, киттек Фатихларга.

— Мин матбугат эшләре комитетына барырга җыенган идем.

— Анда көтеп тора алмаслармыни?

— Дөрес,— дип көлде Борһан,— киттек алайса.

Яңа бистәдәге ике катлы йорт аңа Җаектагы Галиәсгар җизнәсе өен хәтерләтте. Баскычтан менгәндә картузын салып, соңгы вакытта артыгын үскән чәчләрен артка сыпырды. Мондый чәч аны олырак, дөнья күргәнрәк кыяфәткә кертә иде бугай.

Ул Фатихның авыру икәнлеген белә иде, әмма аны сиртмәле арбада күргәч, яхшы ук гаҗәпләнде. Берәр әйбер кирәк булса, хуҗа куллары белән тәгәрмәчне әйләндереп өстәлгә якыная да ала. Сөйләшкәндә дә ул әңгәмәдәшенә әле якынрак килә, әле арткарак чигә, башын чөеп, калын һәм түгәрәк күзлек пыялалары аша карый. Киемендә дә, үз-үзен тотышында да бернинди әленке-салынкылык юк, караңгы төстәге костюмы үтүкләнгән, галстугы пөхтә бәйләнгән, җиңнәрендә — манжетлар. Йөзе аксыл, иреннәре күпереп тора, эчке кичерешләрен эченә яшерергә өйрәнгән гадәтләре белән ул европалы докторны хәтерләтә, иләндерә һәм бер үк вакытта ятсыта да иде.

Габдулланы бер үсмер егет итеп кенә кабул итмәс өчен хуҗага башта шактый тырышырга туры килүе сизелми калмады. Шулай да әңгәмә беренче җөмләдән үк табигый, гади башланып китте. Казан сезгә ничег-

рәк күренә? Әйбәт урнаштыгызмы, ярдәм-фәлән кирәкмиме? Менә шундый әз сүзлелек аралашуны җиңел һәм рәхәт итә иде. Әле Җаекта шәкерт заманында ук Габдулла Фатих Әмирхан исемен акыллы, моңсу хикәяләре өчен үз иткән, алар Бәхтияров белән чыгарган газетаны да яраткан иде.

Чәй белән кош теле керткән гади ситсы күлмәкле кыз бүтән күренмәде. Борһан, урындыгын өстәл янына күчереп, чәй ясый башлады.

— Ольховский хәзер Казанда микән?— дип сорады ул Фатихтан.— Габдулла әфәнденең аның белән очрашасы килә, шуңа соравым.

— Мин аңа үзем шалтыратырмын,— диде Фатих.— Ул рус теле һәм әдәбият тарихы буенча шәһәребездә иң әйбәт белгеч, сөйләшеп карагыз.

...«Китап» нәшрияты зур түгел, аның хуҗасы ифрат сөйкемле кеше иде. Габдулланы егерме сум айлык белән экспедитор вазифасына алдылар. Нәшрият кәнсә өчен «Мәскәү номерлары»нда бүлмә алганлыктан, Габдулла да шунда күчеп урнашты. Көндез укый һәм корректура төзәтә — бу аның төп хезмәт хакын янә берничә таңкәгә арттыра иде,— аннары почтага посылкалар илтә, кибетләргә китаплар җибәрә. Шуннан соң инде Фатих Әмирхан редакцияләгән «Әльислах»ка ни генә язса да — ирек.

Китапчы сәүдәгәрләр Габдулланың тыныч холкын ошатып, яңадан-яңа басмалар белән бик юмарт тәэмин итә башладылар. Берничә ай эчендә Пушкин, Гете, Грибоедов, Толстой, Шиллер, Байрон, Һамсун һәм бүтәннәрнең әсәрләре тупланды. Бу китапларын ул күз алдында тотмады, сандыгына яшереп куйды. Бүлмәсенә кереп-чыгып йөрүче теләсә-кайсы тинтәк аның ниләр укуын белеп тормасын әле. Ә аның бүлмәсенә, чыннан да, кем генә керми иде: танышлар да, ятлар да, байбәтчәләр дә, фәкыйрь шәкертләр дә, чуалышта катнашулары өчен укудан куып чыгарылган студентлар, тагын әллә кемнәр дә!

Кунаклар соң гына таралгач, Габдулла, тәрәзәсен ачып, бүлмәсен җилләтә иде. Бары төнлә генә ул ялгызы кала һәм үз тормышы белән яши башлый. Ольховский белән очрашуын, аның белән сөйләшкән сүзләрне хәтерләп шатлана, «Евгений Онегин»ны гына яңадан укып чыксын — тагын барачак әле ул аның янына.

Бервакыт Фатихларда аны яхшы ук чибәр һәм дәрәҗәле бер ханым белән таныштырдылар. Ул үз мәкаләсенең корректурасын кертеп чыгарга гына кагылган иде, әмма эчтән хатын-кыз челтерәп көлүен, аңа Фатихның калын тавышы да кушылуын ишеткәч, әкрен генә атлап ишектән кире чигенде. Кыланчык туташлар, назланучан кызлар белән ул үтерсәң дә Фатих шикелле иркен сөйләшә алмас иде. Бик озак көтәргә туры килү ихтималын чамаласа да, Габдулла кәефен төшермәде. Заманында үз почмагы булмау аны теләсә кайда онытылып шәхси дөньясында яшәргә, шунда башкалар комачавыннан котылып уйланырга яки хыялланырга, йокымсырап яки ял итеп алырга өйрәтте. Ерактан ишетелгән хатын-кыз тавышлары, аларның тәрәзәдән күренгән сыннары Габдуллага еракта калган апасы белән Нәфисәне искә төшереп, күңелендәге наз һәм моңны чайпалдыра, дулкынландыра иде.

Менә тавышлар якынайды, менә куш ишек тә ачылып китте. Бәхтияров, бер якка тайпылып һәм җиңелчә баш иеп, хатын-кызларга юл бирде. Бераз арткарак калган Фатих сиртмәле арбасында утырган хәлдә дә затлы, күркәм һәм шат кыяфәтле иде.

— Ә-һә!— диде Бәхтияров,— без инде автор корректурасын көтмәскә карар биргән идек, Габдулла монда икән ләбаса! Фирая ханым, сезне шагыйребез Габдулла әфәнде белән таныштырырга рөхсәт итегез!

Ханым тыныч кына елмаеп үзенә таба атлагач, ул ашыгып аягүрә басарга, корректурасын бөгәрләп артына яшерергә мәҗбүр булды. Ханым озын буйлы күренеп куркытса да, каршысына килеп салкынча

кулын биргәч, аның үзеннән һич тә калку түгеллеген абайлады. Озын күлмәге генә зифа буен шулай күрсәткән икән.

Фатих коляскасында болдырга килеп чыккач:

— Габдулла әфәнде дә сезнең яклардан,— диде.

— Әгәр ялгышмасам, Җаектан ич әле? Ул очракта сез Камил Мотыйгыйның я дусты, я дошманыдыр инде,— диде ханым көлеп.

Бәхтияров җитди йөз белән:

— Башкача һич тә мөмкин түгелмени?— дип сорады.

— Камилне белгән хәлдә... Кызганыч, әфәнделәр, мин соңга кала язганмын лабаса...ләкин иртәгә без клубта очрашырбыз дип өметләнәм.

Ул Габдулланың кулын кысты да тышка юнәлде. Бәхтияров аны озата чыкты. Хуҗа белән Габдулла исә бүлмәгә кереп утырдылар. Корректурасын Фатихка сузып, ул төзәтүләрнең юк чамасында икәнлеген әйтте. Мәкаләдә тәнкыйтьнең китап турында төпле фикерләр уятырга тиешлеге, кайбер нәширләрнең, укучыларга ярарга тырышып, түбән зәвыклы, әхлаксыз әсәрләр бастыруы фаш ителә иде.

— Мәкалә әйбәт,— диде Фатих.— Миңа калса, бигрәк тә тәнкыйтьче югары әхлаклы һәм тел тидермәслек зәвыклы булырга тиеш, дигән фикер ошый. Сезгә кунак ханым — завод хуҗасы ошадымы соң?

— Чын капиталистмы?

— Чын. Аның ире губернабызда иң байларның берсе иде.

— Ышануы да кыен.

— Сез сәнәктән көрәк булганнарны гына күреп күнеккән. Ә бу — мирза кызы, гимназия тәмамлаган. Бестужев курслары турында хыялланып йөргәндә шул... хәзер инде мәрхүм иренә юлыккан. Һавалану, йөз чөерүне ул бар дип тә белми, ирләрнең байлыгына кызыкмый, үз эшләрен көнләшерлек оста алып бара. Җәмгыяте хәйрияләргә иң юмарт булышучы. Әдәбиятка гашыйк, шагыйрьләргә табына. Белдерсә, шул гына белдерер инде аны,— диде Фатих елмаеп.

— Ошады ул миңа.

Фатих көлеп җибәрде. Габдулланың җавабы ханымның чибәрлегенә бөтенләй игътибар итмәүне генә белдерә иде.

— Әйе,— дип дәвам итте Габдулла кыенсынып.— Ошады ул миңа. Кыланчык түгел икән. Иртәгә клубта нинди кичә уздырыла соң?

— «Мәгариф» авторлары чыгыш ясый. Сез дә әзерләнегез!

— Юк, юк,— диде ул,— мин шигырь сөйләмим. Тамагым... кһем-кһем...

— Чәй эчәсезме?

— Рәхмәт. Әле китаплар җибәрәсем дә бар, йөгерәм.

Шулай дип чыгып китсә дә, ашыгыч эше юк иде аның. Ялгыз каласы гына килде. Витриналарга күз аткандай урам кырыеннан атлаганда да уе башкада иде. Казанда инде икенче ае. Дөрес хәл итте ул милли пайтәхеткә килеп. Кунакханә ыгы-зыгысында яшәве дә әйбәт. Хәтта әллә ни төпле, эзлекле фикер йөртә алмаган очраклы танышлары, дуслары пәйда булып, үз тирәсендә бөтерелүдән дә файда күрергә мөмкин икән. Кыю фикер йөртәләр, мәшһүр иҗатчы яки хөкүмәт әһле, хәтта ходай тәгалә дип тә тормыйлар, берсенә дә табынмастан, кайнар бәхәсләшәләр, шул сүз көрәштерүләр барышында, үзләре өйрәнмәсә, танышмаса да, әллә ниләрне, әллә кемнәрне телгә алалар. Габдулла көттерми, колагына чалынган «Гаутама»ны я граф Толстой, Декарт әсәрләрен, я марксистлар фәлсәфәсен аңлаткан брошюраларны эзләп, шунда ук кибетләргә чыгып китә.

Озын кичәләрдә диннәр турында, Спиноза, Конфуций һәм Һинд фәлсәфәчеләре, декадентлык, спиритуализм хакында сүз китә. Спиритуализм ислам кануннарының кайберсенә каршы килми, имеш. Ул Һиндстанга замананың һәм тарихи зилзиләләрнең җимергеч хәрәкәтләренә каршы торырлык куәт биргән, имеш... Рух, рух. Ә сәяси төзелеш, социаль оешма? Барлык сәяси тәгълиматлар да җансыз һәм башкалар, һәм тагын шундый башкалар!

Байлыкны нишләтергә? Граф Толстой аны бәла дип саный. Тик алай ук кирәкмәс, матди нигезсез мәдәниятне барлыкка китерү бик икеле. Заводсыз калса, шәһәрләр дә үлеп бетәр иде. Байлык белән мавыкмаска гына кирәк. Ризык, мәдәният җимешләре, рухи хөррият белән туену турында сүз бара икән — эш башка, бу җәһәттән милләтебез бик-бик күпкә мохтаҗ әле.

Хатын-кызларны азат итү фарыз, ләкин аларны эшләтү зыян. Хезмәтсез нинди иректә? Табигать аларга бүтән бирәүгә дә бирмәгән вазифаны йөкләгән инде, шунысы да бик җитә...

Яшьләр төрле, яшьләр эзләнә, әмма Габдулла һич тә аларны тиешеннән югары бәяләми иде. Ныклы иманы бар, акыллы һәм кабилиятле Фатихны, Сәгыйть әфәнде һәм Галиәсгар Камалларны куып җитәргә аларга, әлбәттә, бик ерак әле.

...Сәер холыклы Сәгыйть әфәнде авыррак ачыла, әмма Габдулланың аңа мөнәсәбәте танышканчы ук ачыкланган иде инде. Шигырьләре кайчак артык купшы-фәлсәфи, заманының үткен ихтыяҗларына җавап бирүдән ерак тора сыман, ләкин ул каләмдәшенең укымышлы, тәрбияле, акыллы, әдәби хәяткә яңалык алып килүче булуына шикләнми иде.

Ул аны-моны уйлап тормастан үзенә иркенләп кунакка килергә мөмкин икәнлеген әйтергә ни өчендер уңайсызлана иде. Ләкин үзе аның «Болгар»дагы бүлмәсенә ара-тирә кагылгалый. Сәгыйть әкрен генә урындыгыннан торып, аны:

— Ә, сезмени әле бу?— дип каршылый. Өстәлендә һәрвакыт бер бит ак кәгазь белән карандаш ятыр.

Бервакыт Габдулла бары тик гәпне башлап җибәрер өчен генә:

— Матбугатта шигырегезне күргәнем юк иде, бүген дустым Кариев сөйләп бирде әле,— диде.

— Күрә алмавыгыз табигый шул. Журналларыбыз аны басудан баш тартты. «Мин»не «Волжско-Камская речь» кенә бүтән шигырьләрем белән бергә чыгарды. Тәрҗемәләре әллә ни түгел, ләкин мөндәриҗәләре сакланган.

— Нәширләр, мөгаен, ходай тәгаләгә таш ату омтылышыгызны сизгәндер.

— Андый омтылышым барлыгы намәгълүм,— диде Сәгыйть әфәнде салкын гына.— Шигырьнең ничек тууын үзем дә белмим. Башкача булдыра алмый башлагач кына, тирә-ягыма мөнәсәбәтемне тасвирлыйм. Күзгә яңгырны яки чәчәк аткан болынны, я булмаса берәр хәлне сурәтлимме — моның ничек гәүдәләнүе инде минем өчен әһәмиятсез.

— Карагыз әле,— диде ул икенче юлы,— мин сезне Җаекта чакта ук күзәтә башладым, гәзитегезне укып бардым. Нигә сез шагыйрь башыгыз белән сәүдәгәр, мулла, Пуришкевичларны сүгүгә шул кадәр вакыт һәм көч әрәм итәсез? Әллә сез таралган Дума турында шигырь язгач, шундук бүтәне җыйналыр, аның депутатлары элеккеләрдән акыллырак булыр, дип ышанасызмы?

Габдулла үртәлә башлап:

— Мин җәмгыять тормышына үз мөнәсәбәтемне белдерәм,— диде.— Һәй, сез ул шигырьләрнең мещаннарны ни чаклы җенләндерүен белмисез ич әле!

— Җенләнде дә онытты ич инде ул аны. Юк! Минемчә, әдәбият рухи эзләнүләрне, җиһанны аңларга булышсын ул. Хафизны аңлый торган укучы Дума тирәсендәге шау-шуның да ничә тиен торуын төшенәчәк.

— Сез реализмга караганда романтика яхшырак дип уйламыйсыздыр ич?..— Габдулла, артыграк кызып китеп, романтиканы телгә алганда, Сәгыйть әфәнде бакчасына таш атуын тиз генә абайлап җиткермәде.

— Менә сез дә,— дип моңсу гына көлемсерәде шагыйрь,— романтика искерде инде диюче тәнкыйтьчеләрне кабатларга телисез ахры.

Мин, тормышны чагылдыру ысулы буларак, ул искерә алмый, дип белдерәм. Әйе, безнең тормышыбыз баз шикелле караңгы, тик мин яшьләребезнең аны романтикларча күрүен, аларның якты идеалларга табынып яшәвен яклыйм.

...Кичәдә ул шигырь укымады, арткы сафларның берсендә тамаша кылып кына утырды да Бәхтияров һәм Фирая ханым белән бергә кайтырга чыкты. Фатих, кәефе начарлануын әйтеп, алданрак китеп барган иде.

— Әгәр каршы килмәсәгез, башта сезне кертә чыгарбыз,— диде Фирая ханым Бәхтияровка.

Аны төшереп калдырганнан соң, ханым Габдуллага:

— Ә сез мине озатып куярсыз,— диде.— Моннан ерак түгел, Евангелистлар урамына гына.

— Кунакханәгәме?

— Юк, мин өченче ел инде фатирда торам. Килгән-киткән саен яңабаштан урнашып йөрүне яратмыйм.

Патша сараендагы көзгеләр шикелле зур витриналар, куәтле лаппалар яктысыннан балкып, боздай зәңгәрсу шәүләләрен юлга һәм карлы тротуарларга чәчә иде.

— Аh! — дип кинәт кычкырып җибәрде Фирая ханым пирчәткәле кулын бер якка сузып.— Сез тегене күрәсезме?

Витриналарның берсе алдында йомарланган бер мескен җан иясе — саргылт мәче күзгә чалынды. Габдулла чанадан сикереп төшеп йөгереп килде дә туңып беткән сары йомгакны алып куенына тыкты. Аннары кулыннан тартып алырлар дип курыккан төсле ашыгып:

— Үземә булыр,— диде.— Хәер, әгәр теләсәгез...

— Юк, юк, сездә калсын. Миңа кунакка гына барыр ул. Я, мыраубай, миндә сөт эчәргә ризамы син? Туктагыз, килеп җиткәнбез ич без. Керегә борылыгыз әле, абзыкай.

Извозчикка күтәргә кушылды. Саран гына яктыртылган ишегалдына кереп, өйнең икенче катына күтәрелделәр. Ишекне башына колакчынлы бүрек кигән карчык ачты. Бөркәнгән чапанына ныграк төренеп һәм нидер мыгырдана-мыгырдана, аларны эчкә кертте дә, йөгереп барып, электрны кабызды. Фирая ханым затлы һәм купшы дохасын салып, бер мизгел кая куярга белмәгәндәй тукталыбрак калгач кына, Габдулла аны үз кулына алды.

— Күз алдына китерәсезме?— диде ханым, күңелле җанланып,— кыш, әче салкын, ә мин нибары кофта белән итәктән генә, җитмәсә, ниндидән дип уйлыйсыз?— усакның тасма-тасма йомычкаларыннан көязләнеп йөрдем. Әйе, миңа бер оста шундый искиткеч кием теккән иде. Мин, шул костюмны киеп, чанага менеп бастым да мәҗлескә! Костюмымны эштән чыгармас өчен, баскычтан да сакланып кына күтәрелдем. Ирем белән каенем мине як-яктан култыклап бардылар. Бу көнне киемем халыкны шулкадәр шаккаттырды, шулкадәр сокландырды ки — тамаша! Гаҗәп маскарад кичәсе булды ул.

Аннары җитдирәк һәм серле төскә кереп:

— Безгә, мөгаен, маскарад ясаулар кирәкмәс,— диде.— Мыраубай сөт кенә эчеп алсын да китәрсез. Әлеге әкәмәт тә миңа җитеп торыр ахры. Әйе, тагын нәрсәдер әйтмәкче идем инде мин... Сез берәр чит тел өйрәнү кирәклеге турында уйланганыгыз юкмы? Әйтик, немесчәне?

— Теләк бар инде ул.

— Иртәгә яки... үзегез теләгән башка берәр вакытта мине эзләп табыгыз әле сез. Мария Карловна белән таныштырырмын. Искиткеч хатын!

Ул арада мәче сөтне эчеп бетереп, тәлинкәсен ялый башлады. Габдулла пальтосын киеп, аны куенына алды.

— Я, аллага тапшырдык. Сау булыгыз!— Ханым ниндидер аңлаешсыз хәрәкәт ясады — әллә инде үптерер өчен кулын сузды шунда.

Әллә аны башыннан сыйпарга теләдеме? Бөтенләй үсеп житкәч тә, Газизә апасы, саубуллашканда, аны башыннан сыйпый иде ич.

...Өенә кайтып житкәч, салкын чәйнектән чәй агызып эчте дә, бер китапны алып, түшәгенә кырын ятты. Бу хезмәттә Гаутаманың фәлсәфи карашлары бәян ителә, иң югары әрвахка табынуның күккә ашу, азатлыкка ирешү икәнлеге аңлатыла иде. Ләкин иң югары рух бары шушында гына тамыр жәя һәм тантана итә ала лабаса. Бары шушында гына, дип кабатлады Габдулла шатлыклы хис белән. Югары рух хөкем сөрүе өчен ул бүген нидер эшләде сыман.



«Әльислах» редакциясенең яңалык һәм сафлык вәгъдә итә, үзгәртү дигән мәгънәне аңлата торган исеме дә, икенче каты бүрәнәдән салынган бинасы да, аның йомры култыксасыннан учын шудырып менәргә уңайлы баскычы да, һәрвакыт самавыр кайнап торган аулак бүлмәсе, ул самавырның аскы рәшәткәсеннән алсу шәүлә төшергән кура жиләгедәй күмерләре дә, коридорына хәтле аңкыган чәй һәм папирос исләре, урамнан ияреп кергән суыгы да — барысы, барысы да ошый иде.

Ул анда иртән иртүк, әле ят кешеләр килә башлаганчы ук чираттагы язмасын тапшырырга сугыла һәм кече күңелле Фатих белән бер-ике авыз сүз алыша, аннары аруын да онытырлык дәрәжәдә күтәренке бер хәлдә була торган иде.

Бүген ул редакциядә, әле шактый иртә булуга карамастан, нигәдер йөзләре караңгыланган Сәгыйть әфәнде белән Галиәсгар Камалны очратты.

— Кичә Кәримовлар типографиясенә жандармнар басып кергән,— диде Фатих.

Казан язучыларының ким дигәндә өчтән бере үз әсәрләрен шушы типографиядә чыгарганлыктан, нәшрият бәласе һәркемгә кагыла иде. Галиәсгар полиция арест салган шрифтлар өчен аеруча борчылды. Моннан ун еллар элек татар китаплары бастыручы атаклы типография хужасы Харитонов аңа, матур язу остасына, яңа хәрефләр ясауны тапшырган иде. Хәзер төрләре утызга житеп килгән ул шрифтлар барысы да Кәримовлар типографиясендә тупланган иде.

— Мин ул хәрефләрне барлыкка китерү өчен өч ел сарыф иттем. Рәсемнәрен ясадым, аларны металлга төшердем. Ахыр чиктә кануннар да бар лабаса!

— Законнармы?— дип мыскыллап сорады Фатих.— Риза әфәнде, аларның мөселманнарга кагылганнарын жыйнап, аерым китап төсендә чыгарырга омтылган иде. Зарарсыз эшкә ничек карадылар соң? Цензура тыйды. Инородецларга канун белү кирәкми, имеш!

— Бу бәлаләрдән ничек котылырга? Без бу империянең гражданнарымы, әллә...

— Гражданнары инде, гражданнары,— дип көлде Сәгыйть әфәнде.— Котылу юлы да бар: әсәрләребезне Домбровский типографиясендә бастырырбыз.

— Шаяртасыгыз юк,— дип үпкәләде Галиәсгар.— Кулъязмаларны Изге Гурий жәмгыяте басмаханәсенә тапшырыргамы? Акылдан шашарсың!..

— Бер дә шашмабыз. Анда теләсә нәрсә — миссионер китапчыкларын да, мөселман догалыкларын да нәшер итәләр. Әйе, әйе. Цензура да юк.

Фатих кызыксынып:

— Ә Христос тәрәкләре ни карый?— дип сорады.

— Алар, күрәсең, Марс сукмагыннан түгел, Меркурийныкыннан атлый.

Габдулла атаклы карагруһны исенә төшереп:

— Иманаев Домбровский типографиясенә дә тыкшынып әле,— диде.

— Инородецка анда бик исләре китмәс шул.

— Анын каравы профессор Смирновка тулысынча ышанырлар.

— Мин ул профессорны бер күргән идем,— диде Фатих күңелсез рәвештә.— Әле дә башым җитми: төркиләрне өйрәнүче галим бул да, халыкны дип әйтмим инде, гыйльми өйрәнә торган нәрсәңне шул кадәр дошман күр имеш! «Ревизор»ны тәрҗемә итәргә җыенуыбызны хәтерлисезме? Аны да Смирнов тыйды лабаса.

— Балда турындагы әкиятне дә...

Галиәсгар кайгырып:

— Без укучыларга дистәләгән китап басачагыбызны белдердек. Әгәр цензура аларның тамырын киссә, капчык асып хәер эстәргә чыгасы гына кала!— диде.

Галиәсгар сату-алу эшен яхшы белә, атасы улын шул эшкә әзерләгән иде. Әмма егет аны хәйлә белән җиңде. Сәүдәгәр кызына өйләнергәме? Ярар, кызыкай ошый аңа. Сәүдәме? Хуп, сату итәргә дә риза ул, тик китап кибете генә ачачак. «Бөтен тормышын компромисска нигезләмәкче була!» Габдулла иптәшенә гадел карамавын үзе дә төшенә, әмма эшкуарларның кыяфәте үк саруын кайната башлаганлыктан, каләмдәшенә мөнәсәбәтен һаман үзгәртә алмый иде. Галиәсгар, мәһабәт гәүдәле, сөйкемле булса да, барыбер татарга хас беркатлылыгы һәм җиңелчә хәйләкәрлелеге белән яңа пешеп чыккан сәүдәгәргә яки заводчыга охшый иде. Ул Габдулланың мыскыллы карашына җенләнеп, әмма Фатихка мөрәҗәгать итеп:

— Күрәм, сезгә бу көлке генә!— дип кайнарланды.— Алайса миңа...

— Ярар инде, дускай, ярар!— дип тынычландырды аны Фатих.— Бер-беребезне гаепләп кенә эш төзәлмәячәк. Бәлки «Бәянелхак»ны караштыру гыйбрәтле булыр: тагын ни белән күңел таба икән ул? Әһә, менә. «Декабрьнең өчендә Яңа бистәдә Бәдигъ мәзиннең ата күркәсе чыгып качмыш. Китерүчегә бер сум һәдия кыйлыначак». Хи-хи-хи...

— Анысы гына ярый, кәттәсе монда әле аның,— дип сүзгә кушылды бүлмәгә килеп кергән Бәхтияров.— Мөселман нәширебезнең Зингер машинасын ничек оста рекламалавын күрәсезме? Европа киеме кигән бик хозур балтырлы кызыкай менә ничек педальгә басып тора. Тик аның... башы гына юк!

— Шәригатьчә бу. Чибәркәй, йөзләгән укучыга йөзен дә күрсәтеп, мөселманнарны аздырмас ич инде.

Сүздән сүз китеп шаярыштылар, көлештеләр. Аннары Фатих:

— Ә хәзер, әфәнделәр, җитди нәрсәгә күчик әле.— диде.— Гәзитебезнең күләме үзгәрүен күргәнсездер. Аның күләме генә түгел, эчтәлеге дә үзгәрергә, сәясирәк юнәлеш алырга тиеш. Буржуаз либераллыкка, тар милләтчелеккә кискенрәк каршы чыгуыбыз хаҗәт.

— Хәзерге шартларда урынлы булырмы соң бу?— диде Сәгыйть әфәнде.

— Булыр. Либералларның социалистларга кушылып: «Безне дә кыйныйлар»,— дию күңелгә бер дә ятмый. Милләтчеләрнең, милләт мәнфәгатен кайгырткан өчен безне буалар, эзәрлеклиләр, дип аваз салулары да ачуны китерә. Милләт мәнфәгате безгә дә ят түгел, ләкин без социаль якны алгарак сөрәбез. Саф милли мәнфәгатьләрне генә кайгырту кирәклегенә мин бик үк ышанып та бетмим.

— Кадимче сәүдәгәрләр, ажгырып торган карагруһ руханилар — безнең чын милли бәхетсезлек чыганагыбыз. Алар белән көрәшү, ничек әйтергә инде, үз эчке эшебез диикме?

— Алай гына түгел,— дип каршы килде Фатих.— Кадимчеләр әлеге, сәүдәгәрләрнең хыянәтчел гаепләүләре — жандарм, цензорлар күңеленә сары май. Тәгассып һәм чикләнгәнлегебез хөкүмәт химаясына алына. Беренче нәүбәттә кайсы гәзитне яптылар? Хөсәен Ямашевның большевистик «Урал»ын.

— Ул артык маңгайга бәрә иде,— диде Сәгыйть әфәнде.

— «Урал», башкалардан аермалы рәвештә, халык ихтыяжын ваемлый иде. Сәяси гәзит иде ул!

— Димәк, сез дә үз гәзитегезне үзгәртәчәксез? Болай булгач, Фатих җаным,— дип шаяртты Сәгыйть,— минем шигырьләрне басып маташмассыз да инде.

Мендә кыланчык, дип уйлады эченнән Габдулла, аннары Фатихны куәтләп:

— «Урал» күпчелекне кайгыртты, аның башкалардан өстенлеге дә шунда,— диде.

— Бу ни дигән сүз соң инде?— дип чеметмәкче булды Сәгыйть әфәнде.

— «Урал» капиталга каршы чыгыш ясады, дигән сүз.

— Кара син аны! Капиталистларыбыз күпме соң безнең?

— Әгәр һәрбер либерал журналист капитал файдасына каләм кыштырдатса, һәрбер заводчы үзара көндәшлектә байлык намына изге хакыйкатьләрдән баш тартса, алар күп булачак. Кызларны бозыклыкка төшерәгә, сатучыларны ялганларга һәм алдашырга, шагыйрьләрне әрәм тамакларга тәлинкә тотарга мәҗбүр итсәк... Миңа, син чын мөселман бул, диләр. Ләкин алла хакыйкатен шулай ук капитал каплап тора лабаса. Шушы хәлләргә канәгать кешенең үзен лаеклы зат санарга хакы юк. Һәркемнең җиң сызганып социализмга хезмәт итәргә кыюлыгы җитмәячәген мин яхшы аңлыйм, тик андыйлар һич югы дөреслекне хурлап, күңелендә шуңа дошманлык сакламасын иде...

— Сез буш хыяллар белән мавыгасыз, Габдуллаҗан,— диде Сәгыйть әфәнде.— Большевикларны да укырга кирәк: алар социализм өчен көрәшнең ни икәнлеген ачыграк аңлаталар.

Фатих, тагын нидер әйтергә җыенган Габдулланың кулын эләктереп алып һәм кысып, шаярткан шикелле:

— Габдулла әфәнде бөтен капиталын китап-журналларга тота, мөгаен, социалистларның һәммәсен дә укып чыккандыр инде,— диде.

Аның бу сүзеннән соң бүлмәдәгеләр көлеп җибәрде, киеренкелек таралды. Галиәсгар Сәгыйть әфәндене ашыктыра башлады:

— Безгә кузгалырга вакыт, әйдә. Цензура комитетына барып белешик инде. Хәрефләргә арест салу вәхшилек лабаса.

Алар чыгып киткәч, Бәхтияров тә типографиягә юнәлде. Габдулла, кашларын җыерып, бүлмә буйлап арлы-бирле йөренә башлады. Фатихның үзенә төбәлүен сизеп алгач, кыенсынып туктады да:

— Артыграк кыздым ахры,— диде.— Алар үпкәчелрәк халык ич.

— Әйе шул, кирәкмәс иде,— диде Фатих бүтәнне уйлап торган кыяфәттә.— Кызабыз, үпкәлибез, чөнки һәркем үз мәсләктәшләре, үз гәзите дөресрәк юл тота, дип исәпли. Күп гасырлык йокыдан соң без әле күзләрне ачып җиткермәгән. Бераүләр дәвамлы тәгассып, кара җаһиллык, наданлык һәм бозыклыкны гына күрә, икенчеләр күнегелгән тәртипләрнең какшавыннан курка. Искелек туфрагында башка мәгыйшәт, яңа тормыш орлыклары ятуын сирәк кешеләр генә чамалый.

— Барыбыз да салулап, уңга-сулга тайпылгалап та алабыз бугай.

— Әйе шул,— дип килеште Фатих.— Безнең җәмгыятебез житлекмәгән, буржуазиябез әле сабый хәлендә, эшчеләребез сәяси яктан үсмәгән, зәгыйфь. Уяну көче, яңару омтылышы зур... тик без үсмерләрчә кайнарланып һәм сай йөзеп фикер йөртәбез. Әйе, без барыбыз да үз йөзебезне, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны, күнегелгән тәртипләребезне һәм, ахыр чиктә, иманыбызны саклауны кайгыртабыз. Шәрык мәдәнияте көнкүрешебезгә, аңыбызга үтеп кергән, шуңа күрә ул безгә якынрак. Ләкин без үзебезнең кайда яшәвебезне исәпкә алып бетермибез. Без ике мәдәният, ике кыйтга чигендә яшибез һәм алдыбызга һәрвакыт: «Кайсына табынырга?»— дигән сорауны куярга тиешбез. Безгә шуның берсен генә сайлап алу, икенчесен кире кагу дөрес шикелле тоела. Аларның икесен бергә кушуны асла уйламыйбыз.

— Бу...— диде Габдулла кирәкле 'сүзне таба алмыйча,— каршылыклы фикер.

— Монда каршылык юк түгел. Әмма әзлекле уйны да кире кагу ярамый. Бәлки дөньяга карашыбызда безгә нәкъ менә ике башлангычны — ике төрле мәдәниятне һәм фикерләүне бергә кушу насыйптыр. Бер сәер нәрсәгә игътибар биргәнең бармы: безнең кайнап торган җәмгыятьтә инкярчеләр юк дәрәҗәсендә. Нигилистлар юк! Безнең дин һәм иске тормыш догмаларын камчылавыбыз да ярым-йорты гына инкяр бит. Күпләребез беркатлы рәвештә әнә шул искене сылап-сыйпап, бераз яңартып ары таба яшәргә яраклаштыру өмете белән яши ләбаса. Ниләр эшләнүенә генә игътибар итче! Без искене вакыт-вакыт рәхимсез тәнкыйтьлибез, аннары исә изгеләребез һәм акча капчыкларыбыз белән уртак җәмгыяте хәйрияләргә берләшәбез.

— Җәмгыяте хәйрияләр без оештыра алган һәм халыкка хезмәт итәргә мөмкинлек бирә торган бердәнбер казанышыбыз дип әйтерлек ләбаса.

— Әмма күпме ялган, күпме ялган! Ул акча капчыклары — чалма чалганмы, фрак кигәнме — байлыгының бары валчыгын гына корбан итә, чөнки аларның милек дигән аллалары малларын башкалар белән намуслы уртаклашуны рөхсәт итмәячәк. Анысы беркайчан да булмаячак.

— Димәк, социалистлар хаклы?

Фатих тиз генә җавап бирмәде.

— Әлегә кем хаклы икәнлеген белмим. Бәлки без шушындыйрак хәлдә тагын берничә дистә ел яшәргә тиештер. Халыкның күпчелеге хәлиткеч адымны атларга өлгереп җиткәнче, аның аерым вәкилләре — без генә әллә ни кыйрата алмабыз.

— Ә мәгърифәт тарату? Шушы ике-өч ел эчендә без әз эшләдекмени?

— Мәгърифәтчелегебез дә тулысынча өлгереп җитәргә, аннары картаеп, үз урынын бүтән яңага бирергә тиеш. Без көткән алмаш кайчан килер — эш минем өчен менә шунда.

— Безгә аны русларга караганда озаграк көтәргә туры килер.

— Мөгаен. Әмма бер заман руслар җәмгыятьне үзгәртергә тотынып, шул ук Рәсәйдә яшәүче без исә моңа катнашмабыз, дип уйлау да артык беркатлы булыр иде.

— Давылда катнашуны әйтәсеңме?

— Җаным, теләсә кайсы җәмгыятьнең тәрәккый итүе бүтән җәмгыятьләр, бүтән халыклар белән тыгыз аралашуына бәйләнгән. Безнең өчен иң кадерле нәрсәләр юкса хәлсезләнә, картая һәм ахыр чиктә юкка чыгачак.

— Хәзер сөйләгәннәрең белән гәзитеңнең тоткан юлы әгәр туры килсә...

— Әйе,— диде Фатих нык ихтыяр белән,— ниятләрем шундый. Әгәр берне сөйләп, икенчене эшләргә керешсәм, мин үземне намуслы кеше саный алмас идем.

— Их, Фатих! Миңа әле кайчан гына хөррият, хакыйкать бик якын, ә үзебез көчле, мөрәүвәтле, талантларга, көрәшчеләргә бай шикелле тоелган иде. Яшьләргә эчкерсез үгет-нәсихәт бирерлек вөҗданлы Риза әфәндебез, нәфис шигъриятkә ия Дәрдмәндебез, ягъни, халкыбызны агартыр өчен байлыгын да кызганмаучы кешеләребез бар, дип шатлана идем. Миңа һәркем ачык күңелле, эчкерсез булып күренә, аларның һәркайсы мине аңлар һәм теләктәш кулын сузар төсле тоела иде. Ә хәзер? «Хөррият! Милләт!»— дип кычкырдык-кычкырдык та тагын капитал, кабахәт капитал белән йөзгә-йөз торып калдык. Бездә шагыйрьләр дә, иҗат юлын башлар-башламас, сату эшенә керешә. Эчемдә нәрсәдер өзелде, Фатих. Элек шигырь язсам, шашкан төсле, берәрсенә укырга йөгерә идем: син кардәшем ич, мине аңларга тиеш, янәсе. Аңлыйлар шикелле иде. Хәзер исә шигырьләремне товар кебек тотып, капшап ка-

рыйлар, безгә бир, безгә генә, без күбрәк түләрбез. Ә монысы безгә кирәкми, монда син артык дуамал, артык кискен рәвештә милләтебез тәрәкләрен какшатасың!— Ул тирән сулыш алып, Фатихның тыныч, моңсу күзләренә карап:— Теләсәң, яңа шигырьләремне тыңла әле? Тик редактор икәнеңне оныт, мин аларны бастырырга җыенмыйм,— диде.

Чыкчы, и фикрем кояшы! Китсен өстеңнән болыт,
Бу үлек җанны җанландыр, жылың берлән жылыт!..

Бер йөзең күрсәтсәнә, тугсын гүзәл көннәр минем,
Чәчкәләр атсын өмид бакчамда гөлләр минем...

Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә;
Син дә, вөждан, бер торырсың: ятмагансың мәңгегә..

Фатихның күзләре ялтырап китте, ул тәгәрмәчләренә орынып, коляскасын арткарак тәгәрәтте дә, башын чөеп, Габдуллага төбәлгән килеш, уйланган сыман:

— Безнең тормышыбыз өметтән башка бик күңелсез булыр иде,— диде.— Шигыреңдә үз күңелемә аваздаш нәрсәләр табуыма шатмын.— Аннары бераз тынып торды да өстәде:— Әгәр син бу шигыреңне бастырмау ниятеңнән сүрелсәң, икеләтә куаначакмын. Чәй китерүләрен үтен әле, зинһар...

Май башларында аның хуҗасы, әҗәтләрен түләр өчен, кибетен сатып җибәрде. Яңа хуҗа иске эшчеләрнең хезмәтеннән баш тартты. Габдулла, китаплар тутырган сандыгын, киемнәр төенчеген бер олауга төяде дә, мәчесен алып, редакциягә килде.

— Хәерле булсын,— диде Фатих.— Торакның яхшырагын табарбыз. Җәен мин Кабан күле буенда, Батан бакчасы каршында бер йорт алып, дачага чыгарга булдым. Редакциябез дә шунда урнашыр.

— Мин эшсез дә калдым ич әле.

— Үзебезгә алырбыз.

Габдулла, төенчеген төшереп җибәреп, ачылып китте һәм мәчесен сыйпый-сыйпый:

— Менә, мияубикә, бәхет бер килсә, ишелеп килә ул,— дип сөйләде.

Өй һәм ишегалды яшеллеккә күмелгән, тирә-як тыныч, йөз сажин арырак күл көзгесе җәелеп ята, аңа Ботаника бакчасы килеп терәлгән иде. Салларга кереп кунаклаган малайлар кармак белән балык тота, кайбер чыдамсызраклары дәртле чиный-чиный әле җылынып җитмәгән суга ташлана, өскә калыккач, тагын чырчу килеп юләр сата, аннары яр буеның кояшта җылынырга өлгергән сары комына чыгып тәгәриләр. Габдулла аларны ишегалдына кузна уйнарга чакыра. Алар кебек үк яланаяк, ябанбаш, бакайга тидерсә, алар кебек үк ду килеп шатлана, рәхәтләнеп кычкырып җибәрә.

Уйнап алгач, ул бүлмәсенә керә дә язу-сызуына утыра, аннары төшке ашка туктыйлар, шуннан соң Фатих белән Бәхтияров клубка яки берәрсенең дачасына кунакка китәләр. Ә ул яр буена чыгып утыра да тәмәке кабыза, бистә халкының гармун уйнап, җырлар җырлый-җырлый каекта йөзүен тамаша итә. Эңгер төшкәч, каеклар ярга борын төртә, күл тынып кала, каршы яр өстендә әллә нинди күләгәләр — әллә инде су аналары — күзгә чалына. Бары менә шул чакны гына Габдулла өйгә кайта һәм янкормага күтәрелеп, аларның хуҗалыгын алып барган Саимә түти белән чәй эчә, аннары үз бүлмәсенә кереп тагын эшенә тотына. Кайчак төн уртасына кадәр утырса да, кирәкле нәрсә башына килми, әмма уйларга уй гелән җитәрлек була.

Фельетон һәм мәкаләләрнең узган көн белән бергә юкка чыгуы аны, файдасызга көч түгәм ахры, дигән фикергә китерә иде. Ул фабрика эшчеләренең яртысын тәшкил иткән хатын-кызлар һәм балаларның

түрәләр тарафыннан җәберләнүе турында яза, әмма кыерсыту, аларның желегән суыру һаман дәвам итә. Милли театрның мөшкел хәле, бер жирдән дә ярдәм ала алмавы, шул ук вакыт акча капчыкларының ниндидер Мәккә суфыйларына меңнәрләп садака өләшүе турында яза — театр барыбер мохтаҗлыктан чыга алмый. Җәмгыяте хәйриятләргә тиеннәр генә бирсә дә, туган халкының яхшылык кадерен белмәве, аңгыра һәм тупас булуы турында лаф оручы милләтчеләргә дә мул өлеш чыгарды ул. Телдән һәм матбугатта бердәмлек турында кайнар вәгазьләр сөйләнелсә дә, бердәмлекнең булганы юк, берләшү идеясе — алдашу, күзгә төтен җибәрү генә. Һиндстанда укып кайткан Минһаҗ, әнә, туган ягы Хвалыйн өязендә дәрелфөнүн — университет салам дип, мөселманнардан акча җыйды. Ләкин шуны үзенә йомып калдырып, сату итәргә керешә һәм бай сәүдәгәр кызына өйләнеп җибәрде. Кадетлар партиясе әгъзасы Йосыф Акчура Фәләстингә мәчет салырга китте. Либерал Габдерәшит Ибраһимов шул ук максат белән Япониягә юл тотты. Кадимчеләр, либераллар, эсерлар һәм кадетлар шуларның каһарманлыгына аһ ора. «Бәянелхак» үз битләрендә җәдитчеләрне сүккән мәкаләләрен сыра заводлары рекламасына аралаштырып баса. Үзе хатын-кызларның театрга йөрүен гөнаһ саный, үзе шул чак «Аркадия» фахишәләре турында игъланнар чыгара.

Бервакыт үз капкаларыннан чыгып килгәндә ул тарантастан төшеп маташучы Сәгыйть әфәндене күреп алды. Шагыйрь аңа якынлашып һәм күрешергә кулын сузып:

— Сез чын дәрвиш икән! — диде. — Яшәгән оягызга кадәр аулакта.

Габдулла аны күрүенә шатланып, ялгыз йөрү күңелсез булуын әйтеп, җавап кайтарды һәм кунакны бергә сәйран чыгарга чакырды. Алар дачадан шактый ераклашкач, Сәгыйть:

— «Бәянелхак»ның изге кулы, әйтүләренчә, монда таба да сузыла икән, — дип телгә килде.

— Мотлак изге, — диде Габдулла шаяртып. — Әмма мин ничек милләтче булмыйм ди инде, Сәгыйть әфәнде? Сөйсәм, бары татар кызларын гына сөям, алар исә мине шулардан да аерырга тели.

— Без барыбыз да ялгышканны күрәм инде мин хәзер, — диде Сәгыйть әфәнде һич тә шаяртып тормастан. — Җәмгыятебезне агартсак, ул безгә якынрак булыр, шагыйрьләренәназлырак карар дип уйлап йөрдек... Безнең агай-эне арасында да «дин, милләт, милли» сүзләрен ешрак кабатлаган саен халкыма зур хезмәт күрсәтәм, дип сатышучылар җитәрлек. Әле менә шагыйрьләребезнең берсе «Кызларга мәхсус милли шигырьләрем» дигән тулы бер китап чыгарган.

Габдулла күңелле көлеп җибәреп:

— Коръән шәрифтә: «Адәм ыруында беренче — ирләр, алардан соң — үсмерләр, алардан соң — малайлар, шуннан соң — хатын-кызлар, алардан соң — хонсалар», — диелгән. Коръәндә аталган әнә шуларның һәркайсы өчен хәзер аерым-аерым шигырьләр язарга туры киләчәк инде.

Алар яр буйлап шактый ерак киттеләр, кояш инде баеп бара, әмма Сәгыйть әфәнде әле борылырга уйламый да иде.

— Рөхсәт итегез, Габдулла... мин сезне шулай гына атыйм әле, сез дә миңа шулай «Сәгыйть» дип кенә эндәшегез. Дусларча бер киңәш бирәсем килә: саграк бул, ул өер бездән көчлерәк, аларны намус та, вөҗдан да туктатып калмаячак, чөнки намуслары да, вөҗданнары да юк аларның.

— Мин асла курыкмыйм, — диде ул тыныч һәм гади генә.

— Мин дә курыкмыйм. Ләкин кайчак уйландыра: барыбызны да намәгълүм хәвеф көтә сыман! Хәзер инде хөррият хакында кычкырып сөйләшмиләр, ә кешеләр... кешеләр күз алдында бозыла бара. Ни булган аларга?

Нииндидер үзгәреш аның үзендә дә сизелә иде. Ул элек тә дөньяга каш җыерып, ачу төсмере белән карый, ләкин бу карашта битарафлык та, өркү дә юк иде. Әйтүләренчә, хәзер Сәгыйть әфәнде клуб, редакцияләргә сирәк бара, көндез үз бүлмәсеннән чыкмый, ә кичләрен ресторанга кереп, шәригать саклаучылар җенләнеп сүгә торган атаклы Мәрьям Искәндәреваның җырлавын тыңлый. Ул үзе дә көчле тавышка ия, халык җырларын дәртле һәм моңлы башкара; алар Мәрьям белән бергәләп граммофон тәлинкәсе чыгара торган ниндидер фирма өчен җырлыйлар имеш. Ул Мәрьямгә гашыйк имеш... Тик Сәгыйть гашыйк кешегә һич тә охшамаган иде.

...Иптәше белән саубуллашкач, Габдулла тышта тагын бераз ялгызы йөрде һәм өенә караңгы төшкәч кенә кайтты. Көтелмәгән очрашуга күңеле булса да, йөрәгенә ниндидер билгесезлек, сызлану, зарыгу хисе тынгылык бирмәде: нишләргә, ары таба ничек яшәргә? Таң алдыннан яңа шигырь язылды, ләкин ул җанын сыкраткан нәрсәне тагын чагылдырып бетермәгән иде.

Якын дустым! Сиңа миннән киңәш шул:
Кешеләргә сереңне сөйләмәс бул.
Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,
Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл...
Кача күр, кош кеби, мактауларыннан,
Хәбәрдар бул ки шунда ау барыннан...

Нишләргә?.. Менә шулай баш ватып йөргәндә, аның зиһенен яктыртып бер уй узды: халык иҗатының байлыгы, күпкырлылыгы турында ул бер генә мәртәбә язмады инде, нигә соң әле шул җырларны, риваятьләрне берәмтекләп җыеп, аерым китап итеп бастырып чыгармаска? Мәктәпләрдә милли әдәбият дәресләрен укыту кирәклеге хакында да язды — татар язучыларының иң яхшы әсәрләрен туплап, шуны аерым җыентык төсендә чыгаруга да ирешсә? Менә шул хезмәтләр, бик ихтимал, бушка китмәс иде.

Көннәрнең берендә редакциягә Оренбурдан килгән яшь каләм иясе Галимҗан Ибраһимов килеп керде. Егермесен яңа гына тутырган, озын чәчле, какча йөзле, чандыр, үткен карашлы, кискен хәрәкәтле егет. Нинди акыллы, укымышлы үзе. Борынгы мөселман мәдәнияте, Декарт вәгазьләре, диннәр турында иркен хөкем йөртә. Казанда университетта укыр өчен әзерләнү максатында килгән, тик аңа хәтле Кавказга һәм Кырымга сәяхәт ясарга тели икән.

Шул егетне тыңлап торганда, аның да әллә кайларга чыгып китәсе, әллә кемнәр белән очрашасы, сирәк табыла торган китапларны укыйсы, үзенең элек язган фельетоннарыннан күпкә өстенрәк шәп нәрсәләр язасы килде. Китәргә иде, җан азыгы эзләп сәфәр чыгарга...

Аны икенче очрашу да әсәрләндерде. Әле күптән түгел генә Оренбурда большевистик гәзит чыгарган, хәзер Казанда ярым яшерен һәм, мөгаен, хәтәр тормыш алып барган Ямашев белән очрашу.

— Халыкны агартырга кирәк дисезме? Әйе, сәяси яктан агартырга, милли аң белән янәшә сыйнфый аңын да уятырга кирәк аның.

Икенче юлы редакция бүлмәсендә икәү генә калгач, пальтосының киң кесәсеннән Габдулланың быел февральдә нәшер ителгән китабын тартып чыгарды.

— Иң кирәкле, сәяси яктан иң мөһим нәрсәләр турында хис белән һәм үтемле итеп яза беләсез сез,— диде.— Кыскасы, мин бу шигырьләрне үз гәзитемдә бик рәхәтләнеп басар идем.

Ул шигырьләр, шулар арасындагы «Китмибез!» дигәне дә Думадагы татар депутатларының зарына каршы Пуришкевич һәм Сазоновичларның: «Әгәр сезгә Россиядәге тәртипләр ошамаса, Төркиягә китегез!»— дигән җавабы уңаеннан язылганнар иде.

«Әмма бу шигырьләрдә минем үземә бүген дә кадерле булган юллар бар»,— дип уйлады ул. Бар!

Без күчәрбез, иң элек күчсен безем әмсарымыз,
Һәм дә кайтсын монда үткәргән безем әгъсарымыз.
Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне тәңремез (гыйззе вә җәл)...

...Кечкенә генә станциядә аларны Сембер фабрикантларының галәмәт зур ике тройкасы каршы алды. Авыл юлы буйлап барганда як-якта кара пар җирләре җәелеп калды, куаклыклар якты май яшеллеге белән капланган иде. Алты чакрым чамасы узгач, иңкүлеккә урнашкан, морҗаларыннан төтен баганалары күтәрелгән авыл күренде. Кырыенда авыл манзарасы өчен ят булган озын торбалы соргылт тәбәнәк цех биналары тезелеп киткән иде. Имәнле юл буйлап сулга борылгач, күп санлы янкормалары белән җәелеп утырган утар пәйда булды. Байлар колач җәю белән мавыга иде ахры: йортлары да, тарантаслары да чамадан тыш зур, олаучылары да гәүдәгә алып батыр шикелле. Юл аркылы чыгып барган казлары да салмак һәм мәһабәтләр.

Кара костюм-чалбар, голланд штиблетлары һәм түбәтәй кигән киң җилкәле, мәһабәт хуҗа аларны киң таш баскычтан алып менгәндә, куәтле тавыш белән:

— Сәфәрегез котлы булсын... Чиксез шатмын!— дип кабатлады.

Кунакларны икенче каттагы махсус бүлмәләренә озаттылар, бераздан өрлектәй егетләр аларны юлдан соң юынырга алып китте. Аннары хуҗаның әллә кайдан килеп тулган күп санлы энеләре һәм сеңелләре, дуслары һәм якыннары утырган аш залына керделәр. Озын өстәлләрдә сырлар һәм колбасалар, уылдык, яшелчә, җиләк-җимеш, салкын күркә ите, сарык ите телемнәре һәм нииндидер затлы эчемлекләр. Табында Хәсән әфәнде калкып, йомшак баритон тавыш белән:

— Габдулла әфәнде, мәдәни милләтләрдә беренче тостны кунакка ошаган шәрабтән башлау йоласы бар,— диде. Аннары өстәлдә төрле төсләрен балкытып торган шешәләргә ишарәләп һәм көлемсерәп дәвам итте: — Бездә әле бу җәһәттән аерым милли тәртипләр кертелмәгәнлектән, сыналган йолага таяныйк. Сез бу юлы кайсы шәрабне авыз итәргә ниятлисез?

Бу кадәр төрле эчемлекне кем белеп бетерсен инде! Аңа танышы...

— Шампанский ачыгыз!

Шул минутта ук ак пирчәткә кигән теге озын егетләр шампан шешәләрен бозлы әрҗәдән суырып алып, җилкәләренә асылган ак тастымал белән сөрткәләп, касәләргә эчемлек коя башладылар.

— Сәфәрегез котлы булсын,— диде хуҗа.— Бүген мин халкыбызның мәгърифәт таратучы, матур өметләр уятучы яңа юлбашчыларын сәламләү шәрәфенә ирештем. Сезнең исәнлеккә, мөхтәрәм кунаклар!

Гәпләр дәртле, әмма эчпошыргычрак ага иде. Һәркем башкаларны үзенең җәдитчелек, яңалык яклы икәнлегенә ышандырырга тырышты һәм һәркайсы диярлек диннең зарурлыгын, аңа җәмгыять тормышында лаеклы урын табарга кирәклеген раслады. Математика, география, рус һәм һич югы бер Европа телен укыту фарыз... Сәүдәгәрләр һәм промышленниклар хәзер дога белән генә эшне алга җибәреп булмавын, моның өчен төрле фәннәрдән гыйлем эстәү хаҗәтлеген төшенә иде. Шул ук вакытта җәдитчә укытуның зарарлы ягын да күздә тоталар. Гыйлем үскән җирдән социаль болгануларга да ерак калмаска мөмкин ич.

Аңардан шигырь сөйләвен үтенделәр. Юк, ул кеше алдында шигырьләрен сөйләми. Алар басылган, телисез икән, аласыз да укыйсыз.

— Әфәнделәр, әфәнделәр,— дип искәртте хуҗа,— без кунакны болай йончытмыйк инде!

Чакырылганнар арасында кыек якалы зәңгәр күлмәк, караңгы төстәге кыршылган костюм, дегет исе аңкыткан күн итек кигән морза Япанчыев та бар иде. Кыска челемен төтәтеп, ул әле бер, әле икенче ке-



*Т. Хажиәхмәтов рәсеме*

ше янына килә, тик кунаклар аның яныннан тизрәк шылуны хубрак күрә иде. Морза инде кызмача хәлгә кергән, мәҗлестәгеләргә һич тә үпкәләми: «Яшь чагым, юләр чагым»,— дип җыр шыңшый башлаган иде. Бер заман ул Габдулла янына килеп:

— Безнең Канбик бабабыз Болгар базарларында тәмләткечләр белән сату иткән,— дип белдерде.— Ә безнең морза нәселе аның улы Япанчадан башланып киткән. Син миңа сугыл әле, Япанчыевлар тарихы «Кисекбаш»тан кызыклырак...

Өченчеме, дүртенчеме көн киткәч, хуҗа аның белән кабинетында күзгә-күз гәпләшергә теләде.

— Габдулла әфәнде, әйбәт, зиһенле оныкларым үсә минем. Укыта башларга вакыт үзләрен. Мәдрәсәгә бирү кызганыч, гимназиягә кертү хәтәр. Әгәр аксөяк урыс гаиләләрендәге шикелле, укымышлы хәлфәләр китертеп, аларга өйдә белем бирсәк, ничек булыр икән? Әгәр үземә килсәк, мин оныкларымны бик шатланып сезнең карамакка тапшырыр идем. Бу эшне сезгә дә зыян китермәслек итеп көйләргә мөмкин: гади аралашу, гәпләшү, бергә китаплар уку, сәяхәтләр ясау. Монда һава саф, торак әйбәт, айлыкны гәзиттәгедән ким алмас идегез.

Ул рәхмәт әйтте дә тәкъдимне кире какты. Кызганыч, ике-өч йөгерек акыллы баланы укытуга, аларда әдәби зәвык тәрбияләүгә, бергәләп сәйран чигүләргә ризалашу да ярар иде үзе. Тик ул гыйлем, мәгърифәт казаны кайнап торган шаулы шәһәргә сусар шул, болай да ерак аулак почмакта күп әвәләнде инде.

Габдулла әфәнде аның көтепханәсен тәртипкә сала алмасмы икән соң? Китаплар да, вакытлы матбугат та күп җыйналды, кайсы кайда чуалып ята бирә.

Ул тагын рәхмәт әйтте дә баш тартты. Я хода, бары китаплар белән генә эш ит, җаның теләгәнне укы, уйла, яз һәм яшә шушы оҗмах эчендә! Менә әгәр бераз өлкәнрәк булса, ул, мөгаен, көтепханәгә алыныр иде. Һәм язар да язар иде!

— Аңлыйм, Габдулла әфәнде. Сезнең хактагы фикеремнең шушы көннәрдә алган тәэсирләремнән аерылмавына хәтта шатмын.

Акчурин белән әңгәмәне корудан соң Габдулла җиңеләеп, күңелләнеп тә китте. Менә мәзәк! Шагыйрьгә, һичшиксез, яхшылык эшләргә телиләр, ә ул һаман борын чөерә: тегесен теләмим, бусын өнәмим. Аның либераллар, сәүдәгәрләр, милләтчеләр турындагы мәкаләләрен кунакларның барысы да ошатуы бик икеле, шулай да һәммәсе итагатьле, һәркайсы аның белән дуслашырга омтыла сыман. Араларында дәрт-дәрманлы, укымышлы, милләт гамен кайгыртучылар да, кулына көч һәм абруй туплаганнары да бар. Тик ни көтәләр икән соң алар миннән? Ул елмаеп һәм щукланып: алар үз хакимиятләреннән миңа да өлеш чыгарырга тели, ләкин ни өчен?— дип уйлады.

Юлдашы Борһан Шәрәф исә ял итеп рәхәтләнә, һәммәсе белән җиңел һәм тәкәллефсез аралаша — кунакларның искеләре китә, яңалары килә, тагын искеләре әйләнеп кайта — ул фабрикант Хәсән әфәнденең уллары белән серләшә, оныклары белән шаяра, төрле уеннар уйлап таба, Хәсән әфәнденең туганы һәм эшкуары — фирманың бөтен эшен алып баручы Якуп белән иркенләп әңгәмәләр кора иде. Борһан Якупның эшчәнлегенә, тәвәккәл планнарына соклана һәм көлә-көлә Габдуллага:

— Миңа журналистлык, китап сату белән шөгыльләнгәнче, мануфактурага алынасы калган,— ди.— Кереме шаккаттыргыч, сәясәте юк дәрәҗәсендә.

Көпшәгрәк гәүдәле Хәсән әфәндедән аермалы рәвештә, кече Акчурин ябыграк, мускуллы, киемнәре дә эш кешесенекедәй җыйнак һәм пөхтә иде. Озын, купшы сүзләр сөйләп булашмый, сүзне бәрәкәтле, үлчәп кенә чыгара. Габдуллага ул тәрбияле елмаеп:

— Миңа сезнең кайбер мәкаләләрегез ошый. Муллалар һәм Япанчыев кебек адәм актыклары хәрәкәтенә чик куярга кирәк,— диде.

Габдулла җавап бирергә өлгергәнче, ул инде болдырдан йөгереп төшеп фәйтүненә утырды һәм үз эшләре белән каядыр китеп тә барды. Аның артыннан сокланып карап калган Борһан Габдуллага борылып:

— Ай-һай, уйлый да белә инде,— дип баш чайкады.— Капиталга ия булу гына әз, сәяси хакимлек тә кирәк, ди. Япанчыев белән Акчуриннар аермасын тоясыңмы инде? Миңа икътисадый журнал чыгарырга киңәш бирә, ярдәм дә вәгъдә итә, валлаһый!

Борһанның җиңелчәрәк, кайнаррак акылын әнә нәрсәләр әсир итә икән ләбаса.

Габдулла ялгызы гына паркның иң ерак, аулак почмакларына сукмак сала, бака ефәге каплаган киң буаның ярына утырып, байтак сәгатьләр уздыра иде. Төннәрен исә начар йоклый. Мамык түшәккә ята да ай нурлары шәүләсе төшкән түшәмгә карап, утардагы тавышларга колак сала.

Бервакыт ул ишекне ачып аскы катка төште дә сак кына ишегалдына чыкты. Төне айлы, якты, ишегалдына күләгәләр сузылган, парк уртасындагы буадан бака туе ишетелде. Авыл ягыннан әллә җыр, әллә хатынкыз ыңгырашуы — билгесез авазлар яңгырый. Шул тарафта еракта эт өрә тагын. Ул капкага таба юнәлгән иде, артыннан кемдер атлавын ишетеп туктап калды. Чапан, мескен бүрек кигән бер карт икән. Кулында — мылтык. Кинәт пәйда булган бу карачкыны күргәч, Габдулла әле һаман тынычланып бетә алмыйча:

— Каравылчымы әллә сез? — дип сорады.

— Каравылчы, тагын кем булсын инде. Ә сезне йокы алмыймы? Кһе, кһе...

— Сез миңа йоклаган булгансыздыр, мин генә уятканмындыр.

— Хәзер бездә тыныч,— диде карт иснәп алгач.— Элек кенә ул фабрикта әле стачка, әле янгыннар... моннан җиде чакрымдагы бай йорты тәмам көлгә әйләнде. Минем улым да, җүләр, шул башыбозыклар белән бәйләнеп киткән иде. Ярый әле хуҗабыз алтын кеше, жандармнарга: сез бу егетне кулга алмагыз, ун чыбык сыдырыгыз,— диде.— Карт, бәхеткә тиенгәндәй, көлеп җибәрде.— Сыдырдылар. Шул кадәр дә уңдык инде. Югыйсә, тинтәккә каторга иде, ә хәзер тыныч, ипле генә яшәп ята. Фәкыйрь фәкыйрен, әмма безнең пәйгамбәребез дә ярлы булган лабаса.

— Ә оныкларың укырга йөриме соң?

— Мәктәп бар, әйбәт мәктәп. Өр-яңа, аны да хуҗабыз корды. Тик хәлфәләре генә төпләнеп калмый, килә дә китәләр. Хуҗа сынап, күзәткәләп тора да берзаман: «Юк, туганкаем, ходай юлдашың булсын, бар инде син бүтән карьяга»,— ди.

— Хуҗагызга нинди хәлфә кирәк соң?

— Хәлфәләр белән эш четерекле хәзер. Ярый ла ул акыл белән коръән укый алса, аңлата белсә. Аның әле җәгърәфияне белүе дә фарыз икән. Андыен да эшкә алганнар иде, бер заман аңлата башлаган бу: янәсе, кыйтгалар алты, аларның һәркайсы ярлы белән байга бүленә. Саташтыра, димәк. Ә болай үзе ярыйсы, коточарлык нәрсәләр сөйләмәде, фуражка да кимәде, каеш белән билен дә бумады.

— Мин буа буена бармакчы идем. Адашмам микән? Төнлә этләрне дә ычкындыргансыздыр әле...

— Этебез берәү генә лә безнең. Буа эзләп китсәгез, адашырсыз. Ул сезне, һичшиксез, чокыр буена китереп чыгарыр.

— Ул? Кем соң ул?

— Убыр инде, билгеле. Утырып торыгыз... Монда, аңлыйсызмы, шундыйрак эшләр. Безнең бер егетебез шахтага киткән иде, шунда үзен лава баскан. Үлгән җирендә генә күмсәләр, рухы да тынычланган булыр иде. Юк шул, атасы «туган җирендә җирлим» дип карар бирде. Хәзер үзе дә үкенә моңа. Ни гаиләсенә, ни бүтәннәргә тынгы юк, өрәге котны ала. Сез буага дисез инде алайса?

— Әйе, бераз йөрим әле, һавасы бигрәк хуш.

Тагын ике көннән соң теге алып гәүдәле олаучы Габдулла белән Борһанны кире станциягә илтеп куйды.

...Бистәнең тын тыкрыгындагы бер аулак йортта Габдулла кайчандыр ваемсыз ике ел гомерен уздырган иде. Кустарь күнче һәм аның хатынының үз балалары юк иде. Абзый теккән әйберләрен талчукка чыгарып сатканлыктан, хатыны сәүдәгәрләр заказы буенча түбәтәйләр чиккәнлектән, өсләре бөтен, тамаклары тук. Кайсы көннәрдә шул әнисе: «Габдулла улым, без бүген кәләпүшләрне илтәбез»,— дияр, аны киендерер, үзе дә яңа күлмәк киеп, яңа яулык бөркәнер, аннары өйдән чыгып китәрләр иде. Матур җиһазланган — идәннән түшәмгә кадәр зур көзгесе, сандык кадәрле органы, чиркәү чаңыдай суга торган сәгатьләре сокландыра торган бай йортларга бара иде алар. Бервакыт ул әллә нинди зиннәтле вә алтынлы койрыгын кояшка каршы ялтыратып йөргән тависны күрде. Бу юлы гаҗәпсенеп, шатлыктан исереп кайтты да бистәдәге иптәшләренә дөньяда нинди могҗизалар булу турында сөйләде,— мәчет дивары буенда яшел чирәмдә алар озак хыялланып утырдылар, аннары Иске бистә белән Яңа бистә арасындагы болынга йөгерделәр.

Ул бистәдә, мөгаен, гомер буена да яшәп калган булыр иде. Әмма ике елдан аны асрарга алган ата-анасы икесе берьюлы чирли башладылар һәм: «Без үлсәк, бу бала кем кулына калыр?» — дип хәвефләнеп, Өчиледәге бабасына озатырга ашыктылар.

...Иске койма эчендәге җиргә чүгеп, янтаеп беткән йортны аларга байтак эзләп йөрергә туры килде. Гусар иптәшенә тышта көтеп торырга кушып, Габдулла ишегалдына керде. Өйалды ишеге бикле булганлыктан, шактый озак шакылдатты. Бөкре карчык күзләрен мелт-мелт китереп аңа аптырап карап торды. Габдулла сәкедә утырган кара кашлы, кара күзле, тулы гәүдәле хатынны ярым караңгыда шундук күреп өлгерә алмады.

— Абау! — дип кычкырды ул һәм шунда ук йөзен яулыгы белән каплады.

— Әни, бу мин, исәнме? — диде Габдулла әкрен генә һәм аңа таба атлады.— Син мине таныйсың ич, әйеме?

— Син дә сәламәтмени соң әле? — диде сәкедәге хатын һәм елап җибәрде.— Әйе, әйе!

Карчык нидер мыгырдана, әле ишеккә, әле тәрәзәгә барып карый иде. Ахырда ишекне бикләде дә, сандык өстенә менеп кунаклап, аларга күз тегеп утыра башлады.

Анасы, авызын яулык чите белән каплаган көе, үз хәлен сөйләргә кереште. Ире биш ел элек вафат булган, ул карчык әнкәсе белән генә торып калган икән. Түбәтәй чигеп кенә тормыш алып бару кыен дип кияүгә чыгарга ризалык биргән. Ире — бистәдә мәгълүм кеше: изге Гайнан Вәиси хәзрәтнең мөриде икән.

— Әйбәт кеше үзе, тик син, улым... болай кителмәгәндә генә килеп чыкмаган булсаң... Әллә ул өйдә чакта җомга көнне киләсеңме? Әлләни әйтергә дә белмим инде, белмим, синең үз тормышың, безнең үзебезнеке, бергә яшәргә ходай язмаган булгандыр инде, күрәсең. Бигрәк чандыр, төссез инде үзең, балакаем.

Ул дәшми-тынмый гына аягына басты...

Урамга килеп чыккач, мәзәк һәм тупас күренешкә тап булып, аптыраудан бер мизгелгә катып калды: ике әре сөякле ир-ат гусар иптәше Әбүзәровне кулларыннан каерып тоткан, ә бу ычкынырга тырыша һәм каршысындагы өченче ир-атка тибәргә маташа иде. Төп кебек тыгыз тәнле тәбәнәк, кыяфәте белән йөкче яки кибетчегә тартымрак бу өченче зат тар билле, киң итәкле камзул өстеннән калын постау казаки кигән, башына чуклы фәс чәпәгән иде. Менә шул фәс Габдулланы бутады да инде: кибетчегә фәс нәрсәгә?

— Ә-ә, менә икенчесе дә!

— Ниндидер хаталану бар монда,— дип. Габдулла фәсле абзыйга таба атлады.

— Хата? Алайса син минем ишегалдыма хаталанып кына килеп кердең, ә бу җүлек сине извозчик белән юри генә көтеп тордымы?

— Мин әнкәйнең хәлен белергә генә килдем...

— Әнкәйнең? Һи-һи! Әйтәм улына охшаган син аның.

Гусар хәзер инде каршылык күрсәтүен онытып, шаркылдап көлеп җибәрде.

— Габдулла җаным, без тиешле җиргә килеп эләкмәгән ахры. Бу талчукчы карт ишәк үзенең хатынын урларга килгәннәр дип саташа ич.

Габдулла болай әйткәләшеп торуның файда китермәячәген чамалап, яңа гына мәдрәсә тәмамлаган тәрбияле шәкерт төсен алды.

— Хөрмәтле абзыкай, һәр мөсафир мөселман кардәшенең кунакчыллыгына өметләнергә хаклы. Мин яңа гына мәдрәсә тәмамладым һәм хәзер указ алыр өчен мөфтияткә барышым. Юл уңаенда балачагымда тәрбия биргән итагатьле абыстайның хәер-фатихасын алырга иде исәбем.

— Ә-ә,— дип йомшады гайрәтле абзый,— аны башта ук шулай төшендерергә иде: мин — фәлән, шундый-шундый йомыш белән, дип. Әмма сиңа әнкәеңне бимазалап йөрү кирәкмәс. Кибетемә генә кил син, булачак хәзрәт белән мин үзем рәхәтләнеп сөйләшермен. Әй, сез, җибәрегезсәнә шул җилкуарны!

...Габдулла көтмәгәндә тынычлыгы алынган әнкәсе турында борчылып уйга калды. Тагын бер тапкыр, әмма бу юлы алдын-артын карабрак, хәлен белешергә кирәк. Әллә нинди шөбһәләргә батмасын өчен, әүвәл, әлбәттә, кибеткә сугылу хәерле.

Бер җирдә алты аршын киндер тукыма сатып алып (абзыкайга менә дигән күлмәк-ыштанлык), Габдулла мөрид куышына юнәлде. Кибетче бүләкне күреп тәмам шаккатты һәм арткы бүлмәсендә чәй эчү оештырды.

— Син, энем, ипле егет күренәсең,— диде ул,— өлкәннәрне хөрмәтли беләсең. Юньле мулла чыгар синнән, мөгаен. Указны алгач, тагын безгә сугыл әле син, әйбәтрәк мәхәллә эләгүен кайгыртырбыз.

— Юк, юк, зинһар борчылмагыз.

— Нинди борчылу ул. Кара әле,— диде мөрид серле төстә,— мин сине Мөбәрәк хәзрәт белән очраштырыйм әле. Нәрсә, син аны ишеткәнең юкмыни? Мөбәрәк хәзрәт — Гайнан Вәиси җанапләреңең уң кулы. Син миңа кергәләп йөре, ә әнкәеңне күрүдән фәтва әз. Аның турында беләсең килгәнне үзем сөйләрмен.

— Шулай да мин аның хәлен белешергә телим әле,— дип каршы төште ул.— Кылган яхшылыклары өчен бер бүләк тә илтәсем килә.

— Бүләкне, ярар алайса, сатып ал син.— Аннары җитди төстә өстәде.— Мөбәрәк хәзрәт белән сөйләшеп куйыйммы соң? Аңа юлыгу җиңел эш түгел бит.

— Сөйләшегез,— дип җавап бирде Габдулла.

Яңа бистәдәге ике катлы зур йорт — капкасында ай һәм йолдыз сурәте төшерелгән яшел әләм җилфердәгән, маңгаена: «Сардар Вәисинең ходай фиркасе кәнсәсе вә автонум дини идарәсе. Бөтендөнья дәүләт гыйбадәт йорты», дигән язу кадакланган бина аны инде күптән кызыксындыра иде. Абзыкай аны нәкъ менә шушы йортка алып килде. Юка гәүдәле, алсу яңаклы, пөхтә киемле Мөбәрәк хәзрәт кызларныкыдай нәфис бармаклары белән ашыкмый гына тәсбих тартып утыра иде...

— Баштан ук шуны аңлавыгызны үтенәм,— диде карт,— без көчләү яклы түгел, углым. Безнең иманыбыз — көчләүгә каршы тору гына. Адәм баласына борын-борыннан бирелгән көчләү белән көрәшү көлке булыр иде,— дип көлемсерәде Мөбәрәк хәзрәт.— Халыкка коръән нигезендә барлыкка килгән иман кирәк, әмма коръән мөселманнар җиңеп алга барган вакытта җиргә иңә, ул көннәрдән бирле аларның язмышы байтак үзгәрә. Әйе, кем... Дәүләт хакимияте кешене аздыра, түбәнсетә, боек-

тыра, аның рухи дәртен һәм көчен ала, зәгыйфьләндерә. Без рухны сак-лап калырга тиеш.

Ул аннары мәзһәпнең муллаларны, мәчетләрне һәм рәсми дини йолаларны танымавын, чөнки аларга дәүләт кул салуын сөйли башлады. Мондый очракта дәүләт хакимлегенә буйсыну — ялганны, икейөзлелекне үсендерү дигән сүз. Мәзһәп үз әгъзаларын салымнарны түләмәскә, гаскәрдә хезмәт итмәскә өнди, имеш.

— Безнең фирка халыкны оештырып торган үзәккә әйләнер, ахырчиктә бөтен халык эчкерсез һәм ирекле кешеләр берлегенә әверелер. Хакимнәр шәфкатьсез, алар гаскәргә һәм коралга ия. Булса соң?! Күп миллионлы кардәшлек: үтерегез безне, төрмәләргә ябыгыз, әмма барыбызга да төрмәләр дә, уклар да җитмәс,— ди. Күрегез дә торыгыз: озак та үтмәс, хөкүмәт кайчандыр Бөек Болгар чәчәк аткан борынгы җирләребездә гомер сөреп яткан мәзһәбебезне тану турында указ чыгарыр!

Габдулла — карт янында сәгатькә якын утырды, аны-моны әйтмәде, бары тыңлады гына. Саубуллашканда хуҗа хәйләкәр рәвештә:

— Углым, син мөридебезгә указ көтүең турында сөйләгәнсең,— диде.— Әмма укудан мәгънә тапмаганлыктан, без синең мәдрәсәне ташлавыңны беләбез. Хакимнәргә хезмәт итүче мөфтидән, Диния назарәтеннән указ алучы кеше халыкның рухи җитәкчесе була алмый. Вәгазьче изгелек таратуда ирекле. Яхшылык, изгелек хакимнәр боерыгы буенча барлыкка килми, ул — кешенең табигатендә яши.

Урамда аңына килгәч, Габдулла әле берничә минут элек кенә аңгәмә тылсымына бирелеп утыруына гаҗәпләнде. Ул әле хәзер дә татлы исереклектән арынып бетмәгән, ләкин изге хәзрәтнең мәдрәсәне ташлауны хуплавын хәтерләп, елмаеп куйды. Аһ, адәм балаларының туганлыгы турында кем генә хыялланмый икән! Изге хәзрәтләр дә, Габдулланың дуслары да. Әмма соңгылар яңалыкка омтылып яши, чөнки иң яхшы тәртип тә тора-бара үзгәртелергә тиеш. Вәиси фиркасе исә, киресенчә, иске тәртипләргә таяна. Хәтта иң шәп традицияләр нигезендә дә бөтенесен берләштерү мөмкинме икән соң?

Ул Мөбәрәк хәзрәт белән күрешүе хакында Фатихка берничә көн аны-моны эндәшмәде, аннары гына чишелеп китте.

— Бик кызык,— диде Фатих, күзләрен корректурадан алып.— Ниләр турында гәпләштегез соң? Фирка турындамы?

— Мин үзем тыңлап кына утырдым.

— Мин ул мәзһәпләргә — мөселманныкына да, бүтәненә дә дошманлык белән карамыйм. Бунтарьлар алар, ә бу исә, ни әйтсәң дә, игътибарга лаек. Ләкин мәзһәпләр кешеләрне тормыштан аера...

— Алар берләшү турында сөйли.

— Әйе, алар өметләнә. Әмма вакыт узу белән, теләсә кайсы шундый фирканең сафлары сирәгәя. Бу кешеләрнең дингә ышануы бетүдән дә түгел. Алар мондый йомыкыйлыкка чыдый алмыйлар. Ачлыкка да, суыкка да, түбәнсетүгә дә чыдыйлар, ләкин йомыкыйлыкка, чикләнгәнлеккә — юк.

— Гаҗәп, хакимнәрнең борын төбендә, зур бер шәһәрдә аларга буйсынмауны максат иткән оешма яши. Вәисичеләргә тимиләр, шул ук вакыт безне...

Фатих көлеп җибәрде:

— Алар байлар белән ярлыларны аерып карамый, бу үзе үк инде хакимнәр карашынча, әйбәт сыйфат.— Аннары чырае караңгыланып дәвам итте: — Ул фиркачеләр язмышын бер заман безгә татырга туры килмәгәе әле.

— Безне нинди дә дини фанатиклар белән бутау мөмкинмени?

— Мондый уй полиция департаменты башына килми калмас, әгәр инде килергә өлгермәгән булса... Хәвефле фараз кылулар бар. Парижда Хаҗи-Теләши дигән берәү «Мөселман» дигән русча журнал чыгара башлаган. Ул Рәсәй мөселманнары арасында шулкадәр ачыктан-ачык пан-

исламизм вәгазьли ки. Печән базары каһарманнары аның янында мескен генә булып кала. Теләшине безнең кешеләрдән берәү дә белми, әйтүләренчә, провокатор имеш.

«Милләтчеләрдән кем дә булса шуңа килеп капса, погромга юл ачыла икән»,— дип уйлады Габдулла.

— Шәрәфләрнең хәле ничек соң? — диде ул, алар өстендә куерган болытлардан хәвефләнеп.

— Бердәнбер котылу юлы — типографияне үз кешеләребездән берәрсенә сату гына калды инде. Тик төшенкелеккә бирелмик әле,— дип елмайды Фатих.— Галиәсгар журнал чыгару мәшәкатенә керешкте. Алла кушса, рөхсәт бирерләр. Син, әйдә, ял ит әле хәзер, ә мин корректураны карап чыгыйм.— Ул шулай дисә дә, нидер әйтергә теләгәндәй, алдында яткан газета битен арырак этеп куйды.— Ярар, бар әле син.

Габдулла торып үз бүлмәсенә кереп китте. Фатихның нәрсәнедер әйтеп бетермәве күңелне кыра, әмма ул болай да дусларының яңа хәвефле хәлләргә юлыгырга ихтималлыгын төшенә иде... Аны шул күңелсез нәрсәләрдән читтә калдырырга телиләр иде, күрәсең.

Инде июль бетеп килә, әмма Казан арты кырларына әле бер генә яңгыр тамчысы да төшкәне юк. Газета хәбәрләре дә, авылдан килгән хатлар да, шәһәрдәге сөйләшүләр дә хәвефле иде. Әллә нинди шомлы кызгылт томан йөзгән көннең һавасы эссе, коры һәм күңел сыкратырлык. Болак тәмам кибеп беткән, аннан куе сасы ис аңкый. Кул кырыйлары саекты, аның ләмле суына кармак салып маташкан малайлар да бушка гына азаплана иде. Төннәр дә интектергеч бөркү.

Өчиледән Кәбир мулла килеп чыкты. Ул вафат булган атасы — Габдулланың бабасы мәхәлләсендә калган иде. Сөйләвенә караганда, элек тә ярлы авыл хәзер тәмам пошаманга чумган. Ул Габдулладан ике генә яшькә олы, бераз салмаклана төшсә дә, һаман житез, сүзчән, өметсезлеккә бирелмәгән иде. Габдулланың кыяфәтенә исе китте: ябык, чандыр, сары суккан, йөткерүе дә ямьсез.

— Кара әле, энем,— диде ул,— минем монда эшем күп түгел, кибеткә кереп кадак кына алам. Шуны эләктерик тә, әйдә авылга! Яңа өемне дә күргәнең юк, хатынымны да. Берәр атна иркендә яшәрсең, сөт эчәрсең, аннары үз көеңне үзең карарсың.

Габдулла ризалык бирде. Абыйсы йомышын йомышлаган арада киенде, күршедәге кибеттән күчтәнәч сатып алды, аннары кичке сәгать дүртенчеләрдә, яктыда кайтып житәргә исәпләп, юлга кузгалдылар.

Шәһәр читеннән үк киң кырлар башланып китте, тик алар саргайган, күңелсез соры тузанга күмелеп әлсерәгән иде. Ачулы шаяру белән искән җил тәбәнәк иген сабакларына тими, тисә дә, саксыз гына орынып дулкын йөгертә дә тагын күккә менеп уйнаклый башлый. Юлның юл буена күз алдында һаман шул кызгылт эссе томан эленеп торды, тирә-якта ни кеше, ни бүтән җан иясе очрамады — бушлык та бушлык.

Кичке эңгердә авылга кайтып життеләр. Капка төбендә аларны яшь килен — сөйкемле, тере хатын каршы алды.

— Хуш киләсез! Кунак төшсә — йортка ямь, әйдәгез, әйдә!

Капка әйтерсең лә үзеннән-үзе ачылып китте, ишегалды күләгәсендә тагын бер яулыклы сын күзгә чалынды, ул өйгә кереп барганда хужа хатын:

— Мәйсәрә, Мәйсәрә дим, самавыр куй, җәтрәк кайнаш! — дип кычкырып калды.

— Менә шундый инде минем җәмәгать,— диде Кәбир мулла көлемсерәп, әмма горурлык белән.— Көннең көн буе өйдә кыңгырау чыңлый шикелле.

Кичке чәй әңгәмәләр, хәтерләүләр белән кушылып озак дәвам итте. Ашау-эчүдән соң мәлҗерәбрәк киткән Габдулла йокы баскан хәлдә елмаеп һәм рәхәттән изрәп утырды. Аңа урынны кече өйдә җәйделәр. Башы мендәргә тиюгә, ул йокыга да талды.

Иртән ул күзен ачканда, абыйсы өйдән чыгып китәргә өлгергән иде инде — бакча тирәсен төзәтә икән. Чәй эчкәч, ул да абзар-кура артына атлады һәм алача күлмәк-ыштан, киң кырлы киез эшләпә кигән, кулына балта тоткан ир-атны күреп алды. Бәрәч, абыйсы шул икән ләбаса!

— Көтүлек янәшәдә генә, бәла,— диде ул зарланып.— Сыерлар безнең бакчага керергә генә тора.

Абыйсы, юкәне бөтереп, сайгакны казыкка бәйләргә җыенганда Габдулла ярдәмгә килеп:

— Нишләп мине дә уятмадың? — диде.

— Үзем дә рәтлим мин аны. Ял итәргә кайткан кеше бит син.

Киртәнең эшен төгәлләгәч, ул балтасын билбавына кыстырды һәм энесенә күз кысып:

— Ә хәзер түбәне буярга вакыт,— диде.

— Мин дә булышыйм.

Түбәгә икәүләп менсәләр дә, Кәбир мулла кунагына эш бирмәде, тар басманы күчерә-күчерә, озын саплы пумаласын ипле йөртеп, ялгызы гына буяды. Габдулла исә бер читтә әле утырып, әле ятып тирә-якны күзәтте. Абыйсы аны түбәдән төшәргә үгетләде:

— Шулай да бар әле син, нәнә, күләгәдә утыр, монда башыңа кызу сугар.

— Бергә инде!

— Минем тагын бүтән эшләрем дә бар шул әле.

Авыл имамының мәшәкатьләре башкаларныкыннан һич ким түгел. Ул үз җирен үзе сукалый, чәчүне үзе чәчә, уракны үзе ура, печән чаба, эскертли, мәхәлләсендәге малларны да, халыкны да дәвалый, кечкенә мәдрәсәсендә балаларга сабак бирә, кичләрен ата-аналарга вәгазь сөйли иде. Кайбер ир-ат мәчеттән чыккач та хәзрәттән калмый: укымышлы кеше белән гәпләшергә, киңәшергә тели. Кәбир мулла әдәп белән җавап бирә, әмма үзе мондый аралашудан йончый иде.

— Миңа болай тел тегермәне корганчы, тимерчелектә чүкеч селтәвем әйбәтрәктер юкса. Кайбер муллаларга акыл сатарга гына булсын. Вулыста очрашкан чакларда гәпләре таңга чаклы сузыла. Иман кимергә яки артырга мөмкинме? Ни өчен фәлән тегеләй, фәлән болай? Ә минемчә, иман бар икән — бар, юк икән — юк.

Габдулла көлә. Аңа абыйсы ошый. Болдырда аның белән туйганчы сөйләшкәч, үз ягына керә. Әмма йокысы килми әле. Ачык ишектән тыныч, куе караңгы күк, берсеннән-берсе җетерәк җемелдәгән йолдызлар күренә. Аларның берсе аңа балачактан таныш. Ишектән кыр исләре, авылга гына хас тузан исе килә, шәһәрнекенә бөтенләй охшамаган кыштырдаушыштырдаулар, өзек-өзек сүзләр, авазлар ишетелә. Туган якның сулыш кебек үз һәм гади авазлары!

Әмма һәр туган яңа көн белән калага, өнәмәгән ыгы-зыгыга, тарлыкка, шау-шуга сусавы да һаман арта бара. Инде менә иртәгә абыйсы белән юлга чыгам дигәндә генә ишегалдына бер яшүсмер килеп кермәсенме. Аксыл йөзендә кара керфекләреннән төшкән күләгә уйный, әле борын астыннан төк бәреп чыгарга да өлгермәгән эчкерсез кыяфәте бөтенләй бала гына итеп күрсәтә үзен.

— Мин Әмир атлы,— диде ул,— Иж-Бубый мәдрәсәсендә укыйм. Габдулла абый, белдерергә рөхсәт итегез: безнең шәкертләр шигырьләрегезне шундый ярата, әгәр мин аларга сезнең белән очрашуымны әйтсәм, валлаһи, ышанмаячаклар. Без мәдрәсәдә кулъязма журнал чыгарабыз...

— Хәзер үк таны,— дип шаяртты Габдулла,— үзең дә шигырь язасыңмы?

— Әйе.

— Сөбханалла, бик әйбәт!

Шәкерт чагы, иптәшләре белән кулъязма журнал чыгарулары, илги-

зәр шагыйрь Чулпаныйны очратканда дулкынланулары, гадәттән тыш киләчәк турында хыялланып йөрүләре ерак калдымыни соң әле? Ул үсмер якташына, көтмәгәндә сәламәт фикер йөртә башлаган энесенә, абый кеше караган кебек шатлык катыш гаҗәпләнеп һәм ышанып, тансыклап күз текте:

— Без мәдрәсәдән чыгып киткәндә өем-өем кулъязма журналлар калдырган идек,— диде ул.— Ә сез хәлфәләрегездән канәгатьме соң?

Иж-Бубыйда акыллы һәм намуслы кешеләр эшли, алар яшьләргә дөньяви гыйлемнәр бирә, мәдрәсәдә рус вә бүтән Европа телләрен укытуны яклый иде. Кадимчеләр исә бу мәдрәсәне ничек хурларга белми.

— Бездә былтырдан бирле туган әдәбиятыбызны укыта башладылар,— диде Әмир.— Түземсезлек белән сез төзегән мәҗмуганың тизрәк басылып чыгуын көтәбез.

Алар ике сәгать чамасы әңгәмә кордылар бугай. Саубуллашканда Әмир аңа бер дәфтәр сузды.

— Мин сезгә үз шигырьләремне күптән күрсәтергә тели идем дә, һаман кичектерә килдем. Менә «Шильон тоткыны»н гына тәрҗемә итеп бетерим инде, дип уйлый идем.

Габдулла гаҗәпләнеп:

— Ә нигә нәкъ менә «Шильон тоткыны»н? — диде.

— Сез көлмәгез инде,— диде яшүсмер.— Миңа үзебезнең басынкылык ошамый, чарасызлыгы өркетә. Хөррият дип кычкыруларыбыз да чын күңелдән түгел. Аны сүздә генә таләп итәбез, үзебез аңардан куркабыз, чөнки ирексезлеккә күнеккәнбез инде. Без дә, Шильон тоткыны кебек, үзебезгә турылыклы түгел...

— Ихтимал. Бу турыда артык кискен фикер йөртәсең йөртүен. Ләкин,— диде ул елмаеп,— мин тәрҗемәңне түземсезлек белән көтәрмен.

Иртән абыйсы ат җигеп йөргәндә ишегалдына Әмир килеп керде. Агарынган, дулкынланган йөзенә караганда, ул төне буе керфек какмаганга охшый иде.

— Мин сезгә, Габдулла әфәнде, кичә иң әһәмиятлесен әйтмәгән идем... Әткәй укуым өчен түләүдән баш тарта, мәдрәсәне ташлавымны тели, фетнә йоктыруың болай да җиткән инде, ди.

— Нишләп кирегә сукалый соң атаң? Бүтән мәдрәсәгә күчүеңне телиме?

— Ул мине өйләндереп башка чыгармакчы була. Ә мин...

— Менә тиле, менә тиле,— дип көлә-көлә Кәбир мулла да сүзгә кушылды.— Аңа ирек тәкъдим итәләр, энекәш баш тарта, имеш. Андый бай этием булсамы...

Әмир комач кебек кызарынып:

— Мине байлык кызыксындырмый,— диде.— Күңелем тартмый минем.

Габдулла аның янына килде дә, иңбашына кагылып:

— Курыкма... вөҗданың кушканча хәл ит,— диде.— Сиңа Казанга килергә кирәк. Шунда мине дә эзләп табарсың, кадәри хәл булышырмын.

...Редакциядән кайткач, Габдулла иркенләп ачык тәрәзә буена утыра һәм, кунакханә алдында тарантаслар, фәйтүннәр килеп туктавын, алардан кемнәрнеңдер ашыга-кабалана сикереп төшеп, капкадан кереп китүен, икенчеләрнең шулай ук ашыгып арбага утыруларын һәм дәртле каты тавыш белән извозчикка: «Кузгал!» — дип боеруларын күзәтә-күзәтә, көндезге ыгы-зыгыдан суына башлый иде.

Беркөнне ул кунакханәләре каршына кәләпүш кигән бер юан мәһабәт кешенең тарантаста килеп туктавын күреп, башын борганда кунакның Хәсән әфәнде икәнлеген танып алды. Үзен утарына чакырып кунак иткән фабрикант. Өч минуттан ул инде тирен сөртә-сөртә аның бүлмәсенә кереп, уңайсызлануын юрамалый көлүе белән яшереп:

— Әссәламегаләйкем! — дип исәнләште.— Уф, минем яшьтә мондый баскычлардан күтәрелү дә көч икән.

Габдулла аны каршы алып урындык тәкъдим итте дә кизүдән самавыр китерүне үтенде.

— Шуның янына берәр төрле ризык, пәрәннекме шунда кирәк булыр,— диде ул.

— Уһу, иркен яшисез икән,— диде Хәсән әфәнде,— пәрәннекләр белән дә сыйлый алгач. Миңа бер касә чәй дә бик җитәр үзе. Эссесе, ай-һай, сентябрьдә дә җәһәннәмдәгечә! Сез тартыгыз, тарт, улларым да шулай үзләрен сигарет белән интектерә. Әһә, менә чәй дә.

Кунак шикәрне тешләп кенә каба, зур яулыгы белән битләрен сөрткәндә дә эшлекле мышнавыннан туктамый иде. Сусавын баскач, ул чынаягын тәлинкәсенә каплап куйды һәм өстәлдән читкәрәк авышып утырды.

— Без хәзер Зөябашта һәр кичне сезнең шигырьләрне укырга күнегеп киттек әле, Габдулла әфәнде. Оныкларым ятлап та ала, колакка ягымлы матур-матур әсәрләрегезне балаларның мавыгып укуы үзе бер хозурлык. Ходай тәгаләнең балалар өчен махсус китаплар чыгаруны нәширләребезгә эшкәртүе дә хәерле фал.

Габдулла мондый дәрәҗәле кунакны нәрсә китерде икән, дип баш ватып, әһәмиятсез рәвештә:

— Әйе, әйе,— дип раслаган булды.

— Без, ходайга шөкер, үз матбугатыбыз, менә дигән үз каләм әһлебез җитешкән бәхетле заманга тап булдык.

Эшлекле байның шул кадәр тасма телләнүе сәеррәк иде. Идеалист кешеме икән әллә ул?

— ...Милләтебезнең чәчәк атуы өчен киң юллар ачыла, озакламый Рәсәйнең бөтен Азия кыйсме, Җаектан алып Һират каласынача бөтен җир безнең промышленниклар һәм сәүдәгәрләр кулында булачак. Хөкүмәт кайчандыр калын таш диварлы ныгытмаларын корган җирләрдә хәзер тыныч мөселман бистәләре барлыкка килде. Оренбур, Җаек, Умбы, Троицк — без бөтен җирдә мәчетләребезне, кәрвансарайларыбызны, фабрикаларыбызны аякка бастырдык... Казанда басылган китапларыбызны империянең дистәләгән халкы алдырып укый.

Казан татарлары турында дәртләнеп, горурланып сөйли иде ул: Идел буе болгарларының дәвамы буларак, алар борын-борыннан утрак тормышлы, шәһәр мәдәниятенә, бай традицияләргә ия китаби халык. Төп бишекләре Казан арты булса да, кәсеп итәргә хирыслыгы аркасында, алар Әстерхан вә Оренбур, Уфа вә Умбы, Симәй вә Голҗа кебек терәк нокталар булдырып, борынгы кәрван юлларын җанландырып, ислам мәдәниятен таратырга керештеләр. Идел буе төрки теле хәзер Идел-Урал, Төркестан киңлекләренең латинына әйләнеп бара. Хакимнәр моңа борчыла борчылуын, әмма алар татар йогынтысын һәрвакыт дала халкын Рәсәйгә багындыру өчен файдаланып килде ләбаса.

— Шуны да истә тотыгыз, инде менә йөз илле елга якын мөфти вазифасын Казан муллалары гына алып килә. Кыскасы, Казан татарлары мөселман милләтенең умыртка сөягенә әйләнеп бара, Габдулла әфәнде.

— Андый милләт юк, Хәсән әфәнде,— диде Габдулла тыныч кына.— Казанлылар инде күптән үзенә бер аерым халык булып калыплашты, телләре дә үзләренә генә хас татар теле. Гади игенче, эшчегә сез күздә тоткан төрки тел шактый ук ят, хәтта зыялыларыбыз да аны куллanudan хәзер баш тарта, шул сәүдәгәрләргә, промышленникларга хезмәт итсә генә инде. Әгәр бу җәһәттән минем фикеремне ишетәсегез килсә, каләм иясе буларак, мин әдәбиятыбызның гади кешеләргә — эшчеләргә һәм игенчеләргә аңлаешлы телдә иҗат ителүен хыялланам. Ышануымча, мондый көннәр килеп җитте дә инде.

Хәсән әфәнденең йөзе караңгыланды, әмма ул каршы төшмәде.

— Дөрес. Шигырьләрегезне укыганда мин дә телебезнең шул кадәр байлыгына, аһәңлелегенә иман китерәм. Авыр көрәшләрдә без үз

динебез, үз мәдәниятебезне саклап кала алдык, хәзер инде менә милли капиталга да ия булдык. Капиталсыз шул кадәр гәзит-журнал бастыра алган булыр идекмени? Аһ, әгәр сез нәфис тел белән мөселманнарга аллаһ тәгалә хупларлык саваплы эшләрне бәян итсәгез икән! Тәрәккый хакында! Бәлки ул чакта кайбер руханилар ислах — үзгәртү, төзәтү белән мавыгуларын бераз киметерләр иде. Менә Муса Бигиевне генә алыйк. Нәрсәләр турында язып саташа ул?

Габдулла елмаеп җибәрде: хәйләкәр Муса әфәнде гарептә гыйлем үсү хәзерге заман кешеләренең мәгълүматы артуга бәрабәр рәвештә Коръән эчтәлеген дә үзгәртергә кирәк, дип раслый иде. Истанбул шәйхелисламы аның китапларын гөнаһлы сафсата дип игълан итте.

— Ә сез моңа ник кайгырасыз, Хәсән әфәнде? Коръәнне ирекләрәк аңлатканда тормышның теләсә кайсы ягын, әйтик, хатын-кыз тиңлеген, бүтән диндәге кеше белән дусларча бәйләнешкә керүне дә ислам дине кануннарына сыйдыру мөмкин булачак. Үз эшегездә сезгә дә каферләр белән аралашырга туры килә ләбаса. Яңа шартларга җайлашса, ислам көчәячәк кенә — Бигиев китаплары шуңа хезмәт итә дә инде.

— Хи-хи, безгә инде сәүдә, һөнәрчелекне үстерүдә яңару да җитә. Әхлагыбызны үзгәрешсез саклый икән, без дингә болай да бик разый инде.

— Әхлагыбыз искермәде микән соң безнең?

— Бигиев язмалары кызыклы һәм файдалы дияргә җыенмыйсыздыр дип өметләнәм?

— Ул китаплар мине елмайта гына.

— Артык йомшак әйтәсез. Шуңа каршы чыгарга бер генә лаеклы фикер иясе табылмавын гына күрегез әле. Мин авыл муллаларына өметләнмим, даннары күптән таралган, алар баштанаяк кадимче — искелек тарафдарлары. Әмма менә «Әльислах» яки шундый бүтән хөрмәтле гәзитләрдә... нишләп сез Бигиевне фаш итмәскә тиеш?

— Ишаннар, мулла-мәзиннәр турында шулкадәр күп яздым ки, миңа инде оҗмах ишеге күптән шартлатып бикләнгәндер.

— Оҗмахка килсәк... Анда бәндәне муллалар гына кертми! — диде Акчурин, яклау вәгъдә иткәндәй, тәкәббер кыяфәт белән бүлмәгә күз йөгертеп һәм башын чайкап: — Сезнең талантка дөньялыкта да иркенрәк, уңайлырак яшәү мөмкиндер. Гыйсмәтуллин өенә күзегез төшкәне юкмы? Аның яртысын биләү, мөгаен, сезгә ярар иде.

— Анын хакын гасыр азагынача да түләп бетерә алмам шул.

— Ә сезгә чыгым ясарга да туры килмәс иде. Чөнки ул йортның икенче яртысын безнең акционерлар җәмгыяте алачак.

— Юк, Хәсән әфәнде, миңа шушы бүлмә дә җитеп тора.

— Анысы үз эшегез инде, үз эшегез. Яшь чакта мин үзем дә талымсызрак идем.— Ул егетләрчә аягына торып басты да, симез гәүдәсе белән борылып.— Габдулла әфәнде... Бигиев китабына сез шулай битараф карарга булдыгызмыни? — дип сорады.

— Сез аны, Хәсән әфәнде, ныклап тетәргә, тиргәргә кирәк дип уйлыйсыз бугай...

— Әлбәттә!

— Сезгә мине аңлау, ихтимал, кыенрактыр. Фабрикант кеше мал ала да мал сата...

Хәсән әфәнде аны тыңлап бетерми саубуллаша башлады:

— Әңгәмәбез ифрат та хозур узды. Зинһар озатып мәшәкатьләнмәгез.

Хәсән әфәнде яны белән чыкса да, ишек яңагына ышкылмый уза алмады. Хәтере таралуданмы, ишекне ябарга да онытты. Берничә минуттан кизү егет килеп кереп, самавыр, чынаякларны җыя башлады.

— Гаҗәп! Яңа пешкән булса да, перәннекләргә кагылмагансыз икән, әкәмәт.

Габдулла перәннекләрне төргәге белән егеткә сузды, кизү юмарт хуҗага бөтен йөзе белән балкып:

— Рәхмәт, менә әкәмәт! — дип күздән югалды.

Казанга Никитин циркы килде. Көрәштә могҗизалар күрсәтүче Карәхмәт турында дистәләгән газеталарда алдан ук игъланнар басыла башлады, коймаларга аршын хәрефле белдерүләр ябыштырылды. Печән базары халкы баһадирны күк капусы ачылуын көткәндәй зарыгып көтеп алды.

Кунакханә коридорында беренче тапкыр очрашканда Габдулла пәһлеванны Ассурбанипалга тиңләгәндәй карап торды. Иркен күлмәк, дәү төпле ыштан, кызыл чуклы фәс кигән кабартма яңаклы, киң күкрәкле бу баһадир алпан-тилпән атлап килгәндә һәм пошкырып сулыш алганда, каршысына очраган теләсә кем читкә кагыла, як-яктагы ачылыбрак торган ишекләр исә аның сулышыннан ябыла иде. Коридорның аргы башына барып җиткәч тә ул галәмәт зур гәүдәсе белән риваятьләрдә хикәяләнгән Салсалны, халык теленнән төшмәгән Алып батырны хәтерләтә иде.

Габдулла үз бүлмәсенә кереп бикләнгәч, бу дәһшәтле куәт иясен шундук онытты, төнке тынлыкта язарга җыенып, бераз черем итәргә ятты, кичке эңгердә уянгач, ул тагын Карәхмәтне күзаллады һәм көрәш шау-шуын ишеткәндәй булды. Ирексездән көлеп җибәреп башын чайкады, сикереп торды да тәрәзәгә йөгереп барды. Шаккатып һәм яхшы ук өркеп, минуты белән аннан кире чигенде: кунакханә алдындагы мәйдан халык белән шыгрым тулган, анда меңләгән баш тирбәлә, гөж килә, инде аерым тавышлар, кычкырулар ишетелми, татлы газапка бирелгән иләмсез зур гыйфрит ыңгырашкандай, бердәм гүелдәү генә яңгырап тора иде.

Иртән уянса — тагын шул ук хәл, әмма хәзер инде агарынган, суырылган кайбер йөзләрне аерырга мөмкин иде. Печән базары ягыннан аларга яңадан-яңа төркемнәр килеп өстәлә тора, алар барысы бергә җанланып һәм рухланып:

— Гали батырыбыз! Әй кодрәтле раббыбыз, каферләргә дәһшәт салыр өчен терелткәнсең икән син аны!..— дип тәкрарлыйлар.

Кичке дүрттән сигезгә чаклы гадәттә, ресторан ябыла. Тик хәзер нәкъ дүрттә генә йокысын туйдырган Карәхмәт шунда сыйланырга керә һәм сәгать җидегәчә утыра, аннары гына циркка юнәлә иде.

Капка төбендә аны Печән базарының иң могтәбәр затлары көтеп тора, шулар озатуында Карәхмәт дөбер-шатыр килеп туктаган трамвайга кереп утыра иде. Ике тукталыштан соң трамвайның көче бетә дә туктый. Печән базары каһарманнарының йөзәве дә аны урыныннан кузгата алмый иде. Бервакыт миллионер Сәйдәшев атларын сорап тордылар. Киң күкрәкле, нык бәдәнле айгырлар. Мәшһүр батырны миллионер үзе атландырды. Икенче мәхәлләгә килеп җитүгә, айгыр зарлы кешнәп, ал аякларына егылды. Шунда ук икенче атны җитәкләп китерделәр. Карәхмәт циркка барып җиткәнче, менә шулай дүрт тапкыр ат алыштырдылар: чиксез шатланган халык төркеме батырны гөмбәз эченә күтәреп алып керде. Бу көнне Карәхмәт бер-бер артлы өч йөз көрәшчене күтәреп бәрде. Шуннан соң:

— Бүтән булдыра алмыйм,— дип алышны туктатты. Моның сәбәбен: — Юкса куанычтан нишләргә белмәгән тамашачылар шартларга мөмкин,— дип аңлатты.

Залдагы Печән базары әһеле: «Абау бу көч, абау бу изгелек! Аһ, бу изгелекнең куәте, аһ, бу куәтнең изгелеге!» — дип ыңгыраша иде.

«Кисекбаш китабы»н ул балачагыннан ук хәтерли иде. Бервакыт Мөхәммәт пәйгамбәр үзенең дүрт яраны һәм утыз өч мең мөриде белән гәпләшеп утыра икән. Шул чак аның хозурына киселгән бер адәм башы тәгәрәп килгән дә ярдәм сорап ялвара башлаган: явыз дию

аның гәүдәсен һәм улын кабып йоткан, хатынын тартып алган да тирән коега төшеп чумган. Пәйгамбәрнең кияве Гали батыр шул минутта ук, тылсымлы кылычын — зөлфөкарын тотып, качыры Дөлдөлгә атлана да сәфәр чыга. Ә, әйе, ул әлеге бәхетсез башны күтәрмәкче була, ләкин аңа тулган изгелек шулкадәр күп, салмак имеш, арысландай Галинең дә дәрманы җитми. Шунлыктан баш — җирдән тәгәрәп, Гали аның артыннан бара. Бер заман алар чүлдәге әлеге кое янына килеп җитәләр.

Шуннан соң нәрсәме? Баһадир дию белән алыша һәм явыз гыйфритне җиңә, ә пәйгамбәр өшкерүгә, кисекбашның гәүдәсе кире кайта, улы белән хатыны да терелә... Мәзәк, хыялый кыйсса. Халык иҗатында моңардан да кызыклырак, искиткечрәк вакыйгалар тасвирлана. Карәхмәт исә әкият кенә түгел, җаны-тәне, төсе-бите бар чын көрәшче. Печән базары каһарманнары шуларның барысыннан илһам алып, күз алдындагы тамашаны тылсымга урап хисләнә, хәрәкәткә килә иде.

Боларның барысы хакында «Әльислах» редакциясендә дә гәп кабына, әкият, риваять, хыялдан чын тормышка күчәләр, хатын-кызның әкияттәге кодрәте, тормыштагы бичаралыгы, җәберләнүе турында фикер алышалар. Әкиятләр барлыкка китерелгән заманда халык әле дин йогынтысына артык бирелмичәрәк, хөрриятләрәк яшәгән, шәхес ирегенә күбрәк юл куелган.

Гастрольләрдән кайткан арада редакциягә Миңлебай да кергәли, кайвакыт тормышта оялчан, сәхнәдә чая хатын-кызга әйләнә торган яшь кәләшен дә ияртеп килгәли. Габдулла ул чибәркәйдән:

— Моннан соң тагын кая барачаксыз? — дип сораша.

— Башта Сембергә. Аннары Уфа, Оренбур, бәлки Умбыга да юл төшәр. Күптән түгел бер әкәмәт хәл булды әле бездә... Тик Кариев үзе сөйләсен әнә...

— Ә, син теге нотыкчы турындамы? Без ул көнне «Бичара кыз»ны куя идек, әфәнделәр. Халык ишелеп килә, урам авыш, тамашачылар түбәнге яктан агыла. Берзаман үрдә пинжәген җилбегәй җибәргән, кулларын як-якка җәйгән берәү калыкты да кычкырып мөрәҗәгать кылмасынмы: «Әй, сез, мескен язмышыгызга ачынып үксүчеләр! Барыгыз, милли язучыларыгызның яшь түктерә торган елак пьесаларын карагыз! Хәтта сыерлар да, көтүче курайда уйнаганда, бавырларын ләззәтләндерә торган музыка тыңлап рәхәтләнә. Сез дә, алла коллары, мөгрәүдән туктагыз, миләрегезне кыймылдатыгыз. Кайда сезнең Ибсен, кайда Шекспир, Мольерларыгыз?»..

— Минем кулга килеп эләгәсе калган аның, валлаһи! — ди Галиәсгар шаярткан кебек, әмма кайнарланып.— Нәрсә, ул безнең туган әдәбиятыбызда дөньяви берни дә күрмимени?

— Нигилист! — диде Фатих көлеп. Кыяфәтенә караганда, ул бик канәгать иде.

— Нигилистлар гына җитми инде безгә,— дип нәфрәтләнде Кариев.— Барын да инкяр итүчеләрне женем сөйми.

— Нигилистлар күбрәк булсын иде әле,— диде Ямашев.

Аңа гаҗәпләнеп, янә нидер көтеп төбәлделәр, тик ул инде торып саубуллаша башлады. Габдулла да аның артыннан ук бүлмәдән чыгып китте һәм урамда Ямашевны куып җитте.

— Сез, нигилистларыбыз азрак дип пошынган сыман әйттегез. Бу — бәхәстә кызып китү генәме?

— Һич тә. Мин моны тагын бер кат кабатлый алам: күбрәк булсын иде алар. Сез мине дөрес аңлагыз: безгә инкяр итү рухы җитенкерәми. Барыбызда да әллә нинди чамадаш тыш балалык шаукымы.

— Нигилизм үзе дә балалык чире бугай?

— Эш атамада гына түгел. Икеләнүчелек, җитлекмәгәнлек, кыюсызлык кендегебезгә береккән. Буш хыялларга бирелеп, үзебезне нәни уңышлар белән дә юатабыз.

— Бишенче елда, чыннан да, юандык,— диде Габдулла.— Үземә килгәндә, мин аларга озак ышанмадым. Хәзер инде менә ничәнче ел муллалар, сәүдәгәрләр, депутатлар белән тиргәшәм. Ләкин моннан ни үзгәрде соң? Хәзер безне ислах нәтиҗәсендә ирешкән чамалы гына хокуклардан һәм казанышлардан да мәхрүм итәләр, тагын эзәрли башладылар...

— Эзәрлиләр, үҗәтләнәләр, тик ни өчен? Үзләренең зәгыйфьлеген тойганга, халыктан, аның уянып килгән аңыннан курыкканга ул. Без нәрсәгә ирештек, димәкче буласызмы? Халыкның күзе ачылуга, әкренләп булса да күзе ачылуга ирештек.

— Шулай да, миңа калса, милли өметләр турында сүз кузгалганда, сездә ниндидер өнәмәү пәйда була шикелле.

— Әй, Габдулла,— диде Ямашев шелтәләп һәм моңаеп,— сезнеңчә, туган җырларыбыз, әдәбиятыбыз һәм башкаларыбыз миңа ят инде, ә? Әллә мин сезнең сызлануларыгызны аңламыйммы? Халкыбыз кайгы-хәсрәтен, аның өмет-хыялларын, милли рухын гәүдәләндергән әсәрләрегезне мин арада ныграк яратам лабаса. Халык гаме чагылган әсәрләрегезне аеруча! Мин моны юкка гына әйтмим. Замана шәрехләрен, замандашларыбызның моң-зарын чагылдырмаган әдәбиятның поты бер тиен. Кайбер укымышлы яшь-җилкенчәк, Хөсәенгә аңа революция генә булсын, дип тә уйлыйдыр. Ә миңа менә революциянең исе дә килмәгән «Шүрәле» әкиятегез ошый. Хәер, нигә аннан революция исе килмәскә тиеш соң әле? — диде ул хәйләкәр карашын юлдашына төбәп.— Әгәр сез бизәкле-чачаклы аһ-уһларга бирелеп, халык-көнкүрешеннән, аның хезмәт шигърияттеннән, юанычлары һәм уй-хыялларыннан качмыйсыз, иҗатыгызны халык тормышы белән сугарасыз икән — революция төшенчәсе киң — миңа әкиятләрегез дә бик җитди күренергә мөмкин. Ул милләтнең рухын, узаңын күтәреп, аңа ук хезмәт итә лабаса.— Аннары Ямашев көлеп: — Әйе, мин шундый төзәлгесез инде,— дип өстәде.

— Мин сезне, Хөсәен, әнә шундый максатка омтылучан булуыгыз өчен бәялим дә инде. Күпләребезгә нәкъ менә шул сыйфат җитми бугай...

— Аннан тыш, вакыты да кысан әле аның,— дип шаяртты Хөсәен.— Үпкәләмәгез, мине хәзер эшләрем ашыктыра, йөгерәм.

Ул шагыйрьнең кулын нык кысып саубуллашты да, башкаларны җитез генә әйләнеп уза-уза, күздән югалды.

Габдулла соңгы вакытта тормыш тулылыгын, аның барлык үзгәрешләрен һәм каршылыкларын шулкадәр көчле, шулкадәр газап-шатлыклар аркылы тоя башлады ки, аннан да бигрәк, ул боларны нәкъ менә үз тормышы, үз чынбарлыгы итеп шулкадәр кабул итте ки, инде күптән пәйда булган шигъри роман язу уе аны элеккедән дә битәр дулкынландыра башлады. Әйе, ул гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, хезмәт һәм аның ачы бәхете турында зур итеп, киң итеп яза алыр. Карәхмәт белән акылдан шашу үзе генә дә күңелле, усал, мыскыллы бер дастаный әсәргә азык бирә лабаса. Язылачак романда шәһәр дә, Кырлай басулары да, шагыйрь егет тә, саф күңелле уйчан кыз да, бөтән катлау кешеләре, Печән базары һәм Кисекбаш та гәүдәләнергә тиеш.

...Ниндидер бер минутта ул аның яралгысы аваз бирүен, аның дәвамы оеткылануны, күңеле алгысынуын, шул минутларны кулдан ычкындырмаска тиешлеген аермачык тойды. Башта ул үзен ашыгу-кабаланудан, алданудан сакларга тырышып маташты, тик инде иртәгәсен күкрәгән җилкеткән көчкә берничек тә карыша алмады — кәгазь битләренең берсе арты икенчесен сырларга тотынды. Әсәрне уртасыннан башлавын ул тиз генә абайламады. Колагында Печән базары гүелдәве — арбалар шыгырдавы, атлар кешнәве һәм үгезләр үкерүе, сатучы белән алучы тарткалашуы, алдаучының канәгать көлүе һәм алданучының ачулы тавыш белән сукрануы, халыкның ниндидер гаҗәп нәрсәгә аһ-уһ килүе яңгырап тора иде! Урам ташлары өстеннән сикерә-сикерә бер чалмалы баш тәгәрәп килә дә базарның могтәбәр абзыйлары хозурына

житкәч, ачыйгыланып аваз сала: «Баштан үткәнне сөйлимен, тыңлагыз...» һәм Кисекбаш кайнар күз яшьләрен чыжылдатып урам ташына тамыза.
Печән базары картлары киңәш-табыш кыла башлый:
— Бичарага ак патша солдат җибәреп булышмасмы икән?
— Бәлки аны яклар Садрый Максуди? Без аның өчен күп тырыштык шар салып. Ахырында Думага да сайладык.
— Я булмаса Камчылы ишанга барыйк. Азмыни ул бездән сәдакалар алды. Диюнең, бәлки, сихерен кайтарыр.
Аһ, юк! Бу бичара мөселманны аларның берсе дә яклый алмаячак, Карәхмәт тотынса гына инде... Чакырдылар, килеп тә житте пәһлеван, эстәде башны күтәреп бакмага, тик зәррә кадәр урыныннан тибрәтмәде; чөнки бардыр мең пот искелек бу мидә, ишәк кирелеге, наданлык, мин беләмлек дәгъвасы да вагон-вагон...
Бәндәләрдән кемнең дию күргәне бар? Ул Яңа бистәдә урнашкан фирка башлыгы Гайнан Вәисигә бик охшаган — галәмәт зур гәүдәле, дәү авызлы биниһая башы — гөмбәз кадәр, башында уттай кызыл фәс тә бар, салынып төшкән килешсез мыегы — билләһи, гүя күсе койрыгы. Капка башында: «Монда мәгълүм бужий фирка җания, Табигыйннәр мәзһәбе Гайнания»,— дигән яшел язу тора.
Яңа Кисекбаш кыйссасын тәмамлаганнан соң, ул бушанып калды. Моңга батып һәм хәрәкәтсез озак кына утырганнан соң ул идән буйлап арлы-бирле йөренә башлады. Әүвәл чирле кеше сыман атлады, аннары йөреше җиңеләя, хәрәкәте дәртлерәк рәвеш ала башлады, күңеле сөенеч һәм шатлыктан сикерергә кереште. Бераздан инде ул тагын хафаланып: «Ә соң теге уйлап куйган тагын да колачлырак нәрсәмне кайчан язармын?» — дип үз-үзенә сорау бирде.

Иртәгәсен ул гадәттәгедән элегрәк уянды һәм, чәйләп алгач, редакциягә китте. Анда әле берәү дә юк, өстәлдә типографиядән китерелгән корректуралар гына көтә иде. Ул укырга утырды һәм бер сәгать эчендә аларның эшен тәмамлагач, тәмәке кабызды — алдагы саннар өчен берни дә язарга теләмәде. Ул арада баскычта тавышлар — Борһан Шәрәфнең: «Мәрхабә, узыгыз, ул монда»,— дип кемнедер бүлмәгә чакыруы ишетелде. Аннары ишектән йөзләре алсуланган яшь-яшь ике кыз, алар артыннан төз буйлы, юнкер кебек ыспай-нәзакәтле Борһан килеп керде.
— Таныштырырга рөхсәт итегез... Юк, юк, рөхсәт итегез!
Габдулла урыныннан торып басынкы гына: «Исәнмесез!» — диде. Аны кызларның берсе — тулырак гәүдәле, әмма зифа буйлы, яшькелт-соры күзләре йомшак кына балкып торганы аеруча кыенсындырды. Гади ак батист күлмәге, яшел хәтфә камзулы һәм артка каерып бәйләнгән нәфис ак яулыгы аңа килешеп тора иде. Күпереп торган сөйкемле йөзле шушысы үзен «Зәйтүнә» дип таныштырды. Габдулла аның исемен эченнән кабатлаганда «Чү, ишетелерлек итеп пышылдамадыммы соң?» — дип тагын бер каушап куйды.
Борһан исә, рәхмәт төшкере, кызларны урнаштыргач, чәй әзерләүне үз өстенә алып кына калмады, өзми-куймый сөйләнүен дә белде. Габдулла шул арада шыпырт кына кире үз урынына утырып, кирәкмәгән корректураларны караштырды — чыгып сызарга уңайсыз, кагаеп азаплансын инде менә хәзер бүкән кебек...
Бәхетенә, оялчан кызлар үзләре дә озакламады. Кунакларын озатып кергәч, Габдулла пәриләнеп Борһанга бәйләнде: теләсә кем белән таныштырырга кем кушкан аңа, моннан соң шуны нык белеп торсын...
— Ярар, ярар,— диде Борһан көлеп.— Бик ялынгач, кире кага алмадым инде. Курсисткадар, алдынгы яшьләребез, әле җитмәсә, укучыларың... Хәер, мин монда йомыш белән ич әле. «Кисекбаш»ыңны безгә бир әле син, аерым китап итеп басарбыз.
— Мин аны журнал өчен яздым лабаса. Галиәсгарнең үпкәләве бар.

— Аның белән килештек инде без. Галиәсгар тулаем баса алмый, өлешләп, тәмен генә бетерәчәк.

— Эшкуар да инде үзең, Борһан.

— Бер атнадан кулыңа китабыңны алгач әйтерсең син: эшкуармы Шәрәфләр, түгелме. Их, җаныем,— диде ул моңсуланып,— бәлки шушы поэмаң безнең соңгы китабыбыз да булыр инде. Губернатор тәмам ерткычланды.

Аяз салкын көннәрнең берсендә Габдулланың ишеген шакыдылар. Итагатьле, әмма кыю рәвештә. Ишекне ачкач, ул приказчикка охшаган, әмма бу мәшәкатьле эш өчен өлкәнрәк булган бер намәгълүм ир-атны күрде. Агарган кашларына күләгә төшергән фин эшләпәле абзый, башын җиңелчә иеп:

— Сезне Воздвиженский урамында көтәләр. Тиз генә алып килергә куштылар,— диде.

— Кая? Ни өчен?

— Фурлетов һөнәрханәсенә. Гафу итегез... ашыгырга куштылар. Әбүзәровтер! Гусар лабаса, тарантас аласы иткәндер.

...Әйбәтләп себерелгән киң ишегалдында Габдулла толыптан, кыска мех кырпулы бүректән карт Фурлетовны һәм кабарып торган ас якалы нәфис пальто кигән бер зифа буйлы ханымны күреп алды. Ул сулышы буылып:

— Туктагыз! — дип кычкырды. Чананың туктавын да көтеп җиткермәстән, җиргә сикереп төште һәм әлеге танышына ташланды. Фирая ханым Фурлетовка бер күз сирпеп алды да көлә-көлә аңа таба йөгерде. Аның җыйнак нык аякларында кардай ак фетр итекләр иде.

— Яшермичә әйтегез әле... мин чакыртканны чамаладыгызмы? Тик дөресен генә, бары дөресен!

— Сездем ахры... тик башта мин гусар иптәшемдер, дип уйлаган идем.

— Бик әйбәт! Мин хәзер бөтен җирдә бу вакыйганы гусарга бәйләп сөйләячәкмен.

Әзрәк йончыган, ләкин шат кыяфәтле Фирая ханым, тиешле әмерләрен биреп, Фурлетов ишегалдыннан чыгып киткәндә, бәхет кошын тоткандай:

— Мин бу фәйтүнне губернатор кияве авызыннан йолып алдым,— дип пышылдады.— Менә шулай... Я, ә сез ничек яшәдегез? Нилэр яздыгыз? Басылганнарын укып бардым, билгеле. Поэмагызны, кибетләргә чыккач ук, сатып алдым. Тагын нәрсә бар иде соң әле... Ә, хрестоматия! Анда шигырьләрегездән тыш әкиятләрегез, хикәяләрегез дә урын алуы гаҗәп... «Мияубикә», «Карлыгач», «Төлке һәм йөзем җимеше» — башкаларын хәтерләмим дә инде. Илаһи шигырьләрдән соң... аңламыйм! Бәлки әкиятләр язарга, дәреслекләр төзергә мохтаҗлыктан алынгансыздыр?

Габдулла кылануны уена да китермәстән:

— Эшләгән эшләрем арасында иң юньлесе — шулар,— диде.

— Әйтмәгезсәнә,— дип көлде ханым.— Анысы һөнәрче шөгыле генә лабаса.

— Һөнәрчелек кенә дә булсын ди. Безнең балалар мәктәпләрдә ни укыганны беләсезме соң сез? Дәрвиш маҗаралары, изгеләргә багышланган әкиятләр, пәйгамбәр хакындагы кыйссалар. Бу әсәрләрдә аларның үз ватаны, туган кырлары-болыннары, баһадирлары, хакыйкать эзләүчеләре, безнең милли җырларыбыз, шигырьләребез бармы соң? Сүз җаеннан сорыйм әле: Оренбурда хрестоматиямне ничек кабул иттеләр икән?

— Риза әфәнде — хуплап. Хикәяләрен керткәнгә күңеле дә булган хәтта. Дәрмәндтән сорамадым, хәер, ул хәзерге басмаларны укымый да сыман. Әл-Мәгарри, Хафиз, Шиллер әсәрләренә генә күз сала... Беләсезме, ул гаҗәеп оригиналь кеше: анасы вафатыннан соң, ятимнәр йортын үз химаясенә алган.

— Бездә бер бай — химаяче.— Габдулла, кешене үзе юкта мыскыл итүеннән уңайсызланып, сүзне икенчегә борды.— Сез Казанда озак торасызмы?

— Белмим әле,— диде ханым серле рәвештә.— Тормышым ничек көйләнер инде. Хәзер инде мине Оренбурда берни дә бәйләп тотмый: әнкәй былтыр вафат булды, кызым — кардәшләремдә, тик аны анда озакка калдырырга ярамас, әлбәттә.— Ул, юлдашы ни әйтер икән дигән төсле, тынып калды. Аннары көрсенеп дәвам итте: — Ә Казанда... Казанны яратам мин. Казан артын — бигрәк тә. Җәй генә җитсен, шунда ук авылларга, әткәйнең туган җире Мамадышка юл тотачакмын... Бигрәк мыштым, йомыкый инде сез, ә?

Ул гаепле кешедәй баш какты. Теленә сәер, урынсыз сүзләр килергә тора иде. Төтен тулган салкын бүлмәсендә әңгер төшкәч Фирая ханымны күзаллап: «Син моңайма әле, җаныем, бәгърем»,— дип еш-еш кабатларга ярата иде Габдулла.

— Коточкыч, коточкыч дәрәҗәдә сүзгә саран сез!..

Теләге тормышка ашты — ул аны көн дә күрә башлады...

Ләкин бергә булулар сусавының әз генә өлешен дә кандырмады, сәйран чигүләр, очрашулар һәм сөйләшүләр исә гәүдәсен талчыктыра, җаны әллә мәхәббәттән, әллә аны юксынудан кыйнала башлады.

Авырудан ябыккан тәне якынлык теләгеннән янарга тотынгач, ул күңеле кырылу, оялудан нишләргә дә белми иде. Мондый көннәрдә аңа күтәрелеп карарга да базмый, тик аның тавышының һәр авазы, киемнәренең һәр кыштырдавы, хәтта көчкә шәйләнгән сулыш алуы да үткен хисләрен — ул хурлыклы дип санаган хисләрен уятып ярсыта иде. Мондый халәте бизгәк белән тәмамлана иде. Ә бәлки ул каһәр төшкән тәне талчыгуның дәвамы һәм нәтиҗәсе булгандыр.

Ә кыш тын, бәйрәм шикелле ямьле иде.

Ул кышны ерак заманнардан килгән төсле салкын буяулары, гаҗәеп авазлары, шәһәр көнкүрешенең җанлы күренешләре белән тасвирлады. Ләкин капылт аның хыялында авыл юлы, шул юлдан бүреләрнең җан өшеткеч улавына сискәнеп колак сала-сала арык атын куып барган берәр абзый җанлана иде. Шуннан соң ул әлеге юлны, корык-корык йөткереп, бердәнбер алашасы, ачлык-ялангачлыктан, бәхетсезлектән, михнәтләрдән башка берни көтмәгән киләчәге өчен куркып, сызланып арган әлеге бәндәне сурәтли башлый иде.

Еш кына шүрлектән үзе төзеп бастырган җыентыкны алып актара да: кешеләргә файда китерерлек казанышым шушыдыр ахры, дип уйлый. Ул мондый җыентыкларның яңасын бастырыр, алар барлык балаларның кулына керер... Бәлки, балаларның язмышы аталарыныкыннан бәхетлерәк булыр әле.

Ә хәзергә алар җан асрар өчен ачлык тинтерәткән авыллардан аталары белән Урал мәгъдән учакларына, Донбасс шахталарына, Крестовников, Алафузов, Акчурин заводларына китә, ярым караңгы, сасы, салкын цехларда унар сәгать бил бөгә иде...

...Көтмәгәндә килеп кергән Бәхтияров Габдулланы гадәти уйларыннан аерды.

— Нәрсә, иптәшкәй, ул-бу юктыр ич?

— Бар шул,— диде кунак борчулы төстә.— Шәһәр көтепханәләрендә һәм басмаханәләрендә тентүләр бара. Барысы да Иж-Бубый мәдрәсәсеннән башланган. Җандарм ротмистры, исправниклар кулы астында атлы стражниклар килеп төшә дә... Арест салынган китаплар, вакытлы матбугат арасында Шәрәф басмалары, безнең гәзит тә бар.— Ул калтыранган куллары белән йөзен уып куйды.— Хәзер менә Казанда казыналар. Шәрәфләр нәшрияты ябылды, яңа китапларына арест салынды...

Габдулла күңеле төшеп сүзсез калды. Иж-Бубый — Рәсәй мөселманнарының иң алдынгы мәдрәсәсе, анда астрономия, физика, химия һәм педагогика, хәтта француз теле дә укытыла, хөр фикер канат җәя — спектакльләр кую, әдәби кичәләр уздыру, җырлау, шигырьләр язу, рәсем ясау да гөнаһ саналмый иде. Мәдрәсәгә абыйлы-энеле Бубыйлар җитәкчелек итә, әмма юаш, боек татар җәмгыятендә саф җилләр исә башлауның беренче карлыгачы булган бу белем учагы белән һәр җәдитче горурлана иде.

— Тукта әле,— диде ул Бәхтияровка төбәлеп,— син мине редакциягә алып барыр өчен кергәнсеңдер ич?

— Юк ла, кайдан уйлап чыгардың? Соң инде, анда кем дә калмады.— Соңгы сүзләренә ул үзе дә ышанып бетмәде бугай.— Аннары... анда полиция бәреп керүе ихтимал.

Габдулла — Бәхтияровны сискәндерерлек кискен тәстә:

— Киттек! — диде.

Редакция тәрәзәсендә ут яна, ниндидер шәүләләр селкенүе абайлана иде. Фатих кабинетында алар бүлмә хуҗасыннан тыш Сәгыйть әфәндене, кыяфәте белән семинаристка охшаган коңгырт чәчле Гыйльметдин Шәрәфне һәм кайчандыр Борһан таныштырган ике кызны, янә башкаларны күрделәр.

Фатих яңа килүчеләргә кунакчыл төстә урын күрсәтте һәм өзелгән сүзен дәвам итте:

— Безнең көннәрдә ул мәзәк шаяру гына булып күренергә мөмкин. Ибне Халдун заманында исә ачышка тиң була. Галим җәмгыять каршылыклары көчәюне хроник авыруларга, дәүләт үсешендәге төрле баскычларны исә кеше тормышы мизгелләренә тиңли, ягъни медицина физика тармагы буларак таянычка ала. Без дә үз алдыбызда бары социаль физиканы — кешелек җәмгыяте турындагы фәнне генә күрәбез...

Зәйтүнә ара-тирә нидер әйтергә омтыла, әмма кыюлыгы җитмәгәнлектән, кулъяулыгы белән йөзен җилләтеп кенә кала иде.

Яшертен генә аңа күз салгалаган Габдулла: нинди чибәр, иманлы җан, дип уйлап куя иде. Нәкъ менә эчкерсез ышануы аны шулай сөйкемле итә дә инде. Һәр почмакта шымчы, мәҗлескә җыйналган һәр ун кешенең берсе әләкче булган, ә намуслы кешеләр берсе икенчесеннән шикләнеп йөргән заманда шундый искиткеч ачык күңелле кешене очрату шатландыра да, хәвефләндерә дә.

Ул арада әңгәмә эзлеклелеген югалтты, кемдер самавыр яңартырга йөгерде, икенчеләр Гыйльметдинне үртәргә, кызлар исә, бер кырыйгарак кагылып, үзара пышылдашырга кереште. Габдулла әле һаман аларга караштыргалап торган җиреннән кулына китап тоткан Зәйтүнәнең үзенә таба юнәлүен күреп алды.

— Гафу итегез, Габдулла әфәнде, мин сезнең китабыгызны күптәннән янымда йөртәм инде. Үткән юлы да шуңа тамгагызны салдыртырга теләгән идем.

Ул китапны алып бер мәл уйланып торды да, каләмен карага манып: «Таныш түгел укучыма чын ихтирам йөзеннән»,— дип сырлады.

— Рәхмәт,— диде туташ язуны укып.— Миңа нәкъ менә шушындый язуыгыз кадерле. Югыйсә егетләребез кызларга гел мәхәббәт кенә аңлата, хөрмәт итәргә кирәклекне уйлап та карамый.

— Мин менә бу яктан да шәп булып чыктым ич әле,— дип шаяртты Габдулла. Аннары елмаеп дәвам итте.— Киләчәктә дә кергәләп йөрегез...

— Рәхмәт. Беләсезме, безнең Чистайда туксан яшьлек бер бабай яши. Ул, яшь вакытта Тукаев белән бергә ауга йөри идек, Шүрәлене шунда очраттык, дип сөйли.

— Булды, булды андый хәлләр,— дип көлде Габдулла баш кагып.— Чистайлы бабай булмаса, кайдан күрер идем әле мин ул мәхлукны.

Ул арада Гыйльметдин гүелди башлаган самавырны алып кереп өстәл читенә утыртты һәм халыкны чәй эчәргә чакырды. Барысы да

табын тирәсенә түгәрәкләнде, тик хәзер инде гәп юк-барга, уен-көлкегә күчте. Шул чак Сәгыйть әфәнде бармак изәп, Габдуллага ишарә ясады һәм алар бергәләп алгы якка чыктылар. Ул кыенлык белән пышылдап:

— Бер-ике авыз сүзем бар,— диде.— Ниятләреңне бел им. әмма хәзер Казанда яхшылык өмет итмә, туганкай. Мотлак! Шуңа күрә, әйдә, Әстерханга яки Оренбурга ычкынабыз. Анда сине чакырганнар иде дә бугай?

— Качарга икән, Истанбулга кирәк инде,— диде ул, ипт шенең җенләнәсен алдан ук белә торып.

— Әчпошыргыч кеше син!.. Ярар, болай акыллы баш булгач, теләсәң нишләсәнә.— Ул кырт борылып түр бүлмәгә керде дә барысына берьюлы мөрәҗәгать итте.— Әфәнделәр, төн шәрифләре адәм балаларына ял тели!

— Әйе, вакыт,— дип җөпләде Гыйльми Шәраф.

Ай алла, дип коты очты шул чак Габдулланың, каршы алырга сүз биргән иде ләбаса! Хәзер Коләхмәтовлар өен ничек эзләп табар инде ул?

Бәхете, Гыйльми Шәраф кирәкле адресны белә икән.

— Шуннан узам мин, юл уңае төшереп калдырырмын,— диде ул редакциядән чыккач.— Кара әле, син кулъязмаңны озак тотмаска тырыш. Бәлки без аны баса алырбыз. Нәшриятны үз кешеләребездән берәрсенә сатып булыр, дип өметләнәм әле мин. Кулъязмагызда ике мең юл, дип Фирая ханым ялгышмыймы ул?

— Ике мең юл? Гомеремдә дә шул кадәр бастырганым юк ич минем. Сабыр... Фирая ханым, дидегезме әле?

— Аңа сөйләшүләр алып баруны кушмадым, дияргә җыенмыйсыңдыр ич?

Ул бурлаттай кызарып чыкты һәм Гыйльмигә кычкырып җибәрми көчкә тыелып калды, авыз эченнән, әле тагын бер кат карап чыгасым бар, дип мыгырданды. Бер үк вакытта Фирая ханымга да җенләнде: эшләренә тыгылырга ни хакы бар аның? Шул кадәр күпне аңлый торган башы белән мондый кыланышларның киртәгә сыймавын, мин-минлеккә тиюен һәм, ахыр чиктә, ачуны китерүен ничек чамаламый икән ул?

Габдулла, чанадан төшкәч, олауның узып китүен көтеп торды, бары шуннан соң гына нечкә җепкә асылган чүкеч белән ишек шакыды һәм ул ачылгач, Фирая ханымны алырга ат килүен белдерде. Хезмәтчесе, олаучысы дип уйлыйлар икән — уйлый бирсеннәр.

Кем чакыртуын фараз кылыпмы, ялгызы гына килеп чыкты тагын. Үч иткәндәй, якын-тирәдә «барабыз» очрамады, караңгыда ике-өч мәхәлләне җәяү узарга мәҗбүр булдылар. Бигрәк тә яхшы, караңгыда ул үзен ышанычлырак тоеп, күңелендәгенең җыенысын да әйтеп салды. Хәер, моның өчен аңа нибары бер җөмлә дә җитте:

— Эшләремнең үземнән башка гына хәл кылынуын вөҗданым һәм намусым күтәрми, дип саныйм.

— Сез гадирәк итеп тә аңлата аласыз,— диде ханым кискен рәвештә.

— Аптырыйм инде мин...

— Менә монысы аңлашыларак төшә. Әй, олаучы!

Чанага утыргач та Габдулла үзсүзләнеп дәвам итте:

— Вөҗданым һәм намусым...

— Габдулла җаным,— диде ханым аңа беренче мәртәбә шулай эндәшеп,— боларның барысы турында өйгә кайткач та сөйләшеп булмыймыни соң?

Ул ачуы басылмаган килеш тынып калды һәм шарфы аша сулый башлады. Бөтенесе әллә ничек өзек-өзек иде бу хәерсез дөньяда: арык атның чабуы да, тын тыкрыклардан килгән тавышлар да дулкын-дулкын. Хәзер инде ул битәрләвенең урынсызлыгын һәм мәзәклеген тоеп сүлпәнәя башлады. Тик ханым бүлмәгә кереп чишенгәч, ялангач кулларын диван аркасына салып һәм көлемсерәп юлдагы сөйләшүне искә төшерүне үтенгәч, ул кире дөрләп китте, күңелендәгенең барысын да ярып салырга да минуты белән чыгып китәргә, дип аны иңнәреннән кысып алды. Ханым көлеп

һәм тотрыклылыгын югалта барып, үзенә аны да ияртеп, диванга ауды.

Саксыз рәвештә аның өректәй кара тутлы салкын яңагына ирене орынгач, ханымның кырыс һәм теләктәш иреннәренә дә кагылуын Габдулла инде сизми дә калды...

Ханым аның ничек киенүен һәм чыгып баруын ярым йомык керфекләре арасыннан назлы елмайган хәлдә күзәтеп торды. Артыннан ишекне япканда аның нәрсә пышылдавын Габдулла ишетеп җиткермәде, әмма шактый ышанычлы рәвештә гөман кылды: «Бөтен эшләреңә раббым мәрхәмәт кылсын да үзеңне фәрештәләре сакласын, дип теләде ахры».

Бишенче көнне ул урын өстеннән торып редакциягә китте.

— Иртәрәк кузгалгансың,— дип каршылады аны Фатих.

— Бераз хәл керде кебек инде.

— Доктор җибәрмәкче идем дә, тагын үпкәләрсең дип курыктым. Гадәтеңне беләм ич инде, куып чыгаруың да бар. Шулай да сиңа бер әйбәт табипка күренү зыян итмәс иде.

— Мөгаен. Нинди яңалыклар бар?

— Депутатларыбыз Думага хат язган.

— Ул либераллар минем бер танышыма охшый. Гәүдәсе әзмәвердәй, ләкин үзе миңа килә дә: «Мастер җәберли»,— дип зарлана. Миңа хатлар юкмы?

— Юк. Гадәттән тышрак берәр нәрсә көтәсеңме?

— Әйе, бәлки мине дә берәрсе искә төшерер. Кара әле, әйдә бераз салабыз, Фатих?

— Теләмим һәм сиңа да киңәш итмим. Күңел төшенкелегеннән арын әле... Менә хәзер кызлар киләчәк...

— Кызлар?

— Өркемә инде шул кадәр, утыр.

— Я, утырдым.

— Без инде хәзер четерекле эшләрдә киңәш бирү, киңәш алу яшеннән узган. Ләкин, әгәр рөхсәт итсәң... нигә дип әле сиңа өйләнмәскә?

— Кәләшем юк ич минем.

Фатих, бу җавапның тапкырлык түгеллеген сиздереп, дәшми торды. Аннары үзен дә ышандырырга теләгәндәй, йомшак, хыялый рәвештә:

— Гаилә бәлки бу дөньяда без кадерен белергә тиешле бердәнбер нәрсәдер,— диде.— Я хода, әгәр сине тыйнак, яхшы күңелле кыз да ошатса... Ә Зәйтүнә чынлап та ягымлы, гүзәл бер җан иясе ләбаса...

— Белмим шул,— диде Габдулла әкрен генә,— ягымлы, яхшы күңелле микән ул, әмма син... син — кече күңелле! Рәхмәт. Тик минем өлешем, күрәсең, ялгызлыктыр инде.— Ул, урыныннан торып, иптәшенең кулын нык итеп кысты да бүлмәдән чыгып китте.

Бу сөйләшү аның йөрәгенә сәер, әмма рәхәт бер җанлану өстәде. Бәлки гаилә һәм балаларның бу җиһанда иң кадерле нәрсә булуы чыннан да, хактыр? Мин беркайчан да оптимист булмадым, ләкин аңа карап кына дөнья хәлләренең яхшыга таба баруына нигә икеләнергә соң әле? Тормышта шатлык аз, тик табигать — һәлакәт һәм юкка чыгу түгел, барлыкка килү һәм яңару. Дөрес, син үлемсез түгел, ләкин үләннәр дә язгы ерганаклар да шул язмышка дучар... Кешегә өмет һәм куанычны исә тормыш даимилеге, мәңгелек бирә. Кешене тотрыклылыкка ирешү шатландырырга тиеш. Әгәр сиңа язмыш яхшы күңелле, тугрылыклы берәүне иш итә икән — бигрәк тә баш ватып торасы юк — аңа да, үзеңә дә булыш кына!

...Кичке эңгер җәелеп, аяк асты туңып килә иде, ләкин ул моны тоймады, күзе караган якка урам буйлап атлап китте. Әйтерсең лә, очраклы рәвештә генә биек коймасы өстеннән шәрә тирәк ботаклары тырпаеп торган таныш йорт янына килеп чыкты. Калын комач пәрдәләр белән капланган тәрәзәләрдән урамга җылы якты саркыла иде. Шул чак аның колагына энисе көйләгән назлы бишек җыры ягылгандай булды.

Үзәкне өзеп яңгыраган моң аны тетрәндереп, бу йорттан читкә тайпылырга, чаттан узып барган «барабыз» чанасына сикереп менәргә һәм аны сискәндереп: «Ку, әйдә, абзыкай!» — дип кычкырырга мәҗбүр итте. Олаучы агай гайрәтле аваз салды, юаш кына юрткан алаша кушаяклап алга ыргылды. Зур тизлек аңарда куанычлы хисләр уятты, әйтерсең лә ул качмый, үзе куып бара, яшь, дәртле, көчле һәм ирекле, ирекле!

Моннан соң алар тагын берничә тапкыр кеше алдында очрашты — Шәрык клубында һәм кайдадыр китап кибетендә бугай — Фирая ханым сөенечле, назлы елмаеп, аңа китабын сузды да:

— Талантыгызга табынучыга бер китабыгызны багышлагыз инде. Җылырак, ихласрак итеп языгыз,— диде.

Каләме кыштырдау уңаена ул эченнән «истәлеккә» сүзен кабатлады.

Шуннан соң Фирая ханым, дусларын да кисәтеп тормастан, кинәт кенә каладан китеп барды. Ул арендалаган йортны тиздән Акчуриннарның акционерлар җәмгыятенә саттылар. Йортның тышкы күренеше дә, биек коймалар өстеннән тышка бүселеп чыккан тирәк, өрәңге агачлары да, яшел кандилләре, тәрәзә куышлары һәм ишек уемнары — барысы, барысы да элеккечә калды, ләкин шулай да нидер үзгәргән кебек иде. Капка төбенә фәйтүннәр ешлатып җибәрү, эшлекле кешеләрнең тыз-быз кереп-чыгып киләп сарулары бу йортның аулак тынлыгын, серле ягымлылыгын юкка чыгарды.

Ә тагын күпмедер вакыт узгач, аның кияүгә чыгуы хәбәре килеп иреште. Ирен яшь, киң җилкәле, әллә мех, әллә тукыма фабриканты, диделәр. «Ә миңа тансык ирегем калды»,— дип үз-үзен мыскыл итте Габдулла. Чынлыкта исә ул мондый хөрриятькә мохтаҗ түгел, аңа көтү һәм өмет хаҗәтрәк иде. Шуңа күрә ул редакциядә узган әлеге кичне, сабыр, ягымлы йөзне, саф һәм акыллы карашлы күзләрне — яшьлеге хыялына охшаш берәүне һаман ешрак исенә төшерә башлады.

...Әле туңудан калтырана, әле тәне уттай яна — ул чынаягына аспирин салып эчә дә юрганына төренә һәм буш, битараф карашын диварга төбәп утыра. Яки урынына барып ята да үзенә ерактан күз салгандай була — нинди зәгыйфь, нинди ябык ул, башында исә... теләк тә, фикер дә калмаган.

Әмма төшләре кайнар, киеренке, анда төрле-төрле күренешләр бер-бер артлы алмашынып кына тора: ул әле ап-ак карга яланаяк басып: «Әнкәемне алып китмәгез, алып китмәгез!» — дип кычкырып үкси-үкси йөгерә, әле элекке таныш дәрвише кар өстенә утырган да: «Бу торагыгызны соңгысы димәгез, мәңгелек дип атагыз»,— дип мыгырдана... Дәрвишкә Камил Мотыйгыйның сеңлесе Диләфрүзне хәтерләткән берәү җавап бирә: «Ишетәм, ишетәм, тик сез әкренрәк сөйләгез, колакны ярасыз!» Атлар кушаяклап чаба, кеткелдәп көлүче кемнедер узып китә... Көлүче — Фирая ханым имеш, ул кайдандыр югарыдан, күктән карап тора, ә анда күзләр түгел, йолдызлар, имеш...

Ул уянып китә дә төшенең соңгы күренешләрен хәтерләп: нишләп һаман Зәйтүнә керә соң әле, аның хакында уйлаганым да юк лабаса, дип куя. Шуннан соң, әлеге кызыкайны да онытып, тәмам хәлдән таеп, эчендә бушлык хасил булуын тоеп гаҗиз кала. Ләкин әнә шундый саташкан төннәренең берсендә ул тулы тынлык эчендә уянып китте һәм, ярсулы дәртләнеп, шәм кабызды да кулына кәгазь, каләм алды.

Киеренке тынлык эченнән көчкә ишетелерлек дәрәҗәдә моңлы саз тавышы килгән шикелле тоелды.

> Күз карашымда хәзер үзгәрде әшъялар төсе,
> Сизлә: үтте яшь вакытлар, җитте гомрем яртысы...

Саз һаман нечкәрәк, һаман моңлырак яңгырый, ул, юкка чыга барган авазларны куып җитәргә тырышкандай, ашыга-ашыга каләмен кыштырдатты.

И мокатдәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Җин сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз ахрысы!
Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы.

Ул соңгы юлны язып бетерде дә, актык көчен туплап, урынына барып ятты. Әйе, дип уйлады авыру, бу салкын дөньяның тимер читлегеннән очып китә ул, бичара кош!.. Шәмнең сары канаты дер-дер килә, буялган идәнгә черек утыдай тонык шәүләсен төшерә; тәрәзә артында, тышта әле караңгы, тик коридорда инде аяк шапылдаулары, йокыдан уянганнарның басынкы тавышлары ишетелә.

...Менә шулай аңлы-миңле хәлдә тагын өчме, дүртме көн узды һәм бервакыт ул: «Мин үземне тереләй күмәм ахры, мин хаста түгел, юк, мин бары күңел төшенкелегенә бирелдем. Миңа хәрәкәт кирәк, мин әле көрәшәчәкмен...» — диде.

Иртәнге уннарда Галиәсгар килеп кереп, аның ятагына утырды да:

— Авырыйсыңмыни? Нигә белдермәдең? Сездә телефон бардыр лабаса? — диде.

— Авырыйм? Юк, болай гына ятам әле.— Ул кабат телгә килгәнче ун минут чамасы узды.— Яңалыклар бармы әллә?

— Тыныч кына ят, сөйләшмә. Мин яныңда утырып торырмын.

— Утыр... Тик мин тыңлый алам, яңалыкларны сөйлә инде. Журналыбызны ябарга тырышалармы?

— Беләсеңме, Габдулла...

— Алар япмыйча тынычланмас инде. Нәрсә, Сәгыйть әфәнде кадимчеләрдә эшлиме?

— Алай ук түгел: ул «Казан мөхбире»ндә урнашты.

— Анысын да муллалар чыгара. Борһанның Оренбурга күчеп китүе хакмы?

— Әйе.

— Адәм актыклары,— диде ул.

Икесе дә беразга сүздән язды, аннары Габдулла:

— Мин әзер,— диде.

Галиәсгар, дусты саташа дип уйлапмы, дәшмәде.

— Мин әзер,— дип кабатлады Габдулла.— Миннән китә, ахры, нәгъләт.— Ул куллары белән караватына таянып торып утырды.— Нинди ялкаулык баскан... бирешмик әле шуңа. Җепне тарткала әле, кизү торучыга кыңгырау чылтырату ул... Чәй эчәрбез, чәй эчмәсәм, Галиәсгар җаным, кеше түгел мин. Хәзер инде кулыңны бир, торып басыйм әле.

...Юылган идән исе, тыштан кертеп эленгән сөлгеләрдән күңелгә ятышлы салкын һава сулышы, яңа агартылган мичтән акшар исе — тулаем алсаң, кышкы аклык-пакьлык, тазалык-сафлык бөркелә иде өйдә. Мичтә чарт-чорт янган каен утыны ел фасылын бигрәк тә аермачык күзаллата...

Габдулла мондый халәтне элек тә кичерүен хәтерли: я алла, адәм балаларына үзара ызгышып, бер-берсен җәберсетеп, үпкәләтешеп яшәргә ярыймыни, дип беркатлы һәм якты уйларга бирелгән иде ул. Яшә дә хозурлан: әнә аллы-гөлле урман үзенең купшы киемнәрен сала... Әйе, көз иде, Җаекта Пушкин бакчасында яраткан шигырьләре әсирлегендә илһамланып сәйран чиккән иде ул бер заман.

Һәм менә хәзер — Кәбир мулланың сандык шикелле җыйнак, тәбәнәк өендә кунакта ята ул,— абыйсы хатыны белән олы өйдә, ә ул — кечтеки аулак якта ялгызы рәхәтләнә. Тирә-юньгә күз сала да, авыл халкының кырмыскадай эшчән, тыныч һәм сабыр, көндәм, үзара мөнәсәбәттә гади булуларына, фәкыйрь тормышларын тәмен белеп сабыр кичерүләренә соклана. Җырлары — үзара сөйләшү, әкиятләре — гүя уйлап чыгарылмаган, шушында, ерак түгел җирдә, күрше урманда яки якындагы тау артындагы кайсыдыр патшалыктагы вакыйгалар һәм тарих кебек кенә.

Аһ, тик дөнья мондый түгел, төгәлрәге, бу әле бөтен дөнья да, аның зур өлеше дә түгел, бәлки сугышлар һәм низаглар, курку һәм

көрәш, ачлык һәм туклык арасындагы бер ара гына. Һәнүз, көн арты көн дәһшәтле һәм сулышны кыса торган тормыш белән яшәрг.. ярамый, менә шуңа күрә һавасы саф, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләре тыныч һәм ачусыз хәят бирелә сиңа. Ләкин мондый даусыз, пассив тормыш белән генә дә чикләнү урынсыз, син туйган һәм кинәт серле рәвештә качып котылган мәшәкатьләр, файдасыз һәм хәтәр күренгән ыгы-зыгылардан башка ул һич тә тулы була алмый.

Беренче көннәрдә Габдулла җылыга тиенеп рәхәтләнде һәм йоклады да йоклады, балачакта, бәхетле көннәрдә генә мөмкин булганча йоклады. Кичтән ятып иртәнгә кадәр шулай иркен ял итүне күптән оныткан иде инде. Аннары барысы да каладагыча китте: кичләрен озаклап укый, дәфтәренә кайбер күзәтүләрен теркәп куя да әкрен генә җырлый яки сәгатьләр буе уйга чумып утыра һәм иртәнге якта гына йокыга китә иде. Аның мичен ягу, ризыгын китереп бирү Кәбир муллаларга ярдәмләшеп йөрүче Мәйсәрә апага йөкләнгән иде. Башта ул Габдулланың йомыкыйлыгына, аулакта ятуына гаҗәпләнмәде — тире белән сөяккә генә калган, куәтле бизгәктән җәфаланган чирләшкәдән тагын ни көтәсең инде? Тик бераз аякка баса башлагач та кунакның һаман шул нәни өйдән чыкмавына исе китте һәм үзенчә моңа йогынты ясарга — фәләннәрдә аулакка кызлар-егетләр җыйналып кич утырачаклар дип оеткы салырга, я булмаса, иртәгә Кәбир мулла вулыстка барачак, син дә иярмисеңме дип искәртергә, я булмаса, фәлән кеше китапка кадалып утырган, утырган да акылдан язган дип куркытырга — аны шулай җанлырак, тererәк тормыш белән яшәтергә тырышты. Ә ул исә җавап итеп көлә генә һәм кич утыруның кызыксындырмавын, вулыста эше юклыгын, ә менә берәр кичне аның ире — итекче Һарун абзый янына кагылырга теләвен белдерә иде.

Төгәлрәк әйткәндә, Һарун итекче түгел, читек тегүче иде. Сафьян читекләр, башмаклар тегү фабрика эше рәвешен алган иде. Бары цехлары гына тарау — авылларның берсендә читекне кисәләр, икенчесендә чигәләр, өченчесендә табан, үкчә беркетәләр — әзер товар хәленә китерәләр. Шуннан соң ул я Сембер, я Казан, я Саратов кибетләренә озатыла иде. Һарун абзый исә тегүнең соңгы өлешен башкара, бу эш чын сәнгатьчә осталык таләп итә иде! Башта ул сафьян кисәкләрен сумалалы җеп белән тегә, аннары шуның өстеннән мамык, ефәк яки металл җеп белән атлатып, тупас сумала җепне каплап, һәр бизәкне каеп чыга. Бу эш белән ул кышын гына шөгыльләнә, елның башка фасылларын иген игү, терлек кайгыртуга бирә, әмма аның кыяфәте крестьяннан бигрәк һөнәрчегә, шәһәр кешесенә охшаган иде. Ул моны үзе дә яхшы белә, шуңа бераз тәкәбберләнә дә, ләкин кәпәренеп кеше күңелен кырмый, үзенең мин-минлеген канәгатьләндерер өчен генә бераз кылтая иде. Хәер, авылда бер ул гына һөнәрле түгел: монда мичче дә, балта остасы да, мичкәче, аркан һәм чыпта үрүчеләр дә бар иде. Кышларын аларга авылдан-авылга йөреп тегүчеләр, йон тетүчеләр, итек басучылар да кушыла, аларны көтеп алалар, берәр хуҗаның мунчасында эш урыны бирәләр. Алар янына кичләрен йомыш белән килүчеләр озаклап гәп суга. Һарун абзыйларда да шулай: ул үзе җеп сумалалый, үзе төрле кыйссаларга, мәзәкләргә яки хәбәрләргә колак сала. Габдуллага да мондый кичәләр ошап китте. Һарун абзый тыңларга гына түгел, үзе сөйләргә дә оста иде. Гадәттә ул үзе үк башлап та җибәрә:

— Маңгәрдә берәү, хатынын җирләгәч, елый-елый сукырайган икән диләр. Әмма ул күпмедер вакыттан соң өйләнеп җибәргән. Сорыйлар икән моңардан: сукыр була торып, ничек болай тиз өйләндең соң әле! Һәй, ди икән бу, шуның өстенә саңгырау да булсам, мин тагын да тизрәк өйләнгән булыр идем!

Көлешүләр тынгач, ул янә берәр мәзәкне исенә төшерә.

— Бер бай үлем түшәгендә ята икән. Васыятьләрен әйтә башлаган бу. Өченче ел югалган ике үгезем бар. Әгәр табылсалар, улым үзенә алсын, юк икән, ялчыбызга насыйп булсын!

Тагын шаркылдыйлар, ул арада сандыкчы Фәсхи кыбырсый, кулын селти башлый: мине тыңлагыз, янәсе. Аның мәзәкләре әчерәк:

— Авылга патша хәзрәтләренең түрәләре түләү жыярга килеп төшкәннәр икән. Бичара Мәхмүтнең актык мендәренә кул сузганнар, ә ул бирми, мендәрне үзенә тарта икән. Тартыша торгач, ертылган мендәрнең бөтен җоны, мамыгы идәнгә коела, бүлмәгә оча башлаган. Мәхмүт артларыннан ияреп урамга чыккан да: «Ай бу бәлане! Мин дә мескен, падишабыз да мескен!» — дип такмаклый икән. Мәхмүткә: «Падишабыз нигә мескен?» — диләр икән. Мәхмүт: «Минем мендәргә мохтаж булгач, мескен инде!» — дип җавап биргән, имеш...

Тирә-якта ачлык канат җәя, атна буе котырган бураннар йортларны кәфенгә урый, болыннарны күмә, урманнарны карга батыра, авылларның җанга җылы утларын каплап, юлаучыларны юлдан яздыра иде. Шундый чакта качкыннар турында исәпсез-хисапсыз хәбәрләр тарала. Алар я Казан сәүдәгәрен сагалап тора, я Арча баен талый. Авыл агаена юлыккан чаклары да була, әмма мондый чакта усал зобаның шәфкатьле фәрештәгә әйләнә.

— Күркә Сәйфи вулыстан кайта икән. Ялан кыр. Ул да түгел, юлчыны кемдер куып җитә. Башлыгын күтәреп моңа бер генә күз сала да: «Әй, син икән ич әле бу, Сәйфи абзый!» — ди дә атын кире бора.

— Алла сакласын, кем булган соң ул?

— Качкын инде, билгеле.

— Менә Кышкар Галимәсе бәбиен асып, ирен вулыс шифаханәсенә алып барырга чыккан икән. Аны да кырда куып җитәләр, бичара хатынның коты ботына төшкән, ә теге качкыннар: «Галимә, синмени әле бу? Ку атыңны җәтрәк, бәбиең катып үлә ләбаса!» — дигәннәр.

Мондый хәбәрләр күнегелгән тормыш хәлләренә охшамавы, гади кешенең михнәт чигүенә, дөнья көтүенә ризасызлыгын чагылдыруы, хәтәр, фаҗигале вакыйгаларның өметле очлануы белән әкиятне хәтерләтә иде. Әмма ул хәбәрләрнең кырыслары, гадәттән тыш чыннары да килеп җитә иде. Әйтик, Өчиле Закирҗанының катып үлүе. Күрше авылдагы бай туганына киләсе уңышка кадәр дип он сорарга барган булган икән, бахыр. Шундый хәлләрдә Габдулла үзенең авылга утырмага кайтуын килешсез назлану дип саный башлады.

— Ярый әле вакытында кайткансың,— дип тынычландырды аны абыйсы.— Шәһәр тормышы сине тәмам рәтләгән инде, тире дә сөяккә генә калгансың, йөзең зәгъфырандай. Мич башына мен әле син, бар.

— Менәрмен, менәрмен,— тик син минем кайтуым турында кеше күзендә бик шаулама, аулакта яшисем килә.

— Аңлашыла. Ишеттегезме? — диде ул хатынына,— кунакка тынычлык кирәк, аның турында кеше-карага бик сайрамагыз!

Тынычлык... Чынлыкта ул үзе дә бу шартның бизгәк калтыратуы газаплаган һәр сөягенә, күзенә һәм колагына, әгәр әле чыгып бетмәгән булса, җанына да шул кадәр хаҗәт икәнлеген белеп бетермәгәндер.

Хәзер инде Габдулла аермачык үзенә чахотка тиюен, күңел төшенкелегенең шуның аркасында икәнлеген белә иде. Ләкин ул бу авыруның тәнен интектерсә дә, рухын гадәттән тыш көч белән тулыландыруын, фикер йөртергә, өметләнергә, башка сыймаслык планнарның эшкә ашуына ышанырга мәҗбүр итүен, мөгаен, чамаламый иде. Әмма чире бераз басыла төшеп, тамырларында кан тотрыклы тибә башладымы, хәле әз генә җиңеләйдеме, тирә-якка тынычрак күз салырга керештеме — киләчәге өметсез тоела; әмма бу өметсезлек хәзер инде аны өркетми иде. Ул хәзер менә шундый басынкы, эченә сабырлык, күндәмлек тулган бер хәлдә иде.

Соңгы атналарда ул бик көчле тәэсирләнгән хәлдә яшәде, күп һәм ярсып язды, юкка да кыза, хәтта ваклана башлады; дошманнарына ачы һәм усал уклар атты, кичәге дусларын да кызганып тормады.

Галиәсгар белән үз бүлмәсендә чәй эчкән һәм аңгәмә корган көнне Габдулла сугышчан бер хәлгә керде. Аннары алар Фатихларга киттеләр,

өчесе бергә утырып, дуслыкка тугрылык саклаган, әле кайчан гына караш һәм максат уртаклыгы берләштергән сафларының сирәгәюе турында сөйләшеп утырдылар. Берәүләр, ватаннарын мәңгегә ташлап, Истанбулга китеп барды, икенчеләр каләмнәрен монда сатты. Борһан Шәрәф әнә, Рәмиевләр чакыруына алданып, Оренбурга юл тотты, «Әльислах»та эшли башлаган кичәге шәкерт Рәшит Хәнәфи дә аңа иярде.

Яңа гына уянып килгән җәмгыятебез нинди җитлекмәгән әле дип уйлады ул. Аңарга күпме көлке, беркатлы, вакыты белән күпме яман нәрсәләр хас әле. Суд тикшерүчесе кинәт әхлак турында китап яза, кер юу остасын артист итеп таныталар, ниндидер башмак сатучы мәхәллә имамына әйләнә, кичәге хәрби фельдшер — докторга, наданнар нәшир һәм редакторга әверелә, соңгылары язучыларны үзләренә көндәлек кара эшкә яллый... Кайчандыр ул үз мәкаләсендә: «Укымак — дөрестнең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр»,— дип ышандырырга тырышкан иде. Әмма чалмалы вәгазьчеләргә һәм тук буржуйларга мәктәпләр һәм гимназияләр кирәкми, аларга милләтне берләштерә торган ниндидер бер җирлек кенә кирәк иде...

Хәзер инде ул Иж-Бубый мәдрәсәсен туздыруга ни сәбәп булуын яхшы белә иде. Җәдитчеләр хыялын беренче булып тормышка ашырган бертуган Бубыйлар кадимчеләр матбугатында ике ел буе каргалды. Изге булып кыланучыларның иң әрсезе Ишми ишан үзенең фәтваләрендә: «Ислам диненә бернинди үзгәреш кертелә алмый, менә шул сыйфаты белән ул тотрыклы иман тәшкил итмәгән һәм үзгәрергә сәләтле булган христианлыктан аерылып тора»,— дип игълан итә. Мондый сафсаталар гына җәдитчеләргә аяк чала алмый, чөнки кадимчеләрнең ахмаклыгы күз алдында. Шунлыктан панисламист Ишми ишан әлеге хәлфәләрне... мөселманчылык тарафдарлары дип гаепли! Аннары үзенең бер китапчыгын русчага тәрҗемә итә дә губернаторга җибәрә. «Җәдитчә укытуның асылы — мөстәкыйльлеккә дәгъва белдерү һәм хакимнәргә каршылык күрсәтү. Бу дәгъвалар Рәсәй социал-демократлар партиясе прокламацияләре буенча билгеле». Бер үк вакытта панисламист та, социалист та! Панисламизмга дәлилләр табылмады, әмма мөгаллимнәрне,тыелган әдәбият саклауда гаепләп, төрмәләргә ябып куйдылар.

— Җитәр! — диде ул әлеге көнне.— Без һәр кабахәткә нәзакәтлелек күрсәттек. Һөҗүмгә һөҗүм белән җавап бирергә вакыт.

Беренче башлап ул тар карашлы милләтчеләргә ташланды. Һаман бер сагызны күпме чәйнәргә, сүзне күпме җилгә очырырга мөмкин инде? Алар тау-тау кәгазь әрәм итеп милләтне данлаудан гыйна халык туклыкка да, белемгә дә мантымады, җир дә алмады, завод-фабрикаларда эшләү шартлары да яхшырмады. Фельетоннарының берсендә ул «Татар халкы», «Татар кызы», «Татар бүреге», «Татар кәвеше», «Татар катыгы», «Татар мөгезе» исемнәрендә көн саен диярлек әллә никадәр чүпләр бастырган бер милләтпәрвәрне мыскыл итте. Мондый кешеләрне «сары йортка» ябалар ябуын, ләкин бер җәһәте бар: бу кадәр һәр китабын татарның бер нәрсәсе белән исемләгән, үзенчә милләтче бер мәҗнүнне япканда да «Татар диванаханәсенә» ябарга кирәк... Янә бер каләм иясе милли шигырьләр язган да ресторанга киткән. Монда бер татар баеның бәллүр касәдән коньяк эчеп утыруына күңеле нечкәреп: «Менә милләтебез җәмшит касәдән җам эчте!» — дип шатланган.

Үзләрен милләт терәге санаучы либераллар «Әльислах» тирәсендә туплаңган яшьләргә ваксынып карый, олпатлык саклап, «дуамал малайшалайлар» тәнкыйтенә җавап биреп маташмый иде. Әмма «Әльислах» мөхәррирләренә әнчекләр өстерүдән кыенсынмыйлар. Болары хәзер Фатих Әмирхан белән Габдулла Тукай каләменнән төшкән теләсә нәрсәне хурлый иде. Габдулланы Печән базары шагыйре, такмакчы, әдәбият бакчасына саташып кергән сыер дип атыйлар, Пушкин һәм Лермонтовны тәрҗемә итүе өчен хурлыйлар, төрлечә мыскыл итәләр иде.

«Озак чыдады бу миллэт каһарманнары миңа,— дип уйлады ул.— Мәсхәрә итүемне кичереп, талантымны да таныдылар. Әгәр үзләре белән бергә булсам, шуларның иң бае, иң затлысы кызын кияүгә дә биргән булыр иде миңа, валлаһи».

Дөрес фикерләре дә бар иде, билгеле. Әйтик, алар татарның морза мәдәниятеннән коры калып, күпне югалтуын төшенәләр иде. Менә хәзер яңа байлыкка һәм хакимлеккә омтылганда, алар үз мәдәниятләрен үстерүне дә күздә тоттылар.

Аһ, әфәнделәр, Пушкиннарыбыз, Лермонтовларыбыз, декабристларыбыз, Лев Толстойларыбыз булмау миңа да кызганыч лабаса. Ләкин сез кичектегез... Иртәме-соңмы, революция яңадан кабынып китәргә мөмкин. Әйе, дөньяви гыйлемебез, ирекле мәдәниятебез булмавы бик кызганыч, әмма халкыбыз үзенчәлекле көнкүрешкә, һөнәрләргә, җыруларга, йолаларга ия булып яшәде — бу шулай ук мәдәният ләбаса. Күрше халыклар белән бәйләнешләребез тыгыз, ике-өч тел белмәүчене эзләп табу кыен, башкалардан да нәрсәдер үзләштерәбез — ул үзебезнекенә әйләнә. Хәзер инде сезнең сыйныф берни дә бирмәячәк, бары хезмәт иясе халкыннан гына нидер күтәргә мөмкин. Дөрестен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул, әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә, бу күренештә йөри. Ләкин бу хәл, вакытлы гына килгән бер авыру кеби, әлбәттә, юкка чыгачак, миллэтебез чын тәрәккый юлына басып, алга китәчәк.

Ул аруын тоймый, әмма көннән-көн сула бара иде. Эшләгәндә каты чәй эчеп җылына һәм тәмәке тарта, төннәрен исә йокыга китә, үпкәсеннән тәмәке сөремен йөткереп чыгарып бетерә алмый газаплана иде. Төннәрнең берсендә ул буылып йөткерүеннән аеруча җәфаланды. Ахыр чиктә хәлдән тайган хәлдә торып шәм кабызды һәм өстәл янына атламакчы булды, ләкин тагы ютәл тотып... тамагыннан кан китте. Ютәле шундук туктады, ул караватына кире килеп чалкан ятты да авызын сөлге белән каплады. Тәнен кинәт сәер тынычлык биләп алды, җеп өзәрлек тә дәрманы калмаганлыктан, ул бармак селкетүдән дә сакланды, әмма уй-фикерләре куркусыз, тыныч һәм ачык ага иде. «Болай кинәт кенә булмас әле ул... Кабахәт ютәл, мин артык көчәнеп, тамактагы берәр тамырны шартлаттым, ахры. Иртәгә докторга күренми ярамас». Йокы төшмәде, тик ютәл дә бүтән кабатланмады, зәгыйфьлеге генә саклана, бәлки аны ялкаулык галәмәте дип санаргадыр? Әйе, ялкаулыкка охшаган ич бу, шуңа күрә куркып торасы да юк. Ул хәзер инде тәҗрибәле кешеләрчә көлемсерәп, элекке иптәшләре белән әйткәләшүнең мәгънәсезлеге, үзенең малайларча кызулыгы, Сәгыйть әфәндегә ачуы да, үпкәсе дә юклыгы турында уйлады. Әйдә, үзләре тик яши бирсеннәр! Кешеләргә бәйләнүләрне ташлап, бүтән рухта шигырьләр язарга керешер, янә бер дәреслек төзер, аннары, ходай кушса, романга да тотыныр; ул инде моңа әзер кебек... вакыт, вакыт! Тик башта тормышын тәртипкә салырга кирәктер. Бәлки шәһәрнең бер тын почмагында тыныч фатирга урнашыргадыр, эчеп, типтереп, гомерен файдасыз исраф кылучылардан кендекне тәмам өзеп... Ул ник тинтәкләргә ияргергә тиеш соң әле? Эшләргә дә вакыт кирәк ләбаса... Фикерләр саташкалап ала. Хәер, юк ла. Ул эшләргә кирәклеге, ниһаять, үз гаиләсен, үз почмагын булдыру, балалар гына китерә торган куаныч турында уйлады ич инде. Әгәр яхшы күңелле, сөйкемле берәр кыз... Уйлары чуала шул, ул Зәйтүнә шикелле дип әйтергә теләде, исенә төшерде... Диләфрүз дә бар иде. Өметсезлек белән ышаныч арасындагы тәнәфестә йомыкый, күндәм җан иясе Нәфисә дә пәйда була — аның хисләре, боз астында да үз юлы буйлап ага биргән елга шикелле, һаман йөгерә дә йөгерә. Фирая ханымның таләпчән матурлыгыннан ул үзе качты, хәзер инде менә күз алдында Зәйтүнә тирбәлә. Аларның кайсын гына сөйде соң ул? Әллә берсен дә яратмады, аның барлык хисләре мәхәббәткә сусау гына булды микән? Менә монысы, мәхәббәткә сусавы, һич тә юкка чыгып бетми торган нәрсә, ахры...

Кайчан да булса анысы да үтәр, ул чакта инде барысына да нокта куелыр.

Әгәр аның тормышы башка юлдан киткән булса? Ул, мөгаен, мулла яки хәлфә төсендә авылда яки берәр кечерәк шәһәрдә яшәр, аның гаиләсе булган булыр иде... Язмыш? Ул аны балачагында ук үз туганнарыннан һәм үз катламыннан аера да гади кешеләр — фәкыйрь авыл карчыгы, Казан һөнәрчеләре, тынгысыз игенче тәрбиясенә китереп ташлый. Әмма балачагында ук ул үзен мәдрәсәне тәмамлаганнан соң ата-баба юлына басачак кеше дип күзаллый иде. Басмады. Киләчәк юлын сәләте билгеләдеме? Язмыштан аерып караганда сәләт үзе генә нәрсә соң ул? Нинди дә булса эшчәнлеккә күңел яту язмыш дип аталган мәҗбүриятькә ничек туры килә? Сайлау ирегенә, хөр адымнарга мөмкинлек бармы соң?

Фикерләре бераз бутала... тик менә нәрсә: бәлки аның күз яшьләре, сабыйлык зарлары, ятимлеге шигърият булып бәреп чыккандыр? Бәлки сагыш һәм газапланулар үзе шигърияттер? Мисалга, уен-көлке үзбаш шигърият түгел ич әле. Игенчеләр гомер агышында чыгарган шаян җырларны да җырлый, мәзәкләр дә сөйли, аннары эшкә тотына. Бәлки аларның хезмәте үзе шигърияттер? Ә аның хезмәте — газаплануларны чагылдыру. Ә матурлык?.. Шигърияттне матурлык барлыкка китерми микәнни? Юк, газаплану түгел, кешенең газапларны җиңүе әһәмиятледер, менә шунысы шигърияттер. Михнәт кичерү, аңа бирешмәү...бик таныш нәрсә ләбаса аңа.

Ул таң алдыннан гына йокыга талды һәм яхшы ук әйбәт ял итте. Аннары торып аскы катка төште һәм буфетта чәй эчте. Нәкъ иртәнге унда ул инде докторга күренер өчен чират алырга өлгерде. Хәтерендә Ольховский белән очрашуы, аның Гартманга күренергә димләве калыкты... Әмма ул бүген эзләп килгән доктор Гартман түгел, Мостовщиков иде... Булсын!..

— ...Алай. Билгә хәтле чишенегез. Я, кадерлекәем, тизрәк!

Доктор карсаграк буйлы, тупасрак гәүдәле, дорфарак гади мөгамәләле, әмма аның бу гадилегенең ясалма булуы күренеп тора иде. Ул инде аягына калкып, югалыбрак калган авыруга таба атлады һәм битараф кыяфәттә — шулай бәлки чиркануын яшерәдер — Габдулланың күкрәгенә кыска агач торбаның бүрәнкә сыман башын терәп тыңлый башлады. Уңнан, сулдан, алдан, арттан.

— Киенегез.— Рецепт язарга утыргач сорады: — Элек кемдә дәвalandыгыз?

— Мин әле беренче мәртәбә...

— Беренче? — Ул каләмен алып, шаккаткан төстә Габдуллага карады һәм нигәдер ачуы чыгып эндәште: — Элек кайда йөрдегез соң сез, кадерлекәем? Нигә сез монда, һич югы, өч ел элек килмәдегез?

— Әйе шул, мин чыннан да өч ел чамасы йөткерәм бугай инде. Әмма бронхит...

— Бронхит булса иде ул! Чахотканы, егеткәй, вакытында эләктерү мөһим. Я, менә сезгә рецепт. Хәлегез авырайса, тынычлык кирәк. Башка чакларда саф һавада күбрәк йөрегез. Яхшы ашауны да кайгыртыгыз.

Габдулла үз бүлмәсенә кайтып кергәч үк түшәгенә ауды. Урам шаушуы колагын тондырып, бөтен күзәнәкләренә әкрен генә үтеп керә һәм вак-вак калтырауга әверелеп бара иде сыман. Нинди сөйкемсез бу доктор, дип уйлады ул,— «кадерлекәем», «егеткәй» — уф! Ул авыруны, күп дигәндә, приказчик дип фараз итте шикелле — бу нәрсә мин-минлегенә тисә дә, үпкәләвен таныйсы килмәде Габдулланың. Хөкем карары чыгарылган чакта нинди вак хисләр били аны! Дөресе дә шулайдыр, чахоткадыр аңарда. Тик ул беркайчан да әллә ни таза булмады лабаса. Ютәле дә, бизгәге дә, хәлсезлеге дә электән аптырата килә, тик ул моңа карамый эшли килде. Аның зиһене әле дә ачык, фикерләве анык, ул шушы минутта ук өстәл артына утырырга әзер! Ләкин башта... әз генә черем итеп алырга, бәлки әле Ольховский киңәш иткән Гартманга да сугылырга ки-

рәктер. Тик бер генә табип та аның җирдәге тормышы күпме һәм ничек дәвам итәсен әйтмәячәк, бу бары тик бер тәңрегә генә мәгълүм.

Аннары аны йокымсырау басты... Аңының кайсыдыр бер почмагында — әллә өнендә, әллә төшендә — ул йөрәген сыкратып куйган бик мөһим бер карарын беркетеп куйды: ул беркайчан да өйләнмәячәк, бәхетсезлекнең аңардан тыш янә бер кешегә кагылуына ул һич тә юл куймаячак...

Эчпошыргыч көннәр тагын бер-берсенә ялганды, тик алар элеккеләрдән ачыграк түгел иде. Кичтән түшәгенә яткач, ул туңудан калтырана, төннәрен шау тиргә батып уяна, бүлмә бөркүләнгән төсле күренә, коридорда туктаусыз шапылдау, кычкырып сөйләшү авазлары тынмый, кайчак аның ишеген шакырга тотыналар, тик ул җавап бирми иде. Ул туйдырып бетергән кунакханәне алыштырырга булды. Бәхтияров белән Галиәсгар аңа «Свет» кунакханәсендә бер бүлмә карап кайттылар. Әйбәт: идәне паркет, түшәме биек, киң тәрәзәсе кояшлы якка карый. Әмма ул суык була икән ләбаса! Габдулла моны төне буе өшеп-калтырап чыккач ук төшенде. Чөнки тагын коры ютәл газаплый башлады, туңдырды. Әле кайнар чәй, әле аспирин йотса да, файдасы күренмәде. Димәк, монда калырга ярамый инде. Бәхтияров белән гәпләшү аны икенче борчуга да салды. Жандарм идарәсе аның байтак еллар элек чыккан бер китабы белән кызыксынырга керешкән икән. Жандармнар белән очрашу гына җитми иде инде!

Тукта! Авылның җылы өенә кайтып егылса, яхшырак булмасмы икән хәзер? Өчиледәге абыйсына кайтып керсә? Җитмәсә, уңае да туры килеп тора: сәүдәгәр якташы юлга әзерләнә икән ләбаса.

Авыл үзенең борынгы йолалары буенча яши, һәр яңалык монда ят, шикле нәрсә буларак хәвефле каршы алына. Кадимчелек заманында хаҗәтне үтәгән мондый йолалар хәзер инде искереп, тутыгып беткән коралны хәтерләтә иде. Кулланыштан чыккан мондый корал үзенне йомыкыйлыкка, катып калганлыкка, язмыш кагуларын көндәм кичерүгә, дини хорафатларга гына хезмәт итә ала иде. Әмма, ни гаҗәп, тел бүтән тормыш белән яши, ул тутыкмый, мүкләнми, ә үсә, халык теленә әверелеп килә иде. Шунысы гаҗәп, аксөякләр яңалык, заманчалык, мәдәният дәгъва иткән калада исә ул һаман чүпләнә, аңлаешсызрак була бара. Газета-журналлар халыкка Рәсәй мөселманнарын берләштерү намына уртак төрки тел кертергә тырыша иде. Ләкин авыл, шәһәрнең тәкәбберләнүенә, тупас, әдәбияттан ерак, артык урам теле дип санавына карамастан, үз нигезен ныгыта, һаман ныгытарак бара иде. Әлеге зыялылар тере халык теленнән читләшеп, чынлыкта язмыш бу милләткә насыйп иткән байлыктан, сүз белән бәян ителгән тарихыннан, аның чынбарлыгыннан йөз чөерәләр иде. Әйтик, «Тәңренең кашка тәкәсеме әллә син?» — дигән борынгы мәҗүсилек заманына кайтып калган бер гыйбарәсе генә дә ни тора ич аның! Ә каргалган балаларның кош сурәтенә кереп кара урманга очып китүләрен чагылдырган «Сак-Сок» бәете? Ә Акбүре турындагы риваять?

Хәзерге чынбарлыкны әле һаман танырга теләмәгән ясалма әдәби телнең яшәве гаҗәп ләбаса дип уйлады Габдулла: ул чуклы-чачаклы, купшы, төссез һәм казанлыларның чын тарихына, аларның бүгенге тормышына асла ят булган бер нәрсә. Ә халык җырларының сүзе дә, рухы да — сулышы вә буявы да бөтенләй башка. Аларда алла, күк, теге дөньялар белән бәйле табынулар, ышанулар, өметләрнең эзе дә юк, аларда сулыш кебек табигый нәрсәләр генә гәүдәләнә.

Ә ерак заманнардан килгән озын көйләребез? Аларда, гүзәл шаһзадәләр турындагы әсәрләрдән аермалы буларак, халык язмышы күпкә киңрәк чагыла, тирәнрәк мәгънәләр гәүдәләнә. Тарих җилләре борынгы Болгарны хәрабәгә һәм көлгә әйләндереп таратты да бетерде, яндырылган Казаннан шагыйрьләр һәм һөнәр осталары китеп барды, төзек бина-

лар җимерелде дә харап булды — халык җырларын гына туплар да ватмады, уклар да кадамады. Әнә шул җырлардан гына халыкның чын рухын да, чын телен дә табып була.

Көн арты көн уза, бик күп вакыйгалар, артка чигенгән саен, үзенең әһәмиятен югалта, яңаларына, көнелләрәкләренә чумып яшисе килә башлый. Ул инде хәзер үзен шактый ныгыган, сәламәтләнгән шикелле хис итә һәм шатланып: чирем дә инде минем ул кадәр аһ итәрлек түгелдер, бәлки әле доктор ялгышкан гынадыр, дип уйларга тотына. Әгәр чахотка эләктергән икән, ул үзен шулай кәефле, җиңел хис итә алыр идемени? Ул инде яңадан каланы тансыкларга керешә — бу үзе үк хәл керү, күңел күтәрелү билгесе түгелмени?

Әмма йөрәген шомландырган ниндидер хәвеф аны уйланырга, тирәяккка текәлебрәк карарга мәҗбүр итә иде. Абыйсы да үзен әллә ничегрәк серле тота, аны чамадан тышрак назлый, кеше-кара бимазалавыннан да коткарырга тырыша һәм нәкъ менә шундый фигыле белән шикләндерә иде. Ә беркөнне ул: «Кайтуыңны тирә-күршегә бик белдермәскә кушкан идең, берәр хәтәр эшкә бәйләнмәгәнсеңдер ич?» — дип сорап куйды.

— Юк,— диде Габдулла аны да, үзен дә тынычландырып.— Бик йончыдым, хәл җыяр өчен генә аулакны хуп күрәм...

— Әй дөньясы,— дип уфтанды абыйсы.— Бигрәк караңгы, бигрәк эчпошыргыч инде бу тормыш. Бөтен мәшәкатьләрне ташлап каядыр китеп югаласы килә. Яшьрәк тә булсак, ә?

Габдулла, йоклаганга сабышып, җавап бирмәде. Күп сөйләштеләр ич инде алар, күп уйланылды, төрле планнар корылды... Авылда калырга да гаилә корып җибәрергә, балалар укытырга иде, тик кая инде моңа җөрьәт итәргә! Сәламәтлек тагын төзәлүгә таба китте сыман, нигә инде күпләргә хас тормыштан тәм табып яшәмәскә аңа?

Ләкин мондый тотрыксыз, ышанычсыз, күңелсез хәяттә үзең өчен генә аерым бәхеткә өметләнү мөмкинме икән? Аның өлешенә, иптәшләре өлешенә, эшче һәм игенче өлешенә тигән югалтуларны шәхси бәхет белән генә тутырып буламы икән?

Шәһәргә генә кайтып җитсен, журналларның берәрсен актару белән шул милли өметләр турында авыз суы агызуларга юлыгачак. Идеаллар турындагы язмаларга! Чәнчелеп китсен идеалларыгыз, әфәнделәр! Сезнең идеалыгыз — байлыкны арттыру, ә күңелегез сукыр, караңгы, аңа хакыйкатьне күрү язмаган — күзләрегез алтын белән томаланган. Зәгыйфь рухыгыз исә симергән гәүдәләрегезне көчкә-көчкә генә йөртә.

Ә сез, ярты юлда арыган дусларым, азмы-күпме күзе ачык халык, нинди хәлдә? Китап илтеп биргәч, ач игенчеләр дә бәхеткә тиенәчәк дип гөман кылдыгыз инде сез. Ул китапларда үгет-нәсихәт нинди мул иде. Мин:

> Бу сәнә ачлык җыланы чын халык бәгърен ашый!
> Кит, китап! Сабрит, дип әйтмә,— ул халык көчен ашый!

— дигәч, үпкәләгән идегез. Мин хәзер дә: халыкка үгет-нәсихәт түгел, ипи бирегез дим.

Әй, изге хәзрәтләребез, ә сезнең идеалларыгыз нинди? Җирдә — тәкъва көндәмлек, күктә — оҗмах һәм кыямәт көнне җәза. Сез, иман кирәк, дисез. Хуш, ярлы ходайга ышана, әмма ул иртәгә ачтан үлмәсенә ышанып бетми. Җәза белән куркытуыгызны беләм, әмма курыкмыйм: гайрәтем бик кыйммәткә төште. Кайчандыр мин сезнең сафка кайтырмын да халыкны тәңребез кануннары буенча яшәргә өйрәтермен дип ниятләгән идем... Ә хәзер юк! — мин һәрвакыт хезмәт кылдым, тик һәрвакыт фәкыйрьлектән чыга алмадым, хәзер мин гади халыкның ничек яшәвен, ни турында җырлавын, нәрсә өчен яшь түгүен бераз беләм.

Минем идеалым — намуслы, дөрес юлдан атлау, тормыш чынлыгын язу. Бәлки шул хакыйкать ерак киләчәктә рухи түбәнлектән һәм кешеләрнең ваклыгыннан, үз мәнфәгатен генә кайгыртуыннан югарырак күтә-

релгән яңа буыннарга юаныч һәм таяныч булыр. А, ул гүзәл буын яхшылыклар эшләр өчен өлгереп пешеп җитәр!..

Күзләренә җиңелчә йокымсырау эленгән сыман тоелса да, хисләре үткен, сизгер, башы, зиһене ачык иде. Керфекләрен ачып, караңгыланып килгән күккә карады һәм анда болытлар кәрванын күрде. Кәрванның очлаеп килгән башы алга ашкынган, канат җилпегән көчле кошны хәтерләтә иде. Бу сурәт керфекләрен йомгач та, әле шактый вакыт аңыннан китми торды. Икенче юлы уянгач, ул төн карасы җәелүен, карлы яланнар, сахралар өстенә тулган ай нурлары сибелүен күрде. Башкалардан якты җемелдәве белән аерылып торган Зөһрә йолдыз талгын гына күктә йөзә иде.

...Кайчандыр җирдә йомшак күңелле матур бер кыз яшәгән. Ятим калгач, ул явыз үги анасы һәм аның юньсез кызы җәбереннән җәфалана башлаган. Бер айлы кичтә аңа үги анасы төпсез мичкәгә су ташырга кушкан. Зөһрә чишмә буена барып яшь коя-коя, айга, үзе янына алуын, җирдәге бәлаләрдән коткаруын үтенеп, ялвара башлаган. Кызыкайның инәлүен айдан ерак түгел яшәгән бер йолдыз ишеткән һәм ятимәне үзенә алган. Шул көннән бирле шат күңелле ай үзе дә моңлыга әйләнгән. Ә кызыкайга ярдәм кулын сузган шәфкатьле йолдыз исә тагын да яктырак яна башлаган, кешеләр исә аңа Зөһрә исемен кушкан.

Шул заманнан бирле ул бөтен хәлләрне ялыкмас уяулык белән күзәтә, ятимнәр һәм фәкыйрьләр, кыерсытылганнар һәм ялгызлар — барлык җаннар, барлык тереклек ияләре мохтаҗ булган гаделлекнең җиргә иңүен түземлек белән инде менә ничә еллар — кәрван-кәрван еллар агышы дәвамында көтә дә көтә...

Русчадан **Тәуфикъ ӘЙДИ** тәрҗемәсе.

---

**МӨХТӘР АУЭЗОВ**, казах язучысы.

*Тукайның прогрессив һәм горур поэзиясе ислам диненең катып калган кануннарын, аның фанатизмын нык гаепли, үз халкының алдынгы җәмәгать эшлеклеләрен икеләнмичә рус культурасы казанышларын үзләштерергә чакыра. Аның иҗаты бөек Пушкинның ирек сөюче поэзиясенә якын тора.*

*Тагын шунысы да әһәмиятле: Пушкин реализмын кабул иткән Тукай шул чор җәмгыятенең яраксыз якларын һәм тарихи каршылыкларын ачып сала алды. Тукай чын халык шагыйре иде.*

**БЕРДИ КЕРБАБАЕВ**, төркмән язучысы.

*Мин, әле поэзия өлкәсендә кулыма каләм алмастан элек үк, Тукайның дулкынландыргыч, тирән әсәрләндергеч шигырьләрен күп укыдым...*

*Габдулла Тукайга булган бурычымны үтәү теләге белән, мин аның ике мең юллап шигырен төркмән теленә тәрҗемә иттем...*

---

# Равил Бохараев

## ТУКАЙ ТИРӘСЕНДӘ

ДРАМАТИК ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕКЛӘР

«...хыялым татарча, татар рухында, татар геройлары белән дөньяга бер «Евгений Онегин» чыгарудыр.»

Тукайның соңгы хатларыннан

* * *

...Бронза Державинлы көзге бакча.
Исән чагы әле һәйкәлнең.
Ә яфраклар ята йокымсырап —
Сагынадыр алар җәй тәмен...

Очлы түбәләр һәм манаралар
Төбәлгәннәр бар да гел өскә!
Губернаның кичке башкаласы
Тынып калган горур бер төстә.
Провинциаль ностальгия белән
Чирли шәһәр. Чиркәү чыңнары
Белән янәшәдә саргаялар
Шәрык мәчетенең сырлары.
Кичен шәһәр — моңсу. Әйтерсең лә,
Һавадагы торна рәтләре.
Телгәләнгән чуен челтәрләре,
Сырлы-сырлы рәшәткәләре...

...Пушкингача чорны да җәлләми
Еллар узган. Бакча югалган.
Ә һәйкәлдән шәмдәл коелгандыр —
Бернинди дә хәбәр юк аннан...
Казан карты күккә ашкан үзе —
Белмим, кемнән дога укыткан?
Әсир немец исә ул һәйкәлнең
Урынына басма утырткан.
Һәм опера храмы калкып чыккан
Бакыр бабай торган урында...

---

РАВИЛ БОХАРАЕВ — рус телендә язучы, татар шагыйрьләрен русчага актив тәрҗемә итүче Мәскәү шагыйре.

Эзәрлекли мине борынгы вальс,
Узган саен бакча турыннан...

Кичке Казанның мин асылына
Төшенергә телим үзем дә —
Бөеклеген төсмерләргә телим
Бөек шагыйренең йөзендә...

Державинмы? Менә аның йөзе.
Ә бит үзе морза каныннан.
Татар күзләреннән вакыт аккан —
Күз яшьләре булып агылган...
Юк, ул түгел аның үз шагыйре —
Бөеклеге, гәрчә, хактыр да.
Чөнки аның даһилыгы әле
Сүрән генә һаман яктыра...
Башка исем — чынлык хәбәрчесе!
Эзләп тормый күктә юк Айны,
Йолдызлыкны күзәт: Державинны...
Пушкин... Лермонтов... һәм Тукайны.
Ул кабынды Чор Йолдызы булып —
Я йолдызга тиң ул, я утка.
Ул яктырта, ул яндыра безне.
Һәм не при чем монда чахотка...

Сөялдем дә юеш рәшәткәгә,
Үкседем мин — күңел кайнаган.
Юк, коткарып булмаячак аны —
Хакыйкатьне Тукай сайлаган.
Ә геройны мин табарга тиеш!
Караңгы һәм юеш — тирәлек.
Төшеп киттем Балык рәтләренә,
Вальс бара эттәй ияреп...

* * *

...Йөртә мине өмет һәм мәхәббәт —
Балык рәтләрендә — караңгы.
Минем сагышларым тирә-якка
Караңгылык булып таралды.

Кайда герой? Әллә приказчиклар
Клубыннанмы аны табасы?
Тукай демократ та, тик аның да
Сәүдәгәрләргә үз карашы.
Алып-сату, сәүдә дөньясында
Зыялылык гөнаһ чутлана.
Мещанлык ят аңа...
Ул университет
Каршысына килеп туктала...

Акыл ияседәй чал бу бина,
Тик файда аз аннан татарга.
Иң яхшысы, тукталып та тормый,
Алга карап тагын атларга...

Ыспай гына атлап бара герой,
Калышмыйча шәһәр халкыннан.

Без пассажга — көзгеле зур залга
Керик әле аның артыннан.
Зал — туп-тулы. Офицерлар, франтлар,
Биржевиклар һәм дә ханымнар.
Тыз-быз килә официант халкы,
Балкып тора татлы табыннар.

Мин геройны дөрес керттем микән?
Калам менә ничә кат уйга —
Чөнки Тукай шигырьләрендә юк
Истә калырлык бер вакыйга.
Керсә керсен инде, аннан гына
Булмас әле, әйдә, зыяны.
Бер баласы татар — шәригатьнең,
Ә героем — бераз зыялы.
Реаль җирдә яшәсә дә Тукай,
Тылсым аның һәрбер сүзендә.
Трактирларны тасвирлаган чакта
Уздырган ул хәтта үзен дә.
Ә шулай да, бөтенесен үлчәп
Карагачтын, килдем карарга:
Алып кереп дөрес эшләгәнмен
Геройны мин бу ресторанга...

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

— Тагын шул ук Тукай. Ни әйтергә?
Һәлакәткә дучар ул даһи.
— Сәламәттер әнә Закир Рәми...
— Җитәрегез инде, валлаһи!
«Вакыт» әнә бушлай чыгып ята,
Икеләтә тираж тарала.
— Мин Тукайның дусты!
— Шешәдәше!
— Тагын кысыр ызгыш яңара...

— Тукай нәрсә? Ул терелмәс хәзер,
Ләкин аның килә яшисе.
— Ул шигырьдә — тупас. Вәгазь чәйни.
Ничек инде шуңа дәшмисең?
— Тукай җаны, йолдыз яктысыдай,
Килеп җитәр беркөн безгә дә.
— Батырлык бу! Үлем алдыннан да
Шигырь язу — җанын өзгәләп.
— «Әльислах»та бергә эшләдек без,
Охшаган ул сабый балага.
— Ул, дан эзләп, Җаегыннан китте
Һәм тарыды менә бәлагә.
— Татар даһиеның урны — Казан!
Тукай булмас иде ул анда.
— Һәм Казанда үләргәме аңа?
— Үләргә дә — кирәк булганда...
— Камил әфәнде кем?
— Мин! Ни кирәк?
— Тиеш сезгә мин хат бирергә.
— Кемнән ул хат?
— Туташ — фаэтонда,
Кыенсынды үзе керергә...

Саубуллашты Камил, үкенеп — ник
Кергәнenә бу ресторанга.
Һәм юнәлде Проломный буйлап
Күл ягына — ягъни, Кабанга.
Ресторанның тынчу шау-шулары
Артта калды, тынды, югалды.
Камил «Амур» кунакханәсенә —
Даими номерына юл алды.

Ә кайчандыр шушы номерларда
Тыйнак кына табын янында
Тукай белән Фатих Әмирхан да
Утырганнар Казан таңында...
Гомер итте Тукай номерларда —
Номерлардан башы чыкмады.
Бар дөньясы аның шунда иде —
Шунда язды, шунда сыктады.
Гел Игелек эзләп, бөек дәрвиш
Һәрчак шулай шыксыз яшәде.
Юкса, аңа төпләнергә иде.
Юк, соң түгел — ул бит яшь әле...

Сәер тормыш. Ничек аңлатырга?
Кемгә сөйләсәң дә, аптырый.
Китаплары юкса чыгып тора,
Тиражларын бер дә яткырмый.
Байлыкта да яши алыр иде,
Чөнки әле үсмер чорында
Ул Иделдән алып Бакугача
Дан казанган шагыйрь, чынында.
Ә дуслары аның күпме иде?
Юкка чыкты алар, ә оят?!
Тик шагыйрьне бер дә мул тормышта
Яшәтмәде чын әдәбият...

* * *

«...белмим, үземне кая этәрәмдер...
Оятымнан ничек үлмәдем?
Мин Тукайга хат язмакчы идем,
нәрсә язарга да белмәдем.
Һәм еладым. Ул елаулар безгә
әбиләрдән калган — борыннан.
Хатын-кызны Тукай сөймидер ул —
аз яза бит сөю турында.
Вакытым тар. Кыска язмак булам.
Күңелемдә бүген ут ташты.
Мин төн буе шигырь укып чыктым —
Заһидәне, Гыйффәт Туташны.
Шушы хакта белгәч, ертып атты,
мыскыл итеп әни аларны.
«Урам кызы булыр идеңмени,
инсафсыз кыз?»— диде аннары.
Кыйнады да мине. Бау булмаса,
ярар әле озын толымым...
Нишләргә соң миңа? Я, ходаем!
Күңелләрем нигә тулы моң?..
Берәрсенең кәләшеме булыйм?

Тәмуг утларында сулыйммы?!
Әти — мәчетендә. Өйдә — беркем...
Ап-ак кәгазь ята каршымда.
Яшим әле хода хөкемендә.
Язам — әле бәла күренми.
Гомер итәм мин бикләнгән килеш.
Күз яшьләрем чак-чак түгелми.
Сезне минем укыганым да бар,
һәрбер юлыгызга шатланып.
Әти гәзит алып кайткан иде,
өйдә калган ялгыш сакланып.
Бар да кайтыр тиздән. Мин бары тик
караңгылык күрәм алдымда.
Хурлыктан да курыкмыйча менә,
и әфәндем, сезгә яздым да
Нишләргә дә белмим.Ниләр кылыйм?
Ходай мине бер күрәме, я?!
Сез — пәйгамбәр, тылсым көтәм сездән!
Хәсәнова язды, Рәмия».

* * *

«Тапкан пәйгамбәрне!»— Камил белә:
Пәйгамбәрләр юк үз илеңдә.
Тик кешене коткарырга кирәк.
Я бирергә киңәш, кимендә.
Ә Сәгыйтькә мөрәҗәгать итсәң?..
Ул өстенә киеп алды да,
Озын коридордан бераз узгач,
Шакылдатты номер «6»га...
Ята Сәгыйть нәкъ хан рәвешендә —
Мендәренә кырын яткан да
Мандолина чиртә җитди генә.
Кара төтен бүлмә — тартканга.
Акрын гына чиртеп, һәрбер кылдан
«Тәфтиләү»не эзли сак кына.
Ә идәндә ята ачык дәфтәр —
Яза башланган ул чак кына...

— Ә, килдеңме, ирек такмакчысы!
Мин язалмыйм, нәсер шул килеш.
— Ну тарткансың.
— Көн дә шулай миндә.
— Ташла әле, музыкант, имеш.
Интектермә инде шул кылларны —
Илһам сине, дускай, читләтә!
— Ә син үзең бүген Мәҗнүн кебек,
Бу мәхәббәт мине нишләтә!
— Булырсың да! Менә шушы хатны
Укып кара әле тоташтан.
Миңа аны кичке ашта чакта
Китерделәр шушы туташтан.
— Ләйлә хатымыни?
— Көлмә әле!
Кем уйлаган аның язасын.
Шул газета аркасында хәзер
Акылыңнан хәтта язарсың.

Күз салды да Сәгыйть тиз-тиз генә,
Сәер хатка исе китмичә,
Кире бирде — мандолинасына
Чиртеп алды, бер сүз көтмичә.
— Ниндидер бер истеричканы син
Юатырга тиеш, димәк ки?
Өйрәнергә сиңа вакыт инде.
Нишләргәме? Берни кирәкми!
Ул, мөгаен, кошлар күргән саен,
Качып кына шигырь язадыр.
Таныш түгел иргә, оялмыйча,
Хат язарга ничек базгандыр?
— Ләкин ул бит миннән җавап көтә,
Уйлыймын шул җавап хакында.
— Син яхшылык эшлим дип килдеңме?
Укыттыңмы шуңа хатын да?
Әгәр Тукай адресына килсә,
Әйтмәс иде ул беркемгә дә.
Синең белән без — җилкуар, дускай —
Син Тукайга безне тыңлама!

Чирткәләде Сәгыйть кылларына,
Бик канәгать иде йөзе дә.
Ишетелеп калды кинәт бер көй —
Һич көтмәгән иде үзе дә.
Тик Камилнең бер дә кәефе юк —
Иске дустына ул үпкәле.
Юк, аңа да тәэсир итте бу көй:
Күз алдына килде үткәне.

Хәтеренә төште балачагы:
Ай нурында чалгы чыңнары.
Акрын гына көйли чалгычылар
Иң борынгы таныш моңнарны.
«Тәфтиләү» ул — анда мең гасырлык
Мәхәббәтнең ачы моңнары.
Буламыни халык моңы белән
Сугарылган җырның тынганы?!
Тукай инде үз жиренең данлы
Җырчысына әнә әйләнгән.
Аның Сүзе халык моңнарына
Әнә ничек тыгыз бәйләнгән!

• • •

Татарларга Тукай — ходайдандыр,
Тик бу якта һаман таң атмый!
Ә Рәмия елый-елый уйлый:
Хатын-кызны Тукай яратмый...
Ни әйтергә кызга җавап итеп?
Нинди сүзләр аңа табасы?—
Яратса да, алар арасыннан
Эзли Тукай бары Анасын!
Шагыйрь турында сүз сөйләр чакмы?
Аңлаталсын хәзер кем аңа —
Хатын-кызлардан да илаһи зат
Юк икәнне фани дөньяда...


Караватта яткан папиросын
Сәгыйть эзләп тапкан арада,
Үзалдына Камил уйлап куйды —
Кызга нинди сүзләр табарга.
Әмма Сәгыйть әңгәмәдән туймый,
Дәвам итте иске бәхәсен.
Дустына ул дәште кинаяләп,
Белеп кенә үзе бәһасен:

— Син явызлык эшләмәдем диеп
Уйлыйсыңмы инде беркемгә?
— Юк, әлбәттә!
— Тик явызлык зарур,
Ансыз булмый дөнья бер көн дә.
— Каян килә сиңа бу ышаныч?
— Тормыштан ул. Менә син, әдип,
Чуалдың гел Тукай тирәсендә,
Читләшәсең хәзер нигә дип?
— Ул чахотка белән чирли хәзер.
Мәхрүм инде шигырь утыннан.
— Сез түгелме, аның номерында
Таңга кадәр шигырь укыган?
Аны чиргә сез сабыштырдыгыз —
Тәмәке һәм шәраб, гайбәттән...
— Ялганлама!
— Бер дә ялганламыйм!
Сез җиткердегез, сез, әлбәттә!
— Җитәр!
— Аның рухын сындырырга
Тырыштыгыз, тик ул сынмады!
Сез йөрдегез аңа эшсезлектән...
— Мин яраттым аны!..
Чыңлады
Сәгыйть кулындагы мандолина.
Чыгып китте Камил шашынып...
Кул селтәде: нигә кайгырырга?
Китеп барды аннан ашыгып.

Ул кайтты да ятты — тагын бер кат
Күңеленнән барсын кичереп.
Порт-Артурдан кайткан инвалидтыр —
Урам буйлап
Җырлап узды яшь бер исерек...

Русчадан **Роберт МИҢНУЛЛИН** тәрҗемә итте.

Тукайның 100 еллыгына




Атаклы Кырлай авылы күренеше.

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

# КЫРЛАЙ

Әдәбият тарихына матур яңгырашлы шигъри исем булып кергән Кырлай авылына килсәң, дулкынланудан тын кысыла: Сәгъди абзыйның инешкә таба иңкүләнеп төшкән бәрәңге бакчасында бәләкәй Габдулланың каны тамган. Алты яшьлек малай авыр крестьян хезмәтендә катнашкан, бакчада бәрәңге чүпләгән. Шунда Сәҗидә апасы көрәк белән ялгыш аның аягын кискән. «Моны ник яздың?— диярләр. Ни өчен языйм? Шул вакытта аягым бик авыртканга вә хәзер дә аякта шул җәрәхәтнең эзе булганга, тоттым да яздым»,— ди Тукай.

Сәгъди абзый — халкыбызның иң юньле бер кешесе. Кыска бишмәте өстенә ак киндер алъяпкыч япкан, киндер бияләй кигән атлы-тунлы бу крестьянның эче тулы яхшылык: сабыр холык, ятим балага игътибар, эшлеклелек, хатын сүзенә артык каршы килмичә генә «ир — баш, хатын — муен» мәкален тормышта раслаучы бер ир. «Бездә катык, сөт, ипи күп, теләгәнчә ашарсың»,— дип шатландыра ул ярым ач Габдулланы Өчиледән алып киткәндә. Әмма Казан арты — ярлы, ярлы... Сәгъди абзыйның да сәкесендәге ризыгы шул катык, бәрәңге, ипидән узмый. Габдулла үзенә Фәтхерахман хәзрәт биргән биш тиенне Әтнә базарында ак күмәчкә тота. Юлда кайтканда исә, Сәгъди абзый артына борылгалап кыенсынып кына: «Әниеңә дә калдыр» — ди. Сабантуй көнне Кырлай егетләре-кызлары «чабата киндерәләрен дә бик тырышып, матурлап бәйләп» урамга чыгалар. Чабата кию—фәкыйрьлекнең иң беренче дәлиле. Бәләкәй Габдуллага үлгән бала Садретдинның бишмәтен киертү мәсьәләсендә өйдә тавыш чыга — Сәгъди абзыйның бөтерчек кадәр бу малайга бишмәт алырлык та хәле юк.

Сәгъди абзый күп хәсрәт кичергән. Хәсрәтнең иң ачысын — бала хәсрәтен. Беренче улы — Садретдин, менә-менә кул арасына керер, тырмага чыга башлар дип ата шатлыгы кичереп яшәгәндә генә, җиде яшендә үлеп китә. Крестьян ир өчен, ата кеше өчен нинди зур фаҗига бу! Бәлки аңа исән калыр өчен нибары бер төймә дару җитәсе булгандыр... Караңгы Казан артында аны кем бирсен? Габдулланы уллыкка алган елны Сәгъди абзыйның тап-таза егерме бер яшьлек кызы Сабира тәүлек эчендә кинәт чирләп үлеп китә. Авылда түгел, бөтен өязендә табиб юк, кешегә медицина ярдәме күрсәтү турында уйлау да юк.

Күп тә үтми, язмыш тарафыннан болай да каһәрләнгән Сәҗидә исемле кызы унбишенче яшендә үлә. Инде менә Кушлавычтан килгән Бәдретдин абзый «закон белән» куркытып Габдулланы да алып китә. Сәгъди абзый гаиләсе өчен зур хәсрәт була бу. Бер Сәгъди абзый гына түгел, үз малайлары тугач Габдуллага бераз салкынайган үги ананың да аерылганда елап калуын ятим малайның Кырлайда бик үк үги булмаганлыгын күрсәтә. Бәдретдин абзый белән бәхәсләшкәндә үги ана «үкереп җылап» җибәрә, басу капкасына кадәр «егълаганнары хәлдә» икәүләп Габдулланы озата баралар. «Ахырдан әни: «Онытма безне, онытма! Безне онытсаң, тәмуг кисәве булырсың».— дип, ахыр сүзен кычкырды...»

Тормыш Сәгъди абзыйны фәкыйрьлек белән генә түгел, әнә шулай йөрәк өзгән үлемнәр, газаплы аерылулар белән каһәрле.

...Габдулла Кырлайдан ерак сәфәргә киткән. Йөрәгендә яхшы күңелле крестьян Сәгъди абзыйга зур ихтирам, хыялында калын урман эчендәге Шүрәле, Сәгъди абзый бакчасы башындагы инеш чоңгылында яшәүче су анасы кебек матур хыял, хәтерендә крестьян егетләреннән ишеткән бик күп җыр, әкият белән киткән ул.

Кырлай белән Өчиле арасын ул чорда әле кара урман каплаган булган. Ул кара урман шаулый-шаулый Габдулланы зур тормыш юлына озатып калган...

---

*Журналыбызның быелгы 1—4 саннарында Т. Хаҗиәхмәтов рәсемнәренә бирелгән, Кушлавыч, Өчиле, Сасна һәм Кырлай турындагы текстларның авторы М. Мәһдиев.*

# КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

СССР Министрлар Советы каршындагы Геодезия һәм Картография баш идарәсе 1983 елда Казахстанның Уральск өлкәсе туристик картасын һәм Уральск шәһәренең үзәк өлеше планын бастырып чыгарды. Уральск шәһәре планында күренекле шәхесләр, шул исәптән Г. Тукай исеме белән бәйле урамнар да күрсәтелгән: 1895—1900 елларда шагыйрь яшәгән сәүдәгәр Галиәсгар Госманов йорты (Почиталин урамы, 66 йорт), яшүсмер Тукай хәреф җыючы булып эшләгән элеккеге «Уралец» газетасы типографиясе бинасы һ. б. урыннар. Кыскасы, Уральск үзенең Тукаен онытмаган.

Уральск шәһәре үрнәгендә башкалабыз Казанның да Тукайга бәйле урыннары күрсәтелгән аерым планын төзү бөек шагыйребезнең тормышын һәм иҗатын пропагандалау юнәлешендәге кичектергесез бурычларыбызның берсе булып тора[1].

Дөрес, Казанның күренекле шәхесләр исеме белән бәйле урыннарын күрсәтеп төзелгән схема-план 1977 елда Мәскәүдә дөнья күрде. Ләкин анда Тукайга бәйле булган бары тик өч урын гына аталган: Тукайның Островский һәм Татарстан урамнары чатындагы бакчадагы һәйкәле, шагыйрь исеме белән аталган кинотеатр һәм Татарстан урамындагы 14/59 номерлы йорт, элеккеге «Болгар» кунакханәсе. Шуның өстенә Тукайның «Болгар»да яшәгән еллары да төгәл күрсәтелмәгән. Билгеле булганча, Тукай бу йортта, планда күрсәтелгәнчә 1907 елдан 1913 елга кадәр даими яшәмәгән.

Казанның шагыйрь исеме белән бәйле урыннары схема-планын төзү, аның Уральскидан башкалабызга килү вакытын ачыклаудан һәм беренче көннәрдән алып торган урыннарын билгеләүдән башлау дөрес булыр. Бу уңайдан әдәбиятта һәм көндәлек матбугат битләрендә төрле фараз кылулар, капма-каршы фикерләр дә булды.

Тукай Уральскидан Казанга кайчан килгән, беренче көннәрдә кайда тукталган һәм соңыннан кайларда торган?

Бу сорауларга җавапны шагыйрьнең замандашлары истәлекләреннән табабыз. Мәсәлән, Г. Камал Казанда Тукай белән беренче очрашуы 1907 елның көзендә, ул «Йолдыз» газетасында секретарь вазифаларын башкарганда булуын яза. (Тукай турында замандашлары. Казан, 1960, 73 б.) Моңа Тукайның дусты һәм замандашы, «Әльислах» газетасы редакторы В. Бәхтияров ачыклык өсти. Тукай белән беренче очрашуын ул түбәндәгечә тасвирлый: «Октябрьнең (1907 ел — Х. З.) 10 ында иртә үк «Әльислах» идарәсендә («Болгар» номеры, 12 бүлмә) бернички кеше белән сөйләшеп утырганда, ишектән бер кеше килеп керде». Шуннан соң, В. Бәхтияров керүченең «Болгар»да 40 номерда тукталган Тукай икәнлеген яза. (Тукай турында замандашлары. Казан, 1960, 86 б.) Шулай итеп, замандашлары истәлекләренә караганда, 1907 елның октябрь башларында Тукай Казанда булып, «Болгар» номерларында яшәгән. Димәк, ул Уральскидан 1907 елның сентябрь (иске стиль белән) ахырларында киткән. Бу минем туу турында таныклыгым белән дә раслана. Уральск өлкә загс бүлеге биргән белешмә буенча мин иске стиль белән 1907 елның 25 августында туганмын. Ә әнием, Тукайның апасы Газизә Зәбирова әйтүе буенча шагыйрь Уральскидан Казанга мин туганнан соң бер айлап вакыт үткәч киткән. Димәк, Тукай Казанга 1907 елның иске стиль белән 20—25 сентябрьләрендә юл тоткан. Күп төрле чыганакларда билгеле булганча, Тукай Казанга килеп бераз вакыт үтүгә, гаскәри хезмәткә каралырга Казан артына кайтып китә. Туган якларында ике атнага якын торып, гаскәри хезмәттән азат ителгән Тукай Казанга, «Болгар» номерларына әйләнеп кайта. Замандашы Гыйльметдин Шәрәф истәлекләрендә бу хәл октябрь ахырларында булды дип теркәлгән. Шуннан соң Тукай «Болгар» номерларыннан китеп башка җирләрдә дә тора башлый. Тукай иҗатын башлап өйрәнүчеләрнең берсе, аның замандашы Җамал Вәлиди шагыйрьнең 1914 елда дөнья күргән шигырьләр җыентыгына кереш итеп язылган биографиясендә аның Габдрахман Дәүләтшин җитәкчелегендәге «Китап» ширкәтенә экспедитор булып эшкә керүе һәм ширкәтнең конторасы номерында яши башлавын яза[2]. Шушы ук мәгълүматлар Г. Камалның 1933 елда басылган истәлекләрендә дә теркәлгән.


Тукайның Җамал Вәлиди истәлегендә телгә алынган тору урыны аның Уральскига, апасы Газизә Госмановага 1908 елның 27 мартында язган хаты белән дә раслана. Мәгълүм булганча, Тукай хат азагында үз адресын күрсәтеп түбәндәгеләрне яза: «В гор. Казань, книгоиздательство «Китаб», Абдулла Тукаеву». (Тукай Г. Әсәрләр. 4 т. Казан, 1977, 298 б.)

Югарыда китерелгән мәгълүматлардан күренгәнчә 1908 елда Тукай «Китап» ширкәте биләгән «Мәскәү номерлары»нда да яшәгән. Бу уңайдан Г. Кайбицкаяның «Безгә кадер-

---

[1] Бу хакта кара: «Казан утлары», 1984, 1—12 саннар.

[2] Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре. (Җамалетдин Вәлиди тарафыннан язылган Тукайның тәрҗемәи хале һәм әшгаре хакында бер мөляхәзә.) Казан, 1914, 33—34 бб.




ле йорт» («Казан утлары», 1984, 7 сан) исемле мәкаләсенә тукталып үтик. Автор бу язмасында Тукай Казанга килгәч университет каршында урнашкан иске поликлиника ишегалдындагы йортка туктады һәм шунда ике елга якын яшәде дип яза. Ләкин, югарыда ачыклап үтелгәнчә, Тукай бу йортта бервакытта да яшәмәгән. Тукай Уральскидан соң Казанда биш

ел ярымлап яши. Бу еллар эчендә ул «Болгар», «Мәскәү номерлары», «Свет» һәм «Амур» кунакханәләрендә гомер иткән. «Свет» кунакханәсендә торганын аның замандашы Габдулла Гыйсмәти 1914 елда ук язган: «1912 нче ел, апрель башлары. Ул чакта Тукай «Свет» номерларында, иң читтәге кечкенә бер номерда тора иде». (Тукай турында хатирәләр. Казан, 1976, 133 б.) Шуны да искә алырга кирәк, Тукай берара Фатих Әмирхан «дача»сында да яшәп ала. Бу вакытларны искә алып Г. Камал түбәндәгеләрне яза: «Фатих Әмирхан Кабан күле тарлавыгында Ботаника бакчасы каршындагы йорттан бер «дача» алып, редакциясен дә шунда күчерде, редакция белән бергә Тукай да шунда күчте. Тукайның үзенчә, бик «рәхәтләнеп», үзе дигәнчә яшәгән вакыты шул «дача»да торган вакыты булды» (Тукай турында хатирәләр. Казан, 1976, 64 б.).

Түбәндә Казанның Тукай исеме белән бәйле урыннарының схематик план фрагменты бирелә. Ул киләчәктә башкалабызның теге яки бу дәрәҗәдә бөек шагыйрь исеме белән бәйле урыннарын чагылдырган тулырак карта-схемасын төзүдә чыганак булыр.

1. Татарстан һәм Киров урамнары чатына урнашкан элеккеге «Болгар» кунакханәсе (№ 14/59). Тукай анда даими рәвештә булмаса да, 1907 елның көзеннән 1912 елның декабрь башларына кадәр яшәгән.

2. Киров урамында (элеккеге Мәскәү) урнашкан «Мәскәү номерлары». Бу кунакханәдә Тукай 1908 елда яшәгән. Төгәл урыны әлегә ачыкланмады, шуңа күрә схематик планда да күрсәтелмәде.

3. Ф. Әмирхан «дача»сы урыны. Шагыйрь анда 1909 елда яшәгән.

4. 1912 елның апрель башыннан Тукай яшәгән элеккеге «Свет» кунакханәсе. Кайсы бинада урнашканлыгы әлегә ачыкланмады һәм схематик планда күрсәтелмәде.

5. Элеккеге «Амур» кунакханәсе урнашкан бина (Киров урамы, 70). Бу бинада Тукай 1912 елның декабрь аеннан 1913 елның февраль ахырына кадәр яшәгән.

6. К. Нәҗми һәм Островский урамнары почмагына урнашкан элеккеге Клячкин больницасы. 1913 елның 26 февраленнән соңгы көннәрен Тукай шушы шифаханәдә үткәрә.

7. «Шәрык» клубы урнашкан бина. (Татарстан урамы, 8). Бу клубка шагыйрь еш йөргән, 1910 елның 15 апрелендә үзенең «Халык әдәбияты» дигән лекциясен шушы клубта укыган.

8. 1908—1909 елларда Тукай актив бәйләнештә булган «Әльислах» газетасы редакциясе урнашкан йорт (Тукай урамы, 63).

9. Г. Тукайның Островский һәм Татарстан урамнары чатындагы һәйкәле. 1958 ел. Скульпторлары Садри Ахун, Л. Е. Кербель һәм Л. М. Писаревский; архитекторы Л. Павлов.

10. Г. Тукайның М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы һәйкәле.

11. Г. Тукай исемендәге кинотеатр. (Тукай урамы, 64).

12. Тукай урамындагы бинада ачылачак Г. Тукай музее.

13. Татарстан АССРның Берләштерелгән үзәк дәүләт музее (Ленин урамы, 2). Музейның әдәбият бүлегендә Г. Тукайга багышланган экспозиция урнашкан.

14. «Новый клуб» —1905 елда ачыла. 1912 елда ул хәзерге Татар дәүләт академия театры бинасына күчә (Горький урамы, 13). Клубта һәвәскәрләр, профессиональ театр труппалары, шул исәптән «Сәйяр» тарафыннан спектакльләр куела. Тукай клубка еш йөргән, кайбер әдәби-музыкаль кичәләрдә чыгыш ясаган.

15. Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе урнашкан бина (Гоголь урамы, 4).

16. Татарстан Язучылар союзының Г. Тукай исемендәге клубы урнашкан Матбугат йорты бинасы (Бауман урамы, 19).

17. Габдулла Тукай исемен йөрткән урам.

18. Хәзерге Г. Камал һәм Париж Коммунасы урамнары арасында булган элеккеге Печән базары урыны. Ул Тукайның әсәрләрендә күп тапкырлар телгә алынган, шулар арасында «Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы күренекле урын алып тора.

19. Казан елга портына барганда тимер юл күперен узгач сул кулдагы Яңа бистәдәге һөнәрче Мөхәммәтвәли йорты. 1891—1893 елларда Тукай яшәгән бу йорт урыны схематик планда күрсәтелмәгән. Ә. Фәйзинең «Тукай» романында ул йорт зур булмаган ике катлы Степанов йорты дип бирелә.

20. Казанның хәзерге В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Үзәк стадион каршында булган Ташаяк ярминкәсе урыны. «Исемдә калганнар»ында Тукай һөнәрче Мөхәммәтвәлидә торган вакытында Ташаяк ярминкәсенә баруын искә ала. (Бу урын схематик планда күрсәтелмәгән.)

**Хөсәен ЗӘБИРОВ.**

# ТУКАЙ ШӘҖӘРӘСЕ

*Минем атам Мөхәммәтгариф,*
*Кушлавыч карьясендә*
*Мөхәммәтгалим исемле*
*мулланың угылы булып,*
*14—15 яшьләрендә*
*Кышкар мәдрәсәсенә китеп,*
*...карт атасы*
*исән вакытта ук*
*авылымыз Кушлавычка кайтып,*
*мулла булмыштыр.*
*Мулла булгач та*
*өйләндеке*
*бер җәмәгате илә*
*берничә генә еллар торгач,*
*җәмәгате вафат булып,*
*бер ир вә бер кыз*
*баласы калмыштыр.*
*Моннан соңра атам,*
*икенче мәртәбә*
*өйләнүе уларак,*
*Өчиле карьясе*
*Зиннәтулла хәзрәтнең*
*Мәмдүдә исемле кызыны*
*(минем анамны) алмыштыр.*
*Анам илә*
*бер ел ярым кадәр торгач,*
*беренче бала уларак,*
*мин дөньяга килгәнмен.*

Габдулла Тукай.

«Исемдә калганнар».


Халкыбызда борын-борыннан җиде бабага кадәр үз нәселең буыннарын күңелдән белү һәм нәсел шәҗәрәләрен кәгазьгә теркәү гадәте булган. Гарәп теленнән кергән «шәҗәрә» сүзе агач дигән мәгънәне белдерә. Буыннарның өзлексез алмашып торуын ботаклы агачка охшатып төзелгән шәҗәрәләр язу — элегрәк заманнарда күп халыклар өчен хас булган күренеш. Гарәпләрдә хәтта нәсел шәҗәрәләре төзү белән шөгыльләнүче махсус кешеләр булган.

Тарихи чыганак буларак татар шәҗәрәләренең әһәмияте бик зур. Теге яки бу төбәкнең тарихын өйрәнгәндә, татарча кеше исемнәренең үзенчәлекләрен тикшергәндә алар төп чыганакларның берсе буларак каралалар. Күренекле шәхесләрнең тормышын һәм иҗатын өйрәнгәндә дә шәҗәрәләрнең кыйммәте зур. Бу уңайдан бүгенгәчә төзелеп килгән Пушкин шәҗәрәсен искә төшереп үтик.

Кызганычка каршы, бу мөһим эшкә бездә соңгы елларга кадәр җитәрлек игътибар ителмәде дияргә була. Ниһаять, бу өлкәдә дә җанлану сизелә башлады. Укытучы Зәкия ханым Рәсүлева күп еллар дәвамында Г. Тукайның тормыш юлын өйрәнү, туганнарын барлау белән шөгыльләнде. Шушы эзләнүләр нәтиҗәсе буларак ул бөек шагыйрьнең 200 дән артык туганнарын эченә алган шәҗәрәсен төзеде. Әлбәттә, моны Тукайның тулы шәҗәрәсе дип әйтә алмыйбыз әле. Чөнки бу шәҗәрәнең беренче буыннарында гына түгел, Тукайдан соңгы дәверне эченә алган өлешендә дә ачыклыйсы, тулыландырасы урыннар бар. Теге яки бу шәхеснең туган һәм үлгән елларын, тулы исемен һ. б. ачыклау әнә шундый бурычларның берсе. Түбәндә китерелә торган шәҗәрә киләчәктә шагыйрьнең документаль чыганакларга нигезләнгән тәфсилле шәҗәрәсен төзүдә нигез булып хезмәт итәр диясе килә.


*(110—111 битләрне карагыз).*

# ТУКАЙ ШӘҖӘРӘСЕ




*Р. Якупов тарафыннан өстәлгән мәгълүмат

*Тукайның әнисе ягыннан нәселе*




I *Тукай абзый-туталарының оныкларының оныклары (Тукай племянникларының оныклары)*

II *Тукай абзый-туталарының оныкларының балалары (Тукай племянникларының балалары)*

III *Тукай абзый-туталарының оныклары (Тукай племянниклары)*

IV *Тукай абзый-туталарының балалары (туганнан туганнары)*

V *Тукайның абзыйлары, туталары*

*Тукайның әтисе ягыннан нәселе*



**М. В. Гыйлаҗев,**
КПССның Тукай район комитеты
беренче секретаре

# КАМАЗ КУЕНЫНДА

Безнең район, үзенең бүгенге тормышына ирешкәнче, шактый катлаулы юл үзган. Хәзер без яши торган җирләр элек Минзәлә өязенә кергәннәр һәм патша Россиясенең кызганыч хәлдәге аграр бер төбәгеннән саналганнар.

Басу-кырларны, башлыча, сука, сабан белән эшкәрткәннәр. Җир мәйданы төрле кешегә төрлечә эләккән. Берәүләрнең байлыгы егерме дисәтинәгә җиткән, кайберәүләр исә бөтенләй өлешсез калган. Андыйлар бай хуҗалыкларга батраклыкка яллангannар. Өяз халкы тормышына политик хокуксызлык, ярлылык, культура ягыннан ифрат артталык хас булган. Ул чорда Чаллыда (бүгенге Брежнев шәһәре) бөтен тирә-юнь өчен бер чиркәү мәктәбе һәм тагын бер башлангыч мәктәп эшләгән. Бердәнбер больница өяздәге авыруларга кирәкле ярдәмне күрсәтергә һичничек өлгерә алмаган. Шунлыктан бу якларда үлем-җитемгә чара таба алмый интегәләр. Чиркәүдәге теркәү кенәгәләренә караганда, 1915—1916 елларда, мәсәлән, кешеләрнең гомер озынлыгы уртача нибары егерме бер ел чамасы булган.

Аңлашыла ки, шушындый авыр тормышта газапланган халык Бөек Октябрьне хуплап каршы ала. 1917 елның декабрендә үк крестьяннар, эшчеләр, ярлылар, башка яклардан күчеп килгән ачлар катнашында уздырылган гомуми җыелыш Чаллыда Совет власте игълан итә, аның башкарма комитетын сайлый.

Аннары гражданнар сугышының утлы еллары башлана. Бу дәвернең дәһшәте Чаллы ягын иңләп-буйлап айкый: фетнәчеләр гаугасы, ак чехлар, колчакчылар еркычлыгы — берсе дә калмый. Аларны бастыруда Чапаевның данлы 25 нче дивизиясе дә катнаша.

1920 елда Татарстан республикасы төзелгәч, элекке Минзәлә, кантон төсендә, Татарстанга кертелә. 1921 елның 20 июнендә, ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты карары нигезендә, Минзәлә кантоныннан Чаллы кантоны аерылып чыга. 1930 елда кантоннар районнар итеп үзгәртеләләр.

Крестьяннар, әле колхоз-совхозларга берләшкәнче үк, җирне бергәләп эшкәртү ширкәтләре, коммуналар, авыл хуҗалыгы артельләре оештыралар. Сука-сабаннар акрынлап көчле трактор-комбайннарга алмашына бара. Коллективлашу чорында да, Бөек Ватан сугышы елларында да безнең халык сынатмады. Ниһаять, район зур шәһәр янында, индустриаль нигезгә корылган авыл хуҗалыгы зонасына әйләнде.

1970 ел безнең район тарихына «КамАЗ» маркалы зур йөк автомобильләре заводының һәм машина ясаучылар шәһәренең салына башлавы белән кереп калды. Бөтенсоюз күләмендәге бу удар төзелеш Чаллы шәһәренең дә, районның да язмышын кисәктән тагын да яктыртыбрак җибәрде.

КамАЗ салына башлаган вакытта районның барлык колхоз-совхозлары күп тармаклы хуҗалыклар иде. Алар барысы да аз-азлап кына сөт-май, йомырка, йон, бәрәңге, ит, яшелчә җитештерәләр. Тик алардан кергән азык-төлек халкы кинәт артып киткән яңа шәһәрне тәэмин итүдән бик ерак тора иде. Шәһәр ихтыяҗының нибары 1,3 проценты гына канәгатьләндерелә иде. Шуңа күрә райондагы авыл хуҗалыгы эшчәнлеген тамырдан үзгәртергә, специальләшкән эре хуҗалыклар булдырырга кирәк дип табылды. Моның өчен мәсьәләне җентекләп, фән кушканча өйрәнергә, хезмәтне заман таләбенчә индустриаль нигезгә корырга туры килде.

1976 елда Чаллы районының исеме Тукай районы итеп үзгәртелде һәм, КПСС Үзәк Комитетының махсус карары нигезендә, Тукай районы партиянең Чаллы шәһәр оешмасы составына кертелде. Бу үзгәреш шәһәр яны авыл хуҗалыгы тирәлеген булдыруда әһәмиятле роль уйнады.

КамАЗ төзелеше һәм шәһәр яны тирәлеген үзгәртеп кору бер омтылыш белән башкарылды. Төзелеш коллективлары, шәһәрнең промышленность предприятиеләре авыллар ихтыяҗын вакытында канәгатьләндерү өчен кулларыннан килгәннең барын да эшләделәр. Аларның зур ярдәме нәтиҗәсендә авылларның йөзе яктырып китте, колхоз-совхозларның материаль-техник базасы ныгыды.

1970—1983 елларда районның авыл хуҗалыгын үстерүгә 320 миллион сумлык байлык тотылды. Шуның бәрабәренә районда уннан артык сыер асрау комплексы, дуңгызчылык өчен зур комплекс, елына 102 миллион данә йомырка һәм 14 мең тонна кош ите бирердәй фабрикалар булдырылды. Ел әйләнә яшелчә үстерергә мөмкинлек тудырган ябык бакчаларның мәйданы 30 гектарга җитте. Комбиазык заводы һәм тегермәне булган ипи-күмәч комбинаты кебек заманча предприятиеләр барысы да авылларыбызның тормыш-көнкүрешен яхшы якка үзгәртте.

КамАЗны сафка бастыру елларында авыл җирендә дә 140 мең квадрат метр торак, 13 мәктәп, 11 ясле-бакча һәм күп санлы башка учреждениеләргә яңа биналар салынды. Юллар суздык. Хәзергесе көндә безнең районның теләсә кайсы авылыннан район үзәгенә көзгедәй такыр асфальт-бетон юлдан килергә була. Азык-төлек төягән машиналар безнең районның теләсә кайсы фермасыннан яки басуыннан елның яки тәүлекнең һәр сәгатендә юлга чыга ала. Юлсызлык бәласеннән тәмам котылдык без. Бу яңалык колхоз-совхозлар җитештергән байлыкны югалтуларсыз тиешле урынга илтеп тапшырырга да, авыл халкының шәһәргә бәйле йомышларын җәфаланмыйча гына хәл итәргә дә мөмкинлек тудырды. Гомумән, яхшы юлларның рәхәтлеген сөйләп-аңлатып бетерерлек түгел.

Шаулы төзелеш елларында авыллардагы кешеләрнең тормышы күзгә күренеп яхшырды. Соңгы ун ел эчендә хезмәт хаклары 48—80 процентка кадәр артты. Кибетләрдәге товар әйләнеше өч мәртәбә үсте, колхозчыларга хезмәт күрсәтү елга 40 сум чамасына җитте (Брежнев шәһәрендә — 29 сум). һәм шушы уңай үзгәрешләр эшче көчләрне авылларда саклап калырга ярдәм итте. Якындагы данлы төзелеш безнең авыллардагы кешеләр санын хәтта арттырды да әле.

Яңача үсеш юлы хуҗалыкларыбыздагы басуларның нәтиҗәлелеген күтәрүгә дә китерде. Төзелеш мәйданнары хисабына шактый гектарларын югалткан безнең район өчен бу адым бик мөһим иде. Чәчү кырларыннан фән кушканча файдалану исә безгә бик тиз арада икмәк һәм терлекчелек байлыкларын сизелерлек арттырырга ярдәм итте. Мәйданы 20 процентка кимегән басуларыбыздан элеккегә караганда 17 процентка күбрәк ашлык җыеп ала башладык.

Безне иң шатландырганы — авыл хуҗалыгына эшнең нечкәлеген тирәннән аңлаучы укымышлы кадрлар килүе. Хуҗаларында белем, омтылыш, тырышлык булмаса, әйтик, «Гигант» совхозы кырларыннан гектарга уртача 40—45 әр центнер уңыш җыя алыр идекмени?! Шәһәр халкын яшелчә белән тәэмин итүдә бу кадәр алга китү мөмкин булыр идеме?!

Яшелчә һәм бәрәңгедән, тамыразыклардан тотрыклы уңыш алуда басуларны сугару мөһим роль уйный. Безнең якларда явым-төшем аз була. Бигрәк тә үсемлекләрнең ныгу, көч җыю чорында дым җитмәү уңышны сизелерлек киметә. Шуңа күрә соңгы елларда без басуларны сугаруга зур әһәмият бирәбез. «Татсельхозводстрой» тресты, районның «Сугару» берләшмәсе, мелиорация өчен тимер-бетон әйберләр ясау заводы коллективлары бу юнәлештә аеруча тырышалар.

Хәзер районда меңнәрчә гектар җир сугарыла. Моңа яшелчә үстерү мәйданы тулысы белән керә. Сугарулы җирләр ел саен арта бара. 1990 елга ясалма яңгыр яудыру җайланмаларының санын ике тапкыр арттырырга исәп тотабыз.

Сугару терлек азыгы үстерүгә бигрәк тә ярдәм итә. Соңгы вакытта без андый басуларның һәр гектарыннан 60 ар центнер азык берәмлеге алдык. Бу уңышлар терлекчелектәге хәлләрне яхшыртырга мөмкинлек бирде.

Савым сыерлары өчен унбер әйбәт комплекс салып куйдык. Алардагы хезмәтнең көйле булуы райондагы сыерларны 2,5 мәртәбә арттырырга, һәр сыердан уртача өч мең бер йөз литр сөт саварга уңайлы шартлар тудырды.

1984 елда Тукай районына күршедәге Минзәлә һәм Сарман районнарыннан берничә хуҗалык кушылды. Шуннан соң безнең басуларның мәйданы 130 мең гектар чамасы булды. Мөгезле эре терлекләребезнең баш саны 46 меңгә якынлашты. Бу хәл, билгеле, эшне дә катлауландырды. Яңадан кушылган колхозларда, заман таләбе буенча, хезмәтне яңача көйләргә, басу әйләнешен тәртипкә салырга, авылларның төзеклеген күздән кичерергә, яхшы юллар булдырырга кирәк иде. Уйлавыбызча, без районның авыл хуҗалыгын төбәгебезнең горурлыгы булган КамАЗ дәрәҗәсенә тиң биеклеккә күтәрергә тиешбез. Бу якты максатка ирешүдә ныклы таянычларыбыз — искиткеч уңган кешеләребез бар.

«Гигант» совхозы директоры Нәҗип Зыятдинов Татарстан авыл хуҗалыгы эшчәннәре өчен үрнәк булырлык. Ул унҗиде яшендә сугышка киткән. Мәскәү янында, Белоруссиядә, Балтик буенда каты бәрелешләрдә катнашкан. Каты яраланган.

Аның авыл хуҗалыгындагы хезмәт юлы бригадирлыктан башлана. 1950 елда ук инде аны колхоз председателе итеп сайлыйлар. Нәҗип Зыятдинов хуҗалыкны җайга салып җибәрә. Колхоз ныклы җирлеккә баса. Гомер буе шунда, тыныч кына яшәп ятса да аңа начар булмас иде. Тик коммунист җаны тынычлана аламы соң? КамАЗ салына башлагач, яңа кала кешеләрен азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсе тугач, тәҗрибәле председательгә тагын да җаваплырак эш йөкләнә. Ул «Гигант» совхозының директоры итеп билгеләнә. Хәзер «Гигант» — республиканың иң көчле хуҗалыкларының берсе. Совхоз бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 40—45 әр центнер тотрыклы уңыш җыя. Сугарулы басулар гектарына 70—80 центнер азык бирәмлеге бирә.

Совхоз эшчеләре менә дигән йортларда яшиләр. Поселокта культура йорты, урта мәктәп, спорт залы, балалар бакчасы, сәүдә үзәге бар.

Җәлил исемендәге һәм «Коммунизм» колхозлары эшчәнлегендә дә бик күп уңай мисаллар табарга мөмкин. «Коммунизм» хуҗалыгында яшьләрне колхозга кабул итүне мәңге истә калырлык иттереп оештыралар. Яшь колхозчыларга хезмәт кенәгәсе тапшыру көнендә авыл зур тантана кичерә. Өлкән колхозчылар егет-кызларга матур теләкләр телиләр. Колхозда эшкә калган яшь механизаторларга өр-яңа техника бирелә. Өйләнешүчеләр җайлы торак белән тәэмин ителәләр. Шул чаралар аркасындадыр, мөгаен, соңгы вакытта туган авылларында эшкә калучылар саны арта бара.

Уңай эш алымнарын башкаларга үрнәк итеп күрсәтердәй җитәкчеләрдән РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы работнигы, «Весенний» совхозы директоры Р. М. Низаметдиновны; ТАССРның атказанган зоотехнигы Чаллы кошчылык фабрикасы директоры М. З. Хөснуллинны; «Ворошиловский» совхозы директоры Г. С. Зариповны; «Набережночелнинский» совхозы директоры Р. Я. Ямалеевны; тимер-бетоннан мелиорация әйберләре ясау заводы директоры А. А. Хильченконы; элеватор директоры Г. Н. Закировны; ТАССРның атказанган экономисты «Татарстан» совхозы директоры Х. А. Әхмәтгалиевны; ТАССРның атказанган ветеринария врачы, «Сосновоборский» совхозы директоры А. Х. Алиевны һәм башка күпсанлы уңганнарыбызны санарга мөмкин. Бу хуҗалыкларда партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары җитәкчеләре дә кешеләр белән эшләүнең иң кулай ысулларын беләләр. Алар җитәкчелегендә авылларда дистәләгән белгечләр, үз һөнәрләренең чын осталары үсеп чыкты: Социалистик Хезмәт Геройлары Нәҗип Зыятдинов һәм терлекче Минсәгыйрә Таҗиева; ТАССРның атказанган механизаторы, Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет билгесе» орденнары кавалеры И. В. Ульянов; Ленин ордены һәм Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән Т. А. Мостафина; РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы работнигы С. Г. Фәртдинова һәм башкалар.

Безнең яклар авыр елларда туган илне яклаучы күпсанлы каһарманнар биргән. Алардан Н. Ш. Шәрипов һәм Н. Я. Якупов Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә лаек булдылар.

Тукай районы — моңлы җырчыларга, талантлы шәхесләргә бай төбәк. РСФСРның халык артисты Илһам Шакиров, ТАССРның халык артисткасы Зөһрә Сәхәбиева, М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры солисткасы Галина Казанцева, җырчы Рәисә Тимофеева безнең районда туып үскәннәр. Шагыйрьләр Рәшит Гәрәй, Николай Алешковның туган авыллары да — Тукай районында.

Соңгы елларда районыбыз үзәге Брежнев шәһәрендә Татарстан Язучылар союзының яңа бүлекчәсе эшли башлады. Бу эш нәтиҗәсендә безнең якка тагын язучылар килеп урнашты: Кадыйр Сибгатуллин, Равил Вәлиев, Газиз Мәхмүтов, Нәҗип Мадьяров, Газиз Кашапов һәм дистәләгән яшь язучылар. Алар безнең авылларда еш булалар, әдәби кичәләр, китап укучылар конференцияләре үткәрәләр. Бу әдәби көч безгә колхоз-совхозларда культура-тәрбия эшләре алып баруда нык ярдәм итә.

Район авылларындагы дистәләрчә культура йортлары һәм клублар, мәктәпләр, китапханәләр — барысы да шул ук изге максатка омтылалар, кешеләребезнең тормыш-көнкүреше, эше-ялы матур булсын өчен тырышалар. «Беренче буразна», «Беренче чүмәлә», «Сау бул, кыш!» кебек бәйрәмнәр, сабан туйлары халыкның иң яраткан бәйрәмнәре тәсендә уздырылалар. Бу чараларны үткәрүдә районыбызның үзешчән сәнгать көчләре нык тырыша. Халыкка культура хезмәте күрсәтүдә «Кама», «Набережночелнинский» һәм «Мәгариф» хуҗалыклары үзешчәннәренең уңышларын аерып билгеләргә кирәк. Бу эшләргә тәҗрибәле киңәшче кирәклеге ачык.

Хәзер бездә никахлашу, яңа өйгә күчү, бала туу, паспорт алу, Совет Армиясенә озату кебек шатлыклы вакыйгалар авыл халкының гомуми бәйрәме төсендә үткәрелә.

Районыбыз халкы менә шулай тырышып хезмәт итә, мул тормышта күңелле итеп яши.

# Гомәр Таһир
(Хельсинки)

# Илбарис Надиров
(Казан)

# БӘРӘКӘТЛЕ ХӘРӘКӘТ

*Мәгълүм булганча, Финляндия республикасының башкаласы Хельсинкида 1967 елның апрель аенда Габдулла Тукай исемендәге җәмгыять оештырыла. Бу хакта үз вакытында Татарстан матбугатында кыска гына хәбәрләр булгалаган иде. Г. Тукайның йөз еллыгы уңае белән «Казан утлары» журналы үзенең битләрендә шагыйрь исемен йөртүче шул җәмгыять турында киңрәк мәгълүмат бирүне кирәк тапты. Шуны күздә тотып без Хельсинки университетының төрки телләр укытучысы һәм бер үк вакытта Г. Тукай җәмгыяте җитәкчесе, филология фәннәре докторы Гомәр Таһир белән булган әңгәмәне урнаштырабыз. Әңгәмәне Тукай җәмгыятенең эше белән якыннан таныш булган Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында халык иҗаты секторы мөдире, филология фәннәре кандидаты Илбарис Надиров алып бара.*

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Гомәр әфәнде. Сез иң әүвәл Г. Тукай җәмгыятенең оештырылуына нигез булган тарихи һәм мәдәни сәбәпләргә тукталып үтсәгез иде.

ГОМӘР ТАҺИР. Бу җәмгыятьнең оешуына этәргеч булган ике төп сәбәпне аерып күрсәтим. Аларның берсе һәм иң мөһиме Финляндия мәмләкәте белән Советлар иле арасында 1948 елдан башлап рәсми юлга салынган һәм бүгенгәчә нәтиҗәле дәвам итүче үзара дуслык һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләренә мөмкин булганча файдалы бер өлеш кертүдән гыйбарәт. Моның таррак мәгънәсен Финляндия җирендә гомер итүче татарлар белән Татарстан һәм аның башкаласы Казан арасындагы бәйләнешләрне тагы да якынайту, ныгыту дип аңларга кирәк. Тукай җәмгыятенең моннан унсигез ел элек кабул ителгән рәсми уставында бу хакта ап-ачык әйтелә. Әлегә хәтле үзенең бөтен эшләрен җәмгыять әнә шул олы максатка юнәлтеп алып барырга омтылды.

Җәмгыять оештырылуына нигез сәбәпләрнең тагын берсен Финляндия татарлары арасында бөек Тукай, бай тарихлы татар әдәбияты һәм сәнгате, киңрәк алганда татар халкының рухи культурасы турында күбрәк, төрлерәк мәгълүмат тарату максаты тәшкил итә. Искә алган уставта бу хакта да әйтелгән.

Сүз уңаенда шуны да әйтим, җәмгыятьнең тулы исеме «Габдулла Тукай культура җәмгыяте». Аның уставында, печатендә татар һәм фин телләрендә шул сүзләр язылган.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Җәмгыятьнең җитәкчелеге һәм әгъзалары турында да берничә сүз әйтеп китсәгез әйбәт булыр.

ГОМӘР ТАҺИР. Баштагы тугыз ел дәвамында җәмгыять белән атаклы фин тюркологы, профессор Марти Рясанен җитәкчелек итте. Ул татарча оста гына сөйләшүче, татар тарихы һәм әдәбиятыннан хәбәрдар кеше иде. Үз гомерендә Казанда берничә кат булганы бар. Соңгы тапкыр ул монда 1957 елда килеп, мәшһүр Казан университетында төрки телләрнең чагыштырмача этимологиясе турында лекцияләр укый. Профессор Рясаненны мин үземнең мөхтәрәм остазым дип саныйм. Ул 1976 елда 83 яшендә вафат булды.

М. Рясанен Хельсинки университетында эшли иде. Гомумән бу университетның күп кенә галимнәре — тарихчылар һәм филологлар, гәрчә Тукай җәмгыяте әгъзалары булмасалар да, җәмгыять эшендә турыдан-туры катнашып, аңа файдалы ярдәм күрсәтеп

килделәр. Моңа, әлбәттә, минем озак еллар буе шул университетта эшләвем дә сәбәп булгандыр.

Профессор М. Рясанен вафатыннан соң җәмгыять белән җитәкчелек итү вазифалары миңа йөкләнде.

Саны ягыннан җәмгыять зур түгел, анда 24 кеше әгъза булып тора. Аларның өчесе өлкәннәр, ә калганнары яшьләр.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Җәмгыятьнең эшләгән эшләре турында сүз башлаганчы, Финляндиядә яшәүче татарлар тарихына карата тулырак мәгълүмат аласы килә. Минем белүемчә, Сезнең шәхси китапханәгездә бу мәсьәлә буенча бай гына фактик материал тупланган. Анда төп урынны төрле урында татар, фин, швед, инглиз, немец, төрек телләрендә язылган газета, журнал мәкаләләре, кыска-кыска белешмәләр алып тора иде. Соңгы елларда бу темага караган аерым хезмәт дөнья күрмәдеме?

ГОМӘР ТАҺИР. Финляндия татарларының тарихы турында якын елларда махсус тикшеренү язылыр дип өметләнәбез. Моның өчен нигез булырдай чыганаклар, дөрестән дә, байтак җыелды. Бүген исә белешмә төсендә генә булса да, мин кайбер мәгълүматлар белән уртаклаша алам.

Финляндия татарларының гасыр ярымлык тарихы бар дияргә була. Финляндия әле рус патшалыгының бер өлкәсе булып саналган чагында ук рус армиясендә хезмәт итүче гаскәри татарларның кайберләре финнар җирендә төпләнеп калулары мәгълүм. Моның документлары бар. Узган гасыр ахырына таба исә бу якларга Петербургтан, Мәскәүдән галантерея маллары белән сату итүче вак сәүдәгәрләр, кырык тартмачылар килеп йөри башлый. Чикләр ачык булу сәбәпле, монда килеп-китеп йөрү кыен булмаган. Ул вак сәүдәгәрләр чыгышлары белән нигездә әүвәлге Нижний Новгород губернасының Сергач өязенә кергән дүрт-биш татар-мишәр авылыннан булып, арадан кыюраклары финнар җирендә калу язмышын сайлаган. Тора-бара алар монда үз гаиләләрен, туганнарын һәм ярудашларын да китергәннәр. Чөнки бу якларда җир иркен, тормыш итү әллә ни кысан булмаган. Фин халкы да аралашу һәм күршелек өчен ачык күңелле халык булып чыккан. Нәтиҗәдә Сергач төбәгендәге авылларның бер төркем кәсепче игенчеләре берәм-берәм Финляндиягә күченеп, шул илдә җирләшә, утраклаша башлый. Бу күченү 1923 елларга кадәр дәвам итә. Минем әтием Зариф та шул юлларны үткән. Ул Финляндиягә гасыр ахырында килә. Туган авылы Куйсуга (русчасы Овечий овраг) еш кайтып йөри һәм ил өчен авыр 1921 елда мине, ике туганымны бөтенләйгә бирегә китерә. Ул чакта мин әле унбер яшьтә генә булганмын.

Хәзерге вакытта Финляндиядә бер меңнән артык татар бар дип исәпләнә. Алар нигездә биш шәһәрдә яшиләр. Хельсинкида һәм аның тирәсендә торучылар саны биш йөз чамасы, калганнары Тампере, Турку, Котка, Ярвинпээ шәһәрләренә таралышкан. Ыру, нәсел-нәсәп һәм якташлык җепләре белән якыннан бәйләнешкәнгә күрә, Финляндия татарлары төрле шәһәрләрдә торсалар да, аерым бер колония тәшкил итәләр. Аларның кәсеп-шөгыльләре турында да бер-ике сүз әйтеп китим. Андагы татарларның күпчелеге сәүдә аланында эшли. Соңгы елларда экономист, инженер, юрист, врач булып эшләүче яшьләр арта төште.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Финляндия татарларына багышлап язылган мәкаләләрдә аларның рухи ихтыяҗларын күз алдында тотып корылган аерым җәмгыятьләр турында да сүз бара.

ГОМӘР ТАҺИР. Иң зур җәмгыять — 1925 елда оештырылган «Исламия җәмгыяте». Исеменнән аңлашылганча, ул дин эшләре белән идарә итә. Алтмышынчы еллар башына хәтле бу җәмгыять «Мәхәллә хәбәрләре» дигән еллык җыентык чыгарып барды, балалар өчен берничә дәреслек бастырды. Чөнки 1948—1969 елларда Хельсинкида башлангыч татар мәктәбе эшләп килде. Ә соңыннан укучы балалар җитмәү сәбәпле, ул мәктәп ябылды. Сүз уңаенда әйтеп китим, ул мәктәпне коручыларның берсе мин идем. Баштагы ун ел дәвамында аның директоры вазифаларын да үтәдем. Хәзер өч яшьтән алып алты яшькә хәтле балалар өчен бакча эшләп килә. Анда уннан артык бала йөри.

Моннан кала Хельсинкида «Финляндия төрекләре берлеге» дигән бер җәмгыять бар. Ул, кагыйдә буларак, мәхәллә йортында милли кичәләр үткәрә, һәвәскәр концертлар оештыра. Яшьләр көче белән ел саен татар драматургиясе классиклары Г. Камал, М. Фәйзи һ. б. аерым пьесалары сәхнәгә куела. Берлек җәмгыяте 1975, 1979 елларда ике музыкаль такта (грампластинка) чыгарды. Анда Хельсинки яшьләренең вокаль-инструменталь ансамбле башкаруында татар җырлары һәм көйләре язылган. 1980 елда берлек «Безнең җырлар» дигән калын гына китап нәшер итте. Җыр китаплары әүвәл дә чыгып килә иде.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Мин ул грампластинкалар, җыр китаплары белән яхшы таныш. Монда игътибарны бер нәрсә җәлеп итә. Соңгы унбиш-егерме елда Финляндия татарлары арасында Татарстан белән кызыксыну, «Казан утлары», «Азат хатын» журналларын алдыру, татар грампластинкаларын сорату күзгә күренеп көчәйгән икән, моны барыннан да элек Тукай җәмгыяте башкарган эшләрнең бәрәкәтле тәэсире белән аңлатырга кирәктер. Чөнки нәкъ менә Тукай җәмгыяте Татарстаннан даими рәвештә артистлар һәм галимнәр чакырып Хельсинкида, башка шәһәрләрдә концертлар, лекцияләр оештыра башлагач, культура өлкәсендә аралашу даирәсе шактый киңәеп, җанланып китте. Сез искә алган грампластинкалар яисә җыр җыентыкларын шуны раслаучы аерым мисаллар дип карарга кирәктер. Аларда Татарстан артистларының соңгы елларда яңгыраган популяр җырлары һәм Казанда чыккан җыр китапларыннан сайланган текстлар үзәк урынны алып тора. Әйтелгәннәрдән тагын бер нәтиҗә ясарга мөмкин кебек. Финляндия татарлары арасында әдәбият, сәнгать, милли тел һәм тарих өлкәләре буенча Казанны үзләренә рухи кыйбла итеп сайлаучылар саны елдан-ел арта бара.

ГОМӘР ТАҺИР. Әйе, болар хаклы әйтелгән, хакыйкатькә туры килә торган фикерләр. Алар белән килешми мөмкин түгел.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Финляндия татарлары тормышында культура факты булып саналырга лаек тагын бер мәсьәләгә тукталасы килә. Безгә билгеле булганча, алар арасында әдәби иҗат белән шөгыльләнеп, китаплар бастыручы аерым авторлар бар.

ГОМӘР ТАҺИР. Дөрестән дә, бездә әдәби иҗат белән шөгыльләнүче өч-дүрт кеше бар. Алар берсе дә профессиональ язучылар түгел, ә һәвәскәрләр. Яшьләре ягыннан да шактый өлкәннәр.

Хәсән ага Хәмидуллага быел 88 яшь тула. Арада ул иң күп язучы. Аның шигырьләре, пьесалары, автобиографик романы бар. Әсәрләрен үзенең бастыру машинасында күбәйтә. Әле күптән түгел генә аны Финляндия язучыларының исемлегенә кертteләр. Үзе гомер буе сәүдә эшендә булды.

Гәүһәр ханым Туганай 1970 елда үзенең ике китаптан торган шигырьләрен бастырды. Аның кайбер шигырьләре үз вакытында «Азат хатын» журналында да дөнья күргән иде (1969, 3 сан).

Садри Хәмит тел, тарих мәсьәләләренә багышланган кечкенә мәкаләләр, бездәге татарлар тормышында булган төрле хәлләр турында парчалар яза. Шигырьләре дә бар. Язган әйберләрен үзенең рәсемнәре белән бизәп, үзе бастырып тарта. Ул — Тукай җәмгыятенең эшчән әгъзаларыннан берсе.

Бу өч авторга өстәп Тамперәдә яшәгән һәм инде вафат булган Гайсә Хәкимҗанны күрсәтергә кирәк. Үзенең шигырьләрен туплап ул өч җыентык чыгарды. 1969 елда Тамперәдә басылган «Татар шагыйре Габдулла Тукай» исемле рәсемле җыентыкны төзүчеләрнең берсе иде. Тукай җәмгыяте әгъзасы сыйфатында 1970 елда безнең белән бергәләп Казанда булды.

Искә алган язучылар үз китапларын шактый аз данәдә бастыралар, чөнки аларны таратасы, укучысын табасы бар бит. Ул китаплар язучының гаиләсе, туган-тумачалары даирәсендә күбрәк билгеле дисәм, хата булмас.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Хельсинкига баргач мине һәм юлдашларымны Сез ул язучылар белән таныштырган идегез. Кайбер китапларны укып чыгарга да мөмкинлек булды. Аларда иске авыл тормышын, ерактагы туган җирне сагыну мотивлары өстенлек итә. Фольклор катламы шактый. Этнографизм көчле. Танып белү ягыннан анда әдәбият тарихы өчен кызыклы гына образлар, сюжетлар бар. Шул ук вакытта югары эстетик таләпләр күзлегеннән карасаң, аларда шактый кимчелекләр дә табарга мөмкин. Әмма ул әсәрләрне җентекләбрәк тикшереп дәлилле сүз әйтүне киләчәккә калдырыйк.

Шушы уңайдан, Гомәр әфәнде, Сез андагы татар алфавиты турында да берничә сүз әйтсәгез иде.

ГОМӘР ТАҺИР. Алтмышынчы елларга кадәр гарәп алфавиты өстенлек итә иде. Ул хәзер дә рәсми алфавит булып санала. Соңгы елларда, бигрәк тә яшь буын арасында, латин хәрефләре белән язу гамәлгә кереп бара. Тик ул алфавит әлеге хәлендә шактый чуар һәм урыны белән хәзерге татар әдәби теленең орфография кагыйдәләренә җавап бирми. Аны мөкәммәләштерәсе бар. Алда әйтеп үткәнчә, соңгы унбиш-егерме елда Казанда чыккан журнал, китапларны укучылар күбәя бара. Димәк, Сездәге алфавит белән таныш кешеләр саны да үсә дигән сүз.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Сүзне Тукай җәмгыятенең эшчәнлегенә күчерик. Унсигез ел дәвамында җәмгыять телгә алып сөйләрдәй, истә калырдай нинди эшләр башкарды?

ГОМӘР ТАҺИР. Максатларына турылык саклап, җәмгыять үзенең эшен берничә тармакта алып барды. Иң мәшәкатьле, әмма иң игелекле тармак Финляндия татарлары арасында Татарстаннан килгән сәнгать осталары һәм галимнәрнең чыгышларын оештыру белән бәйле. Икенче тармак күбрәк фәнгә караган, ул Казан галимнәренең аерым лекцияләрен Хельсинки университеты укытучылары һәм студентлары аудиториясендә тыңлау һәм фикер алышудан гыйбарәт. Ниһаять, өченче тармакны Тукай җәмгыяте җитәкчесе буларак минем ялгызым гына яисә юлдашларым белән бергә Татарстанга килүләр, Казан җирендәге очрашу, аралашулар тәшкил итә.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Шул тармаклар буенча эшләнгән эшләрне ачыграк, тулырак итеп күз алдына китерәсе килә.

ГОМӘР ТАҺИР. Җәмгыять чакыруы буенча Финляндиягә килгән беренче кунаклар татар әдәбияты галимнәре булды. Алар арасында ике профессор — Мөхәммәт Гайнуллин һәм Хатип Госман, шулай ук университет доценты Резеда Ганиева бар иде. Бу төркем Хельсинкига 1967 елның августында килеп, ике җыелышта катнашты.

Беренче җыелышка өч йөзгә якын кеше килгән иде. Казан галимнәре Татарстанның яңалыкларга бай тормышы турында, бигрәк тә милли культура һәм әдәбият, мәгариф һәм фән өлкәсендә ирешелгән казанышлар турында сөйләделәр, соңыннан күп төрле сорауларга җаваплар бирделәр. Бу җыелыш Финляндия татарларының күпчелеге өчен зур яңалыклар ачкан җыелыш булды. Чөнки алар автономияле Татарстан мәмләкәте турында беренче мәртәбә дөрес хәбәр ишетеп, хакыйки мәгълүматлар алдылар.

Икенче җыелыш Хельсинки университеты галимнәре белән очрашуга багышланган иде. Анда академик Итконен, профессорлардан М. Рясанен, Йоки, Бахрус, Аро, Валлинкоски катнашты. Фин галимнәре үзләре эшләгән гуманитар кафедралар, университет каршындагы гыйльми җәмгыятьләр турында бай мәгълүмат биргәннән соң, Казан галимнәре университетның татар филологиясе бүлеге һәм Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы фәнни тикшеренүләргә күзәтү ясадылар. Җанлы әңгәмә төсендә барган бу очрашу ике ил галимнәре арасындагы фәнни элемтәләрне башлап җибәрү юлында бик әһәмиятле бер вакыйга булды.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. 1968 елның маенда җәмгыять Татарстаннан бер төркем сәнгать осталарын чакырткан иде. Сезнең архивта аларның концертлары уңае белән фин матбугатында басылган кызыклы гына материаллар саклана кебек.

ГОМӘР ТАҺИР. Татар сәнгате осталарының бу беренче килүе, дөрестән дә, Финляндия татарлары өчен аеруча истәлекле һәм тәэсирле булды. Танылган нәфис сүз остасы Айрат Арсланов җитәкчелегендәге бу төркемдә атаклы җырчылардан Илһам Шакиров һәм Венера Шәрипова, күренекле композитор Рөстәм Яхин, атказанган скрипкачы Марат Әхмәтов һәм мәгълүм баянчы Марс Макаров бар иде.

Халыкны концертка чакырып җәмгыять алдан әзерләнгән программалар таратты. Ә фин һәм швед телләрендәге дүрт газетада концерт буласы көнне афишалар, соңрак концертка карата мактау сүзләре язылган җылы рецензияләр басылды. Менә шуларның берсе. «Ууси Суоми» газетасы үзенең 28 май санында «Татарстан кунаклары» дигән исем астында түбәндәгечә язды:

«Бу көннәрдә Хельсинкидагы фестиваль арасында эчтәлеге белән безнең як өчен сирәк бер концерт игътибарны үзенә тартты. Аны карау дәрте белән рухланган публика швед сәүдә институты залын шыгрым тутырган иде. Сүз Татарстаннан килгән алты артистның музыкаль һәм шигъри байлыгы, төрлелеге белән күңелне җәлеп иткән концерты турында бара. Репертуарда татар халкының милли шагыйре Габдулла Тукай иҗатына күркәм урын бирелгән иде. Моның сәбәбе бар. Чөнки артистлар төркеме безнең илгә Хельсинкида оештырылган һәм шагыйрь исемен йөртүче җәмгыять чакыруы буенча килде. Бу җәмгыятьнең бер максаты Тукай иҗатын Финляндиядә, шулай ук башка илләрдә популярлаштырудан гыйбарәт. Зур уңыш белән үткән концерт экзотик музыкасы, сурәтле поэзиясе белән Хельсинки публикасына тирән тәэсир ясады һәм ерактагы бер илдә көр күңелле, бай традицияле рухи культура чәчәк атуын раслаучы матур мисал булды».

Бу рецензия белән янәшәдә газета Габдулла Тукайның Казан үзәгендә куелган һәйкәле рәсемен дә урнаштырды.

Чыннан да, татар артистларының бу концерты бәйрәм төсендә үтте. Тамашачылар һәр чыгышны таң калып, йотлыгып тыңладылар.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Бу урында мин шәхси архивымдагы ике хатны телгә алып узар идем. Аларны миңа Тампере шәһәреннән исеме алда искә алынган һәвәскәр шагыйрь Гайсә Хәкимҗан җибәргән иде. 1968 елның 16 июнендә язылган беренче

хатка өстәп ул «Казан артистлары» дигән шигъри тезмәсен дә салган иде. Офсетта күбәйтеп таратылганга күрә, ул тезмә Сезгә дә таныштыр дип уйлыйм. Ул шигъри хатта безнең артистларның концертларына олы бәя бирелә.

Икенче хатка теркәп (ул 1969 елның 28 августында язылган) җибәргән язма үзенең рухы белән мәкаләгә охшаган. Ул да офсетта басылган һәм Финляндиядә мәгълүмдер дип уйларга кирәк. «Шатлык» дип аталган бу мәкаләдә Финляндия татарлары арасындагы кайбер эчке каршылыклар да яктыртыла:

«Илле еллардан бирле ана йортымыздан бөтенләйгә аерылган кебек чит җирләрдә үксез балалардай яшәп килдек. Финляндиядә туып-үскән яшьләремезнең ана йортымыздан һич хәбәрләре булмаганлыктан алар Финляндиядә генә татарлар бар дип уйлыйлар иде, картларымыз башка җирдә дә татарлар чиксез күп икәнен белсәләр дә ни файда?

Моннан берничә ел элек һич итмәстән кара болытлар астыннан нурлы кояш ярып чыккан кебек ана йортымыздан Хельсинкига татарлар килә башладылар. Аларның килүләре Финляндиядәге татарларның җаннарын яңадан тергезеп җибәрде. Үзләрен татар дип әйтергә куркып йөргәннәр дә гайрәтләнеп аяк өстләренә шатланып бастылар, төрекләшкән татарларның да күзләре ачылып оятлы булган кебек булдылар.

Шулай итеп ике араларымыздагы юллар ачылып китте. Үткән елны Казан якларыннан татар артистлары һәм музыка осталары килеп җырлар җырлап, шигырьләр әйтеп, төрле музыкалар белән фин татарларының кәефләрен ачып, каралган йөрәкләрен нурландырып китделәр. Бик күп рәхмәт аларга!»

Гомәр әфәнде, безгә билгеле булганча, Финляндиянең ул вакыттагы президенты Урхо Кекконен Татарстан артистларын кабул иткән иде.

ГОМӘР ТАҺИР. Әйе, бу вакыйга 1968 елның 29 маенда булды. Президент Урхо Кекконен Татарстан артистлары белән сәгатькә якын дустанә әңгәмә алып барды. Бу очрашуның Тукай җәмгыяте тарихында күренекле һәм истәлекле бер вакыйга булуын билгеләп үтәсе килә.

Әңгәмә барышында президент У. Кекконен Татарстанның экономикасы, культурасы, фәне турында сорашты. Ахырдан ул Финляндия белән Татарстан арасында урнашкан элемтәләрне ныгыту, үстерү юнәлешендә һәр ике тарафка да уңышлар теләде. Фин матбугатында бу очрашу турында берничә хәбәр булуын да әйтәсе килә.

Саубуллашыр алдыннан У. Кекконен Татарстан артистлары белән рәсемгә төште. Бу рәсем ике көннән соң башкаланың швед телендә чыгучы газетасы «Нуфундстадсбладет»та басылып та чыкты.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Ул истәлекле рәсем үз вакытында Татарстан матбугатында да ике мәртәбә — «Азат хатын» журналында һәм Р. Фәхретдиновның «Җырчы» дигән китабында дөнья күргән иде.

ГОМӘР ТАҺИР. Тукай җәмгыяте Татарстан артистларын тагын ике җыелышына чакырды. Аларның берсе 1977 елның октябрь башында җәмгыять оештырылуга ун ел тулу уңае белән үткәрелде. «Финляндия йорты» дип аталган атаклы йортның мәһабәт концерт залында уздырылган бу тантаналы җыелышка дүрт йөздән артык кеше килгән иде. Алар арасында Хельсинки университетының татар сәнгате белән кызыксынучы фин укытучылары һәм студентлары да булдылар.

Җыелышның рәсми өлешендә доклад ясау миңа тапшырылды. Анда сүз җәмгыятьнең үткән ун ел эчендә эшләгән эшләре, планнары, Татарстан һәм Казан белән дустанә элемтәләрнең ныгый төшүе турында барды. Моңа өстәп Казанда Тел, әдәбият һәм тарих институтында, шулай ук университетта Габдула Тукай иҗатын өйрәнүгә багышланган яңа хезмәтләр хакында да мәгълүматлар хәбәр ителде. Шагыйрь исемен йөртүче җәмгыять җыелышында бу хакта сүз кузгату табигый иде, кирәк иде.

Аннары концерт булды. Бу юлы артистлар составының яртысы яңа иде. Безгә әүвәлдән таныш Айрат Арсланов, Илһам Шакиров, Марат Әхмәтов белән бергә бу концертта танылган җырчы Римма Ибраһимова, оста пианист Марат Сираҗетдинов һәм баянчы Рокыя Ибраһимовалар катнашты.

Программада (ул басылып алдан ук халыкка таратылды) ике бүлек каралып, «Габдулла Тукай ядкаре» дип аталган баштагы бүлек тулысы белән шагыйрьгә багышланган иде. Анда Тукайның үз шигырьләре һәм татар язучыларының шагыйрьгә багышланган әсәрләре, халыкның һәм композиторларның Тукай шигырьләренә нигезләнеп иҗат иткән җырлары яңгырады.

Тамашачылар концертның бу бүлеген дә, популяр әсәрләрдән торучы икенче бүлеген дә бик яратып кабул иттеләр. Артистлар тарафыннан сокландыргыч осталык белән башкарылган милли җырлар, музыкаль әсәрләр һәм шигырьләрнең тылсымлы сихри көче залдагы халык күңелен кабат тетрәтте.

Тукай җәмгыятенең юбилеена багышланган тантаналар бу юлы Хельсинкида гына калмады, татарлар яшәгән Тампере һәм Ярвинпээ шәһәрләренә дә күчте. Бу шәһәрләрдә дә махсус җыелышлар үткәрелеп, Татарстан сәнгать осталарының концертлары тамашачыларның әчкерсез мәхәббәтен яулап алды.

Туган илләренә китәр алдыннан Казан артистлары янә бер концерт бирделәр. Ул нигездә рус телендә барды. Чөнки бу юлы тамашачылар Финляндиядәге Совет илчелеге хезмәткәрләре иде. Концертның зур уңыш белән үтүе хәтердә сакланган.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Тукай җәмгыятенең безнең артистлар катнашында узган чираттагы җыелышын үткәрү фикере 1980 елның җәендә Сез Казанга килгәч туган иде.

ГОМӘР ТАҺИР. Әйе. Татарстан мәмләкәтенең 60 еллыгына багышланган тантаналарда катнашу өчен Тел, әдәбият һәм тарих институты мине һәм гаиләмне Казанга чакырган иде. Шул бәйрәм көннәрендә Татарстанның 60 еллыгына багышлап Хельсинкида да махсус бер җыелыш үткәрү теләге туды. Без бу теләккә ирештек. Шул елның ноябрендә җәмгыятьнең тантаналы җыелышын үткәрдек. Бу җыелыш программасы да алдан бастырылып халыкка җиткерелгән иде. Җыелышка дүрт йөзгә якын кеше килде. Анда төп доклад белән Казан галиме, танылган әдәбият белгече Азат Әхмәдуллин чыкты. Ул Татарстан һәм аның культурасы, матур әдәбияты һәм гуманитар фәннәре, мәмләкәтнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында күркәм итеп, рухланып сөйләде.

Соңыннан ике бүлектән торган бай концерт булды. Аның төп эчтәлеген Татарстан турындагы җырлар, шигырьләр тәшкил иттеләр. Артистлар арасында бу юлы да яңа исемнәр бар иде. Финляндия татарларының ихтирамын казанган Айрат Арсланов, Венера Шәрипова һәм Римма Ибраһимовалардан тыш әлеге юлы безгә Татарстанның күренекле җырчысы Хәйдәр Бегичев һәм оста баянчы Рәгъде Халитов килгән иде.

Хәйдәр Бегичев җырлавын халык бигрәк тә сокланып, үз итеп тыңлады. Тумышы белән Горький өлкәсенең Сергач районыннан булуы еракта гы якташларының аңа булган мәхәббәт һәм якынлык хисләрен тагы да арттырды, күрәсең.

Концерттан соң халыкка ике документаль фильм күрсәтелде. Аларның берсе «Киң Идел буенда», икенчесе «Кар бизәкләре» дип атала иде. Бу фильмнар тамашачыларны Татарстанның бүгенге тормышындагы яңалыклар белән таныштырды.

Шул ук көннәрдә Тукай җәмгыятенең Татарстан юбилеена багышланган тагын бер җыелышы Тампере шәһәрендә үткәрелеп, Казан кунаклары анда да зур уңыш белән чыгыш ясадылар.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Җәмгыять эшчәнлегендә Мәскәүнең концертлар оештыру үзәге аша Финляндиягә барган Татарстан артистларын файдалану очрагы да булды бит. Исегездәдер, 1982 елның маенда Ринат Ибраһимов җитәкчелегендәге бер төркем татар артистларының «Финляндия — СССР» җәмгыяте планнары нигезендә Финляндиягә килүе турында Сез миңа хат язган идегез. Артистлар Сезнең илдәге 9 шәһәрдә булып, 27 концерт бирәләр. Алар нигездә рус телендә бара. Ә Хельсинкидагы концертларның берсен Сез Тукай җәмгыяте исеменнән татар телендә оештырасыз. Ул концерт «Совет культурасы һәм фәне йорты» дип аталган йорт залында була. Анда Р. Ибраһимов күбрәк татарча җырлый, ә инструменталь ансамбль милли көйләр, биючеләр милли биюләр башкара.

ГОМӘР ТАҺИР. Ул концерт халыкка ошады. Татарстан артистларының ул вакыттагы чыгышлары турында фин газеталары бик хуплау, мактау сүзләре яздылар, берничә рәсем дә басылды.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Сез алдарак Тукай җәмгыяте эшчәнлегендә фәнни бәйләнешләрнең дә игътибар үзәгендә торачагын искәртеп киткән идегез. Үткән гомер эчендә бу өлкәдә ниләр эшләнде соң?

ГОМӘР ТАҺИР. Әүвәл шуны әйтеп үтим. Казан галимнәрен Финляндиягә Тукай җәмгыяте генә чакырмады, аларның кайберләре минем тәкъдимем буенча Хельсинки университеты ректоры тарафыннан да чакырылды.

Хельсинкида төрле елларда тугыз татар галиме булды. Азат Әхмәдуллин, мәсәлән, университет галимнәре алдында да бер лекция укыды. Лекция төркология өлкәсендә

татар-фин бәйләнешләренә багышланган иде. Икенче лекциясендә галим Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни эшләре, хезмәтләре турында сөйләп, университетка институт чыгарган китапларны бүләк итте.

Профессор Альфред Халиковның Урта Идел һәм Урал буендагы фин-угор халыклары белән төрки халыкларның борынгы тарихына, профессор Диләрә Тумашеваның совет чорында татар тел гыйлеме үткән тарихи юлга, тел белгече Искәндәр Абдуллинның борынгы әрмән-кыпчак кулъязмаларына багышланган лекцияләре һәр аудиториядә дә тирән игътибар белән тыңланып, яхшы бәягә лаек булды.

Язучы һәм галим Мөхәммәт Мәһдиев Габдулла Тукайның йөз еллыгы уңае белән Татарстанда эшләнә торган эшләргә, яңа хезмәтләргә тукталды, үзенең әдәби иҗаты хакында сөйләде.

Ниһаять, Сез үзегез дә Финляндиядә өч тапкыр булдыгыз. Һәм һәр килүегездә кызыклы гына чыгышлар ясадыгыз. Алар турында үзегез үк әйтеп китсәгез әйбәтрәк булыр иде.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Мин сөйләгән лекцияләр өч темага караган иде. «Г. Тукай һәм халыкның җыр дөньясы», «Бүгенге һәм борынгы җырлар» дигән лекцияләр магнитофон ярдәмендә музыкаль мисаллар белән аралашып барды. Татар һәм фин-угор халыклары иҗатындагы типологик бәйләнешләр турындагы лекция университетта гына укылды. Соңгы сәфәремдә мин «Шүрәле» балетына һәм Тукай-Кырлайга багышланган мәгълүм фильмны да алып барган идем. Аны халыкка өч урында күрсәттек һәм һәркайда тамашачылар ул фильмны сокланып, яратып карадылар, югары бәя бирделәр.

Мин тагын шуны әйтер идем, Казан галимнәре өчен бай тарихлы Хельсинки университеты аудиторияләрендә лекция укулар, аның гуманитар фәннәр өлкәсендә эш алып баручы күренекле галимнәре белән очрашулар онытылмас, истәлекле бер вакыйга булып калды. Очрашулар вакытында фин галимнәренең татар халкына, аның тарихына һәм культурасына олы ихтирам белән караулары гел сизелеп торды. Хельсинки университетының гаять бай фәнни китапханәсе һәм архивы бар. Анда тюркология, шул исәптән татар теле, әдәбияты, тарихы буенча санаусыз күп чыганаклар тупланган. Алар белән ныклап танышасы, аларны өйрәнәсе бар әле.

ГОМӘР ТАҺИР. Мин Сезнең бу фикерләргә тулысынча кушылам. Өстәп шуны әйтергә теләр идем. Киләчәктә Хельсинки университетында татар телен киңрәк өйрәнүне оештыру теләге бар. Моның өчен Казаннан берәр белгеч-укытучы чакырту өмете күңелдә тора.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Тукай җәмгыяте эшчәнлегендә тагын бер тармак — Сезнең Казан җиренә килеп йөрүләрегез бар бит әле.

ГОМӘР ТАҺИР. Җәмгыять эшчәнлеген дәвамлы һәм тулы канлы итәр өчен Казан белән киңәшеп, элемтәдә тору кирәклеге һәрвакыт сизелде. Шуңа күрә мин Казанга еш килеп йөрдем. Үткән еллар дәвамында Татарстан башкаласында җиде тапкыр булып, җәмгыять өчен дә, үземнең фәнни эшләрем өчен дә бик күп файдалы киңәшләр алдым.

Килүемнең һәр мәртәбәсендә Казанга мине Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты чакырды. Иң беренче сәяхәтем хәтергә бигрәк тә нык уелып калган. Ул 1966 елның июнендә булды. Бөек Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган бәйрәм көннәре иде. Төрле яклардан килгән күп кунаклар белән очрашу, бай эчтәлекле фәнни конференциядә катнашу бүген дә истән чыкмый. Татар галимнәре белән беренче элемтәләр шунда башланды.

Хәзерге вакытта минем китапханәдә Тукай турында бик күп әдәбият тупланды. Аның асылын Казанда татар галимнәре язган хезмәтләр тәшкил итә. Шуларга таянып Тукайның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты турында фин телендә бер китап яза башладым.

Казанга килгән саен вакытымның күп өлешен фәнни бәйләнешләрне ныгытуга юнәлтә идем. Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми советы утырышында ике мәртәбә чыгыш ясап, Тукай җәмгыятенең эшчәнлеге һәм Хельсинки университеты тюркологларының яңа хезмәтләре хакында сөйләдем.

Казанга өч сәяхәтем гаиләм белән бергә булды. Шуларның икесе Татарстанның 50 еллыгын һәм 60 еллыгын билгеләп үткән истәлекле көннәргә туры килде. Без һәммәбез дә — хатыным Халидә ханым, кызларым Рәхилә, Тинәт, улым Окан ул бәйрәм көннәренең олы тантанасын күреп йөрдек, шәһәрнең төрле якларында үткән Сабан туйларында катнаштык, борынгы Болгарга, Тукай-Кырлайга бардык, татар театрларында милли әсәрләр карадык, күңелле концертлар күрдек, В. И. Ленин һәйкәленә, Габдулла

Тукай һәйкәленә чәчәкләр куйдык. Кая гына барсак та, мондагы милләттәшләр безгә ачык чырай, кунакчыл илтифат күрсәттеләр. Казан җиренә бәйле онытылмас хатирәләрне без бүген дә дулкынланып һәм рәхмәт хисләре белән искә төшерәбез.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Безнең әңгәмә тәмамланып килә. Финляндиядәге Тукай җәмгыяте эшләгән эшләрне бер тирәгәрәк туплап, кыска гына бер йомгак ясасагыз әйбәт булыр иде.

ГОМӘР ТАҺИР. Әгәр сөйләгәннәрне саннар теленә күчерсәк, җәмгыять үзенең яшәү дәверендә Казан кунаклары ярдәме белән уналты җыелыш үткәрде инде. Аларның тугызы Хельсинкида, алтысы Тампереда, берсе Ярвинпэздә узды. Ул җыелышларда Казаннан килгән тугыз галим һәм ундүрт артист катнашып, алар Тукай җәмгыяте эшчәнлегенә олы һәм изге өлеш керттеләр. Күпчелек күңелен үзенә тарткан җыелышлар, концертлар, лекцияләр, документаль фильмнар — болар барсы да Финляндия татарлары белән Совет Татарстаны, Казан арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгыту һәм бер-беребезне яхшырак аңлау өчен ышанычлы нигез булып торды. Ниһаять, моның Финляндия белән СССР арасындагы үзара әйбәт күршелек мөнәсәбәтләрен саклау өлкәсендә дә билгеле бер әһәмияткә ия булуын әйтеп китү урынлы булыр.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Биредә Хельсинки университеты белән урнашкан фәнни элемтәләрнең ныгый төшүен дә телгә алу зарури булып күренә.

ГОМӘР ТАҺИР. Әйе, үткән еллар эчендә Казан галимнәре Хельсинки университетында сигез лекция укыдылар. Беренче карашка моның Тукай җәмгыятенә турыдан-туры мөнәсәбәте юк кебек. Әмма ике ил арасындагы фәнни бәйләнешләр күзлегеннән караганда бу факт шулай ук җитди игътибарга лаек.

ИЛБАРИС НАДИРОВ. Җәмгыять башлаган эшнең Финляндия татарларына бәрәкәтле йогынтысын раслаган тагын бер күренеш турында берничә сүз әйтәсе килә. Соңгы елларда Татарстан артистларының Мәскәүдә яисә Ленинградта даими була торган концертларын һәм сәхнә уеннарын карар өчен Финляндия җиреннән төркем-төркем туристлар килә башлады. Минем белүемчә, Татарстанның 60 еллыгына багышлап 1980 елның декабрендә Мәскәүдә үткәрелгән сәнгать-әдәбият көннәренә Финляндиянең төрле шәһәрләрендә яшәүче татарлардан 23 кеше килгән иде. Татар дәүләт академия театрының 1984 ел августында Ленинградтагы гастрольләре вакытында аерым спектакльләрне карарга дип 44 кеше килә. Ниһаять, 1985 елның маенда Илһам Шакировның Ленинградта биргән концертларын карарга килүчеләр дә булды.

Әүвәлрәк, Тукай җәмгыяте оешып эшкә керешкәнче, мондый мисаллар бөтенләй юк иде бит. Бу мисаллар, минемчә, җәмгыятьнең ике ил арасында дуслык күпере булып хезмәт итүенә өстәмә дәлил.

Гомәр әфәнде, җәмгыятьнең алдагы планнарын ничегрәк күзаллыйсыз?

ГОМӘР ТАҺИР. Чираттагы олы эш булып Хельсинкида Тукайның 100 еллыгына багышланган бер җыелыш үткәрү тора. Аның программасын ныклап уйлыйсы бар әле. Үзенең традицияләренә туры калып, җәмгыять бу җыелышны да Татарстан галимнәре һәм артистлары ярдәмендә күркәм бер вакыйга булырлык итеп үткәрер дигән өмет бар.



# ТАТАРСТАН АССРның ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

## *(1958—1985 еллар.)*

### *1958 ел*

1. Композитор **Фәрит Заһидулла улы Яруллинга** — «Шүрәле» балеты өчен. Композитор **Нәҗип Гаяз улы Җиһановка** — «Җәлил» операсы өчен.

2 Язучы **Әхмәт Сафа улы Фәйзигә** — «Тукай» романы һәм Г. Тукай иҗатын популярлаштыруда актив эшләве өчен.

3. Режиссер **Шириязданн Мөхәммәтҗан улы Сарымсаковка**, художник **Әнәс Ибраһим улы Тумашевка**, артистлар **Хәлил Гали улы Әбҗәлиловка**, **Фатих Әкрам улы Колбарисовка**, **Асия Хәсән кызы Хәйруллинага** — Ленин орденлы Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Җилкәнсезләр» спектаклен куйган һәм төп рольләрне башкарган өчен.

4. Художниклар **Лотфулла Әбделмән улы Фәттаховка** һәм **Харис Габдрахман улы Якуповка** — «Татар халык әкиятләре» китабына иллюстрацияләр өчен.

5. **Нияз Курамша улы Даутовка** — М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрындагы «Алтынчәч» һәм «Евгений Онегин» операларын куйган өчен.

### *1959 ел*

1. Язучы **Габдрахман Сафи улы Әпсәләмовка** — «Сүнмәс утлар» романы өчен.

2. Качалов исемендәге Казан зур драма театры артисты **Николай Сергеевич Провоторовка** — «Өченче патетик» спектаклендә В. И. Ленин образын иҗат итүе өчен.

3. Композитор **Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы Яхинга** — яңа җырлары һәм романслары өчен.

4. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты **Фәхри Хөсәен улы Насретдиновка** — актив концерт эшчәнлеге һәм совет композиторлары әсәрләрен пропагандалавы өчен.

### *1960 ел*

1. Шагыйрь **Сибгат Хәкимгә** — «Ленин фәрманы белән» (рус телендә) һәм «Җил исми яфрак селкенми» (татар телендә) исемле шигырь җыентыклары өчен.

2. Художник **А. П. Бурлакга** — «Беренче нефть» дигән картинасы өчен.

3. Драматург **Г. К. Вахитовка (Хәй Вахит)** һәм Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры режиссеры **Р. Ә. Бикчәнтәевкә** — «Беренче мәхәббәт» драмасы һәм спектакле өчен.

4. Минзәлә колхоз-совхоз театрының баш режиссеры **С. Г. Өметбаевка** — «Язылмаган законнар», «Тамырлар» исемле спектакльләре өчен.

5. **Татарстан АССРның дәүләт җыр һәм бию ансамбленә** — хезмәт иляләре арасында татар хор культурасын һәм СССР халыклары музыка иҗатын пропагандалавы өчен.

## *1966 ел*

1. «Сайланма әсәрләр» дигән шигырьләр җыентыгы өчен шагыйрь **Хәсән Туфанга**.
2. Яңа җырлар циклы өчен композитор **Җәүдәт Фәйзигә**.

## *1967 ел*

1. Татарстан культура эшлеклеләре (Г. Тукай, М. Җәлил, Ф. Әмирхан, Г. Кариев, Г. Ибраһимов) портретлары сериясе өчен скульптор, ТАССРның халык художнигы **Б. Урманчега**.
2. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының «Гүзәлем Әсәл» спектакле (Ч. Айтматов повесте буенча) өчен әсәрне сәхнәгә куючы **Т. Ходжаев**, художник Э. Гельмс, артистлардан **Н. Гәрәева**, **Ш. Биктимеров**, **Ш. Әсфәндиярова** һәм **Р. Таҗетдиновларга**.

## *1968 ел*

1. Өч томлык «Татар халык мәкальләре» җыентыгы өчен **Нәкый Исәнбәткә**.
2. «Казах кызы сөйгәнем», «Солдат җыры», «Гөлләрем», «Безнең кардәшлек», «Мактанчык егет», «Бормалы су» җырлары өчен **Заһид Хәбибуллинга**.

## *1969 ел*

1. Язучы **Ибраһим Газига** «Онытылмас еллар» исемле роман-трилогия өчен.
2. Артист **Айрат Арслановка** «Туган җирем — Татарстан», «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән әдәби концерт программалары өчен.

## *1970 ел*

1. «Канатлы яшьлек» исемле җырлар җыентыгы һәм татар халык музыка иҗатын җыюда, аны пропагандалауда нәтиҗәле эшчәнлеге өчен **Александр Сергеевич Ключаревка**.
2. Театр һәм музыка-башкару эшчәнлеге өлкәсендә 1968—1969 елларда «Татар халык җырлары», «Җырларым сиңа, Октябрь» исемле концерт программаларын башкарып, татар халык җырларын, татар композиторлары әсәрләрен пропагандалавы өчен **Илһам Гыйльметдин улы Шакировка**.

## *1971 ел*

Театр сәнгате өлкәсендә — Кәрим Тинчуринның «Американ» һәм «Сүнгән йолдызлар», Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» әсәрләрен сәхнәләштергән өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе **Марсель Хәким улы Сәлимҗановка** һәм РСФСР һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, художник **Николай Дмитриевич Кузнецовка** бүгенге көн индустриаль пейзажлар циклы өчен.

## *1972 ел*

1. Әдәбият өлкәсендә — язучы **Фатих Хөснигә** «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» китабы өчен.
2. Балалар әдәбияты һәм сәнгать әсәрләре өчен шагыйрь **Шәүкәт Галиевкә** «Әти белән кабинада», «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Котбетдин мәргән», «Шәвәли», «Тәмле торт», «Кызык» исемле шигырь җыентыклары өчен.

## *1973 ел*

1. Әдәбият өлкәсендә язучы **Гариф Ахунҗан улы Ахуновка** «Чикләвек төше» повесте һәм «Хәзинә» романы өчен.

2. Театр сәнгате өлкәсендә ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор **Әнвәр Закир улы Бакировка**; РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, либретто авторы һәм постановщик **Игорь Валентинович Смирновка**; РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе художник **Борис Георгиевич Кноблокка**; РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дирижер **Хәсби Вәлиулла улы Фазлуллинга**; РСФСРның атказанган артисты балет солисты **Ревдар Фәиз улы Садыйковка** — Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында куелган «Су анасы» балеты өчен.

## *1974 ел*

1. Язучы **Мирсәй Әмиргә (Мирсәяф Мәсәлим улы Әмировка)** — «Агыйдел» пьесасы өчен.

2. Әдәби тәнкыйтьче **Нил Гафур улы Юзиевка** — «Шигырь гармониясе» һәм «Хәзерге татар поэтикасы» китаплары өчен.

## *1976 ел*

1. Драматург **Диас Нәзих улы Вәлиевкә** — «Дәвам» («Сиңа тормыш бүләк итәм») пьесасы өчен.

2. Шагыйрь **Марс Садри улы Шабаевка** — «Җикән камыш», «Онытма», «Сине эзлим» дигән шигырь китаплары өчен.

3. Режиссер **Равил Рәхим улы Тумашевка** — Татар дәүләт күчмә театрындагы «Сандугачлар килде безгә», «Үзебез сайлаган язмыш», «Сары чәчәк ата көнбагыш» спектакльләре өчен.

## *1977 ел*

1. Шагыйрь **Гамил Афзалга (Афзалов Г. Г)** «Айлы кичләр» һәм «Борылам да карыйм» дигән шигырь китаплары өчен.

2. Кинорежиссер **В. И. Беспаловка** — «Кырлай», «Татар гармуннары», «Нәҗип Җиһанов музыкасы» дигән музыкаль телефильмнар өчен.

3. Солистка **И. Ш. Хәкимовага** — М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Ф. Яруллинның «Шүрәле», Ә. Бакировның «Су анасы», П. Чайковскийның «Аккош күле» балетларында төп рольләрне башкарганы өчен.

## *1978 ел*

1. Шагыйрь **Равил Абдрахманович Фәйзуллинга** — «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы (1976) өчен.

2. Художник **Сергей Осипович Лывинга** — «Татарстанда Ленин булган урыннар буйлап» картиналары сериясе һәм Г. Тукайга багышланган эшләр циклы өчен.

## *1979 ел*

1. Драматург, пьеса авторы **Туфан Абдуллович Миңнуллинга**, режиссер-куючы **Гали Кәримович Хөсәеновка**, Мәдинә ролен башкаручы **Дамирә Нәҗмиҗановна Кузаевага** — Әлмәт татар дәүләт драма театрында куелган «Ай булмаса, йолдыз бар» спектакле өчен.

2. М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты **Ренат Исламович Ибраһимовка** — 1976—1978 еллардагы концерт программалары өчен.

## *1980 ел*

1. **Юзеев Илдар Гафуровичка** — шагыйрь. «Таш диварлар авазы», «Өзелмәс кыллар» поэмалары авторы.

2. **Маликов Васил Маликовичка** — скульптор, тарихи-революцион һәм хәрби-патриотик темаларга эшләнгән скульптура әсәрләре циклы («Чекист Н. Голубятников», «Соңгысы», «М. Җәлил») авторы.

## *1981 ел*

1. **Рәсүлев Атилла Кадыйровичка (Атилла Расих)**, язучы — «Язгы авазлар», «Ике буйдак», «Сынау» (трилогия) һәм «Ямашев» романнары өчен.

2. **Актерлар Кузин Евгений Андрианович, Федотов Юрий Степановичка** — В. И. Качалов исемендәге Казан рус драма театрында куелган «Большевиклар», «Изгеләрнең изгесе», «Астория» гостиницасы» спектакльләрендә башкарган рольләре өчен.

3. **Бакулин Герман Алексеевичка** — архитектор, **Зәкиев Әүфагъ Зәкиевичка, Парамонов Игорь Петровичка** — инженер-төзүчеләр, **Фәйзуллин Әнәс Нуруллович-ка, Хисаметдинова Сания Шәкүровнага** — бизәү эшләре мастерлары — Казанда Татарстан Художниклар союзының Күргәзмәләр залы бинасын проектлаштырган һәм төзегән өчен.

## *1982 ел*

1. **Нуруллин Ибраһим Зиннәтовичка**, язучы — «Тукай» («Молодая гвардия» нәшрияты, «ЖЗЛ» сериясе, 1977 ел, рус телендә) һәм «Габдулла Тукай» (Татарстан китап нәшрияты, 1979 ел, татар телендә) китаплары өчен.

## *1983 ел*

1. **Гыйләҗев Аяз Мирсәетовичка**, язучы — «Җомга көн кич белән» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары өчен.

2. **Еникеев Ренат Әхмәтовичка**, композитор — «Муса Җәлил истәлегенә» исемле вокаль-симфоник поэмасы һәм соңгы елларда иҗат ителгән камера әсәрләре өчен.

## *1984 ел*

1. **Еникеев Әмирхан Нигъмәтҗановичка (Әмирхан Еники)**, язучы — «Повесть һәм хикәяләр» һәм «Юлчы» китаплары өчен.

2. **Мулюков Бату Гатаулловичка** — композитор, **Родионов Григорий Васильевичка (Гәрәй Рәхим)** — либретто авторы, **Васильев Владимир Михайловичка** — дирижер, **Сөнгатуллина Зилә Даяновнага, Бегичев Хәйдәр Аббясовичка** — опера солистлары — М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында куелган «Каһәрләнгән мәхәббәт» («Кара йөзләр») операсы өчен.

## *1985 ел*

1. **Арсланов Нури Газизовичка**, шагыйрь — «Иделем — илем» исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы өчен.

2. **Нигъмәтҗанов Мәхмүт Нигъмәтҗановичка** — музыка белгече, татар халык музыкасы турындагы «Татар халык җырлары» һәм «Идел буе татарларының халык җырлары» дигән хезмәтләре өчен.

## Майя Плисецкая,

СССРның халык артисткасы,
Социалистик Хезмәт Герое,
Ленин премиясе лауреаты.

# ГҮЗӘЛ ҺӘЙКӘЛ

СССРның Зур театры филиалы сәхнәсендә Фәрит Яруллинның «Шүрәле»сен — Габдулла Тукайның әкият-поэмасы нигезендә иҗат ителгән балетын куярга әзерләгән чакта хәбәрчебез репетициядән соң Майя Плисецкая белән аның өендә очрашып сөйләшкән иде. Майя Михайловна бу балетта кош-кыз Сөембикә ролен — төп рольне башкара.

— Мин үзем бу балетка гашыйкмын. Оркестр уйный башлау белән, бөтен арыганнарың онытыла. Аның музыкасы шигърияткә бай, образлы, аңлаешлы. Ә безнең өчен моның әһәмияте бик зур... Сез соң ул балетның сюжетын беләсезме?..

Һәм балерина безгә кара көчләрне җиңгән мәхәббәт хакындагы борынгы татар әкиятен сөйләргә керешә, әмма ул башкаларча сөйләми, фәкать балерина гына сөйли алганча сөйли — җанлы итеп төшендереп бирә. Көйнең агышына кушылып, аның йөзе һәм куллары җанланганнан-җанлана бара.

Менә оркестр башкаруында канатлар кыштырдаганы ишетелә: карурман уртасындагы аланга кошлар очып төшә. Канатларын салгач, алар кызларга әверелә, кызлар биеп китә. Бу биюне читтән генә Шүрәле күзәтеп тора. Шыпырт кына килә дә бер кызның канатларын яшерә. Ахирәтләре очып китә, аянычлы хәлгә эләккән Сөембикә берьялгызы урманда торып кала...

Урманда пәри туе башлана. Шүрәле Сөембикәне үчекли. Шул вакыт якындагы авылның көчле һәм игелекле бер егете урманга килеп чыга. Пәри туен туздырып, ул Шүрәле белән алыша башлый, Сөембикәне коткара да авылына алып кайтып китә.

Авыл халкы бик рәхәтләнеп аларның туенда бии, күңел ача. Әмма кызның күңеле бераз боеграк: ул ахирәтләрен сагына. Туйга мыштым гына килеп кергән Шүрәле аңа канатларын кире кайтара. Шуннан кыз яңадан кошка әверелә дә очып китә. Егет, кулына ут тотып, аны эзли чыга...

— Бер генә минут! — дип, Майя Плисецкая сүзен бүлә дә күрше бүлмәдә чылтыраган телефон янына чыгып китә. Аныңниләр сөйләшкәне безгә ишетелеп тора:

— Юк, юк, бернинди концертка да катнаша алмыйм. Кичләрен «Шүрәле» белән мәшгульмен...

Безнең янга чыккач ул: «Нәрсәдә калган идек әле?» — дип сорый.

Батыр егет урман уртасында эзләп тапканда, Шүрәле кызның канатларын яңадан алып өлгергән, Сөембикә инде аның кулыннан ничек ычкынырга белми газаплана. Хәле мөшкел икәнен сизенеп, Шүрәле урманга ут төртә. Егет үзенең сөйгәнен азат итеп, Шүрәленең үзен ут эченә ыргыта. Ләкин аларга да котылу мөмкинлеге инде калмаган, бар яктан да ут ябырылып өсләренә килә. Егет, кызны коткарып, үзе шунда калырга ниятли. Тик Сөембикә, аның мәхәббәт көче алдында баш иеп, канатларын утта яндыра. Ут шунда ук сүнә...

Майя Плисецкая үзенең хикәятен басынкы гына тавыш белән:

— Әлеге парның финалдагы мәхәббәт адажиосы — балеттагы иң-иң поэтик урын. Анда мәхәббәтнең үлемне җиңүе искиткеч матур чагыла,— дип тәмамлады.

Һәм соңыннан атаклы балет остасы Майя Плисецкая «Шүрәле» балетының Татар дәүләт опера һәм балет театрындагы куелышын 1957 елда Мәскәүдә караганлыгын әйтте, әлеге спектакль турында уй-фикерләре белән дә уртаклашты.

Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы бөтен илебез Бөек Октябрь социалистик революциясенең 40 еллыгын тантаналы төстә үткәрергә әзерләнгән бер дәвергә туры килде... «Шүрәле» балеты аеруча зур игътибарга лаек. Беренче мәртәбә Казанда 1945 елда куелган бу әсәр аннан соң да әле Мәскәү, Ленинград, Киев, Рига, Улан-Удэ, Ташкент, Горький, Харьков, Одесса, Львов, Саратов h. б. шәһәрләрнең опера-балет театрлары сәхнәләрендә үзенең яңадан тууын күп тапкырлар кичерде. Татарстан музыка-хореография сәнгатенең гүзәл казанышы илебез чикләрен дә үтеп чыкты: «Шүрәле» балеты Болгариядә, Румыниядә дә куелды.

Бу әсәрнең хикмәте нәрсәдә, аның шул чаклы популярлык казануы нидән килә соң? Моңа җавап бер генә: балетның эчтәлеге һәм музыкасы халыкчан. «Шүрәле»-

нең сюжетына татар әдәбияты классигы Габдулла Тукайның әкият-поэмасы нигез итеп алынган. Либретто авторы Әхмәт Фәйзи, моңа өстәп, татар халык иҗатыннан шигърияткә бай, кешенең кодрәтенә, акыл көченә тирән ышаныч, яхшының яманны җиңеп чыгуын тасвирлаган башка мотивларны да мул файдаланган.

Балетның эчтәлегенә искиткеч бер гүзәллек биргән халыкчанлык — татар композиторы Фәрит Яруллин иҗат иткән музыкага да хас сыйфат. Бию өчен гаҗәеп кулай бу музыка халык авыз иҗатыннан алынган моң белән сугарылган. Балетның музыкасында персонажларның бер-береннән нык аерылып торуына, аларга капма-каршы музыкаль характеристика бирелүенә дә игътибар итмичә мөмкин түгел. Сөембикә партиясе үзе җиңел, үзе җырга тартым лирик яңгыраш алган булса, Былтырга кыюлык-батырлык темасы хас, ә инде Шүрәле һәм аның мохитын мәзәк яисә куркыныч авазлар чагылдыра.

Татар балетының талантлы артистлары үз партияләрен югары профессиональ дәрәҗәдә, чын-чынлап рухланып башкаралар. Үз роленә гашыйк булсаң гына, Былтырны, Татарстанның атказанган артисты Әдһәм Нарыков иҗат иткәнчә, курку белмәс, нечкә хисле образ дәрәҗәсенә җиткерергә — бу геройны халык әкиятләрендә яшәгән образына якынайтырга мөмкин. Бию техникасын ныклы үзләштергәнлектән, артист үзенең бөтен осталыгын образны ачып бирү максатына юнәлдерә.

Сөембикә партиясен башкаручы Татарстанның атказанган артисткасы Наилә Юлтыеваның уйнавына һәм биюенә дә шундый ук соклану, рольгә бөтенләй гашыйк булу, мөкиббән китү хас. Гәрчә сәхнәдә барган вакыйгалар әкият дөньясын чагылдырса да, артистка аларга һичшиксез ышана, үзен искиткеч табигый тота. Аның биюендәге форма пөхтәлеге дә сокландыра.

Бу балетта «урман сарыклары» кешеләргә каршы куела. Мәкерле һәм хәйләкәр Шүрәле партиясен Сәлих Хәйруллин гаять оста итеп башкара. Ул искиткеч җиңел һәм житез гәүдәле булып, һич көтмәгәнчә, күз ияләшмәгәнчә кискен гәүдә хәрәкәтләре ясый, бик матур итеп биеккә сикерә. Ут пәриенең биюе исә бик тә җитез булуны таләп итә. Экспрессияле бу биюне Елена Потемкина бик мәгънәле итеп башкара. Җен-пәриләрнең гаҗәеп катлаулы композициядән торган биюләрендә кардебалет үзен тотанаклы коллектив итеп күрсәтте, иң кыйммәтлесе — бер бөтен ансамбль тәшкил итте.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Хәсби Фазлуллин дирижерлык иткән оркестр башкаруында музыка хәйран гына ипле һәм дә моңлы булып агыла. Балетмейстерлар Людмила Бордзиловская белән Шәймөхәммәт Байдәүләтов шактый авыр һәм җаваплы эш башкардылар: аңарчы күпме театрда куелып, зур сәхнә тәҗрибәсе туплап өлгергән «Шүрәле» балетының алар яңа редакциясен күрсәттеләр.

Илебезнең Зур театры куйган спектакльдә миңа үзәк рольне — Сөембикә партиясен башкарырга туры килде. Безнең спектакль дә кызыклы гына килеп чыкты. Һәрхәлдә, минем үземнең күңелемә хуш килә. Шулай да Татарстан балетмейстерлары тәкъдим иткән редакциядәге кайбер элементларны, ачышларны безнең театр да ныклап, игътибар белән өйрәнергә тиештер дип карыйм. Әйтик, Мәскәү спектаклендә Былтырны ни сәбәпледер аучы итеп күрсәтәләр, ә бит ул урманга утынга барган крестьян егете, һәм бу Тукайның үзендә дә нәкъ шулай!

Сөембикәнең канатларына бәйләнешле тема да М. Җәлил исемендәге театр спектаклендә бүтәнчәрәк, миңа калса, дөресрәк хәл ителә, тирәнрәк мәгънә салына. Мәскәүдә куелган спектакльдә мәкер иясе Шүрәле, яшертен генә килеп, авылга үтеп керә дә урланган канатларны кызга кайтарып бирә, һәм шуннан соң кыз яңадан очып китә, ягъни явыз көчләр көенә бии башлый. Казанда куелган спектакльдә сюжет икенче төрле юнәлеш ала: Сөембикә бөтенләй яңа дөньяга, кешеләр арасына килеп керә, үзе дә кешеләргә генә хас тирән хискә бирелә һәм очып китүдән баш тарта. Шүрәле һәм аның иярченнәре — кара көчләр — аны урлап алып китәләр.

Бездә куелган спектакльнең соңгы күренешендә Сөембикә үзенең канатларын утка ташлый. Моның белән ул гомерлеккә кешеләр янында калуын раслый. Шулай да канатлар халык хыялында ирекә очуның символы булып яшәп килгән, һәм аны алай ансат кына утка ягу килешеп бетми торгандыр. Ихтимал, героиняның үз канатларын авылдашларына бүләк итүе дөресрәк буладыр. М. Җәлил исемендәге театр спектаклендә нәкъ әнә шулай хәл ителә дә инде.

Мәскәү кунаклары куйган спектакльдән куанып-канатланып чыкканда, исеңә кылт итеп бер сагышлы нәрсә килеп төшә: «Шүрәле»нең талантлы авторы Фәрит Яруллин Гитлер басып алучыларына каршы батырларча көрәшеп һәлак булган... Бөек татар шагыйре Г. Тукай өчен, патриот-композитор Ф. Яруллин өчен туган халкының сәнгате ирешкән әлеге зур казаныш — үзе әйтеп бетергесез гүзәл бер һәйкәл!







*Атаклы «Шүрәле» балетыннан күренешләр.*

Риф Якупов фотосы.

**Рашат Низамиев**

# МАТУРЛЫКНЫҢ ЯШӘР УРЫНЫ

ПОВЕСТЬ

*«Шүрәле»мне үлеп сагындым...»*
Фәрит Яруллин.
1942. 16.X. Хәрәкәттәге армия

## Сүз башы

Сәхнәдә «Шүрәле» балеты бара...

Декорация. Сәхнә уты. Биючеләр. Шуларның барысын берьюлы хәрәкәткә китереп, оркестр уйный. Музыка давылы эчендә әле скрипкалар хоры өстенлек итә башлый һәм залга җиңелчә-нәфис моңнар түгелә. Әле кларнетлар авазы ашыга-ашыга өскә калкып чыга һәм кисәтүле сәер аһәң булып колакка бәрелә. Ак һәм кара. Мәкер һәм намус. Мәхәббәт һәм нәфрәт. Менә шуларның үзара тартышы, кискен бәхәсе тылсымлы бер музыкага әверелгән дә матурлык тантанасының җиңәргә тиешлеген раслап бәргәләнә, алга чакыра. Андый чакта кешенең тормыш ваклыкларыннан биеккәрәк күтәрелүе гаҗәпмени! Көн һәм төн, ай һәм ел дигән төшенчәләр кинәт юкка чыга, гомернең мизгел генә икәнлеген тоясың. Шуны аңлаудан күңелдә бер хис ташып тула: үзеңә бирелгән шушы мизгелдә дөньяны мөмкин кадәр матурлап, бизәп китә алсаң икән!

Сәхнәнең бәрхет пәрдәләре ябыла. Зал гөмбәзендәге авыр люстра, көчле алкышлардан сискәнеп, камелия чәчәгедәй салмак кына ачыла, яктыра башлый. Театрның имән ишекләрен ачып урамга чыгасың. Дөньяда никадәрле үзгәреш! Күкләр биегәйгән, шәһәрнең йортлары һәм автобуслары, җилләре һәм чәчәкләре өр-яңа мәгънә белән каршыңа йөгереп килә. Ә мәгънәсе бик гади: сөй, шатлан, яшә, ләкин җиргә матурлык бүләк итәргә тиешлегеңне онытма! Ыгы-зыгылы урамнарны иңләп таныш түгел кешеләр ашыга. Йөз чалымнарыннан, омтылыш-хәрәкәтләреннән тиз абайларга мөмкин: гомернең һәр минуты кадерле икәнен аңлаганга күрә, яхшылык эшләп калырга ашыга алар...

Композитор иҗат иткән даһи музыка минем тын гына агып яткан тормышымны, уй-фикерләү рәвешемне әнә шулай үзгәртеп ташлый, табигать уйлап тапкан чын асылыма кайтара!

«Шүрәле» балеты... Аның моңнары Азия, Европа, Америка халыкларына кадәр барып җитте. Озак еллар сәхнәдән төшми торган бу балетны инде ничәнче мәртәбә каравым. Караган саен өр-яңа хисләр, рухи сафлану кичерәсең. Фикерләү, дөньяны аңларга тырышу җегәрен

---

НИЗАМИЕВ РАШАТ 1950 елда Татарстанның Саба районында туган. Берничә китап авторы. Шигырьләр, повесть һәм хикәяләр яза. Казанда яши. СССР Язучылар союзы члены.

арта. Афишада «Шүрәле» исемен укыдыммы, бар эшемне ташлап театрга ашыгам. Юк, музыкасының матурлыгын аңлар өчен яки фәлән артист фәлән рольне ни дәрәҗәдә уйный икән диеп кенә түгел. Соңгы вакытларда мине балетны тудыручы — композитор Фәрит Яруллин үзе кызыксындыра.

«Язган әйберләремнән эзләгез сез мине...» Моны Сент-Экзюпери әйтеп калдырган һәм бу сүзләр теләсә кайсы иҗатчының язмышын танып-белүдә ачкыч булып тора. Бөек Ватан сугышы кырларында ятып калган Фәрит Яруллин бер әсәре белән генә дә метеор күк балкып, атылып узды. Метеор атыла да сүнә. Ә менә талантлы композитор үзенең «Шүрәле»се белән кешеләрнең күңел күгендә мәңгелек эз калдырды. Я, гаҗәп хәл түгелмени бу?!

Менә шушы гаҗәпләнү хисе, Фәрит Яруллинның шәхесен аңларга тырышу теләге тынгылык бирми миңа. Уйларым Фәрит Яруллин исеме кергән китаплар, газета һәм журнал битләре белән тулыланды. Алдымда — Фәритнең балачагын, студент елларын, хәрби көннәрен чагылдырган фотоpәсемнәр. Өстәлемдә — гаиләсеннән, дусларыннан, полкташларыннан килгән хатлар. Колагымда — Фәритне якыннан күреп белгәннәрнең истәлек-хатирә сүзе. Казанда Фәрит яшәгән һәм укыган биналарның һәр ташына, һәр бүлмәсенә игътибар белән текәләм, ул йөргән урамнар буйлап узам...

Бөртекләп җыйган хатирәләр һаман үсте, зурайды. Төрлечә чәчелеп, таралып яткан мозаика ташларын күргәнегез бардыр сезнең. Менә шушы төсле ташларны билгеле бер тәртиптә тезеп, һәркайсын тиешле урыннарынаябыштырып чыксаң, диварда без хыялланган сурәт барлыкка килә. Минем белән дә шулайрак булды. Әкрен-әкренләп хыялымда композиторның тормышы, дивардагы панорама сыман, балкып-ачылып китте. Һәм көннәрдән бер көнне мин шундый халәткә күтәрелдем ки — үземне кайчандыр Фәрит Яруллин мохитендә яшәгән кебек хис итә башладым! Мин аның тормышын үз күзләрем белән күргәнмендер кебек. Ул яшәп калган гомердәге ун мең дүрт йөз сиксән өч көннең һәр секундын яттан беләмдер кебек. Очраган бер кешегә озаклап-озаклап әнә шул хакта сөйли алырмын төсле...

Әйтер сүзем тәмам өлгереп җитте! Тау-ташларны ярып чыккан һәм диңгезгә ашыккан чишмә сыман, ул да дөньяга омтыла, кешеләр арасына ашыга. Дәшми калырга хакым юк иде. Менә ни өчен Фәрит Яруллин турында сөйлисем килә минем.

Кайдан, нәрсәдән башларга?

Хикәят безне, кадерле укучым, Курск дугасының дәһшәтле көннәренә алып керер...

## 1

1943 елның 5 июле.

Таң сызылып килгән минутлар...

Сугышның рәхимсез чынлыгына үч итеп, офыкларны яктыртаяктырта, канлы кызарыш белән яңа көн туып килә. Курск дугасы өстендә хәвефле, сискәндергеч тынлык. Бу Дуга бормаланып казылган траншеялар, дошман сизмәслек итеп ныгытылган дзотлар, чирәмле окоплар, маскировкасы-ние белән көнбатышка төбәлгән туплар, ут нокталары тезмәсеннән тора. Оборона тынлыгына күнеккән солдат һәм сержантлар, кече һәм өлкән офицерлар бүген инде йокламый, беренче залп яңгыраганны көтәләр.

19 нчы танк корпусының укчы взвод командиры лейтенант Фәрит Яруллинның да бөтен аңы, рухы, тәне уяу. Сизгерлек һәм хәтер йокламый. Менә шушы халәтне солдатларга да күчерергә кирәк — тиздән зур бәрелеш булачак...

Кинәт... күзгә күренми торган коточкыч зур бер йодрык иртәнге тынлыкны челпәрәмә ватып ташлады! Җир белән күкне тоташтырып утлы тасмалар агыла, бөтен тирә-як гөрселди, уфылдый, дер селкенә. Героик симфониянең увертюрасын уналты тавышлы «Катюша»лар залпы башлап җибәргән иде, инде шушы ансамбльдә «Лука-Лукич» һәм «Марфуша»ларның [1], гаубицаларның да тавышы ишетелә...

Күк — гигант барабан, безнең артиллерия, әйтерсең, бертуктаусыз әнә шуны дөбердәтә. Тоташтан гөрселдәгән әлеге авазларда җиңүгә омтылышның барлык төсмерләре бар кебек. Әнә бит дошман ягында ут һәм балчык фонтаны чөелә, гитлерчыларның ай буе хәстәрләгән ныгытмалары күккә оча. Сул яктагы курганнар артыннан кара төтен баганасы ургылып чыкты. Ургылып чыкты да, тагын да карала һәм җәелә төшеп, кемдер көч белән этеп җибәргәндәй, өскә күтәрелде. Бәлки, фашистларның ягулык склады янадыр? Кайнап-кайнап чыккан кue төтен, гадәттә, шуның билгесе.

Соңарып булса да дошман артиллериясе телгә килде. Ут белән ут алыша, тимер белән тимер якалаша. Акыл, хәйлә, зирәклек, нервылар сугыша. Капма-каршы ике иман, ике көч көрәшә. Җир өсте тоташ гүелди, кайный, актарыла. Мең кыллы дөнья тоташтан зеңләп тора. Меңәрләгән яшен берьюлы яшьнәгәндәй итеп күкләр тетри. Гүя каяндыр әкиятләрдәге унике башлы аждаһа килеп чыккан да зәһәрле канатын баш очында җилпи-җилпи давыл уйната, унике авызыннан берьюлы ут һәм төтен галәмәте чәчеп ухылдый, сызгыра, җир белән күк арасында бәргәләнә...

Шушы мәхшәр эчендә кешенең исән калуы мөмкин түгелдер шикелле. Ләкин бу шулай тоела гына. Әнә, траншея, аралашу юллары буйлап элемтәче һәм санитаркаларның чабулаганы күренә. Окопка сеңгән сугышчылар вакыт-вакыт башларын күтәреп алга карыйлар.

Ут... Төтен... Шартлау...

Фәрит Яруллинның бер колагында — канонада тавышлары... Икенчесендә — моннан ике ел чамасы элек язылган, ләкин сәхнәгә менеп өлгермәгән «Шүрәле» балетының аккордлары...

Командир-композиторның колагында ике аһәң, ике оран сугыша! Аларның кайсы көчлерәк, кайсысының яшәргә хакы зуррак? Җиңел түгел Фәриткә... Канонада кайтавазы «Шүрәле» моңнарын бәреп чыгарырга, пыран-заран китерергә, аста калдырырга тели. Ничә еллар буе Фәритнең күңелендә йөргән һәм, ниһаять, бию-моң хәрәкәтләренә әверелгән бу матурлык юкка чыга аламы соң? Юк! Ул яши, көрәшә, тантана итә, чөнки һәр матурлыкның үз язмышы, үз киләчәге бар!

«Шүрәле» тиздән Мәскәү һәм Казан сәхнәләренә чыгарга тиеш иде. Ләкин... менә шушы каһәр суккан сугыш бөтенесен йөзтүбән әйләндереп ташлады.

Сугыш...

Фәритнең күңелендә беренче минутларында ук сугышка каршы нәфрәт уянды. Музыкага багышланган, әмма башкарасы эшләренең бер өлешен генә үтәп өлгергән, матурлыкка гашыйк күңелнең шәхси протесты иде бу. Ул — композитор, иҗат кешесе, табигать аңа, гүзәлекләр тудыр, дип хәер-фатиха биргән дә башыннан сыйпап тормышның киң, олы сукмагына озатып җибәргән. Шулай булгач, утлары кайнап торган гарасат уртасына керү мәҗбүри микән соң аңа? Бәлки, бернигә дә карамый, матурлык иленә сәфәрне дәвам итәргәдер? Иҗади уй-ниятләрен тизрәк кәгазьгә төшерү, яңа тормыш тантанасын зурлау — аның иң олы бурычыдыр?

«Шүрәле» балетының репетицияләре тукталды, фронт сызыгы күренмәс җепләр белән тылга да килеп тоташты. Сугыш тормышны бөтенләй башка эздән куалап алып китте...

[1] «Лука Лукич», «Марфуша» — гвардия минометларын фронтта шулай дип йөрткәннәр.

*Аның күңеле матурлык эзләүдән гыйбарәт иде. Матурлык кешегә алга бару, биеккәрәк күтәрелү өчен кирәк. Тормышның беркайда да язылмаган якты бер законы әнә шулдыр. Илдәшләрең белән уртаклашсаң, үзең тапкан матурлык мәңгә, миллионга тапкырлана. Күктән болыт булып агамы яисә җирдән сабый булып атлыймы, ул һәркемнең йөрәге аша узарга тиеш. Матурлыкның яшәр урыны — Ватан.*

Фәритнең уйларын бүлдереп снаряд шартлады. Гомуми шау астында аның тавышы юньләп ишетелмәде дә кебек, ләкин траншеяга һәм гимнастерка якасына салкын балчык яңгыры мул коелды. Уттан туган балчык ничек алай салкын була икән? Әллә җирдән аерылгангамы?

Канонаданың туктар исәбе күренми: туплар кубарган ут, төтен, тузан өермәсе гигант пәрдә булып, үзенә бер дәһшәт салып дала өстендә йөзә, кайный, тугарыла. Туып килгән көн яктысы шушы кара пәрдә кочагында бәргәләнә-бәргәләнә дә күкнең кайсыдыр почмагыннан җиргә караш ташлый. Тик аны да вакытның кайсыдыр мизгелендә яндыргыч снаряд, куәтле янгын балкышлары күмеп китә. Ачы төтен, көек исләре тынны буа. Офыкта чиратлашып кызгылт һәм кара төсләр шәүләсе бии. Әгәр бу дәһшәтле атыш төнлә булса, күктә йолдыз янгыннары башланыр иде мөгаен.

Эссе... Ләкин сугыш ялкыны кешене беркайчан да җылытмый, киресенчә, үлем салкыны булып аркасына елыша. Кеше өчен дөньяда йөрәк җылысыннан да кадерле нәрсә юк. Кешелек сугышны нигә уйлап чыгарды икән? Кул биреп күрешәсе, туганлашып кына яшисе урында нигә әле бер-береңнең йөзенә ут сибәргә? Аңлый Фәрит: барысына да фашизм гаепле...

Чү! Ерактагы урман эчләреннән шүрәле авазы ишетелә кебек. Күз күреме җирдәге киңлекләрдә ялкын телләре шүрәле булып бии, әле шырыйлап кычкыра, әле каһкаһә белән көлә. Таныш авазлар, таныш хәрәкәтләр... Болар — аның балетыннан түгелме соң! Менә утынчы егет Былтыр сөйгән яры Сөембикәне коткару өчен карурманга — Шүрәленең чытырманлы оясына якыная. Сөйгәнен коткара һәм җен-париләр оясына ут төртә, явызлар патшасы Шүрәлене кайнап торган ялкын уртасына чөеп ташлый!

«Шүрәле»дә урман яну күренеше — бары хыял җимеше, сәхнә тамашасы. Ә менә кара туфраклы Курск-Орел далалары чын-чынлап әнә шундый мәхшәр мәйданына әверелер дип кем уйлаган? Биредәге янгын мең вә миллион тапкыр куркынычлырак. Явыз Гитлер... Менә кемне бар халыклар һәм дәүләтләр исеменнән дөрләп янган ут эченә ташларга кирәк!

Күпме күнегәм дисәң дә, күнегеп булмый — канонада тавышлары күңел төпкелендә яткан әллә ничаклы уйларны актарып чыгара, хәтерне кузгата, гомер һәм яшәү мәгънәсе турында уйлата башлый.

Фәриткә — егерме тугыз яшь...

Сәер хәл: тирә-ягыңда туплар шартлаганда вакыт төшенчәсе кайчак туп көпшәсендәге һава шикелле тыгызланып килә икән. Үткәннәрең шундый якында кебек: кулыңны суз гына — алар инде бөтенләе белән синеке. Киләчәгең шундый якын кебек: күзләреңне йом гына — ул инде якты балкыш булып каршыңда басып тора. Шулар уртасында — бүгенге көнең, бүгенге халәтең — актарылып торган уй һәм кичерешләр давылы. Күз йомган ара — кар һәм яңгырлар астында күмелеп калган әллә кайчангы көннәреңә «ә» дигәнче кайтып җитеп була. Керфекләрен күтәргән арада киләчәкнең кул җитмәс киңлекләрен колачлау куәте бар кешедә. Димәк, вакыт — шартлы нәрсә, телисең икән, гасырларны минутка тиң аның. Уйлап карасаң, яшәү формуласы, бәлки, гомернең өч минутыннан гыйбарәттер: үткәннәрең... бүгенең... киләчәгең...

Кыскамы син, озынмы син, гомер? Нинди булсаң да, бөтен барлыгың, язмышың әнә шушы формулага сыйган да беткән синең!

Колакта сугыш... Ике якта — ике симфония.

Фәрит Яруллин, тормышының барлык минутларын бергә тоташтырып, әнә шул симфониянең кыл уртасында басып тора бүген. Күңеленнән генә үткән гомерен барлый. Ә күңел соңгы көннәрдә нишләптер һаман балачакка кайта. Бәлки, үткәннәрне сагынудан, сугыш вәхшәтен онытып торырга теләүдәндер бу? Ә балачак илендә, чыннан да, рәхәт. Анда — этисенең кул хәрәкәтләре, әнисенең ягымлы тавышы, Тукайның тылсымлы шигырьләре...

## 2

Кечкенә Фәрит, уйнап туйгач, урам эте һәм извозчик атларыннан сакланып кына өйләренә кайта.

Кич. Ярыйсы гына иркен бүлмәнең барлык почмакларын ике керосин лампасы яктырта. Аларның берсе — мич буенда, икенчесе — чуклы ашъяулык ябылган өстәл өстендә моңсу гына көлемсерәп утыра. Әтисе, мич буендагы лампа яктысына елыша төшеп, үз шөгыленә күмелгән. Муен өстенә атландырып бәйләгән күн алъяпкычын тезләре өстенә җәеп салган да кырлы игәү белән ниндидер агач кисәген ышкылый. Шулкадәр бирелеп, җентекләп, кулындагы әйберләрне ут яктысына кат-кат куеп карый-карый эшли ул, мондый төгәллек сукыр энәгә җеп саплаган чакта гына кирәктер, мөгаен. Әмма аңлаган кешегә алтын куллы әтисенең шөгыле энә саплаудан күп тапкырга четереклерәк: шалтырап торган буш, иске мандолина кабырчыгына җан өрмәкче була ул!

Кичә әтисе күршедәге Гыйльфан сәүдәгәрнең кара айгырыннан бер учлам кыл өзеп алган иде. Койрык кылы дияр икән аны, скрипка сызгычына тарттыру өчен шуңардан да кулае юк. Аларны әтисе юды, сөртте, иң тазаларын сайлап югартын киштәгә куйды. Киштәдәге әйберләргә әтисенең рөхсәтеннән башка кагылырга ярамый. Әйдә, шулай да булсын, ди. Тик менә ат кылы сызгыч кылларына әверелгәч, Фәритнең кулларына кайчан да бер эләгеп зеңләми калмас әле. Малайның сабыйларча өмете хәзергә шул тирәдәрәк йөзеп йөри.

— Улым, яле, өстәл янынарак утырыйк.

Монысында ягымлы тавыш белән әнисе дәшә икән. Нәгыймә исемле ул. Борынгы көйләрне җырлап җибәрсә, Фәритнең сулышы тамагына килеп бөялә, күзләреннән яшь тәгәрәп чыгардай була. «Тәфтиләү» дигәнен тыңлаганда бигрәк тә шулай...

Әнисенең дә үз киштәсе бар. Анысына да рөхсәттән башка кагылырга ярамый. Бирейдә тарак, көзге, чулпы, хәситә шикеллерәк хатын-кыз әйберләре, ә бер читтәрәк тышлары искерә төшкән эреле-ваклы китаплар, каты тышлы калын альбом. Фәрит өчен хикмәтләрнең иң зурысы әнә шунда, дөресрәге таякны «әлиф» дип таныта башлаган китаплар эчендә ята иде.

Әнисе кош баласы тоткандай итеп, сак кына тота китапны. Бармак битләре белән җиңелчә орынып кына үзенә кирәкле битләрне эзли. Менә шул чакта Фәритнең каршында гаҗәеп серле капка ачыла: гарәп хәрефләре белән язылган сүзләр, тигез-тигез сукмаклар, бормалы бизәкләр... Монысы кая илтә дә, тегесе кая барып чыга икән? Юк, сукмак кына түгел, бер-беренә таянып үскән чытырманлык, ерып чыккысыз карурман бу! Капкасы ачыла ачылуын, тик менә атлап керер юлы кая соң аның? Кай җиреннән тотынырга белми аптырый Фәрит, берничә хәрефне генә укый да килеп төртелә. Их, шартлатып укый белсәң иде шуларны — дөньяда синнән дә акыллы, синнән дә көчлерәк кеше булмас иде! Берни эшләр чара юк, хәзергә өлкәннәр укыганны колак торгызып тыңларга гына кала.

Әнисенең бармаклары арасында китап битләре кыштырдый. Китап түгел, ә бәлки кәкре-бөкре, сыгылмалы-түрткеле рәвештә тезелгән хәрефләрнең шулай үзара сөйләшүедер ул? Әнисе тавышын көйләү өчен йомшак кына тамак кырып куя, йорт башының рөхсәтен алырга теләгәндәй, эти кеше ягына карап ала.

— Укып җибәр, әнисе. Тукайны тыңлап үскән бала игелекле булыр. Олыга да, кечегә дә ярый аның язганнары. Кулым эшләсә дә, колагым ишетә минем...

Шулай ди дә мандолина сәдәфләренең ныклыгын тикшергәндәй итә әтисе. Кечкенә Фәрит Тукайны китаплар яза торган юмарт бер абый дип күз алдына китерә. Әтисенең Тукай белән якыннан танышлыгы, шагыйрь абыйның музыка яратканлыгы турында ул чакта каян беләсең ди! Әтисе боларны соңрак, үсә төшкәч сөйләр аңа. Ә хәзергә Фәритнең бөтен игътибары әнисенә юнәлгән: ниләр укыр икән ул, янәсе...

Әни кеше ак яулыгын маңгай турыннан артка кайтарып бәйләгән. Яулык астыннан чыгып торган бер тотам чәче һәм балан зурлыгындагы кып-кызыл алкалары аңа гаҗәеп бер матурлык өсти. Өйдә беразга тынлык урнаша — әнисенең бер ноктага тупланып укый башларга әзерләнүе.

Әнисе укый башлауга, Фәрит тәмам онытыла, барлык хыял-кичерешләре белән әкият ихтыярына бирелә. Ул урманның матурлыклары! Җир җиләге, күбәләкләр, гөлләр-ганҗәләр дисеңме — һәммәсе берьюлы хыялны биләп ала. Рәхәт менә шушы тылсымлы, йомшак, ягымлы дулкында тирбәлү. Әнисенең тавышымы соң бу, әллә Фәрит чыннан да Кырлай урманнары уртасына килеп эләктеме? Айлы кич. Әнә, батыр егет урманга утынга китте... Чү, рәхәт кенә түгел, куркыныч та икән әле әкият тыңлау:

Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Я өрәкме, нәрсә бу?
Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!
Борыны кәп-кәкре — бөгелгәндер тәмам кармак кеби;
Тәз түгел куллар-аяклар да — ботак-тармак кеби.

Әнә нинди икән ул шүрәле! Килче икәү уйныйк бераз кети-кети, дигән булып кешеләрне куркыта, хәлдән тайганчы кытыклый... Ярый әле Былтыр атлы егет батыр булып чыкты — шүрәленең бармагын бүрәнә ярыгына хәйлә белән «һоп» итеп кенә каптырды да куйды!

Әнисе укып бетерә дә ни өчендер сүзсез генә елмая.

— Әни, шүрәле чынлап та бармы ул?

— Юк, улым, уйдырма гына.

Фәриткә күңелсез булып китә, шүрәлене чын-чынлап бардыр дип уйлаган иде ул. Менә, ышанып утыр син китапка...

— Юк икән, алайса нигә язалар?

— Әкият — сөйләр һәм укыр өчен матур ул. Тукай абыең шуны истә тотып язган.— Әтисе улын үз янына чакырып ала: — Кил әле бире. Күрәсеңме, менә бу кыллар үзе бер әкият!

Әтисе Фәриткә дигән мандолинаны көйләп тә бетергән икән. Яле, карап карыйк дигәндәй, башын хикмәтле генә селкеп алды да нәни яфрак чаклы нәрсәкәй белән кылларга чиртә башлады. Зең... зең... трил... лил... Әтисенең бармаклары озынаеп килгән кара сап буйлап йөренә, уң кулы исә кыллар өстендә кош канатыдай лепердн. «Каз канаты» көе... Көйгә кушылып, лампа ялкыны да пыяла куык эчендә сизелер-сизелмәс кенә бии шикелле — әйтерсең, өйдә канат җиле агыла. Я хода, гап-гади кылларда шулкадәр дә илаһи, сагышлы моңнар булыр икән!

Бу кичтә Фәрит беренче тапкыр мандолина чиртеп карады.

Баштарак мандолина кечкенә кулларны ятсынды бугай әле. Урындыкта утырып торган малайның тез башына да курка-курка гына сыенды шикелле. Кылларына кагылгач та: «Нихә-ә-л-л?»— дип озак кына зыңлап торды. Үзенчә исәнләшүе булгандыр, күрәсең. Аннары Фәрит

бармакларын бер кылдан икенчесенә сикертте. Нечкә яңгыраш белән калын авазлар бергә кушылып һаваны тирбәтте:

— Зең... зиң... заң...

Искиткеч бәхетле минутлар иде бу! Тартылган кыллар, синең ихтыярыңа буйсынып, әнә нинди авазлар чыгара, телеграф чыбыгыдай зеңли. Фәритнең бармаклары шушы кылларга тоташып үскәнме әллә: алар да җиңелчә бер рәхәтлек белән тирбәлә, йөзә, моң булып калтырана. Гәүдәсендәге сихри тетрәү туп-туры бармак очларына агып төшә сыман. Мандолинага кушылып Фәрит әллә үзе чыңлыймы? Ул үзен ике аяклы, ике куллы тере көй итеп тоя башлады. Күзеннән, колагыннан, чәчләреннән чың агыла шикелле. Менә ничек була икән ул моң дигәнең!

Беренче тапкыр үзе чыгарган «зың-заң» моңнарын әле дә хәтерли Фәрит. Менә хәзер дә шул чың колагында яңгырый төсле... Әллә ул чың түгелме? Бик сәер ич...

Баксаң, туплар шартлавыннан җир үзе тоташ зыңлап тора икән!

### 3

Әйе, җир күчәреннән ычкынган сыман тетри, чайкала.

Лейтенант Яруллин, күтәрелә төшеп, күз карашы белән генә сугышчыларын барлап алды. Дөрес, ерактан аларның гимнастерка һәм каскалары гына күзгә чалына, ләкин командир һәркайсының кояшта, җилдә һәм җәйге челлә рәшәсендә каралган йөзен канонада тузаны астында да аермачык күрә. «Бу тузан нидән гыйбарәт икән?— дип уйлап куйды Фәрит.— Туфрак кисәкчәләреме ул, әллә челпәрәмә килгән тынлыкның һава белән укмашкан юшкынымы?»

Маңгае тоташ ак бинт белән уралган сержантны санчастька илтә торган аралыктан алып киттеләр.

Шул вакыт уң флангта иелә-иелә йөгерүче элемтәче күренде. Киләкилешкә лейтенант янына чумәште:

— Сезне... рота командиры чакыра!

Фәрит траншеяга сикереп төште. Сугышчылар уентыклап ясалган ячейкага сеңгән, култык асларыннан автомат түтәсе күренеп тора, кирза итекләрендә — сугыш тузаны, окоп балчыгы. Әйе, оборона көннәрендә туфракны байтак актарырга туры килде аларга. Эх, бу егетләрдән алмагач чокыры гына казытырга иде дә бит. Үссен иде шау чәчәкле бакча! Алма битле кызлар алма җыеп кына йөрсен иде биредә...

Бүрәнә блиндажның ишеге ачык. Яруллин килеп кергәндә, рота командиры өлкән лейтенант Куралев кем беләндер телефоннан сөйләшә иде. Йөзе җитди, кырыс, маңгаенда — вакытыннан иртә уелган җыерчыклар. Фәритнең инде байтактан көзгегә караганы юк. Көзгегә текәлеп караса, калын иренле, кысынкырак күзле, кабарып торган куе чәчле, уйчан-сагышлы ир-егетне күрер иде ул. Бераз ябыккандыр, аның да күз төпләрендә яңа җыерчык арткандыр, бәлки...

Стенадагы сәгать бер якка янтайган — монысы каядыр якында шартлаган снарядлар эше, әлбәттә. Комбат күренми, позицияләргә чыккан, күрәсең. Түрдә таныш түгел яшь лейтенант карта өстенә иелеп нидер карый иде.

Ниһаять, рота командиры торып басты, куллары белән сыпыргалап каеш-гимнастеркасын, кобурасын рәтләгәндәй итте.

— Иптәш Яруллин, беләсеңме, нәрсә бу?— Куралев имән бармагы белән атышлар тавышына ишарәләде.— Бүген иртән немецлар зур һөҗүм башларга тиеш булган. Молодцы, безнең артиллерия ярты сәгатькә алданрак өлгерде. Дошманның ниятен алдан белеп торулары шәп бит, ә!

Рота командирының үз итеп сөйләве, шул ук вакытта хәзерге минуттагы хәлнең кая таба барганлыгын сиздерергә тырышуы да иде

бу. Куралев, яңа приказны җентекләп аңлатканнан соң, сүзен йомгакларга ашыкты:

— Немецлар соңарып булса да һөҗүмгә күтәреләчәк. Личный составны сугышка әзерләгез! Өстәмә боеприпаслар биш минуттан килеп җитәчәк. Ут секторлары үзгәрешсез кала.

Сталинград янында җиңелгәннән соң немецларның бер як кабыргасы таралып төште. Курск дугасында реванш аласы килә дошманның. Безнекеләр исә немецны яңа «күчтәнәч» белән сыйламакчы була — Фәритнең чамалавынча, фронтта әнә шундыйрак хәлләр урнашкан иде.

Кинәт блиндаж тирәсендә нидер шартлады. Түшәм-стеналар дер селкенгәнне әллә тойдылар, әллә юк, өчесе берьюлы кул белән башларын капладылар. Көек исе килә түгелме... Күзләрен ачып җибәрүгә Фәрит үз-үзенә ышанмыйча бер адым артка чигенде: өстәл һәм стена буйларында ялкын телләре биешә иде! Шартлау дулкыны стенадагы керосин лампасын өстәлгә атып бәргән дә янгын ясап маташа... Фәрит нар өстендә яткан шинельне тиз генә өстәлгә китереп каплады. Тегеләр икесе стена буйлап үрмәләүче ялкын телләрен кыр сумкасы белән кыйнарга керештеләр. Бәхеткә каршы, утны тиз сүндерделәр. Таныш түгел лейтенант почмагы көеп чыккан картасын нишләтергә белми кулында селкеп тора, яңагында — зур сугышның кечкенә янгыны пичәтләп калдырган корым эзләре, гаҗизлек билгеләре. Фәрит аны кызганып куйды, ләкин күтәрелеп сүз әйтмәде. Нишләтәсең, табигате шундый аның: зуррак, хәтәррәк кичерешләрдә дә күбрәк эчтән янучан бит ул.

Немец снаряды, чыннан да, нәкъ блиндаж түбәсенә килеп төшкән, кәс һәм туфракны дуамал көч белән актарып ташлаган иде. Ләкин түшәмне җимерә алмаган, ни әйтсәң дә Дугадагы корылмалар озаклап, инженерлык техникасының соңгы казанышларына нигезләнеп эшләнде шул.

Ә кешенең... кешенең ныклыгы нәрсәдә соң? Аңарда таш яисә корыч ныклыгының әсәре дә юк бит. Ул беренче карашка сөяк һәм мускуллардан гына тора шикелле. Әмма кешедә бернинди ташта яисә корычта да булмый торган өстенлек бар: ул — зирәклек, рухи ныклык, тормышка мәхәббәт. Кешеләрне менә ни яшәтә! Яшисе килү хисе кешегә тумыштан биреләдер. Ләкин тормышка мәхәббәт сабый чактагы беренче дусларыңнан, табигать белән танышудан башлана булса кирәк. Фәритнең дә шулайрак булды ич.

Әнә ул көннәрнең хатирәсе «сагындыңмы?» дия-дия офыкта тирбәлә. Әтисенең туган авылына кунакка кайтулар хәтернең кайсыдыр почмагында тавышсыз аҗаган булып уйнаклый...

## 4

Шәйхулла белән Фәрхетдин киндер капчыкларын асып килеп тә җиткәннәр. Шәйхулласы кыска кара ыштан, утыртма якалы зәңгәр күлмәк кигән. Фәрхетдиннең өстендә дә шул ук киемнәр, ләкин аныкылар яңарак, күлмәк җиңендәге сәдәфләренә хәтле ялтырап тора. Өстәвенә, ул каюлы бәрхет кәләпүш тә киеп җибәргән. Гаҗәпмени, әтисе тирә-якта атаклы тегүче икән аның. Авылда малайга такмак та чыгарып өлгергәннәр:

Энекәем Фәрхетдин,
Түбәтәең бәрхеттин...

Фәритләрдән бернечә яшькә олырак Фәрхетдиннең исе дә китми, елмаеп тик тора. Бүген алар кунак малай белән урманга чикләвеккә менәргә сөйләштеләр. Өчәү бергә җыйналуларының сәбәбе дә шул.

Урман аларны кочак җәеп каршылады, арба эзе төшкән чирәмле юлдан әчкәре әйдәкләде, юл буендагы биек үләннәре белән муеннардан

кытыклап калды. Эчкәре кергән саен уймак-уймак аланнар, бөдрә куаклыклар, стенадай баскан агачлар тезмәсе. Менә нинди икән ул чикләвек! Ботак очлары саен учлам-учлам кишәнкеләр эленгән. Үрелдеңме, капчыгыңа сикерергә генә тора. Биектәгеләрен ыргаклы таяк белән аска сыгып төшердеңме, алары да үзеннән-үзе синеке инде.

Фәрит олы бер кишәнкене кат-кат тотып карады, учларында сикертте. Санап караса, берүзендә — тугыз чикләвек! Йомры күзләрен шар ачып, тәмам берегеп үскәннәр. Менә болары — чуклы-чуклы керфекләр. Чикләвек төнлә керфекләрен йома микән? Шул хакта сүз кузгалгач, Фәрхетдин чатнатып җавап бирде:

— Керфекләрен йомса, тиен урлап китә аны, бик беләсегез килсә.

Тапкыр сүздән рәхәтләнеп көлештеләр. Фәрхетдин гел шулай: теле телгә йокмый, дөрес булса, йоклаганда да сөйләшә, имеш. Ә Фәритнең беразга ялгыз каласы, урмандагы бихисап авазларны тыңлый-тыңлый рәхәтлек кичерәсе килә. Аның уйлавынча, малайлар шушы куаклык тирәсеннән ерак китмәскә тиеш. Аннары бер көн әбисе, сандугач оялары да менә шулай язулы була, дип коръән китабындагы сүзләрне күрсәткән иде. Бәлки, сандугач оясын да эзләп табар әле ул, язуларын укырга тырышыр.

Капчыгын кочаклап бара торгач, Фәрит икенче бер аланга килеп чыкты. Аның каршысында таң калырлык тамаша ачылган иде: кояш нурлары алтын пәрәвез җебе булып куактан-куакка тартылган, күбәләк һәм яфраклар әнә шул алтын кылларда тирбәлә-тирбәлә генә якты бер көй уйный: лепер-лепер... без-без-з-з... тюф-тюф-ф-ф... Күңелләрне әсир итәрлек бу күренешкә кошлар концерты да килеп кушыла. Хәтта аяк астында шартлап сынган коры ботак тавышы да шушы аһәң эчендә ятышлы, үз булып ишетелә. Челтерәп торган моң исә кыңгырау чәчәкләреннән тарала бугай. Ә менә урман шавы каяндыр өстән, кояшлы киңлекләрдән агылып килә. Тагын да өстәрәк... көн яктысында качып яткан йолдызлар кыштырдавы ишетелә кебек.

Күрче,биредә һәр нәрсә яши, җырлый, шатлана икән! Син дәшми торган саен алар колагыңа тагын да ачыграк булып керә. Онытылды, йотылды Фәрит, хәтта урмандагы агачларның ничек үскәнен дә аермачык тоя башлады шикелле...

Малай каршында мөлдерәмә тулы моң дәрьясы тирбәлә иде.

Сандугачның язулы ояларын очратмады Фәрит, аның каравы менә нинди хикмәткә тап булды ул. Өч самавыр юанлыгындагы бер каенны әллә давыл, әллә яшен төптән үк аударып салган. Түбәндәге озынлы-кыскалы чыралары күккә карап тырпаеп тора. Коры, шылтырап кипкән, кулың белән орындыңмы — зеңләргә генә тора. Вәт могҗиза: урманның да үз «мандолинасы» бар икән ләбаса! Нечкә чырымтаны чиртсәң, нечкә аваз чыга, калыны — калын тавыш белән җавап кайтара.

Кинәнде генә Фәрит урман мандолинасында уйнап! Үзе дә белеп бетермәгән өр-яңа көйләрне чиртте. «Әпипә»не өздергән чакта күбәләкләр гел аның тирәсендә бөтерелде шикелле.

— Ау-у-у!!!

Шәйхулла белән Фәрхетдин аның югалуын сизделәр ахры, әнә бит ничек итеп борчулы аваз салалар. Фәрит җилкәсенә аскан капчыгын янбашына таба шудырды да иптәшләре ягына элдерде. Элдерде дип әйтү генә ансат: чынлыкта исә шүрәле бармагыдай кәкре ботаклар күлмәктән янсә ыштан балагыннан эләктерә дә җибәрмәскә маташа. Кайсылары муенга ук үрелә башлады, исәпләре — кытыклап карау микәнни? Тукта, әгәр бу чынлап та шүрәленең үзе булып чыкса? «Әйдәле, тәти егет, кети-кети уйныйкчы бер»,— дип күлмәк чабуыңнан тарта башласа, чикләвегеңне биреп тә котыла алмассың!.. Нишләргә? Иң яхшысы — йөгерү, оят булса да, тизрәк Фәрхетдиннәр янына барып каплану.

Әнә шул йөгерү, кабалану харап итте дә инде Фәритне! Ниндидер черек төпкә абынды да гөрселдәп үлән арасына егылды ул. Берничә

тапкыр мәтәлчек тә атып алды. Ә иң хәтәре менә нәрсә: сыңар мөгезле шүрәле инде тәмам якын килеп җиткән, озын-озын бармакларын селкеткәләп баш очында тулгана.

Шунысы гаҗәп: шүрәле әнисе тавышы белән сөйләшә... Күрәсең, ул үзенең тавышын әллә ничә төрлегә үзгәртә ала дыр. Сикереп торды Фәрит, кычкырып елый-елый тагын алга ташланды. Берни аңламаган ике дус, кунак малайны шундый хәлдә күргәч, куркышып калдылар.

— Ни булды, елан чактымы әллә?

— Шүрәле... шүрәле күрдем...

Фәрхетдин инде сабакка йөргән, дүртенче сыйныфны бетергән малай иде. Фәритнең бу сүзләрен ишетүгә, кулы белән эчен тотып сыгыла-сыгыла көлә башлады.

— Эх син, камырсыз пәрәмәч! Урманда шүрәле була димени? Китапта гына язалар аны.

— Ипидер, күрдем...

— Яле, күрсәт шүрәлеңне.

Барып карасалар, Фәрит абынып егылган урында, корыган ботаклары белән күкне ермачлап, нибары карт шомырт агачы басып тора. Курыкканга — куш дигәндәй, шуның ботаклары шүрәле бармагы булып күренгән ләбаса...

## 5

Ул шомырт агачы исән микән? Кайтып, төпләренә ятып, эх, тагын бер тапкыр — бу юлы инде озак-озаклап күккә карыйсы иде! Әнә, шул ук күк, шул ук ботаклар. Кемнеңдер кулы белән үргәндәй итеп, күк йөзенә ябалдашлар челтәре ябышкан...

Тукта, бу күренеш нәрсәне хәтерләтә соң әле? Күтәрелеп карыйсың, күк йөзе бер үк зурлыктагы квадрат һәм ромбиклар белән бүлгәләнгән... Монысы — позицияләрне авиация күзеннән яшерү өчен тарттырылган җәтмәләр. Менә сиңа охшашлык!

Кинәт офыкны гүләү тавышлары күмде.

Офыкта — дошман самолетлары...

Лейтенант Яруллин рота командирының блиндажда әйткән сүзләрен исенә төшерде. Киләләр кабахәтләр, канатлары белән кояшны каплардай булып киләләр! Гүләү тавышлары отыры якыная, шомлы аваз дулкыны юлындагы барлык нәрсәне сытып-изеп, җир белән тигезләп нәкъ менә аның взводы өстенә килә кебек.

Безнең зениткалар күкне тарый: һавада тубал-тубал төтен йомгаклары кабына башлады. Эскадрильяның башында — кара свастикалы фашист бомбардировщиклары, аларның ян-ягында мессершмитлар. Шартлау дулкыны беренче бомбалар чыелдавын туфрак итеп өскә чөйде...

Зенитчылар ут өермәсен көчәйттеләр, шуңа булса кирәк, күтәреп килгән йөкләрен чама белән генә ташлап, бомбардировщиклар качу ягын чамалады. Ниһаять, икесенең койрыгына ут капты! Дөрләп янган самолет, корсагыннан кара тасма сүтә-сүтә, фашистларның үз ягына таба үкереп очты. Самолет кечерәя бара, ә менә күкне урталай телгән кара төтен тасмасы зурайганнан-зурая, койрыклы кометадай дуга ясап, җиргә якыная.

Мессершмитлар — җиңел сөякле, китәргә ашыкмыйлар. Аларның берсе, әтәчләнеп, рота өстенә атылды. Моторы һаваны түгел, ә бәлки баш миен һәм колакларны бораулый кебек. Бу иләмсез тавыш теш казналарына хәтле үтеп керә, теш сызлаганнан да яманрак итеп йөрәгеңне талый. Бу — янау авазлары лабаса! Кешелеккә, тормышка кизәнү тавышы. Әнә, баш күтәрергә дә ирек бирмәскә маташа. Арканңа баса-баса җир белән тигезләргә, сулышыңнан яздырырга тели. Янау —

ямьсезлек тавышы. Мәнә ни өчен ятышсыз, килбәтсез яңгырый ул. Шуңа охшашлы авазларның Шүрәле янавына да килеп керүе очраклы хәл түгел икән.

Музыканың янауга хакы бармы соң? Бетховенның сугышчан ноталары ничек туган? Бахның трагик моңнары нәрсә ул? Сораулар өермәсе янау тавышы белән якалаша, хакыйкатькә җавап эзли. Шул кыска арада Фәрит күңеленнән бер генә фикер ялтырап узды: тормыштагы авазлар музыкага үзе бәреп керә...

Тимер тырнакларын ыржайткан машина күкне кыйгачлап аска ташлана, траншея һәм окопларны пулемет уты белән чәрдәкли. Бу хәвефле мизгелдә гомереңне секундлар хәл итә: я калдың, я беттең дигән сүз. Бәхеткә каршы, пулемет уты Фәрит янәшәсендәге бруствер туфрагын гына теткәләп узды.

Өстеңә ябырылган самолетка күзеңне дә йоммый туры карау өчен зур егетлек кирәк. Куркудан телсез яки ихтыярсыз калуың да бик ихтимал. Баягы самолет, ничә кусаң да тешләшергә каны каткан кигәвен сыман, кабат әйләнеп килде, җиргә кадалырдай булып тагын аска ташланды.

Взводның иң оста мәргәне рядовой Козодоев бу юлы түзмәде, пулеметын самолетка каршы төбәде. Нәфрәт куркудан көчлерәк. Козодоев усалланып һаваны кистерде, бер айкау белән иптәшләренә дәрт, рух өстәде. Аңа карап башкалар да башын югарырак күтәрде, булачак бәрелешкә әзерләнде.

Самолет китеп югалды. Козодоев үпкәләгән кыяфәт белән пулеметын читкә тибәрде: шуны да булдырмадың, янәсе.

Аның кыюлыгын уртаклашудан Фәритнең маңгае тирләп чыккан иде. Маңгаен сөртә-сөртә артына борылып караса — кыр казлары кебек тезелеп безнең истребительләр килә! Тавышлары, һава ярып килүләре бөтенләй башка — үз, җанга якын. Әйе, җан тулы яктылык, ышаныч уята торган авазлар да бар шул әле дөньяда. Тормыш шуның белән матур. Әниләрнең: «Улым...»— дип йомшак кына әйтеп куюында никадәрле моң, колакны иркәли торган рәхәтлек! Аз гына игелек өчен дә кешеләр бер-беренә рәхмәт әйтә. Мәнә шундый чакларда рәхмәт сүзенең ягымлы яңгырашы йөрәгеңә сары май булып ята. Куаныч-шатлык килгән минутларда да кешенең тавышында мөлаемлык чишмәсе челтери башлый. Пышылдап кына әйтелгән ярату сүзләре исә тоташтан алсу моңга манчылган була...

Канатлы төркемгә ияреп, Фәритнең уйлары да әнә шулай оча иде.

Күктә кызыл йолдызлы самолетлар күренү белән сугышчыларның йөзе яктырды: безнекеләр дә йоклап ятмый, димәк!

Һава сугышлары башланып китте. Азагы ничек бетәсе дә мәгълүм булмаган кискен, кыска, рәхимсез бәрелеш. Утлы траектория сызып ядрәләр атыла, үкереп очкан самолетлар төрлечә әйләнеш ясап бер-берсен кысрыклый, юк итмәкче була. Бераздан хәл, чыннан да, үзгәрде: дүрт самолетларын югалткач, немецлар тәртипсез рәвештә чигенеп көнбатышка сыздылар.

Безнең яктан да югалту бар иде: көрәшнең соңгы минутларында бер истребитель утка чорналды. Аның очучысы сикерде сикерүен. Тик язмыш җилләре аны кая, фронт сызыгының кай ноктасына илтеп ташлады икән? Бәлки, Казан авиация мәктәбендә укыган егетләрнең берседер ул. Яруллин билгесез очучының язмышы өчен өзгәләнде.

Иң мөһиме: безнекеләр һава сугышында үзләренең өстенлеген күрсәтте. Димәк, көч безнең якта! Вак-төяк атышларны исәпләмәгәндә, фашист җәй буе ник бер тапкыр һөҗүм итеп карасын! Юкка дисеңме син моны, башларын югалтудан курка алар. Көрәштә кемдер җиңеп чыгарга тиеш. Сабан туенда да шулай бит: берьюлы ике батыр була алмый, кемдер — аста, кемдер өстә кала. Ләкин сугышның кануннары башка. Аста калдыңмы — ул сине сыта, тураклый, яшәү чутыннан сызып

ташлый. Сабан туенда исә батырлар көрәштән соң да аяк өсте басып кала, бер-берсен тәбрикләп елмая. Чөнки бу — яшәүне, иптәшлек һәм туганлыкны зурлау бәйрәме.

Сабан туе... Тыныч көннәрне юксынуданмы, кинәттән хәтергә төштең әле син! «Мин исән, мине туплар да вата алмый!» — дип аваз бирүеңне әллә...



6

Икенче бер вакыт этисе белән авылга сабан туе карарга кайттылар. Мең авазлы сабан туеның кызган, кайнаган чагы. Шома, биек колга башында чигүле сөлге җилферди. Халык, кулларын селки-селки кычкырып, көрәшчеләргә гайрәт бирә:

— Бирешмә, Гайфи!

— Калышма, Шакир!

Сөлгеләр билгә ята. Бер-берсенең ныклыгын сынарга теләгәндәй, батырлар кисәк-кисәк чүгәләп, йолкынып мәйдан тирәли йөренә. Куәт бөркелеп торган сак, сыгылмалы хәрәкәтләр. Шакир абыйсын таный Фәрит. Тегермәнче булып эшли ул, өреп тутыргандай тыгыз капчыкларны биеләй урынына чөеп кенә йөртә. Шуңа да мускуллары чүлмәктәй кабарып тора аның.

Батырлар инде тәмам арыган. Шуны чамалап булса кирәк, кызыл тасма бәйләгән бабай аларга хәл алырга куша, беләгенә элгән чиләктән һәр икесенә дә берәр йомырка суза. Фәрит йомырканы бал кашыгы белән сугып та көчкә вата, ә менә Шакир абыйны күр син: баш бармагы белән орынуы кая — йомырка кабыгы урталайга киселә дә төшә. Менә ничек эчә икән батырлар йомырканы!

Көрәш бара торсын, Фәритне бит барыннан да бигрәк җырлы-биюле уеннар, шау-шулы тамашалар кызыктыра.

Әнә, көрәш мәйданыннан бер читтәрәк яшь егетләр, яшь кызлар кулга-кул тотынышып «наза» уйный. Кызлар кулы тоткан егетләрнең авыз ерылган, борын күтәренке. Фәрит, кайда басып торганын да онытып, «наза» уйнаучыларны күзәтә башлады. Арадан кызларның кайсыдыр көчле, яңгыравык тавыш белән җыр башлап җибәрә, күмәкләшеп шуны җырлаганнан соң кара-каршы баскан сафлар чәчәк таҗыдай ачылып китә. Уен башындагы ялгыз егет сайлана-сайлана гына сафлар уртасыннан уза. Кемне алыр, чакырулы караш ташлап кайсы кызның беләгенә орыныр икән ул? Бирейдә бары тик үзләре генә аңлый торган серле караш, җыр, киная. Әнә бит урынында басып тора алмаган мут егеткә ни дип төрттерәләр:

Тимә чия агачына,
Чияләрен коярсың.
Кагылма кеше ярына,—
Үз ярыңны җуярсың...

Сабан туе гөли дә гөли, ярына сыймаган елга кебек дулкынлана, үзе тудырган моңнарда үзе үк тирбәлә.

— Уйна, Заһидулла кордаш!

Монысын кырык яшьләр тирәсендәге бер ир әйтә. Фәритнең этисе уртада йомылып кала. Бию көйләрен аннан да оста өздерүче тирә-якта юк икән. Этисе уйнаганда Фәритнең күзләренә яшь килә, бармак очлары кымырҗый башлый. Нидән бу, аңламассың. Кеп-кечкенә тальянның кай җиреннән шулкадәр дә тирән, күзләрдән яшь китерерлек моң чыга икән? Чылтырап аккан су тавышлары, ат дугасыннан коелган кыңгырау авазлары тарала кебек. Этисенең Казанда да еш уйный торган көе бит бу!

Чулпыларын чыңлата-чыңлата, чеметеп тоткан алъяпкычларын дәртле селки-селки кызлар бии...

Өйдә тагын бер шатлык көтеп тора икән аларны — әбисенең күрән сарыгы бәтиләгән! Кара, бөдрә тунлы, менә мин дөньяга килдем дигәндәй, шомырттай күзләре белән төбәп карап тора. Ул әнисен имгәндәге кыланмышларын күрсәң: нәни тояклары белән идәнне тыкырдатып үзенчә бер көй чыгара, өстәвенә койрыгы белән бертуктаусыз «дирижерлык» итә.

Яратты Фәрит бу тиктормасны, йомшакта йокласын әле дип, бөдрә кунагын мендәр өстенә үк күтәреп салды. Бу хәлне күргүгә әбисе әйтә куйды:

— И-и, улым, бәтине мендәргә салу килешмәс. Табигать баласы ул, аның урыны чирәмдә.

Бәтине идәнгә төшерделәр. Үпкәләмә, бәти! Ишегалдында син үзеңне иркенрәк тоярсың, инеш буендагы чирәмлекләр синең өчен теләсә кайсы мендәрдән дә йомшаграк булыр!

Чирәмле сукмаклар исә туп-туры болынга алып төшә. Андагы үләннәр биек, сусыл, хуш исле. Сузылып ятсаң, гәүдәң күренми дә! Бихисап үлән очлары кояшны иркәләп тора шикелле. Юк, кояш барыбер үлән сабакларын аралап өскә чыга, ачык яткан күзләреңә тула...

Дугада да озын булып үлән җитлекте. Окобыңа елышып ятканда биредәге үләннәр дә кояшны капларга тырыша кебек. Карыйсың: офыкларны үлән урманы каплаган... Араланып кояш чыгасы урынга үлән арасыннан нибары кара шәүләләр шуыша. Көнбатыштан авыр гөрелте ишетелә.

## 7

Офыкта тузан пәрдәсе пәйда булды.

Ышаныргамы-юкмы: чокыр һәм үләннәрне таптап, җәрәхәтле кырдаланы иңләп танклар ташкыны килә!

Колак төбендә сискәндергеч аваз чыңлый. Чыңлый-чыңлый да, әлегә берни булмаганны белгертергә теләгәндәй, күктә эленеп тора. Чалгы йөзедәй үткен бу авазны нигә безнең кырык бишле туплар челпәрәмә китереп ташламый икән, бәлки, җиңелрәк булыр иде. Юк, җиңеллек эзләргә ярамый, каршыда — рәхимсез чынбарлык, кешелек намусыңны сыный торган аяусыз бәрелеш.

Яруллин берничә адым атлау белән ике сугышчысы янына килеп җитте. Кырык бернең декабрендә Мәскәү яны сугышларыннан ук немецны куып килгән карт солдат Батаев күршесендәге яшь солдат Осипенкога нидер аңлатып маташа иде. Командир аның соңгы сүзләрен генә ишетеп өлгерде:

— Мин сугышның беренче көненнән бирле фронтта. Бернинди ядрәнең алганы юк әле, аллага шөкер. Курыкма, алга кара. Мать якасын фашистның!

Йөзеннән балалык чыгып бетмәгән рядовой Осипенко ПТРын[1] шундук алгарак чыгарып көйли башлады. Унсигез яшьлек бу егетне взводка моннан бер атна элек кенә пополнениедән китерделәр. Яруллин аны шундук үз итеп өлгерде. Моның җитди генә сәбәпләре дә бар иде, әлбәттә. Беренчедән, пополнениедән килгән яңа кешеләргә аерым бер игътибар кирәк. Ияләшсен, күрсен, өйрәнсен, шунда үзенең дә холкыфигыле ачылып китәр. Ә ул әнә тиз арада үзенең ихлас күңелле, көрәшкә омтылучан икәнлеген күрсәтеп тә өлгерде. Икенчедән, һәм монысы тагын да мөһимрәге, Осипенко Украинадан иде. Үз гомерендә бер тапкыр күргәне булмаса да, күңелендә Фәрит Украинага карата аерым бер мәхәббәт йөртә. Сөеклесе Галина Киевта туып-үскән, укыган, театрда артистка булып эшләгән аның. Декада әзерлек уңае белән килгән жиреннән Казанда торып калды ул...

[1] ПТР — танкка каршы ата торган мылтык.

Менә ни өчен украин егетеннән туганягы, туган авылы турында сөйләтү кызыклы һәм рәхәт иде Яруллинга. Кызганычка каршы, Киевны ныклап күргәне юк икән аның. Эвакуация вакытында поезд белән узып киткәннәр китүен, ләкин төнлә кай җирен күреп өлгерәсең ди шәһәр тикле шәһәрнең. Аның каравы Осипенко поселок буендагы күмер шахталары һәм терриконнар турында мавыгып сөйләде. Азактан, ачыш ясагандай, әйтеп куйды:

— Терриконнар нәкъ менә пирамида инде! Сугыш кырында да терриконнар бар икән — Осипенко кулы белән бомба чокырларына ишарәләде.— Тик алар йөзтүбән капланган һәм җиргә баткан пирамиданы хәтерләтә...

«Күзәтүчән егет икән бу»,— дип уйлады командир үзалдына елмаеп.

Болары — биш-алты көн элек булган хәл. Уен эш түгел: ә бүген Осипенконың чын сугышта беренче тапкыр чирканчык алуы.

— Гранаталарны әзерләргә. Дошманны үткәрмәскә!

Дошман танклары траншея сызыгына ук килә калса дип, эчкә уеп ясалган борылышларга запас гранатометчиклар да куелган иде.

Колак төбендә тагын кайтаваз чыңларга кереште...

Маскировкаларны чөеп ташлап, безнең танклар корыч ташкынга каршы китте. Моторлардан чыккан төтен рәшәсе, чылбыр асларыннан күтәрелгән тузан арасында менә-менә башланачак бәрелешнең кайнарлыгы, дәһшәте төсмерләнә. Һава сугышлары, гадәттә, тиз тәгәлләнүчән. Ә менә җирдәге бәрелешнең кайчан, ничек бетәсен тәгаен генә әйтеп бирү шактый кыен эш.

Башланды! «Кырык бишле» туплар гөрелтесенең беренче дулкыны фашист танкларына килеп бәрелде. Фәрит берьюлы ике танкның дөрләп яна башлавын күрде. Маяга ярап тора бу! Хәзер инде шуны мөмкин кадәр ишәйтергә, үрчетергә кирәк.

Дошман үзенең тимер тараны белән оборона сызыгын бер ыргымда өзеп ташламакчы иде. Ләкин безнең танклар аларның юлын буды, рәтләрен чуалтып ташлады. Сугыш кырының уртасында кара баганалар тасмасы арткannan-арта — ике яктан да югалтулар күп. Кара-каршы кисешкән атышлар, тимергә-тимер бәрелгән тавышлар, утлы өермә сулышы тоташ бер оран булып баш өстендә тирбәлә: дан-доң... дан-доң... Күкнең кайсыдыр төшендә бу юлы инде чын-чынлап гигант айбалта эленеп тора шикелле. Гүя, кемдер шуны туктаусыз борчып тора, чаң урынына кага! Шуның кайтавазы тешкә суга, колак пәрдәләрен кыса, төтен һәм тузан булып күзләрне кисә.

Сул флангтагы безнең бер танк алдында снаряд шартлады. Ягулык багын чәрдәкләде булса кирәк, аның тимер гәүдәсенә шундук ут капты. Экипаж членнары люктан чыгып килә. Молодцы, пехотадан ике сугышчы ярдәмгә ташландылар, киемнәренә ут капкан танкист сикерә-бәргәләнә җиргә ятып ауный. Аны ут әсирлегеннән ничек кирәк алай коткардылар шикелле.

Күктәге авыр айбалта чыңына металл һәм чылбырлар чыкырдавы кушыла...

Тимер силуэт булып кинәттән каршыда танк шәүләсе калыкты. Тузан һәм төтен пәрдәсенә ышыкланып килде микәнни, ничек күрми калганнар аны? Маскировка өчен ясалган чуар таплары-ние белән йөзеп, кубарылып, җирне тырный-тырный егетләр яткан траншеяга килә. Фәрит гранатасын әзерләгән арада күз кырые белән генә егетләренә карап алды. Окоптан каскасы калыккан Осипенконың мылтыгы аваз бирде. Тимәде! Фәритнең гәүдәсе пружинадай җыерылып килде — танкны каршылар алдыннан кешене һәрвакыт шундый бер киеренкелек биләп ала.

Осипенко тагын курокка басты. Шул ук секундта командирның күзләрен каршыдагы яктылык көлтәсе бер мәлгә сукырайтып алды. Яна

башлаган немец машинасыннан автомат аскан кара шәүләләр сикерә иде. Кыска очередь аларны кисеп кенә төшерде.

Рядовой Осипенконы күр син: бруствер өстенә менеп баскан да кулларын селти-селти сикерә — үзенең сугышчан шатлыгын дөнья белән уртаклаша:

— Ура! Беренче танк!

Карт солдат Батаев түзмәде, Осипенконы киредән окопка тартып төшерде. Ләкин ирен читләрендә елмаю: Осипенконың бу җиңүендә үзенең дә беркадәр өлеше барлыгын искәрергә тели шикелле.

Яшь солдатның беренче җиңүе! Үз гомерендә беренче тапкыр дошман танкысын җимерүе. Килер вакыт: бәлки, Осипенконың күкрәгенә беренче орден тагарлар... Беренчеләр һәрчак истәлекле була, хәтергә уелып кала.

Фәритнең тормышында да азмы булды «беренче тапкыр» дип сөйләрлек вакыйгалар! Беренче тапкыр буденовка кигән минутларын да яхшы хәтерли ул. Беренче тапкыр сәхнәгә чыгуы да шунда булды ич. Дөрес, уйнар өчен түгел, әтисенә ияреп кенә...

Хәтер җебенең бер очы Казан урамнарына барып ялгана. Келтер-келтер... келтер-келтер... Мостовой ташларын келтерәтеп, ярымачык арбада әтисе, тагын ике музыкант һәм бер малай бара...

## 8

Извозчик аларны Казан читендәге хәрби казармага илтеп куйды.

Кызыл Армиянең акларга каршы көрәшкә китәчәк бер часте икән бу. Часовой, әтисе күрсәткән документларны карап чыкты да, винтовкасын җайлый-җайлый, кемнедер көтәргә кушты. Аннары күн фуражкасында кызыл йолдыз янып торган зифа буйлы, көләч командир кунакларны зур гына соргылт бинага алып керде. Үзенә күрә клуб икән бу. Рәт-рәт иске урындыклар тезелгән, сәхнә шикелле мәйданчыкның бер почмагында фортепиано да бар.

— Репетиция ясый торыгыз,— диде командир көр тавыш белән һәм, бер читтә нишләргә белми басып торган Фәритне күргәч, эре-эре атлап аның янына килде. Саф татарча итеп исемен сорады. Фәрит югалып калды, исемен әйтүе дә бик көчсез, юаш килеп чыкты. Йолдызлы абый чүгәләгән килеш кенә дәү куллары белән Фәритнең аркасыннан сөйде:

— Минем энекәшкә охшагансың син, вәт нәрсә! Гармунда уйнаган була ул. Син дә сыздырасыңдыр әле, шулай бит?

Фәрит күзләрен йомып кына баш селекте. Шушы кыска сөйләшү, биленә каеш буган командир абыйсының үз итеп каравы күңелен әллә нишләтте дә куйды.

— Пәрдәсе юк икән моның, Заһидулла,— диде мандолинада уйный торган музыкантларның берсе сәхнә алдына ымлап.

— Син, Гарифҗан, борчылма. Кешедән яшерен эшебез юк ич безнең.— Әтисе шулай дия-дия тальян гармунын күн капчыктан чыгара башлады.

Тиздән залга шау-гөр килеп кызылармеецлар кереп тулды. Гимнастерка өстеннән каеш буганнар, кулларында винтовка. Тирләп чыгу һәм еш-еш сулыш алуларына караганда, бер-бер житди эш белән шөгыльләнгән болар. (Яшь чырайлы, әмма тәвәккәл йөзле Осипенко менә кемнәрне хәтерләткән икән аңа...)

Сәхнәдә музыкантларны озата килгән командир күренү белән ялан-баш зал тынып калды. Командирлары кулын селки-селки бигрәк тә матур, тәэсирле итеп сөйли:

— Ихтыярый кызылгвардияче иптәшләр! Революция дошманнары иске тәртипләрне яңадан кайтарырга маташа. Ләкин бу барып чыкмая-

чак! Кызыл Армия соңгы тамчы канга хәтле сугышырга әзер. Колчак Казанга якынлашып килә. Кайчандыр Ленин укыган шәһәргә. Ләкин без шәһәрне Колчак этләренә бирмәбез! Шулай бит!

Залдагылар бердәм рәвештә: «Шулай!» — дип кычкырдылар, кемдер буденовкасын өскә чөйде.

— Ә хәзер сезнең алдыгызда... халык музыкантлары ансамбле чыгыш ясый!

Әтисе артка таралган чәчләрен кулы белән сыйпап алды да фортепиано каршына килеп утырды. Ике музыкант исә курай һәм мандолина белән «Иске карурман» көенә кушамалык итә. Тирән моң белән башланып киткән бу көйне Фәритнең берничә тапкыр тыңлаганы бар. Хәзер исә ул тагын да ныграк тәэсирләнде, күңелен шом һәм моңсулык биләде. Күз алдына җай гына чайкалган карурман килеп басты... Акларның отряды әнә шунда гына посып торадыр да, мена-менә өскә ташланыр шикелле. Хәер, нигә куркып калырга әле, мылтыклы кызылармеецлар каршыда гына утыра лабаса...

Көй тәмам. Залдагылар тамашаны дәррәү алкышлый, «молодцы!» дип кычкыра. Әтисе иптәшләренә кушылып баш ия, шул хәлендә чигенә-чигенә гармунына таба бара, кулына тальян ала.

Концерт беткәч сугышчылар тагын бер кат озаклап кул чаптылар. Әтисенең гармунда да, мандолина һәм фортепианода да бердәй матур уйнавына сокланды Фәрит, горурлык хисләре кичерде. Музыка тыңлаганнан соң әнә ничек шатлана, канатлана халык! Үскәч, һичшиксез, музыкант булырга! Шушы якты, яшерен хыялын Фәрит түкми-чәчми генә Казанга алып кайтсын әле менә...

Алгы рәттә утырган командир җәһәт кузгалып тагын сәхнәгә күтәрелде.

— Кызылгвардияче иптәшләр! Кунакларга тагын бер кат рәхмәт белдерик! Революция исеменнән үзебезнең менә шушы истәлекне дә бүләк итик. Аны булачак яшь музыкантка кидерәбез!

Командир соңгы сүзләрен әйткәндә йолдызлы, озын колакчынлы буденовка Фәритнең тузгак чәчле башына менеп кунаклаган да икән инде. Баш киеменнән борыны гына күренеп торган яшь «музыкант»ны мандолиначы Гарифҗан абый кулларына тотып югары күтәрә.

Фәритнең үзенә күрә беренче тапкыр «сугышчы» булып караган тантаналы минутлары бу!

Казанга кичкә таба кайтып төшәләр. Кичке чәйдән соң бераз ял иткәч, әтисе кулына тальян гармун ала, Фәритне үз янына чакырып китерә. Әниләре күршедә. Менә шундый чакларда мавыктыргыч музыка дәресе башлана. Әтисенең кулында тальян тәмам тере бер кошка әверелә, очына, талпына, сыгылмалы хәрәкәтләр ясый, канатларын бер ача да бер яба. Өстәге эре, җиз сәдәфләренә хәтле сикереп-сикереп куя аның. Ә уникe теле, миңа бас, миңа дигән шикелле кызыктырып, бармаклар астында биешә. Нәкъ кызылармеецлар клубындагыча!

— Күрәсеңме, бармакларны сыгылмалы тотарга кирәк. Юкса бер телдән икенчесенә күчкәндә моңга зәгыйфьлек килә.

Гармун инде Фәритнең тез башларына сикереп төшкән. Әтисенен киңәшләрен колагына салганнан соң малай тальянның көмеш телләренә баса башлый... Ах, никадәрле могҗиза: шушы нәп-нәни бармаклар хәрәкәтеннән билгесез бер көй агылып чыксын әле!

— Матурлык иң элек күңелдә туа, улым. Аннары гына дөньяның олы матурлыгына кушыла ул...

Әтисенең сүзләрен ир уртасы булып килгәндә дә онытмый Фәрит.

*Аның күңеле матурлык эзләүдән гыйбарәт иде. Матурлык кешегә алга бару, биеккәрәк күтәрелү өчен кирәк. Тормышның беркайда да язылмаган якты законы әнә шулдыр. Илдәшләрең белән уртаклашсаң, үзең тапкан матурлык меңгә, миллионга тапкырлана...*

...Фәрит сугыш кырын күзәтә. Осипенконың брустверга сикереп менүендә матурлык чалымнарын күреп гаҗәпләнгән иде ул. Бу тойгыны шартлау авазлары да күмеп китә алмады. Сугыш дәвам итә. Бусы ни тагын? Сокланудан Фәритнең күзләренә яшь килде. Әнә, санитарка Валя яралы танкистны сугыш кырыннан сөйрәп алып чыкты! Пилоткасына сыешмаган чәчләре йөзенә таралып киткән. Плащ-палаткасын сугышчылар күтәреп алгач та иелә-иелә танкистның хәлен кайгыртты ул. Гап-гади бер кыз кеше гомерен саклау, озайту өчен көрәшә... Күр әле, шушы тикле мәхшәр эчендә дә матурлыкка урын бар икән!

## 9

Далада кургашындай авыр, ямьсез тынлык урнашты.

Кеше күңеле ямьсезлекне күтәрергә тиешме соң? Әле кайчан гына корыч әзмәвердәй үрмәләгән фашист танклары туктап калды, үлде, шлак булып катты. Тирә-якта көйгән-актарылган туфрак, корымланып янган танк мәетләре...

Сугыш кыры — шартлау, вәхшәт, ямьсезлек иле. Күңел боларның берсен дә кабул итәргә теләми. Ләкин нишлисең, матурлыкның яшәр урынын коткару өчен кеше барысына да түзәргә тиеш.

Сугышчылар маңгай тузанын кул аркасы белән сөртә-сөртә солдат паегыннан авыз итәләр, бүгенге көн вакыйгалары турында үзара сөйләшәләр. Исәннәр яши, сулый, шатлана, кайгыра. Шулай, тормыш дигән нәрсә, яшәү өчен кирәк булган бөек хәрәкәт бернигә дә карамый дәвам итә.

Кешене әйтәсе дә юк, табигать яраткан үләннәргә чаклы бернинди утка, хәвефкә карамыйча яшәргә, фәкать яшәргә-үсәргә ашкынып тора! Әнә, былтырдан калган арышларга хәтле тишелеп чыккан да инде башакка өлгергәннәр. Болар инде быелгы арыш. Сугыш табигатьне дә яралый: чәчелмәгән иген кырында яралы арышлар. Алар тирбәлгәндә башаклардан нindирәк моң чыга икән? Бәхетсез, кайгылы, гарип моңдыр, бәлки?

Табигатьтә җәй, июль башы. Шуңа күрә Фәритнең күңелендә дә җәйге хатирәләр. Кинәттән күзенә чалынган ялгызак арышлар аңа туган ягын, Татарстан кырларын хәтерләтте, Кече Сөн һәм Кырлай урманнарын исенә төшерде. Әллә ничек шунда ауный-ауный ятып елыйсы килә. Тик күзеңә карап торган сугышчылар алдында килешәме соң! Мондый чакта иң яхшысы — уеңны бүтән юнәлешкә борып җибәрү.

Яруллин траншея стеналарына караш ташлады. Инде ничәмә кат күрелгән, ә шулай да караган саен өр-яңа хикмәтләр ачыла. Күр, чын мәгънәсендә геологик катламнар түшәлгән биредә: туфрак, ком, кызыл балчык... Иң өстә яткан уңдырышлы кара туфракта җылылык, кешеләр белән тугандашлык мәгънәсе бар кебек. Ком катламы тотрыксыз, таралучан, соры бер дулкын рәвешендә сузылып киткән. Кызыл балчык исә тыгыз, авыр, картларча уйчан күренә — аңардагы шушы төсмерләрне, мөгаен, фагот һәм контрабас ярдәмендә тасвирлап булыр иде. Мезазой катламнары, ерак дәвернең билгесез моңнары прессланып килгән...

Бүгенге мәхшәрне кичеп тә исән калган чикерткә җырында киләчәктән тылсымлы хәбәр бар шикелле!

Траншеялар — уйлар шикелле озын, чиксез, бормалы. Исән генә йөреп кайтсын — сугышны, вәхшәтне, аналарның күз яшен һәм җимерек шәһәрләрне үз күзләре белән күргән композитор Фәрит Яруллин явызлыкка, фашизмга каршы симфония иҗат итәчәк. Шул ук вакытта совет халкының фронттагы героикасын чагылдырган опера язу турында да хыяллана ул. Сугыш тынып торган араларда аның зиһенен, хыялын шушы ике теләк чорнап ала, тойгылары фәкать шушы дулкында кай-

ный. Тыгызланып килгән хисләренең бер өлешен кыр сумкасындагы дәфтәренә дә төшерде төшерүен, ләкин болар — диңгездән бер тамчы гына. Муса Җәлил... Ягымлы, хәрәкәтчән күзләр, эчке ныклык белән беркетелгән дәрт, омтылыш. Менә кем язар ул операның сүзләрен!

Фәритнең күңеленнән илһамлы минутлар йөгереп узды...

Траншея бүрәнәләре, кечерәеп, пианино клавишларын хәтерләтте. Берәүнең дә башына килмәслек мондый күзаллаулар, әрнүле җәрәхәтсаташулар — музыкадан башка яши алмау галәмәте, әлбәттә. Әле кайчан гына оборона ныгытмалары кору өчен урман кискән иде алар. Ял вакытларында Фәрит төркемнән читкәрәк китү җаен карады. Аның өчен ял — иҗат вакыты, музыкаль гимнастика дәресе өчен менә дигән мөмкинлек иде. Яңа гына киселгән агачларның сырлы-бөҗралы төбе — гүя патефон тәлинкәсе. Аңа Фәрит хыялындагы симфониянең кайсыдыр өлеше язылгандыр шикелле. Бармакларын агач бөҗралары өстәндә биетәбиетә үзе иҗат иткән көйләрне уйный, тыңлый, йөрәге аша уздыра ул.

Аккордлар! Оркестр өзгәләнә, тирә-юньгә нәфрәт һәм нәләт моннары тарала...

Аккордлар! Агач төбендәге эзләр-бөҗралардан җиңүгә, килер көнгә ышаныч тантанасы саркып чыга...

Җилкәсенә кемнеңдер җиңелчә кагылуыннан гына айнып китә Фәрит. Караса — рота командиры өлкән лейтенант Куралев икән. Рота командиры өчен аның подразделениесендә солдатлар, сержантлар, кече командирлар гына бар иде шикелле. Музыкантларны һәрвакыт сәхнәдә, скрипка һәм рояль артында гына күреп өйрәнгән яшь Куралев ул чакта исә үзенең ротасында яңа бер шәхес — Мәскәү консерваториясен тәмамлаган татар композиторы Фәрит Яруллин барлыгын ачты.

Сугышта шундый хәлләр дә була икән.

Фәрит, урман егу көннәрен хәтерләп, үзалдына елмаеп куйды. Аннары икенче бер күренешне исенә төшерде. Шәм шикелле төз, озын нарат бүрәнәләр. Шуларны яр буена әрдәнәләп өеп куйганнар. Сагызлы бүрәнә башлары тулган ай кебек балкып ята. Менә сиңа ай тавы — бүлешә башласаң, һәркемгә җитәрлек! Агыйделдән сал булып агасы бүрәнәләр өеме икән бу. Якын килеп, бүрәнә башларын тотып-тотып карады Фәрит. Сырлы-сырлы, тылсымлы бөҗралар — еллар тамгасы икән. Берсеннән-берсе кечерәеп эчкәре таба бара-бара да бүрәнәнең нәкъ урта бер җирендә нокта белән тәгәлләнә.

Монысы — балачакта Уфа пристанендә күргәннәре.

## 10

Таяну ноктасы диләр. Агачның таяну ноктасы шулдыр, бәлки? Дөньяга яралу белән туфракка таяна ул. Кинәттән үсеп, калкынып китә. Кеше дә шулай: туган туфрагына таянып үсә, орчык кадәрле малайдан каһарман булырдай ир-егеткә әверелә. Аның да күңелендә бөҗрадай тыгызланып еллар эзе кала.

Шул «бөҗра»ны сүтеп кенә җибәр, каршыңда үткән көннәр сәхифәсе ачыла.

Фәриткә ул чакта тугыз яшьләр чамасы булгандыр. Әтисе үзенең гаиләсе белән Уфа шәһәренә күчеп килде. Алар Никольский урамындагы ике катлы агач йортның өске катында яши башладылар.

Фәриткә иң ошаганы Агыйдел һәм Дим буе булды. Бәйрәм көннәрендә халык көймә һәм пароходларга төялеп сәхрәгә чыга, сулар гизеп йөри. Гәҗит кисәге җәеп яр буена утыр да рәхәтләнеп күзәт, тамаша кыл бәйрәмне. Ак пароход өсләрендә кызыл әләм җилферди, чәчләрне кытыклап. Дим ягыннан бәйрәм җиле исә. Я, моңардан да ямьлерәк, ләззәтлерәк ни булырга мөмкин тагын! Балачакның бәйрәмнәрне күңеленә аерата якын кабул итүен дә истә тотсак, бәхет менә шушы кояшлы, көләч көннең үзе төслерәк буладыр инде ул.

Көймәләрнең кайсына хәтта самавыр да алганнар. Башы кәкрәйтеп ясалган калай торбадан каз мамыгыдай җиңел төтен күтәрелә. Табын да корып җибәргәннәр, дөньяның тәмле ризыклары шундадыр, дип уйлый торгач, төкрегеңне йотып җибәргәнне сизми дә каласың.

Дим өстендә курай, гармун, җыр авазлары яңгырый. Курай дигәннәре бигрәк тә моңлы икән, болай да очынырга торган күңелне әллә кайларга ияртеп алып китә...

Чү, монысы нинди кирәкмәгән шау-шу тагын? Малайларның хыялы шундук чирәмле ярга әйләнеп кайта. Берәрсе ялгыш хәрәкәт ясады микәнни — көймә читендә утырган гармунчы егет тальяны-ние белән суга капланып төште. Менә сиңа мә! Нишләргә? Гармунчыга ярдәм итү малайлар кулыннан килә торган эш түгел — бердән, ерак, икенчедән — юньләп йөзә дә белми ич алар.

Бәхеткә каршы, көймәдәгеләр су өстендә түбәтәе йөзеп йөргән егеткә ярдәм кулы сузалар. Тигезле-тигезсез айканудан көймә чайкала, бер якка янтая. Суга батучыны коткару — казалы эш икән ләбаса! Ярый, ниһаять, көймәгә тартып менгерделәр аны, ә менә гармуны белән нишләргә соң? Ул инде, әлбәттә, нык чылангандыр, эченә су кереп тулгандыр, телләре яраксыз хәлгә килгәндер. Бу егет һәм аның иптәшләре җан дустың булырдай тальянны бер дә кадерли белмиләр микәнни?

Бик кызганды Фәрит гармунны. Әгәр көченнән килсә, бу егетләрне беркайчан да су гизәргә чыгармас иде ул.

...Вакыты җиткәч, Фәрит сабакка йөри башлады.

«Агамалы Гали углы» дип аталган бу татар мәктәбенең исеме үк кызыклы иде. Хикмәт исемдәмени, иң мөһиме — сабакташ дусларың яхшы булсын да, дәресләр күңелле үтсен. Бәхет басты Фәритне: Әхмәт исемле дусты кесәсеннән бер чикләвек чыкса да һәрвакыт урталай бүлеп ашый, Хәсән исемлесе еш кына рояльдә уйнарга өйләренә кунакка чакыра.

Җыр дәресеннән укыткан мөгаллимгә табигать бөтенесен кызганмыйча бүләк иткән: скрипкада уйнау, көйнең теләсә кайсы җиреннән башлап китү, җырларның килеп чыгу тарихын сөйләү дисеңме — менә шуларның һәммәсен дә бөтен шартына җиткереп башкара иде ул. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нәкый Исәнбәтнең кайбер сүзләргә басым ясый-ясый дәртле итеп сөйләвендә үзенә күрә илаһи бер тылсым, сихер бар. Аның Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич кебек «тере» шагыйрьләрне якыннан күреп белүе, үзенең дә шигырь һәм хикәяләр язуы — малайлар өчен соклангыч өлге, буй җитмәслек абруй.

Әдәбият дәресләре — музыка шикелле үк, сине биеккә күтәрә, тылсым дөньясына алып керә. Тукайның «Шүрәле»се матур әкият икәнлеген Фәрит инде аңлап укый, шигъри ләззәт кичерә. Ә менә шүрәленең рәсемен ясап карасаң, ничек булыр икән? Чиста кәгазь битен кәкре-бөкре сызыклар белән чуарлый Фәрит, урман сарыгына озын бармаклар, сыңар мөгез, кәкре борын ясый. Ясый-ясый да үз-үзеннән оялып куя: шүрәленең «ш» хәрефенә дә якын килмәгән, әллә нәрсәкәй ич бу! Чү, Нәкый абыйсы Фәритнең чит эш белән шөгыльләнгәнен күреп тә алган ләбаса...

Ачуланыр дип көткән иде Фәрит, әмма мөгаллим кәгазьдәге сурәткә көлемсерәп карап торды-торды да дәшми генә кара тактага таба юнәлде. Такта йөзлегендә акбур шыкылдаганы ишетелде... Сызды-бозды, фокусчыныкыдай җиңел, күз иярмәс хәрәкәтләр белән мөгаллим ә дигәнче тактага шүрәле рәсемен ясап куймасынмы! Һәммә җире Тукай язганча — осталык дисәң дә ярый моны.

Көннәр, ничек тәгәрәп туса, шулай тәгәрәп уза да торды.

Фәрит башта үзлегеннән, аннары этисе ярдәмендә рояльдә уйнарга өйрәнде. Иске генә саргылт бу рояль өйнең түр почмагына урнашкан иде. Менә шуңарда сәгатьләр буе уйный Фәрит, күзләрен йомып уйный — әйтерсең, нидер эзли, киләчәгенең сукмак очын табарга тырыша ул. Этисе улына карап соклана, башын кыңгыр салып нindider тирән

уйларга бирелә... Тагын да алга китү өчен чын педагоглардан өйрәнергә, махсус музыка мәктәбендә укырга кирәк малайга. Әмма Уфада андый мәктәп юк...

— Улым, сиңа, һичшиксез, ары таба укырга кирәк.

Әтисе бер ноктага озаклап төбәлгән җиреннән кинәт сикереп тора, кулларын Фәритнең җилкәсенә сала. Бөтен холык-кыяфәтендә — канатлану, нинди зур бер эшне хәл итәр алдыннан гына була торган очкынлы караш.

— Телисеңме, кире үзебезнең Казанга китәбез. Анда сәнгать техникумы бар, шунда укырга керерсең...

Казан! Бала чагы үткән таш кала, Проломный урамнары, Ташаяк ярминкәләре белән кайнап торган газиз шәһәр. Бәләкәй Апуш пар атта ничек килеп кергән булса, уналты яшьлек Фәрит тә хыялындагы пар атларда әнә шулай дәртләнеп, рухланып аяк басачак үзенең туган каласына!

## 11

Ниһаять, Фәрит — Казан музыка техникумы студенты...

Берьюлы виолончель һәм фортепиано классларында уку шулкадәр үзенә бөтереп алды ки, хәтта ишегалдындагы яшьтәшләре белән футбол тибәргә дә вакыты юк аның. Моның өчен тамчы да үкенми Фәрит. Музыка дәресләрен, бәрхет тавышлы виолончельне һәм яңгыравыклы фортепиано авазларын дөньядагы беренинди рәхәтлеккә дә алыштырмас иде ул. Яшьлекнең зуррак, биегрәк максатлар белән янарга тиешлеген аңлаганнан бирле үзе дә кинәт зураеп, җитдиләнеп китте соңгы вакытларда.

Әтисенең шәкерте булган Салих Сәйдәшев әсәрләрен көннәр буе уйнарга әзер ул. Казанда, чынлап та, «йолдыз»ларның иң балкыган чагы: музыкаль сәхнәдә — Салих Сәйдәшев, театр сәхнәсендә — Фатыйма Ильская, шигърият трибунасында — Такташ белән Туфан. Мәдәният учакларын беренче чиратта шулар нурлый, шулар балкыта да инде.

Яшьләрнең ТРАМ [1] дип аталган беренче театры... Спектакльләр барышында Фәрит триода уйный. Менә шунда йөри башлагач, әллә нәрсә булды да куйды аңа — ашавыннан язды, виолончельдә уйнаган җиреннән кирәкмәс урында туктап кала, сөйләшкәндә кайчак иптәшләрен дә ишетми. Шуның аркасында кичәгенәк тә уңайсыз хәлдә кала язды.

— Фәрит, Фәрит дим!

— ...

— Фәрит, ни булды сиңа? Сөйләшми дә башлаган, кайнар бәрәңге йоттыңмы әллә?

— Ә?

— Кыланышың кырга сыймый, мәйтәм.

Театрда кәмит рольләрне уйнаучы эшче егет Хәкимҗан икән. Күренеп тора: тәнәфес арасында сөйләшеп, эчен бушатып аласы килә егетнең. Аулаграк почмакка дәшүе бер дә бүтән түгелдер.

— Фәрит, син бит сер тотасың, име? Менә нәрсә, парин, минем озатып йөри торган кыз тиктомалдан кәҗәләнә башлады бит.

— Ничек тиктомалдан?

— Шулай. Кичә Тукайның «Шүрәле»сеннән интермедия куйган идек. Мин шүрәле булып уйнадым. Әмма ләкин үз башыма кыланганмын икән. Үзе дә шүрәле бит ул, дип иптәш кызлары кушамат такканнар миңа. Кызыйга җитә калган, сырты белән борылды да куйды.

Фәрит сүзсез генә елмаеп җибәрде.

— Киңәш бирче, нишләргә икән?

[1] ТРАМ — эшче яшьләр театры (театр рабочей молодежи).

Тапкан кешесен! Хәкимҗанга киңәш бирер егетме соң Фәрит? Үз хәле хәл: спектакльләрдә һәрвакыт баш рольләрне уйный торган Хәмидәгә үлеп гашыйк булган чагы аның. Беркөнне клуб буфетына керергә ризалатты Хәмидәне. Пирожки һәм кайнар чәй белән сыйлады үзен. Кызның зур, кара күзләре ифрат та матур, төнге йолдыздай серле иде. Ике якка тарап ачылган чем-кара чәчләренә нибары бер тапкыр кагылу өчен генә дә ярты дөньяны бирерсең. Ул тавышы дисеңме — берүзендә әллә ничә оркестр моңнары! «Таня» спектаклендәге яшь врач Таня образын шундый итеп башкара, залда тын алырга кыймый утыралар. Кыскасы, Хәмиданең үзенә дә, уйнавына да муеннан гашыйк ул.

Чәйне озаклап, тәмләп эчтеләр, икесенә дә күңелле булды. Фәрит, барлык кыюлыгын җиеп, бүген кич озатып куярга мөмкинме, дип сорады Хәмидәдән. Кызның керфекләре дерелдәп куйды, кызарынды, аннары гына түбән карап әйтте:

— Соңга калдың, минем егетем бар шул инде...

Ике буш стаканны күтәреп торган өстәл, әйтерсең, кинәттән чайкалды, кул астыннан шуып чыкты. Фәритнең әйтер сүзе калмаган иде. Менә шул чакта авыл кызларының «наза» уйнагандагы әллә кайчангы җыры хәтеренә төште аның:

Тимә чия агачына,
Чияләрен коярсың.
Кагылма кеше ярына,—
Үз ярыңны җуярсың.

Ах, авылның беркатлы күренгән хәйләкәр, зирәк кызлары! Еллар узгач та сез аяк очларына басып кына кайчангыдыр кунак малайга, хәзер инде егет булып килгән Фәриткә тагын бер кат шушы җырны җырлыйсыз, мәхәббәт эшендә гадел булырга өйрәтәсез...

Хәкимҗанга боларны ничек сөйләсен ди Фәрит? Кем тыңласа да кычкырып көләчәк, җебегән син, дип әйтәчәк. Шуңа күрә ачылып китмәде Фәрит, бармакларын язган булып торды-торды да җавап кайтарды:

— Ә син ашыкма. Бәлки, аның сынап каравыдыр?

Хәкимҗанга бу җавап ошады булса кирәк, мә бишне, дип кулын учка сукты да яшел пәрдә арасына кереп югалды. Сәхнә идәненә кадәр агылып төшкән пәрдә берьюлы селкенеп куйды: әйтерсең, бер-берсен куышып, яшел дулкыннар йөгерешә.

## 12

...Дуганың җиденче көне.

«Цитадель» операциясе барып чыкмады! Прохоровка юнәлешендә — утыз, Поныри юнәлешендә нибары сигез чакрым эчкәре кергәннән соң немецларның хәле мөшкелләнде, хәрби җегәре күзгә күренеп какшады.

Атна буе оборона сугышлары алып барганнан соң совет гаскәрләре бөтен фронт буйлап контрһөҗүмгә күчте. Сәгать ярымлык артхәзерлектән соң инде ничә ай траншея һәм окоп эчләрендә яткан пехота, ниһаять, бөтен буйга тураеп басты, куәтле «Ура!» тавышлары астында дошманга ташланды.

Бу — җәядәй киерелгән Курск дугасының да тураеп басуы, Берлин йөрәгенә төбәлгән укларын барлап, хәрәкәткә китерүе иде.

Ниһаять, иркенлеккә, кыр-дала киңлегенә аяк бастылар. Сау булыгыз, үзенә сыендырган, дошман күзеннән яшергән, һәртөрле һәлакәтләрдән саклаган траншея борылмалары! Сездә башланган героик симфониянең дәвамы көнбатышка күчә...

Фәрит, йөгереп барышлый, снаряд чокырларын әйләнеп узды. Автоматлы, каскалы, кызыл йолдызлы пехота атакага бара. Сафлар дулкын-дулкын булып йөгерә. Йөгергән уңайга аяк астындагы җир артка

таба шуыша кебек. Муенга җил сарыла. Солдатның һава ярып баруында никадәрле теләк, мәгънә, омтылыш! Алга бару — үзе бер матурлык.

Взвод алдына кичтән үк сугышчан бурыч куелган иде. Рота командиры приказны кат-кат аңлатты: «Беренчесе — Н. авылын дошманнан азат итәргә. Икенчесе — елганы кичеп плацдарм яуларга һәм шуны, өстәмә көчләр килгәнче, ике сәгать буе кулда тотарга!»

Картадан күренгәнчә, Н. авылы биредән сигез чакрым ераклыкта. Алар кичәргә тиешле елга исә авылдан дүрт километр арырак.

Заданиене үтәү өчен иң элек немецларны алгы траншеялардан бәреп чыгарырга кирәк. Миналар кырының кайсы участогында «коридор» ясалган — моны һәркем яхшы белә. Төнлә саперлар кадап калдырган билгеләр нәкъ рота командиры әйткән урында иде. Таң алды сыеклыгында коридорны хәвеф-хәтәрсез генә кичтеләр. Менә шул чакта кинәт немецларның пулеметы телгә килде!

Немец хәйләкәр кылана иде: сугышчылар тукталдымы — ул да туктый, кузгалсалар — шундук һаваны тураклый башлый. Автоматтан гына ала торган түгел — ераграк. Командирның рөхсәтен дә сорап тормастан, снаряд чокырыннан ефрейтор Килдуразов үрмәләп чыкты. Кулында — граната бәйләме. Утыз метр чамасы үрмәләп барганнан соң Килдуразов кинәт туктады да күкрәген тотып хәрәкәтсез калды... Ах, фашист бәдбәхетләре, мушкага алып та өлгерделәр!

Взводның язмышы — үлем куркынычы астында. Алга барырга өмет киселде дигән сүз. Яруллин теләсә нинди минутта да салкын кан белән эш итә торган Батаевка ым какты. ПТР белән дигәнне сүзсез дә аңлаган солдат авыр мылтыгын төбәп атып җибәрде.

Күрәсең, шартлау арткарак эләкте, пулеметның ажгыруы басылмады.

Ни сәбәпледер соңарып, сул флангтан безнең пулеметчы да ут ачкан иде. Батаев фашистның җиде бабасын суганлап-борычлап искә алды да икенче тапкыр курокка басты. Бу юлы осталык мизгеле аның кулында иде: немец пулеметы котырган урында көчле шартлау күтәрелде.

Взвод яңа бер ыргым белән траншеяга якынайды. Яраланучылар кайсы тын гына, кайсы ялварып шәфкать туташын көтә. Килдуразовны әйләндереп карады Фәрит, аның йөзендә үкенечле мәгънә уелып калган иде. Зур һөҗүмнең беренче минутларында ук үлеп калу нинди кызганыч! Дөньядагы әйбәт егетләрнең берсе иде ул юкса.

Автомат тавышлары барабан тарылдаганны хәтерләтә. Немецлар траншеясындагы каскалы соры күләгәләр инде аермачык күренә, ядрәләр сызгыруы ешая.

— Ятарга!

Фәритнең тавышын җил өзеп алды. Командирдан күреп, сугышчылар да түмгәккә, снаряд чокырына ышыкланып дошман белән каракаршы атыша башладылар. Кул гранаталарын бәрү өчен, ах, тагын йөз метр чамасы җир узарга! Ләкин шул араны узу сират күперен кичү белән бер булачак — менә нәрсәне барлык күзәнәге белән тоя Фәрит. Үзе генә булса, бер хәл, аның бит ике яклап сузылган канаты — утнысуны бергә кичкән, инде тәмам йөрәгенең яртысына әверелгән взводы да бар ич әле.

Кичә Яруллин Осипенконың сыкранып, күңелсезләнеп бер читтә басып торуын күргәч, яшь солдат янына килде.

— Син нәрсә болай үзгәрдең? Ни булды?

Осипенко уңайсызланып китте, сыкрануын җиңәргә тырышып әйтте:

— Иптәш лейтенант, кирза итекләрнең зурысы эләккән миңа. Үкчәне кырды...

Чыннан да, кирза итекләренең зурлыгын күрер күз белән дә чамалап була иде. Тик моны Яруллин ничек алданрак күрмәде икән? Командир, старшинага егетнең итекләрен алыштырырга күрсәтмә биргәннән соң, Осипенкога әйтә куйды:

— Җебемә... Мондый кыяфәт килешми сиңа, егетем. Бик кыен вакытларда мәҗбүри елмаерга өйрән син. Шундук үзгәреп, эчтән яктырып китәсең андый чакта.

Күз тимәсен, бүген әнә Осипенкода төшенкелекнең эзе дә юк...

Фәрит офыкка карады. Кызыл «каскалы» кояш, окоптан калыккан солдат шикелле, мәгърур генә күтәрелеп килә иде.

13

Каршыдарак кына борыны калҗайган, бер як чылбыры сыдырылып төшкән «тигр» калкынып тора. Фашистның гомере шушында төгәлләнгән, димәк. Фәрит шуыша-шуыша танк ышыгына үрмәләде. Биредән ату ышанычлырак, хәлне чамалау да күпкә җиңелрәк иде. Осипенко да, сирәкләнеп калган үләннәрне урый-урый, командирга таба шуыша. Гитлерчыларның уты дәррәү көчәеп, аларны яңадан җиргә яткырды. Каракаршы атыш байтак дәвам итте.

Фәрит иренен чәйнәде, ачу белән гранатасын капшап куйды. Бушка очкан ядрәләр кызганыч — аны бит тылдагылар сукыр атыш өчен түгел, фашистның явыз йөрәген чәрдәкләү өчен атап койганнар лабаса!

Ут сирәгәеп калган арада лейтенант тагын алга шуышты. Уң флангтагы берничә сугышчы да туп-туры траншеяга таба үрмәли иде. Аларның иң алдагысы беренче гранатасын томырып та өлгерде. Бу хәлне күреп торган сугышчыларга кинәттән дәрт керде. Менә ул озак көттергән, югалтулар бәрабәренә яулап алынган хәлиткеч минут! Бер генә секундны да кичектерергә ярамый!

Командир, «атакага!» дигән мәгънәне белдереп, автоматын өскә күтәрде. Шушы рухландыргыч хәрәкәт төрлечә сибелгән сафларны гүя берьюлы кузгатып җибәрде! Кайта-кайта яңгыраган «ура»! тавышлары астында взвод немецлар траншеясына якыная иде...

Тимерчыбык киртәне дә сикереп уздылар...

Үлем яңгыры астыннан исән чыккан сугышчылар траншеяга бәреп кергәч тә гаҗәпләнеп калдылар: гитлерчылар соңгы минутта күтәренеп качып киткәннәр икән, тоткарлау өчен үзәктә бары ике пулеметчы калдырганнар. Әнә, берсе исән. Соры гимнастеркасы тәтенгә ыслану, тузан-туфракка буялу нәтиҗәсендә тагын да ямьсезләнеп сорыланган. Йөзендә — искитмәле туңлык, битарафлык. Бары авыртудан сыкрану билгеләре генә аның адәм баласы затыннан икәнлеген әйтеп тора. Мөгаен, «смертник»лар мәктәбен узгандыр бу. Әнә бит, үзенең сукыр фанатизмы белән соңгы минутларда гына безнең ничә сугышчыны һәлак итеп ташлады.

Бу бәндәнең башына нинди уйлар да йөрәгенә нинди кичерешләр хуҗа икән?

Яруллин немец телен вата-җимерә булса да әсирдән фәкать бер нәрсә хакында сорады:

— Син Бетховенны беләсеңме?

Немец башын селекте, «найн» дип җавап кайтарды. Белми, ишеткәне дә юк. Ә бүтәнчә булу мөмкинме соң? Ата фашист, бәлки, әллә кемнәрнең музыкасын тыңларга яратадыр, әмма солдатларын ул башкача рухта тәрбияләгән, сукырларча табынырга өйрәткән, аларга кан һәм үлем белән эш итү миссиясен йөкләгән. Германия, шушы хурлыклы көннәреңнән азат булыр сәгатең ерак микән синең?

Лейтенант немецка җирәнү катыш кызгану хисләре белән карады һәм, алыгыз дигәнне белдереп, ым какты. Сугышчылар тиз арада траншеяның ике ягына сибелделәр: бу тынлык артында хәйлә-мазар посып тормагае...

Суынырга өлгермәгән автоматлар тагын алга төбәлде.

Немец траншеялары урыны-урыны белән тәмам теткәләнеп беткән иде. Снаряд чәрдәкләгән бүрәнәләр, чалкан авып төшкән гәүдәләр, туфрак астыннан тырпаеп торган фашист итекләре... Җимерекләрне лейтенант күрми узарга тырышты, бу урыннан тизрәк ераклашасы килә иде аның. Ләкин безнең артиллерия нык һәм төгәл бәргән: тагын җимерекләр, тагын фашист каскалары...

Ниндидер сәер тынлык. Командир ике сугышчысына өстән барырга боерды һәм траншея стенасына таяна-таяна алга таба хәрәкәт итте. Шулвакыт алда немец блиндажы күренде. Аның ишегендә ак җаймадән ертып ясалган ак әләм шәйләнә. Нәрсә бу, провокацияме? Әллә берәр өлкән офицерның чынлап та әсир төшәргә теләвеме? Таякка беркетелгән әләмне сугышчылар да күреп алдылар, автоматларын алга төбәгән хәлдә, әмер көттеләр.

Блиндаж эченнән немецча кычкырган тавыш ишетелде. Ярты минут уздымы-юкмы, кулларын өскә күтәргән гитлерчы үзе дә күренде. Күзлекле, озын буйлы, интеллигент чырайлы немец солдаты иде ул.

Сугышчылар каушый-каушый нидер әйтергә теләгән әсирнең ниятен тиз чамаладылар. Фәрит соңгы сүзләреннән аның художник икәнен аңлады. Бу мәхлүк җан сугыштан туйган, кан кою һәм каршылык күрсәтүнең мәгънәсезлеген соң булса да аңлаган, күрәсең.

Арада немец солдатының әнә ниндиләре дә бар икән. Тик моңа кадәр кылган гөнаһларыңны кая куярсың да, үлгәннәрнең катгый хөкеменнән ничек котылырсың икән син? Бәлки, Гитлерның рәсемнәрен ясап көн иткәнсеңдер әле... Әллә алар җырын «җырламаганга» күрә алгы сызыкка ташладылармы сине?

Мотор тавышы ишетелүгә, барысы берьюлы артка әйләнеп карадылар. Траншея алдына килеп туктаган безнең Т-34 башнясыннан шлемлы танкист җиргә сикерде. Килә-килешкә кобурасыннан пистолет тартып чыгарды да якыннан гына немец солдатына атып җибәрде. Бу шулкадәр тиз арада булды ки, әгәр Фәрит ярсулы танкистның кулына кагылып өлгермәсә, әсир солдат траншея төбенә авып төшәчәк иде.

— Тукта!

Каршындагы лейтенантның кычкыруыннан танкист бермәл югалып калды, ләкин үзен бик тиз кулга алды. Аның маңгаеннан-гөрләп тир ага иде.

— Тапкансыз кызганыр кеше! Барысын да теге дөньяга озатырга кирәк аларның. Ә сез, иптәш лейтенант, юкка гуманист булып маташасыз.

Сугышчылар ике командирның кайсын якларга белми аптырашып калдылар...

## 14

...Бөтен барлыгы белән тоя Фәрит: бер адым алга атлаган саен Украина җиренә, Киевка таба якыная алар. Сәгать унике — көн уртасы. Хәзер Мәскәүдә Кремль курантлары сугадыр. Мәскәү йокламый, көнетөне фронттан яхшы хәбәрләр көтәдер.

Мәскәүнең кинәт кенә шулай искә төшүе гаҗәпмени? Фәрит биредә биш ел консерваториядә укыды, музыка серләрен үзләштерде, үзенә яңа дуслар тапты. Ул көннәрне онытырга мөмкинме соң!

Шагыйрь Әхмәт Фәйзи белән бирегә тагын да якыннан дуслашып китте ул. Мәсьәләне тоткан җиреннән өзә торган Муса Җәлил дә алар янына еш килә, киңәш-фикерләрен уртаклаша. Фәрит Яруллин белән Нәҗип Җиһановның киләчәгенә аеруча өмет белән карый иде ул.

Фәрит яраткан, хөрмәт иткән кешеләрдән тагын берсе — профессор Генрих Ильич Литинский иде. Уртача буйлы, җиңел хәрәкәтле, игътибарлы һәм таләпчән бу профессордан дәресләр алган саен шуңа ныг-

рак ышанды Фәрит: кеше күңел хәзинәсен башкалар белән күбрәк уртаклашкан саен үзе дә югарырак күтәрелә, башкалар каршында дәрәҗәлерәк була бара икән.

Бервакыт алар арасында мондыйрак сөйләшү булды.

— Беләсеңме, егетем, карап-карап торам, синдә яхшы мәгънәсендәге үҗәтлек зур.— Профессор утырган килеш кенә фортепиано корпусына таянган хәлдә сөйләшергә ярата иде.

Фәрит моны үзе дә чамалый, тик бу хакта остазының авызыннан ишетү әллә ничек уңайсыз кебек тоелды.

— Бездәге уку программасы синең өчен таррак. Теория белән генә чикләнмичә, практик дәресләрне ешрак үткәрербез. Опера һәм балет әдәбиятын дәреслекләр аша да укып, өйрәнеп була. Ә минем киңәшем: аларны сәхнәдә килеш күрергә тырыш, күз һәм колак икесе берьюлы күбрәкне эләктерә...

Шуны истә тотып, Фәрит театр һәм концертларга ешрак йөри башлады.

Чайковскийның «Аккош күле» балеты аны тәмам сихерләде, чиргә сабыштырды...

Бетховенның Тугызынчы симфониясе концертыннан кайтышлый чак кына трамвай астына эләкми калды...

«Кеше менә нинди могҗизалар эшли ала икән!» — дигән соклангыч фикергә килде ул.

Өч-дүрт ел эчендә Фәрит байтак җырлар, романслар, инструменталь әсәрләр язды. Тик менә башлаган симфониясен һәм «Зөлхәбирә» операсының беренче пәрдәсен һич тә төгәлли алмый ул: көче, тәҗрибәсе җитми, күрәсең. Бәлки, бер үк вакытта «Шүрәле» белән җенләнүе дә комачау итәдер? Тукайның соклангыч әкиятен музыкада гәүдәләндерәсе килә аның. Киңәшкән, бәхәсләшкән чакта дуслары да бу фикерне хуплыйлар, Фәриткә өмет баглыйлар. Әсәрнең тулаем планы өлгереп җиткәнче үк Фәрит Былтыр атлы егетнең урманга утынга килү күренешен язарга керешә.

Әхмәт Фәйзи, дустының иҗади нияте белән якыннан танышкач, елмаеп куйды һәм белдекле кыяфәттә әйтте:

— Сюита да, чуртым да түгел бу, дускаем. Сизәсеңме, үзеннән-үзе хәрәкәтләр сорап тора. Балет чыгачак синең бу фантазияңнән!

Шул кечне мәсьәлә хәл ителде дә куйды: балетның либреттосын Әхмәт Фәйзи язачак, вәссәлам!

Бернечә төн йокламый газапланганнан соң күңелдә балетның төп идеясе яктырды: «Алга барырга, биеккәрәк күтәрелергә!» Утыр да яз гына — кешелек бәхете өчен көрәш турындагы әсәрнең моңнары инде дулый, үзенә мәйдан сорый.

## 15

Биеккәрәк күтәрелү өчен кеше алга барырга тиеш. Алда һәркемне хыял, өмет, башкарасы эшләр көтеп тора. Алга бару — үзе бер матурлык!

Сугышта төрле хәлләр була. Озын-озын походлар кичкәндә кайчак тәмам аяктан егылыр дәрәҗәгә җитәсең. Оборона вакытларында исә гел бер рәвешлерәк яшәү солдатның канын суыта башлый. Атакага бару — бөтенләй башка! Солдатның иңнәренә, әйтерсең, канат үсеп чыга. Шушы канаты гына исән булсын — аны инде берни дә туктата алмаячак. Итекләр һәм снаряжение җиңеләя, беләкләргә гайрәт тула. Шулай булмыйни, Туган илне азат итү хисенең иң кайнар, иң күтәренке чагы бит бу.

Алга барырга!..

Күр әле, никадәрле тәңгәллек: сугыш башлангач та балетның идеясе Ватан язмышына, авторының шәхси тормышына ук бәреп керде. Кешелек бәхете өчен көрәшә-көрәшә Фәрит үзенең взводы белән алга бара...

Берничә чакрым җир узганнан соң дошманның икенче оборона сызыгы күренде. Немецлар, югалту ачысына буылып, бу полосада коточкыч каршылык күрсәтергә керештеләр. Пехотаның тирә-ягында дошман миналары ешрак ярыла башлады. Күңелсез, ачу китергеч хәл иде бу. Әнә, сул флангтагы безнең бер танкка ут элеп тә өлгерделәр! Ләкин танк очып барган факелдай барыбер алга ыргылды һәм траншеядагы расчетларны тимер чылбыры белән тураклый, изә башлады. «Канга — кан, үлемгә — үлем!» Сугыш көннәрендә туган шушы лозунгның дөрли-дөрли януы, үч дәһшәтенә әверелеше иде бу...

Сугышчылар автоматтан ата-ата траншея эченә сикерделәр. Кул сугышы башланды. Өстенә ташланган гитлерчыны Фәрит көч-хәл белән аска егып салды, янәшәсенә килеп баскан Батаев тегене автомат белән шундук тынычландырды. Хәлнең мөшкеллеген аңлап, немецларның күбесе аралашу юлларына ташланды.

«Өченче!» — дип кычкырды яшь солдат Осипенко утка чорналган фашист танкысына күрсәтеп. Ләкин шундук кулбашын тоткан хәлдә җиргә сыгылып төште. Яруллин, санитарка Валя белән бер үк вакытта диярлек, Осипенко янына килеп җитте. Күкрәктән өстәрәк, сул як кулбашы яраланган егетнең. Шул урында гимнастеркасына күгелҗем кан табы бәреп чыккан. Әле кайчан гына үкчәсен кирза итек кырганга да еламсырап торган Осипенконы танырлык та түгел: ул бернигә дә игътибар итмәстән елмаерга азаплана, нәрсәдер әйтергә җыена:

— Иптәш командир... кыен чакта... мәҗбүри елмаерга... өйрәнеп кенә килгәндә...

Ярасы авыр иде, күрәсең, санитарка кыз ихтыярына бирелеп, Осипенко сүзсез калды. Ә күзләрендә никадәрле теләк, мәгънә, үкенеч чаткылары яна!

Әллә нәрсә булды Фәриткә: тез буыннары йомшады, тел очындагы сүзләре әллә ничек калтыранып чыкты. Аның гәүдәсе буйлап, әйтерсең, әллә ничә тармаклы яшен берьюлы узып китте...

Кыен булды украин егете Осипенко белән саубуллашу. Фәрит өчен ул — хатынының туган ягын, Украинаның җанлы бер кисәген тәшкил иткән сердәш, арадашчы иде ләбаса. Күңел тынычлыгы иде... Әгәр ядрә килеп тимәсә, инде сугышчан чыныгу алган Осипенко фашистларның Рурда коелган байтак танкларын туктаткан булыр иде бу көннәрдә. «Хәзергә сау бул, Осипенко! Тизрәк терел, кайчан да бер күрешербез, бәлки...»

Бүген сугышчылар дошманны җиде чакрым куып бардылар. Н. авылына якынаер алдыннан кич тә җитте. Үзәк Россиянең җылымса төне арыган-талган сугышчыларга, ниһаять, ял алып килде. Кыр кухнясы соңару сәбәпле, котелоклар гына буш тора. Менә монысы аяныч хәл иде...

Взводын барлаганнан соң Фәрит йодрыкланып килгән кулы белән йөзен каплады: өчәү үлгән, Осипенкодан кала тагын икәү җиңелчә яраланган иде. Шунаргамы, сугышчылар артык кычкырып сөйләшмәделәр, шаяртмадылар, һәркем үз эше белән мәшгуль.

Әтисенә исәнлек хәбәре саласы иде дә бит, тик менә караңгылык куерды, күк гөмбәзендә бихисап йолдызлар шәмдәле кабынды. Иртәгә башкарырмын дип, бу эшен ул таң яктысына калдырды, часовойларын кисәтеп куйды.

Бер-берсенә сыенышып солдатлар йоклый.

Шүрләве булдымы, әллә төнге разведка борчыдымы аны — немецлар ягыннан берәү автоматын тырылдатып алды.

Күзгә йокы керми, әйтерсең, тән организм ихтыяҗы белән исәпләшми торган машинага әверелгән. Тагын да гаҗәбрәге — төн карасын телеп, кайсыдыр куаклыкта сандугачлар сайраша башлады. Менә сиңа концерт! Сугыш тынлыгы уртасыннан ишетелгән бу илаһи аваз атыш һәм шартлаулардан колагы тонган сугышчыларга могҗизалы тәэсир итте. Һәрхәлдә, Фәриткә шулай тоелды. Сандугач бернинди үлемнең, шарт-

лауның да яшәүне туктата алмаячагы, тормыш утының беркайчан да сүнеп калмавы хакында өздереп сайрый иде. Флейта өлгесен кешегә сандугач бүләк иткәндер, мөгаен: әнә бит, мажор бизәкләрнең, борылышларның һәркайсында шуның моңнары...

Табигатьнең бу могҗизасын фашист солдаты да тыңлый микән? Россиянең гап-гади бер авылына кереп йомылган фрицлар ни уйлый икән хәзер? Төн сандугачының очынып-очынып сайравы, мөгаен, ачуын гына китерәдер аларның...

Чиратлап-чиратлап кына көн дә килә торган бу кичләр бер-беренә ни дәрәҗәдә охшаш икән? Көйне җаның теләгәнчә кабатларга мөмкин, ә менә төннәр кабатланамы? Юк дияр идең, нигә соң бүгенге төн һәм аның сандугачлары әтисенең туган ягын искә төшерә дә үзәкне өзә?

Тукта, төнге җил, исми тор! Фәрит гомеренең рәхәт бер көнен ашыкмый гына хәтереннән уздырсын әле.

## 16

...Җәйге көн, июль урталары. Кырларда мең тугыз йөз утыз сигезенче ел икмәге өлгереп килә. Кайчандыр кунак малай булып йөгергән юллардан Фәрит әтисенең туган авылына — Кече Сөнгә кайтып төште. Бу юлы да кунакка. Тиң казык башында әлсерәп утырган берән-сәрән чүлмәкләр, тыкрык-койма читәннәре егетне танымады. Ул, чыннан да, башка иде шул: аякта елтыр ботинка, өстә «шәһәрски» күлмәк-чалбар, дулкынлы калын чәч артка таба кайтарылып төшкән. Кулда да букча-мазар ише генә түгел, почмаклары каймаланган кибет чемоданы.

Әтисе студент улын озаклап кочаклады, артка чигенә төшеп таза, сөйкемле егетне тагын бер кат күздән кичерде. Башын чайкый-чайкый, бик күрсәтми генә дымлы керфекләрен сөртеп тә алды бугай әле. Нәрсә иде бу? Якты юлдан атлаучы баласы өчен горурлыкмы, әллә Уфа һәм Казан шәһәрләрендә яшәгән чакта бергә-бергә нужаны да байтак татыган улының язмышына ышанып җитә алмаумы? Икесе дә бардыр, мөгаен, ни әйтсәң дә байтактан күрешкәннәре юк ич аларның.

— Улым, син бөтенләйгә түгелдер ич? — Ир уртасы Заһидулла бу сорауның урынсыз икәнлеген белә торып, сүзне каян башларга аптырагannан әйтеп ташлады.

— Күпкә түгел, әти. Ике атна торам да китәм.

— Азрак икән шул. Бу Мәскәүләр тәмам каптырган икән үзегезне.

— Үзебез дә нык каптырабыз, әти. «Шүрәле»не төгәлләп киләм менә.

Әтисе Фәритнең иҗат планнары белән хат аша яхшы таныш иде, шуңа күрә булачак балетның яңа бүлекләре турында сорашты, хуплау хәрәкәтләре ясый-ясый бүлдерми генә улын тыңлады.

— Хәтерлисеңме, әле кайчан гына урманнан шүрләп кайткан идең. Инде хәзер шүрәленең үзен биетергә чамалыйсың, ә?

Әтисенә кушылып, Фәрит тә рәхәтләнеп көлде, балачак дуслары Шәйхулла белән Фәрхетдинне исенә төшерде. Тик менә алар икесе дә әллә кайчан авылдан читкә чыгып киткәннәр икән.

Музыкант кешенең гаилә тормышы мәшәкатьле булгандырмы, әллә Фәрит белеп бетермәгән башка сәбәпләр дә бардырмы — әтисе белән әнисе инде байтак еллардан бирле бергә яшәмиләр иде. Фәрит үги әнисен кичкә таба гына күрә алды: Хәнифә исемле бу ана нәкъ шул көнне Мәскәү студентына энекәш алып кайтты! «Кендек әби»нең сөйләшүеннән Фәрит энекәшенең чәчләре чем-кара икәнлеген генә аңлап калды...

— Заһидулланың Мәскәүдә укый торган улы кайткан!

Бу хәбәр тиз таралган, күрәсең, ул көнне йорт бусагасын атлап керүчеләр байтак булды. Бер күрешү өчен атап кергәннәр, хәл-әхвәл сорашалар, бар белгән киңәшләрен әйтеп калырга ашыгалар. Фәрит

этисенең авылдашлары белән урамда, кырда, су буенда да очрашты, аларның төрле-төрле сорауларына җавап бирде. Ә күңел кичне, ялгызлыкны көтә! Менә шул чакта гына беркемнән тартынмый уйланырга, табигатьтәге авазлар чалымын тыңларга мөмкиндер шикелле...

Кичен ул ишегалдына чыгып күктәге йолдызларны күзәтте, ай яктысында коенган алмагачларның тылсымлы серләшүен тоемларга тырышты. Болар бар да талгын хәрәкәт, табигатьнең үзе генә белгән моңнар кочагында йөзүе иде. Менә шул чакта өздереп-өздереп сандугач сайрарга кереште. Әйтерсең, кунак егет хөрмәтенә адажио башкара! Ул да түгел, авыл уртасында гармун тавышы, егетләр җыры яңгырады. Гармунның өзгәләнүе авыл өсләтеп кенә ага-ага да йолдызлар тарафына китеп югала шикелле. Әйе, авылның күге тулы — моң, туфрагы тулы — хикмәт, чишмәсе тулы — сихәт икән...

Аннары Фәрит өйгә керде.

Учакта ялкын бии, казанда су җылына. Мич каршына утырган этисенең күзләрендә ут шәүләсе яктырып-яктырып китә. Моңсу серле, уйчан күзләр бу. Аларда нинди яшен чагылып уйнаганын, нинди моңнар кайнаганын Фәрит аңлый да, аңламый да шикелле.

Самавырга күмер салырга кирәк. Этисе күмер кыскычын таба алмагач, ялангач кулы белән казан астына үрелеп утлы күмер чүпли башлый. Кузлы күмерләрне учтан-учка сикертә дә самавыр морҗасына ташлый. Ул бу эшне шулкадәр җиңел, тыныч башкара, әйтерсең, кулларында күн пирчәткә аның...

Икенче көнне Фәрит урманнан бер төргәк яшел ылыс күтәреп кайтты.

Кунак егеткә атап, авыл мунчасы ягылган иде. Андый мунчаны тагын кайчан күрерсең икән? Идәнгә яшел ылыс җәелгән — кайнар су койган саен урман исе бөркелеп чыга. Әрем катыш кычыткан кыстырылган каен себерке — җилләнеп селтәнгән саен җәйге хуш ис тарала. Тамагың кипте исә мунча болдырында сине әчкелтем әйрән көтеп тора. Менә кайда ул дөньяның рәхәтлекләре!

Ә инде Хәнифә апасының майда йөздереп пешергән коймагыннан, карлыган яфрагы салып пешергән чәеннән дә авыз иткәч, Фәрит авылга тәмам гашыйк булды, хәтта студент икәнлеген онытып җибәрде.

Кошлар ничек канат кагынса, вакыт та шулай җитез хәрәкәтләнә икән. Фәритнең китәр чагы җиткән иде. Соңгы минутта Мирсәет исемле кечкенә энекәшенә яратып, үз итеп ягымлы караш ташлады да саубуллашып чыгып китте. Бу — ике туганның беренче һәм соңгы күрешүе дип берәү дә уйламагандыр, әлбәттә.

Этисе Берсутка кадәр озата барды. Җәйнең бүгенге шикелле җиләс, тымызык көннәре иде бу. Офыкта толым-толым каурый болытлар. Менә аларны җил әкрен генә сүтә башлый, алмашка кибән-кибән кадәрле болытларны куып китерә. Күк белән җир бер-беренә һаман саен ныграк якыная, дөньяга басынкылык иңә...

Лейтенант Яруллинның талчыккан керфекләре дә бер-беренә тәмам якыная, төнге чәчәктәй йомылып китә...

## 17

— Иптәш лейтенант!

Күз кабакларына тыгыз булып болытлар бөялгән, шуңа күрә керфекләрне һич кенә дә селкетеп булмый. Ә күзләрне ачарга кирәк, чөнки кемдер йомшак тавыш белән һаман бер үк сүзләрне кабатлый, кузгалырга куша...

Часовойның командирны уятуы икән бу. Күзгә йокы чүбе кергән, һич кузгалыр әмәл юк. Яруллин плащ-палаткасы кочагыннан сикереп торгач кына йокы артка чигенде, офык артына төшеп югалды. Офык алланган, яңа көнне башлау хәстәре белән тулышкан. Бик вакытлы

уятканнар, каядыр еракта көн саен йотылып фронт хәбәрләрен тыңлаучы әтисенә һөҗүм башланганчы хат язып өлгерәсе бар аның.

Ак кәгазь бите буйлап каләм йөгерә. Фәритнең хисләре, язасы сүзләре каләм очыннан туп-туры дәфтәр битенә агыла иде: «Без зур һөҗүмгә күтәрелдек, әти. Кичә дошманны җиде чакрым куып бардык. Фашизмның көннәре санаулы калып бара. Эх, тизрәк бетерәсе иде бу кырылышны! Юкса асыл егетләрне тартып ала сугыш. Күңел һаман тыныч көннәрне сагына. Тегермән буасына төшкәлисеңме? Яр буйларын быел да сары чәчәкләр күмгәндер шикелле. Буада балык уйныйдыр, урманда кура җиләге пешкәндер — шуларның һәммәсен кайтып үз күзләрем белән күрәсем килә...»

Кайчандыр ишеткән хикмәтле сүзләр кинәттән Фәритнең хәтерен яктыртты. Имеш, ерак юлга сәфәр чыгасы бер егеттән сорыйлар:

— Әниеңнең ризалыгын алдыңмы?

— Алдым,— ди егет,— мин аны җилкәмдә килеш күтәреп Хаҗга кадәр алып бардым.

— Синең бу эшең газиз әнкәңнең бер ачы тулгагына да тормый. Ата-анага гомер буе хөрмәт күрсәтсәң дә таман,— дип җавап кайтара ил картлары.

Бик тә мәгънәле, хикмәтле сүзләр. Әнисе тапкан, күкрәк сөтен биреп үстергән, дөньяның иң зур рәхмәтләре яусын аңа. Ә менә әтисе улының кулларына тылсымлы ачкыч тоттырды, музыка дигән могҗизалы дөньяның уртасына хәтле озата килде, кешеләргә кулыннан килгән хәтле яхшылык эшләргә өйрәтте. Бүгенге көндә Фәрит сәнгать баскычларының югары бер ноктасында басып тора икән, ул үзенең барлык уңышлары белән беренче чиратта әтисенә бурычлы. Тик менә әтисенә әйтәсе рәхмәтен әйтеп, күрсәтәсе кадер-хөрмәтнең бер өлешен булса да күрсәтеп өлгердеме ул? Ә ил каршында үтисе, йөрәк һәм акыл эше белән түлисе бурычлары тагын күпме аның?

Өч почмаклы солдат хатын бөтен шартына китереп бөкләгән вакытта командир-композиторның күңеле аша шушы олы мәгънәле, тынгылык бирми торган гамь-сораулар ташкыны узды. Хәерлегә булсын, бүгенге көн нигәдер моңсу, сагышлы башланды.

Һөҗүм алдыннан гаҗәеп бер тынлык булып ала. Бүген дә шундый хәл иде: кичәге сөрем таралган — офыклар карандаш белән сызгандай аермачык беленеп тора, табигать тын гына йоклый, туар көн мәшәкатьләрен җигелеп тарту өчен хәл җыя. «Шылт» иткән аваз да юк, әйтерсең, кичәгенәк бу җирдә рәхимсез сугышлар булмаган.

Солдатлар, команда булганны да көтмичә, уяна башладылар. Гәүдәдәге киеренкелекне җиңү өчен сугышта кайчак ярты минут та җитә. Менә-менә атака башланыр чакта ни җаның белән йоклап ятмак кирәк! Син йоклаган арада әллә нихәтле үзгәрешләр булгандыр, әнә шуларны күрми калгансыңдыр шикелле тоела башлый.

Каршыда — Н. авылы. Приказны үтәргә: бернигә дә карамый авылны фашистлар кулыннан тартып алырга кирәк бүген!

Июль. Күкрәп торган җәйнең көз каршына таба кузгалыр чагы якынлашып килә. Шуны сизепме, ул үзенең үләннәренә — ныклык, чәчәк орлыкларына тыгызлык биреп калырга ашыга. Бусагада — август. Табигатьнең уйланыр, акыл җыяр чагы. Агачларда беренче сарылык төсмерләнер вакыт.

Моннан ике ел элек тә табигатьтә җәй тантанасы иде. Җирдә әле сугыш юк, вакыт үзенең авырлыгын тыныч көннәр бәясе белән үлчи иде. Ул чакта кешеләр августны аеруча дәртләнеп көттеләр. Чөнки 1941 елның августында Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре үткәреләчәк иде. Ул чакта декада турындагы хәбәрне ишетүдән дә зур куаныч булды микән?

18

Бу хәбәр Фәритне аеруча канатландырып җибәрде! Газаплы һәм ләззәтле төннәрдән соң «Шүрәле»нең каралама хәлендәге клавиры тәмамланып килә иде. Казан, җиң сызганып, декадага әзерләнә. Ә шуңа кадәрле Фәритнең тормышында тантаналы вакыйга булды: аны Композиторлар союзына кабул иттеләр! Өстәвенә, союзның Музфонд оешмасы Фәрит Яруллинга зур суммада акча бүлеп бирде: менә сиңа ярдәм, эшеңне тизләт, диделәр.

Студиянең худсовет утырышы, ниһаять, «Шүрәле» балетының музыкасын тыңлап карау, аның художество үзенчәлегенә бәя бирү өчен җыйналды. Тыңладылар, утырыш өстәле тирәсендә беразга сәер тынлык урнашты.

— Моңа кадәр безнең музыкабызда күренмәгән новаторлык бар әсәрдә,— диде берәү соклануын белдереп.

— Новаторлык бар барын, тик мондый «мөгез чыгару», традицион рамкаларны җимерү халыкка аңлаешлы булыр микән соң? — дип сорау ташлады икенчесе.

— Чыннан да, милли колоритның аз икәнлеге үзен сиздерә. Миңа калса, бу әсәрдә татар көйләре өстенлек итәргә тиеш иде кебек,— диде өченче бер иптәш.

Фәритнең күз аллары караңгыланып китте. Халык моңнарын, татар музыкасы традицияләрен үстереп, фантастик дөньяны тасвирлаганда рус классиклары тапкан алымнарны иҗади файдаланып, заманча ритмнар белән баетып, гади һәм катлаулы да булган әсәр аша эпик яңгыраш бирергә омтылган иде ул. Остазы профессор Литинский да үзе тыңлый алган бүлекләрне ошаткан иде югыйсә. Менә сиңа мә — биредә исә кайбер иптәшләр Фәритнең шушы омтылышын аңламаска маташалар. Әллә инде күрмәмешкә салышуларымы... Болай да аз сөйләшә торган Фәрит үз уйларына йомылды.

Шулай да музыкаль әсәрне сәхнәләштерергә дигән карар чыгардылар, котлап авторның кулын кыстылар.

Казанның мехчылар клубы.

Бергә репетицияләргә килгән саен Фәрит бер үк хәлне күрде: алты-җиде яшьләр чамасындагы малай, клуб бакчасының тимер рәшәткәләренә сөялгән дә, эчтә агылган музыка авазларын онытылып тыңлый.

— Исемең ни атлы, энем?

— Фазыл.

— Әйдәле, курыкма, эчкә үк кереп тыңлыйбыз.

Бу малай аның үз балачагын хәтерләтә иде. Фәрит музыкага гашыйк җанны клуб эченә әйдәкләде. Фазыл карышып-нитеп тормады, шундук иярде дә керде.

Спорт залы чын-чынлап сәхнәгә әверелгән! Уртада Шүрәле күренү белән кинәт кенә тәнәфес тынлыгын сәер яңгырашлы, янау-куркыту характерындагы көй сызыклары алыштыра. Кларнетлар башкаруындагы үзенә бер төрле бу авазлар тезмәсенә кыллы һәм агач уен кораллары да килеп кушылгач, урман пәриенең үтә явызлыгын аңлаткан шомлы, ыгы-зыгылы картина барлыкка килә... Ул да түгел, кардай ак канатларын җилпеп, кызлар-аккошлар зифа хәрәкәтләр белән вальс бии башлый. Якты, дәртле вальс дулкынында Украинадан килгән яшь балерина Галинаның ягымлы сыны, бер ноктага төбәлгән уйчан йөзе күренеп-күренеп китә. Аны игезәк «кызлар» төркеменнән тапмый каламы соң Фәрит! Соңгы вакытларда репетициядән соң икесе бергәләп Галактионов урамына кадәр җәяүләп кайта алар.

— Кул һәм арка хәрәкәтләрен камилләштерәсегез бар. Яңабаштан! — дип боера таләпчән балетмейстер.

Сәнгатьнең бер генә төре дә җиңел бирелми икән — күр син, балет артистларының ике яңагыннан кара тир ага, берничәсе хәтта кирәк саен сөртенү өчен муенына сөлге дә бәйләгән...

Хореографияне һәм сәхнә кануннарын яхшы белгән Фәрит тәнәфес вакытында үзе дә артистларга ярдәм иткәли, киңәшләрен бирә.

Бу юлы клубтан өчәүләп чыктылар.

— Синең энекәшең дә бармы әллә? — дип сорады Галина урталарындагы малайга ымлап.

— Бар, әлбәттә. Тик ул авылда яши, аннары Фазылга карый күпкә бәләкәйрәк.

Малайның түбәсе күккә тигән иде, бүгенге шатлыгы өчен Фәрит абыйсына кычкырып рәхмәт әйтте дә ялан тәпи килеш Тукай урамына элдертте.

Кояш, төшлекне әллә кайчан узган да, ерактагы таш йортлар эргәсенә авышып килә. Авыр трамвайлар чыжлый, янәшәдән җиңел машиналар уза. Ә тротуар — аларныкы. Әмма балет моңнарыннан, уртак тантанадан аерыла алмаган ике яшь йөрәк өчен бу да тар — һәм алар, үзләре дә сизмәстән, Кабан күле ярына килеп чыгалар, кулга-кул тотынышып яр читеннән бара башлыйлар. Дулкын өстендә ике шәүлә пәйда була. Менә алар бергә кушылып-кушылып китә, куллар ярдәмендә тагын бергә тоташа...

— Фәрит, шулкадәр соклангыч музыканы ничек иҗат итә алдың син?

Фәрит сүз табалмый төртелеп кала. Ни дияргә? Их, әгәр аны тел белән аңлатып булса икән, Галинасы хакына бер туктаусыз сөйләр дә сөйләр иде ул.

— Безгә Кырлай урманнарын барып күрәсе иде бер! Менә шуннан соң барын да аңлар идең син.

— Алып барасыңмы, Фәрит? Кайчан? — дип очына Галина һәм күзгә-күз очрашкач керфекләрен салмак кына читкә ала.

— Вакыт булу белән, ярыймы?

Икесе дә ризалашалар. Тиктормас бер балык су өстендә тылсымлы боҗра ясый. Фәриткә кызык, күңелле.

— Беләсеңме, Галина, Кабан күле төбендә су кызлары яши, дип ишеткәнем бар минем. Әйдә, тыңлап карыйбыз, бәлки, ни сөйләшкәннәрен ишетербез.

— Кирәкми, син аларны күрсәң, миңа әйләнеп тә карамый башларсың,— дип шаярта кыз һәм култыклаган килеш кенә Фәритне үзенә карата.

Кызлар елмаюы... Шушы матурлыкка табынмый калган егетнең булганы бар микән соң әле дөньяда?

## 19

Галина...

Менә кем ул сугыш җәһәннәме эчендә дә йөрәкне җылытып, күңелне яктыртып тора! Ярый әле бу дөньяда хат дигән могҗизаны уйлап тапканнар. Менә кыр почтасы сиңа сөеклеңнән хат китерә. Рәхмәт әйткәнеңне әллә хәтерлисең, әллә юк — чөнки тышлыктагы адрес күзләреңне гипнозлап өлгергән була инде. Кабаланып кына конвертны ачасың, беренче сүзләрне укыйсың... Шул секундтан дөньяда туган як җиле исә башлый. Күңел бер талпыну белән Казанга, Галинасы янына кайтып төшә. Меңәр чакрым ераклыкны җиңеп, ике йөрәк очраша!

Дошманны куа-куа алга бару лейтенант Яруллин өчен үзе генә белгән аерым бер мәгънәгә ия. Алда — Днепр елгасы, аннан да арырак — хатынының туган шәһәре Киев. Галинасы Киев турында, аның табигате, архитектурасы, урам һәм мәйданнары хакында Фәриткә сәгатьләр буе сөйли иде. Шәһәр уртасында диярлек Днепр җәйрәп ята. Яшеллеккә төренгән текә ярлар, сөзәк таулар тезмәсе. Шундый тауларның берсендә — уналтынчы гасырда ук утыртылган карт юкә. Һәр яз саен әле дә булса

яшәрә, яфрак яра икән. Шау-шулы Крещатик урамы, тормыш агышына ис китми генә оеп утырган борынгы каштаннар... Галина боларны яратып, җанландырып сөйли.

Фашистлар Киевны да варварларча җимерде, яндырды, талады. Лейтенант Яруллинның сугышчан юлы — нәкъ менә шушы шәһәргә таба! Кунак булып түгел — поход тузанына баткан, азатлык алып килүче солдат сыйфатында алга барышы аның. Галинасы ничек шатланачак моңа!

...Ниһаять, иртәнге биштә һөҗүмгә күчтеләр. Немецлар да йоклап ятмаган, күрәсең, авылга якынайган сугышчыларны көчле ут яңгыры җиргә ятарга мәҗбүр итте. Кайсыдыр калкулыктан дошман минометлары залп бирә. Ах, шайтан алгыры, аның взводы миналар яуган участокка эләкте. Яруллин, маневр ясап, сугышчыларны көч-хәл белән куркынычлы зонадан алып чыкты. Шул сәбәпле, уң флангкарак күчтеләр. Командир баштарак ачу белән тешләрен кысты, әмма шул ук вакытта икенче бер тәвәккәл фикер аны хәтәр эшкә чакыра иде.

Немец һаман да котырына, ротага кузгалырга ирек бирми. Шушы хәлне бәяләгәннән соң командир үзлегеннән карар кабул итте: уң флангтан әйләнеп дошманның артына төшәргә һәм юк итәргә!

Саклануның барлык чараларын файдаланып, взвод авылга якыная башлады. Иске агач йортларда тереклек билгеләре күренми, авылның бар булган кешесе йортын ташлап киткән яисә кар базында ышыкланып ята, күрәсең. Ә каядыр якында, автомат тавышларын күмеп, пулемет ыжгыра. Тыкрык буен чамалап килделәр: биредән күзәтү һәм хәрәкәт итү җайлырак. Салам түбәле агач фермалар буеннан узганда Фәритнең колагына сарык кычкырган аваз ишетелгәндәй булды. Ватык тәрәзәле торак эчендә ниндидер тавыш, ыгы-зыгы бар шикелле. Фәрит түзмәде, сак кына борыла төшеп шул якка йөгерде. Ул килеп җиткәндә Батаев ферма торагының ишеген ачып азаплана иде. Бер читтә немец солдаты аунап ята.

— Ни булды?

— Менә, ут төртеп маташа иде. Сизми дә калды, олактырдым үзен.

Ферма ишеген ачып карау белән, андагы дистәләгән сарык төркеме куркудан бер почмакка өерелеп килде. Күзләрендә — өркү, калтырау, үрә баскан колакларында — шомлану билгесе. Үлемнәрен сизделәр микәнни? Бу бичараларны куып алып китәргә өлгермәгәч, ут төртергә уйлаган бит, ә, ике аяклы мәлгунь.

Йорт һәм коймалар ышыгына сыенып, сугышчылар һаман саен эчкәре үттеләр, дошман белән ике ара кыскара бара. Тегеләрнең пулемет һәм автоматлары ярсып ата да ата, безнең егетләргә үлем куркынычы яудыра. Бу минутларда бер секунд бер кеше гомеренә тиңдер, бәлки? Шуңа күрә сузарга ярамый. Билгеле бер ара калгач, иң элек гранаталар тондырырга!

Ике башта ике пулеметны күрү белән аңлады Фәрит: немецларның каршылык күрсәтү өчен калдырылган һәм нык көчәйтелгән взводы бу. Өченче пулемет чарлак тәрәзәсеннән ут яудыра.

Гитлерчылар авылны ныгытмага әйләндереп бетергәннәр: хәтта фланг якка да икешәр кат тимерчыбык киртәсе корганнар. Фәритнең кулын тимерчыбык чәнечкесе тырнап узды. Башка вакыт булса, авыртуын тояр иде, ләкин хәзер моның ишегә игътибар итәр чакмы соң!

Киртәлекнең икенче катын арчыганда көтелмәгән фаҗига булды. Чыбыкның бер очына шартлагыч тоташтырганнар, күрәсең, кинәт кубарылган шартлау ике сугышчыны ике якка чөеп ташлады! Немецның ике куянны берьюлы тотарга теләве иде бу. Шартлау — алар өчен сигнал, безнең өчен — үлем.

Чынлап та шулай: немецлар утның бер өлешен взвод ягына күчерделәр. Сугышта мәкерлекне алдан күреп булмый, димәк, приказны куркыныч астында үтисе! Сугышчылар, ядрәдән ышыкланып, алга үрләделәр. Бәхеткә каршы, ара ерак калмаган иде инде. Аннары читәннәр, койма-

куралар да — яхшы маскировка. Чардактагы пулеметны кемдер тончыктырып та өлгерде.

Беренче гранаталар очты. Фашистлар аңга килеп өлгергәнче, рәттән икенчесен дә тондырдылар. Мондый «мунча»ны тегеләр көтмәгән иде, күрәсең, исән калганнары кая туры килсә шунда ата-ата, тәртипсез рәвештә авыл эченә ташландылар. Ләкин аларны автомат уты бик тиз урталай бөгеп салды. Каршылык күрсәткән немецлар тулысынча юк ителде. Трофей пулеметларның берсе хәтта бөтенләй зарарланмаган да иде.

Батаевның беләге яраланган икән, аның кулын бәйләп муенына астылар. Карт солдат моны бик авыр кичерде. Һөҗүмнең иң кызган чагында иптәшләреннән читтә каласы килми иде аның. Куралев, сугышчан җиңү белән котлап, егетләрнең кулын кысты, хәзер генә кул астында булса, һәркайсыгызга бирәр медаль тагар идем, дип сөйләнә-сөйләнә солдатларының аркасыннан какты.

— Ә син, Батаев, хәзер үк санчастька җыен.

— Сез нәрсә, иптәш командир, ядрә мине чеметеп кенә узды. Миндә әле автоматны беләгемә салган килеш тә фрицның арт сабагын укытырлык рәт бар.

Куралев белән сүз көрәштерү файдасыз икәнен белгәнгә күрә, Яруллин батырчылык итеп арага керде:

— Рядовой Батаев, шушы минуттан сине связной итеп билгелим! Связнойның бурычлары нидән гыйбарәт икәнен беләсеңме?

— Беләм! — дип җавап кайтарды Батаев, һәр ике командирның икесенә дә берьюлы карарга тырышып. Куралевның: «Карап карарбыз»,— дия-дия мыек астыннан елмаюын барысы да ризалык билгесе дип аңладылар.

Кайсы кая поскан авыл кешеләре, яшереп саклаган ризыкларын күтәреп, солдатлар арасына атылды. Бала-чага, хатын-кыз, карт-коры, араларында бер генә дә ир заты күренми. Елый-елый безнең сугышчыларны кочалар, үбәләр, һәркайсы үз ризыгыннан авыз итүеңне үтенә. Бу тәэсирле күренеш Фәритнең аяк очларына хәтле кымырҗытып алды. Унике яшьләр чамасындагы кызның инәлеп бер читтә басып торуын гына аңламады ул. Кинәт кыз:

— Әтием! — дип кычкырып җибәрде һәм каршындагы солдатның куенына барып сарылды.

Авыл кешеләре берьюлы «ах!» итте, сугышчылар исә ни дип әйтергә белми аптырашып калдылар.

Өлкән яшьтәге бер хатын вакыйганың асылын сөйләп бирде:

— Фашистлар куркытканнан соң теленнән язган иде ул. Штык белән күкрәгенә тердерәләр бичараның. Менә ходайның рәхмәте, үзебезнекеләрне күргәннән соң теле ачылды бит балакайның...

Менә нинди могҗизаларга ия икәнсең син, азатлык! Бәлки, күзсезләргә — күз, аяксыз калганнарга аяк та кайтарып бирә аласыңдыр әле син...

Сугыш китергән югалтуларны ил буйлап берәм-берәм җыясы бар әле. Үлгәннәрнең каберен барлыйсы, исәннәрнең кадерен зурлыйсы бар. Боларны эшләү өчен дә иң элек син кирәк, азатлык!

Сугышның бар белгәне — вату, җимерү, тураклау. Тормышны матурлыктан, яшәү бәхетеннән мәхрүм итү. Фәритнең «Шүрәле»сен дә сәхнәгә менәм-менәм дип торганда гына сугыш рәхимсез төстә туктатып калдырды, сөякчел куллары белән матурлыкны буарга үрелде...

## 20

Сугыш хәбәре ул чакта тормыштагы барлык хыял-максатларны челпәрәмә китереп ташлады, кешеләрнең йөзләренә хәвеф һәм борчылу

тамгасы сукты. Фронттан көн дә авыр, күңелне тырный торган хәбәрләр килә башлады.

Фәритнең күңеленә сугышка каршы нәфрәт бәреп керде. Дөрес, хәрби кеше түгел ул, гап-гади бер музыкант, иҗат планнары белән янып яшәүче яшь композитор. Аның күңелендә никадәрле музыка яңгырый — менә шул моңнарны кәгазьгә төшерәсе дә халыкка яңгыратасы иде. Ләкин бөтен ил авыр кайгыда, фашизм белән үлемгә-үлем чагында ул моңнарны яңгыратудан ни файда? Илгә хәзер кырыс, сугышчан, ир-егетләрчә көрәшче аһәң кирәк. Ә Фәрит музыкант буларак моңа үзен әзер түгел шикелләрәк тоя. Илгә хәзер соңгы тамчы канын да кызганмый торган ышанычлы солдатлар кирәк. Җирдә матурлыкны арттыру турында хыялланган Фәрит нишләргә тиеш соң хәзер? Рояль клавишлары өстендә талпынасы бармакларның мылтык тәтесенә басарга, кеше үтерергә хакы юктыр, бәлки? Аның эшеме соң бу?

Фәрит рухи газап, эчке көрәш утларында янды, ләкин сорауларының очына чыга алмады.

Казан урамында сөйләшеп йөргәндә Фәрит үзеннән беразга өлкәнрәк Мусаның нык кына үзгәреп, кырысланып калуын сизде.

— Беләсеңме, сугышка каршы бер шигырь туып килә миндә. Аны болайрак башларга уйлыйм:

Талаучылар килде ил чигенә
Бәхетебезне тартып алырга.
Күтәрел, ил, дошман өстенә,
Соңгы көрәш, соңгы давылга!

Муса, шигырьнең азагын күңеленнән дәвам иткәндәй, озак кына дәшми барды. Аның бу кыюлыгына сокланудан, тәэсирләнүдән Фәритнең дә йөрәгендә куәтле дулкын кайный башлаган иде. Көчле рухлы марш сорап торган бу сүзләргә Фәрит көй язарга вәгъдә итте.

Муса оптимист кеше иде. Башын югары күтәреп барган җирдән шунда кинәт сорап куйды:

— Телисеңме, табышмак әйтәм... Үзе зур, үзе кызыл, нәрсә ул? — Аннары, Фәритнең җавап биргәнен дә көтмичә, йорт стенасындагы язулы калайга төртеп күрсәтте: — Әнә, кара, Большая Красная урамы булыр ул. Зур Кызыл урам... Әйе, без тормышта да урамның зурысыннан, кызылыннан барырга тиешле кешеләр!

...Сугыш башланып өч атна узуга, «Кызыл Татарстан» газетасында аларның «Соңгы көрәшкә» дигән җыры басылып та чыкты.

Йөрәк каны белән язылган җырның явыз дошманнан үч алуы Фәритне канатландырып җибәрде. Аптырап калгандагы уй-хисләргә тормыш үзе үзгәреш кертә икән. Шулай итеп, Фәритнең йөрәге дә үзеннән-үзе нәфрәтле җырга әверелде.

Йөрәк — нәфрәтле җыр!

Военкоматтан чакыру кәгазе килгәч тә Фәрит юл капчыгын төйнәде. Тик бер нәрсәгә йөрәк мае сызды аның — әле кайчан гына бергә тормыш корып җибәргән Галинасы гастрольдә иде — нишләмәк кирәк, башны башка куеп саубуллашу мизгеле насыйп түгел икән аларга...

Военкомат бинасында ыгы-зыгы — шәһәр үзенең улларын свастикалы аждаһага каршы көрәшкә туплый. Кемдер елый, кемдер соңгы сүзләрен әйтеп калырга ашыга. Беркем тарафыннан идарә ителми торган тигез гөжләү, җанлы хәрәкәтләр, уй-сагышлы карашлар. Кызмача бер агай улына киңәш бирә:

— Улым, без ундүртенче елда шулай итә торган идек: снәрәт сызгырдымы, башыңны тотасың да җиргә капланасың. Зинһар, сакла үзеңне. Мимечләрнең безне җиңгәне юк әле, сынатма, чатан Хәйрүш малае икәнеңне онытма!

Фәриткә моңсу булып китте. Әгәр бираедә басып торса, әтисе аңа нинди киңәшләр бирер иде икән? Әтисе — авылда, берни белми калды ул.

Шул вакыт Фəритнең каршына пар толымлы, зəңгəр күлмəкле бер кыз килеп басты. Битлəре алсуланган, сулыш алулары ешайган. Кайсыдыр мəктəптə җыр-музыкадан укытучы Сиринə Салихова иде бу.

— Фəрит абый, сезне таныгач та йөгердем...

— Ни булды?

— Миңа берни дə юк, менə сезгə ни булган? Чынлап та китəргə җыенуыгызмы, əллə...

— Əйе, Сиринə, мин сугышка китəм.

— Фəрит абый, ə «Шүрəле»... Без аны кайчан карарбыз соң?

— Карарбыз, Сиринə! Тик соңрак... Хəлне белəсең ич...

Сиринəнең күзлəре дымланып килде. Чая бу кыз үзен бик тиз кулга алды, кирəкмəс дип торуына карамастан, тулы сумкасын актарып, Фəритнең юл капчыгына алсу алмалар, берничə кыяр тыкты.

— Туры килүен кара син, Фəрит абый, базардан кайтышым бу. Тартынмагыз, безгə дигəннəре күп əле анда.

Дəресе якынлашып килə икəн, Сиринə китте. Үзеннəн соң бер кочак җылылык, дуслык, хəерле юл сəламе һəм үзенең битедəй алсу алмалар калдырып китте ул.

Бинаның зур залына җыеп хəрби комиссар нотык сөйлəп алды, исемлекне барлады, урнашу-китүлəр турында җентеклəп аңлатты. Фəрит өчен бөтенлəй таныш булмаган, ыгы-зыгылы ят дөнья иде бу. Төнлə хəрби эшелонның теплушкасында барганда да кинəттəн килеп чыккан үзгəрешкə иялəшеп җитмəде, үзен-үзе тəртипкə китерə алмый интекте. Биредəге шау-шу аның музыкаль дөньясы өчен чит иде. Җитмəсə, поезд тəгəрмəчлəре хыянəтчел тавыш белəн колак төбендə бер үк сүзлəрне тəкрарлый:

— Тук... тук... Казаныңнан китеп син дөрес эшлəдең микəн?.. Тук... тук...

## 21

Фронтка китеп дөрес эшлəде ул. Матурлыкның капма-каршысы — фашизм дигəн явызлык белəн очрашты. Күзгə-күз, йөзгə-йөз очрашты һəм аңлады: матурлыкны тудыру гына аз, аның өчен көрəшə дə белергə кирəк икəн!

Ə көрəш, əнə, көннəн-көн үсə, зурая, көнбатышка таба җəелə бара...

Н. авылын азат иткəннəн соң, елга буена җитəрəк, ялга туктадылар. Хəзер аларның батальоны тынычлап сулыш алачак, боеприпаслар яңартачак. Иң мөһиме — сирəгəеп калган сафларга пополнение килəчəк.

Сугышчыларның кəефе күтəренке. Тамак ялгау белəн шундук юл капчыкларын рəтлəргə, корал һəм башка кирəк-яракларны барларга керештелəр. Тез башына яки прикладка дəфтəр бите куеп хат язган солдатларга карау рəхəтлек бирə иде. Кайдадыр еракта һəркайсының əнисе һəм сөйгəн яры, яки хатыны һəм балалары өзелеп хəбəр көтə. Иң ышанычлы элемтə — өч почмаклы солдат хатлары! Менə ни өчен Фəрит солдатларының хат язып утыруына бөек бер күренеш итеп карый.

Солдат фантазиясенең чиге юк, табигатьнең һəр үзенчəлеген «ə» дигəнче кыр шартларына яраклаштыра ул. Яңгыр суыннан калган күлдəвекне көзге итеп, берəү əнə кырына, сакал-мыегын төзəтə. Берничə сугышчы елга суында гимнастеркасын сыгып маташа. Җай гына чыксын, чисталыкка өйрəнгəн адəм баласы һаман шуны куа, төс-кыяфəтен матурларга тырыша.

Əле генə ут эченнəн чыккан солдатларның уен-көлке сөйлəшүе бер караганда гайре табигый шикелле, лəкин бу — дөреслек, моны берни белəн дə юкка чыгара алмыйсың. Яңарак кына связной вазифаларын үз өстенə алган Батаев тирəсендə əңгəмə бигрəк тə җанлы бара:

— Чеметеп кенə китте дисең инде, ə?

— Батаев, связной булачагың төшенә кергән идеме?
— Бер кул белән дә ата аласың икән, пистолет тоттырырга кирәк сиңа!
Эчкерсез карт солдат боларның барысын да күтәрә, үртәшергә дә әзер, тик госпитальгә генә алып китмәсеннәр аны.
Фәрит үзе дә Галинасына хат язып салды. Кечкенә кызы Наилә турында күбрәк язарга кушты. Бер-берсен тамчы да күрмәгән ата белән бала арасы күренмәс җепләр белән тоташкан, сугыш әнә шуларны өзәргә, теткәләп ташларга тели. Ләкин мөмкин хәлме соң бу! Бердәнбер газиз баласын күрми һәм кочакламый торып, Фәритнең үләргә хакы юк...
Моңарчы үлән арасында посып яттылар микәнни — кинәт күктә берәм-берәм тургайлар пәйда булды. Очынып-очынып югары менделәр дә канатлы кыңгырау булып көмеш тавыш белән сайрарга керештеләр. Гөнаһсыз җан ияләре! Сугыш җиле сезнең сайрауларга да үзенең эзен салып өлгергән: никадәрле нәләт, ачыну моңы! Кояшны самолетлар каплый ала, ә тургайлар беркайчан да капламый — алар бүтән. Туган илнең күкләре кояш елмайганда, тургайлар сайрап торганда мең тапкыр гүзәлрәк, ягымлырак икән шул.
Бу дәртле тамашага карап Фәрит үзе дә фантастик очыш кичерә иде. Безнең бабайлар гомер буе иген иккән, тургай җырын юлдаш итеп яшәгән. Бәлки, авылның гап-гади зиратында, каен төбендә дә шушы моңны тыңлап яталардыр... Гомеренең бик тә кыска икәнлеген тою хисе вулкан кебек тышка бәреп чыкты. Илгә, кешеләргә файда китерерлек ниләр эшләп өлгерде соң әле ул? Гомер башланып кына килә иде, аны да сугыш үз төпкеленә суырып алды, музыкадан аерылып торырга мәҗбүр итте. Аның күңелендә никадәр моң, карындагы бала кебек, якты дөньяга чыгасы килеп талпына!
Кеше гомере, һәртөрле кичерешләр рәвешендә тамчылап җыела-җыела да, яшәү турындагы зур бер хакыйкатькә әверелә икән: туган халкыңа хезмәт ит, дөреслекне раслап яшә, җирдә кулыңнан килгәнчә матурлык һәйкәлләре калдыр. Шушы хакыйкатьне аңлаудан Фәритнең тамагына кайнар төер менде, күзләренә яшь пәрдәсе эленде...
Тургай тавышларында Идел буеның барлык моңнары бар иде шикелле.

## 22

Идел буе — Фәрит өчен изге һәм кадерле як. Ул туып-үскән Казан каласы Иделнең матур бер борылышына урнашкан. Ульяновск шәһәре — Казаннан астарак. Фәрит өчен бу шәһәрдә хәрби училище тормышы башланды.
Сугыш ерак, ләкин аның сулышы бирегә хәтле килеп җитә, һәр кешенең йөрәге аша уза. Әнә, курсант Сафиуллинның бертуган абыйсыннан «похоронка» кәгазе килгән... Радио көннән-көн авыр, бәгырьне телә торган хәбәрләр китерә.
Идел буена урнашкан бу шәһәр дә фронт өчен яши иде. Идел! Заманында күпме бәрелешләрнең тере шаһиты булган ул. Ук һәм җәя, кылыч һәм калкан тотып килгән күпме дошманның башы елга төбенә чумган. Инде дошманның тагын да мәкерлерәге шушы якларны буйсындырмакчы була. Юк, фашист әзмәверен совет кешеләре Иделнең тагын да тирәнрәк төпкеленә тәгәрәтер! Идел — үзенең муллыгы һәм гүзәллеге белән символ дәрәҗәсенә күтәрелгән исем, дуслык елгасы. Шуны гитлерчылар кулына бирү мөмкинме соң! Татар халкының бөек рухын Тукай әнә ничек төгәл әйтеп биргән:

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез!

Дүрт айлык хәрби курслардан соң, ниһаять, фронтка китәр чак житте. Полковник Протасов залдагы элеккеге курсантларына карап болай диде:

— Сез инде хәзер булачак командирлар. Ленин туган шәһәрдә укуыгызны онытмагыз. Дошман көчле, ләкин без аңардан да көчлерәк. Фронт сызыгының кай жиренә эләксәгез дә, сынатмагыз, улларым!

Соңгы сүзләрне әйткәндә полковникның тавышында дулкынлану сизелә иде.

Ләкин юлда Фәритне бәхетсезлек сагалап торган икән: тимгелле тиф кинәттән генә урын өстенә екты аны. Менә шунда хәтеренә төшерде... Кышкы салкын көн. Курсантлар шартлы дошманга каршы «атака»га бара. Гыйнвар жиле шинель итәкләрен йолка, кирза итек буйлап балтырга суык үрмәли. Идел өсте — ак юрган, боз чатнап ярылган урыннарны да кар каплаган. Йөгереп барган жиреннән аягы таеп китте дә, Фәрит кинәттән кар чоңгылына чумды. Терсәкләре белән бозлы стенага таянган килеш аякларын кыймылдатып карый — алар тоташ су эчендә. Иптәшләре аны мәкерле чоңгылдан көч-хәл белән тартып чыгарды. Салкын, эчтән калтырата, аяклар чемер-чемер килә. Аны шул хәлендә тиз генә гарнизон госпиталенә кайтардылар. Аякларын спирт белән уганда хәрби врач әйтте:

— Иң мөһиме, тыныч булыгыз. Яшьлек үзенекен итәчәк, тиздән савыгырсыз.

Яшь организм, чыннан да, үзенекен итте: Фәрит тиз терелеп чыкты. Әмма бер тигән суыкның кайчан да булса яңадан бәреп чыгу ихтималын Фәрит белми иде әле...

Тифның куркыныч, мәкерле, озакка сузыла торган авыру икәнен Фәрит шулай ук белми иде.

Кече лейтенант петлицасын тагып кына өлгергән Яруллинны Куйбышевтагы хәрби госпитальгә кайтардылар. Баш шаулый, гәүдә тирли, ут яна. Ах, күкрәк турысына салкын боз куеп шушы кайнарлыкны сүрелдерергә! Тик Фәритнең бөтенләй хәле юк, ак халатлы шәфкать туташының кереп чыкканын да томан аша гына күрә ул. Тәндә кабарынкы, тимгел-тимгел алсу таплар. Тел аңкауга ябышкан, үтереп эчәсе килә...

Баш берзаман тагын да ныграк шауларга тотына. Ялгыз палатаның ак стенасында шомлы, ямьсез шәүләләр калтырана... Шүрәлеләр биюе ич бу! Фәритнең саташулы уйларына образлы музыка ташкыны бәреп керә. Көйнең агышы бер төшә, бер күтәрелә. Килбәтсез, ватык-сынык, ыгы-зыгылы музыка астында Шүрәле каһкаһә белән көлеп, Фәрит каршында иләмсез бармакларын селкетә. Барабаннар дөбердәгән, кларнетлар улаган саен, кытыклау, янау хәрәкәтләре ясый-ясый, авыруның өстенә килә...

Имеш, Фәрит — Былтыр атлы егет икән... Тик нигә соң аның кул-аяклары бер дә хәрәкәтләнми, янында гына чөйле-ярыклы бүрәнә күренми? Шулай да Фәрит ниндидер могжиза белән Шүрәлене бер читкә алып ыргыта... Чү, кемдер дәшә түгелме? Кочагына алып тибрәтә торган жиңел, салмак, сыгылмалы музыка... Аккоштай йөзеп килгән кыз Былтырның сөйгәне Сөембикә, имеш... Түгел лә, ай шикелле балкып торган Галинасы ич...

— Сез саташасыз бугай...

Кем дәшә шулай? Кайсы дөнья бу? Каршында ак халатлы шәфкать туташының басып торуын көч-хәл белән абайлый Фәрит.

— Я, алтыным, үтәме? Инде менә дару кабыгыз. Иң мөһиме — сезгә борчылмаска кирәк.

Бер белмәгән кешесенә «алтыным» дип эндәшә түгелме соң? Нинди ягымлы сүз! Ә бәлки, Фәритнең музыкант булуын, Казаннан икәнен дә белеп өлгергәндер ул...

Шуларны хәтереннән чигерә-чигерә лейтенант кулына бинокль алды да дошман ягын күзли башлады.

Немецлар үзләре чыккан күперне шартлатып өлгергәннәр. Су эчендә баш-башлары тырпайган субай баганалары шәйләнә. Күренеп тора: хәтәр участок бу. Елганы кичәргә ташландыңмы, үз-үзеңне утка илтеп тыгасың дигән сүз. Димәк, елганы төнлә кичәргә туры киләчәк. Ярый әле ышыкланыр өчен берән-сәрән булса да куаклыклар бар.

— Селкенергә берсенә дә ирек бирмә! — диде Яруллин тал төбенә сыенган снайпер солдат янынннан узып барышлый. Снайпер борылып баш селекте һәм:

— Иптәш командир, кемдер килә,— дип артка ымлап күрсәтте.

Хәрби киемле чит кешене Яруллин танымады, ләкин комбатның: «Красная звезда» газетасыннан хәрби корреспондент киләчәк, туп-туры сиңа җибәрәм»,— дигән сүзләрен хәтеренә төшерде.

Ыспай киенгән, лейтенант погоннары таккан, күзлекле яшь бу егет үзен Василий Конов дип таныттьı, ягымлы елмая-елмая сумкасыннан дәфтәр һәм авторучка тартып чыгарды. Аның бар кыяфәтеннән һәм сөйләшүеннән, чыннан да, журналистлык куәсе бөркелеп тора иде.

— Иптәш лейтенант,— дип мөрәҗәгать итте ул Яруллинга,— сөйләгез әле, Н. авылын азат итү ничегрәк булды? Дошманны хәйлә белән җиңдегезме? Әллә үзегез генә белгән башка бер сәбәп бармы?

Яруллин иңбашын сикертте, нәрсәсен сөйлисең инде, янәсе, алар урынында теләсә кайсы взвод шулай эшләр иде.

— Хикмәте менә шушы егетләрдә аның...— Яруллин кул хәрәкәте белән үзенең сугышчыларын күрсәтте. Корреспондент ашыга-ашыга яза, фикеренең дәвамын көтеп Яруллинга да карап ала.

— Без, иптәш корреспондент, бары намус кушканны эшләдек. Шуңа күрә гаҗәпләнерлек әйбер юк биредә.

— Аңлыйм, ләкин шул ук эшне бүтәннәр башкарыр әле, дип көтеп ятарга да мөмкин ич, шулай бит?

— Монысы инде егетлек түгел, сугыш кызганда бигрәк тә...

— Рәхмәт, мин дә шулай уйлыйм. Иптәш лейтенант,— Коновның йөзенә уңайсызлану билгеләре чыкты,— сезне музыкант диделәр миңа, бу дөресме?

— Ярый, дөрес тә булсын, ди.

— Сугышның ни өчен алгы сызыгында булуыгызны аңлыйм. Шулай да сорарга батырчылык итәм: музыкадан аерылып тору кыен түгелме сезгә? Сугыштагы хәлләр музыкаль фикерләвегезне тупасламас микән?

— Яшермим, музыкадан аерылуны баштарак авыр кичергән идем. Ләкин тора-бара аңладым: мин биредә дә кирәкле кеше. Җиңү симфониясенә минем үз өлешем керергә тиеш. Бу хокукны штык белән яуларга туры киләчәк...

Хәрби корреспондент әңгәмәдән бик канәгать иде.

— Сез бүген төнлә елганы кичәсез икән. Мин сезнең бу операциядә катнашырга һәм газетабызга кайнар эзләрдән репортаж язарга телим. Шәт, каршы килмәссез,— диде ул аннары һәм, чокырдан күтәрелә төшеп, елга аръягына карады.

— Ихтыярыгыз. Ничек телисез, шулай эшләгез.

Кинәт немецлар ягында снайпер винтовкасыннан аткан тонык тавыш яңгырады. Коновның «ах!» дип кычкыруыннан Яруллин имәнеп китә язды: дошман ядрәсе егетнең күкрәгенә килеп тигән иде! Корреспондентның кулыннан сумкасы төшеп китте, дәфтәр-каләмнәре үлән өстенә чәчелде.

— Анда... әнкәйгә... язган...

Конов соңгы җөмләсен әйтеп бетерә алмады, Яруллинның кулларында килеш сыгылып төште. Сугышта күпме йөреп, Яруллинның кеше гомерен кулларында болай тотып торганы юк иде әле, чарасыз калып егетнең йөзенә иелде, әле генә сөйләшеп торган әңгәмәдәшен сак кына хәрәкәтләр белән уятырга тырышып азапланды. Коновның күзлек пыяласында чагылып күренгән агачлар, күк һәм болытлар сәер бер сурәт

рәвешендә дөньяга томраеп карап тора. Гүя күзлек, хуҗасының гомерен озайтырга теләгәндәй, бакый дөньяны күреп калырга ашыга иде...

Конов лейтенант Яруллинның кулларында килеш җан бирде.

Аның кыр сумкасыннан, чыннан да, әти-әнисенә язган хаты килеп чыкты. Бүгенге әңгәмәне язарга тиешле кәгазь битләре үлән арасында ак күгәрчендәй талпына. Ул төнге репортажын язып өлгермәде, ләкин композитор Яруллинның тормышка булган мәхәббәтен яңартырга, сайланган юлының дөреслеген тагын бер кат аңларга, килер көнгә ышанычын ныгытырга өлгергән иде.

Кешенең җаны кай төштә соң? Йөрәктә түгел, ләкин күкрәкнең күзгә күренми торган кайсыдыр бер эчкәрге ноктасында ул. Әнә шул сызлый, авырта башладымы — түз генә! Яруллинның җаны сызлый, үзенә ни кирәген дә белмәстән, ярсулы оркестрдай дулый, шаша, бәргәләнә иде...

## 24

Фәритнең бәхетенә күрә, теге чакта тиф куркынычы чигенде.

Яңа дивизия оешкан вакытта колактан-колакка сүз йөрде: янәсе, Сталинградны сакларга җибәрәчәкләр икән...

Хәбәр дөрес иде — танк һәм пушкаларны, солдат һәм офицерларны төягән хәрби эшелон, тәгәрмәчләрен кырыс тукылдатып, көннәрнең берендә көньякка таба кузгалды.

Төшкә керер дип тә уйламассың: менә шул чакта Фәрит Яруллинның тормышында көтелмәгән бер вакыйга булды.

Дуслары язган хәбәр буенча, Мәскәү консерваториясенең Саратов шәһәренә эвакуацияләнеп килгәнен белә иде ул. Ә менә эшелон шул тирәдән узар, анда ике тәүлек буе туктап торыр, һәм иң гаҗәбе — кырык икенче елның августында ул үзенең профессоры Литинский белән очрашыр дип кем уйлаган!

Ишек төбендә хәрби киемле егетне, дөресрәге, калын иренле, киң җилкәле кайчангыдыр шәкертенең ябыгып һәм талчыгып калган йөзен күргәч, профессор бер мәлгә сүз әйтә алмый торды, аннары гына Фәритне туганнарча кочаклап алды. Консерватория елларының җылысы тамчы да суынмаган икән, икесенә дә рәхәт булып китте.

— Сөйлә, нинди җилләр ташлады сине? — Генрих Ильичның бөтен игътибары Фәриткә юнәлгән иде.

— Эшелон җилләре,— диде Фәрит хикмәтле көлемсерәп һәм ашыкмый гына хәрби тормышын хикәяләп алды.

— М-да... Сугыш кеше язмышын ничекләр үзгәртеп ташламады, ә? Үзем дә бөтенләй уйламаган җирдә җан асрап ятам менә.

— Идел буендагы шәһәрләрнең һәммәсе дә әйбәт, Генрих Ильич.

— Шулай шулаен, анысына сүзем юк. Әмма Мәскәү сагындыра.

— Миндә дә шундыйрак хәл, Генрих Ильич. Кичә юлда Мәскәүнең шаулы урамнары төшкә кергән иде. Уянып китсәм — тәгәрмәчләр шавы икән...

Литинский елмаеп куйды.

— Карап-карап торам да, Фәрит, синнән шәп кенә командир чыгарга охшый. Ә син бит тумышың белән композитор, моң иясе. Менә болар ничек чагыша икән дип гаҗәпләнәм.

Шулай сөйләнә-сөйләнә профессор керосинкага аш җылытырга куйды. Үзе пешергәнме ул аны, әллә ашханәдән китергәннәрме, Фәрит төпченергә яхшысынмады. Генрих Ильич сүзен дәвам итте:

— Ишеткәнең бар микән, заманында Франциядә шундый бер җәза уйлап чыгарганнар: кеше туйганчы ашый ала, ләкин аны хәрәкәтләнүдән мәхрүм итәләр. Кеше, мескен, ифрат газаплана, үләр чиккә җитә. Сугышның сине дә шулай җәзалавы бар, Фәрит. Бер караганда уй-хисләреңнең тирәнлегенә юл ача ул, икенче карыйсың — иҗат эшеннән мәхрүм итә. Шулай түгелме?

— Шулай. Тик мин туып-үскән илемнең зурлыгын, бөеклеген эзләп киләм. Ә бу юлда җиңеллек көтәргә кирәкми.

Профессор соклануын яшермәде, турыдан-туры әйтеп салды:

— Менә училище дисәң дә ярый ичмасам! Политик яктан тәмам чыныктырганнар үзеңне.

Фәритнең бармаклары уйнауны үлер чиккә җитеп сагынган иде. Хуҗадан әдәпле генә рөхсәт сорады да пианино артына утырды. Үзеннән-үзе бии, талпына башлаган бармаклар арасыннан дулкындай салмак ритмлы, сагышлы көй агып чыга... Фәрит үзенең балетыннан «Тәфтиләү» җырына нигезләнгән вальсны башкара иде...

Төнгә кадәр сөйләштеләр, фикер алыштылар. Артык шаулатмый гына бер-берсенә пианинода уйнадылар. Рус һәм чит ил классикларының искиткеч моңы Фәритне күкләргә кадәр күтәрде дә тагын җиргә алып төште. Кешенең күңелен яктырта, зиһенен үткенәйтә, эчке иманын ныгыта торган сирәк очрашуларның берсе иде бу. Хыялга бәйсез рәвештә яши торган чынбарлык та янәшәдә генә иде: тимер юл, хәрби состав, часовойларның өзлексез хәрәкәте, әмер тавышлары...

Тиздән китәргә тиешле кече лейтенант Фәрит Яруллин, әлеге чынбарлыктан бер көнгә булса да аерылып, башка дөньяда яши. Тимә, борчыма син аны, вакыт!

## 25

Ә хәзер, әйдә, рәхәтләнеп борчы, вакыт! Разведканың соңгы мәгълүматлары белән танышырга, төнге һөҗүмгә әзерләнергә кирәк...

Караңгылык төшкәндә взвод командиры каршына гражданский киемдәге билгесез картны тотып китерделәр. Таза бәдәнле бу карт күзләрен челт-мелт китереп ашыга-ашыга аңлатырга тотынды:

— Таллыклар арасында яшереп куйган көймәм бар. Елганы кичкәндә ярап куяр ул сезгә. Биш кешене, валлаһидыр, рәхәтләнеп йөздерә.

— Ә елга тирәнме?

— Төрле урын бар. Иң тирән җире билдән югары артмастыр.

— Яхшы сүзең өчен рәхмәт. Ә күперне кайчан шартлаттылар?

— Чигенү белән, бәдбәхетләр! Колхоз оешкан елны гына күмәкләп салган идек югса.

Төн карасы куергач, немецлар күккә яктырткыч ракета чөя башладылар. Пулемет уты белән көйдереп аласы иде дә бит үзләрен — ярамый, үзеңнең кайдалыгыңны фаш итү генә килеп чыгачак. Шуны истә тотып, лейтенант бу уеннан кире кайтты. Әйдә, һаман саен ут чөяргә кулларында «әндри казнасы» юктыр әле дип фикер йөртте.

Бераздан ракеталар, чыннан да, күзгә күренеп сирәгәйде, берзаман бөтенләй тынып ук калдылар.

Башларга мөмкин!

Теләп команда булу белән сугышчылар елгага сак кына кузгалдылар. Төн. Йөрәк тибешенә тәңгәл булып, аяк астында итек табаны йомшак кына тавыш бирә. Колакка су агышы ишетелгән кебек. Көймәдә киткән беренче төркем тавыш-тынсыз гына аргы як караңгылыгына күмелде. Бүрәнә, күпердән калган такта кисәкләрен файдаланып, башкалар да су эченә кереп китте. Кирза итек кунычына авыраеп су тула, күкрәкләргә дулкын сарыла. Саклык, тагын бер тапкыр саклык — бу хакта һәркайсының колагына уйдырып әйтелгән. Менә хәзер башка взводлар да елга төбенә аяк баскандыр. Ахыры хәерле булсын, төнге сугыш — хәтәр, мәкерле, күзеңне бәйләп разведкага барган шикелле.

Немецлар сизенде булса кирәк, күктә тагын койрыклы яктылык кабынды. Сугышчылар ярга аяк басарга өлгергән иде инде — шул коткарды. Югса су төбендә озак посып ятарга берәүнең дә яңагында саңак юк.

Атыш башлану белән йолдызлы күк җиргә егылып төште кебек. Караңгылык уртасыннан пулеметларның утлы хәнҗәре сузылды. Таллыклар тирәсенә чүмәшү белән лейтенант ятарга приказ бирде. Плацдармны ничек тә сакларга, кулдан ычкындырмаска кирәк. Каршыдарак бер немецның автоматтан атканы күзгә чалынды. Фәрит утны тиз генә шунда күчерде. Безнекеләрдән берәү җан ачысы белән кинәт кычкырып җибәрде — кем булды икән, аңа ярдәм күрсәтүче бармы бу минутта? Бераздан атышлар сирәгәйде — немецлар да посып яткан урыннарын фаш итүдән шикләнделәр булса кирәк. Ике як та нидер уйлый, көтә, исәп-хисап итә. Немецлар ягында кинәт рәттән ике граната шартлады. Куш йөрәкле кемдер берәү, төн караңгысына ышыкланып, немецлар позициясенә барып килде, күрәсең. Килде ди әйтү дөрес микән? Ул тирәне немецлар ике яклап ару гына «тарадылар». Атыш тагын көчәйде, аннары тагын тынып калды.

Төн шулай мәшәкатьле, йокысыз узды.

Төн чигенеп, куаклыклар шәйләнә башлау белән, взвод һөҗүмне көчәйтте, немецлар посып яткан окопка, түмгәк һәм таллыкларга таба үрмәләде, плацдармны киңәйтте. Югалтуларны күреп кенә командирның йөрәге әрнеде. Һәркемнең гомере кадерле, ләкин көрәшергә, дошманны җиңәргә кирәк!

Взвод хәлиткеч һөҗүмгә ташланды.

## 26

...Бронетранспортер һәм танкларга төялгән пехота алга, көнбатышка ыргыла!

Колак төбендә — җил сызгырган, машина моторы гүләгән тавышлар. Танк башнясына кадаган кызыл байракның җил тыгызлыгын ертып, җилфердәп баруы Фәриткә героик музыка, күңелендәге симфониянең бер кисәге булып ишетелә...

«Алга барырга, биеккәрәк күтәрелергә!» Үзенең «Шүрәле»сенә әнә шушы идеяне салырга тырышкан иде ул. Җир йөзендә фашизм барабан каккан чакта исә алга бару, биеккәрәк күтәрелү берничек тә мөмкин түгел. Менә ни өчен сугышка керде Фәрит. Йөрәк җимеше «Шүрәле»се Казанда, Туган илендә, Европада яңгырасын өчен сугышты һәм алга таба да үзен аямый сугышачак ул.

*Аның күңеле матурлык эзләүдән гыйбарәт иде. Матурлык кешегә алга бару, биеккәрәк күтәрелү өчен кирәк. Тормышның беркайда да язылмаган якты бер законы әнә шулдыр. Илдәшләреңбелән уртаклашсаң, үзең тапкан матурлык меңгә, миллионга тапкырлана. Куктән болыт булып агамы яисә җирдән сабый булып атлыймы, ул һәркемнең йөрәгә аша узарга тиеш. Матурлыкның яшәр урыны — Ватан.*

Тормыш югалтулардан да тора.

Һәлак булырга туры килсә, аның иманы, уй-фикере ачык: әгәр син дөньяда дөрес яшәгәнсең, «кешеләргә кала моңнарым» дип әйтердәй азмы-күпме яхшылык эшләп өлгергәнсең икән — үлем шулай ук яшәүдән, тормышыңның дәвам итүеннән гыйбарәт.

Чү, тукта! Тормыш, көрәш шавымы бу, әллә Бетховенның Тугызынчы симфониясеме шулай күкләрне иңләп ага? Фаҗигале, ләкин гаделлек һәм якты киләчәкнең тантана итәсенә ышаныч тулы авазлар томырылып каршыга килә...

«Музыкага караганда хәрби сәнгатьне начар белүем никадәр кызганыч: мин аны тар-мар китергән булыр идем...» Бетховен моны Наполеонга карата әйтә. Прусс армиясе Иен сугышында җиңелгәннән соң әйтә бу сүзләрне. Фәрит Яруллин — сугышларда утны-суны кичкән солдат, ул Гитлерны ничек итеп тар-мар китерәсен һәр ике өлкәдә дә яхшы белә. Аның барыр юлы — көнбатышка, җиңүгә таба!

Нинди гаҗәеп хәл: татар композиторы Фәрит Яруллин немец халкының бөек музыканты Бетховен янына бара лабаса! Дуслык, туганлык, азатлык хисләре белән Германия, нигә бөек улларыңның зирәклегенә богау салдың? «Берләшегез, миллионнар!» — дигән сүзләрен аяк астыңа салып таптадың?

Ләкин хакыйкатькә, дуслык һәм азатлык хисләренә богау салу мөмкинме соң? Әнә, композитор Яруллин үзенең рухи туганы, көрәштәше Бетховен каршына очрашуга бара...

## Эпилог

Тыңла, дөнья! Сиңа әйтер сүзем бар.

Фашизм, миллионнарның гомерен өзү белән бергә, Фәрит Яруллинның язылмаган, ләкин һичшиксез язылачак булган симфониясен дә үтерде.

Лейтенант Яруллин Орел шәһәрен, Смоленск һәм Витебск өлкәләрен азат итүдә катнашты. Гомере өзелмәсә, азатлык алып килүче солдат буларак, Бетховенның һәйкәле һәм рухы каршына килеп тә һичшиксез баш иячәк иде ул.

Яруллин һәлак булып, унтугыз көн үткәннән соң совет гаскәрләре Киевны азат итте.

Әле туплар да тынмаган чакта — 1945 елның 12 мартында — «Шүрәле» балеты Казан сәхнәсенә менде.

Ниһаять, планетага Бөек Җиңү килде!

Курск ягының атаклы сандугачлары, сез инде башка буын, сугыш зәхмәтен күрмәгән яңа токым. Ләкин сезнең өздереп сайрауларыгызда барыбер утлы елларның сагышлы бер кылы зыңлый шикелле. Тургайларым, сез дә сайрагыз, кешеләргә һәрвакыт таң сәламе, тыныч еллар икмәгенең муллыгы турында хәбәрләр китерегез. Быелгы арышларым, сезнең башак өсләрендә фәкать рәшәләр җылысы гына тирбәлсен.

«Шүрәле» балеты Мәскәү, Ленинград, Киев, Рига, Таллин, Одесса, Ташкент, Саратов, Львов, Чиләбе һәм илебезнең башка күп кенә шәһәрләрендә куелды. Болгария, Румыния, Югославия, Албания илләрендә зур уңыш белән барды, немец, инглиз һәм француз тамашачыларының ихтирамын яулады.

Мәскәү сәхнәсендә Сөембикә ролен шөһрәтле артистка Майя Плисецкая башкарды һәм балетның музыкасы турында иң гүзәл сүзләрне әйтте.

1958 елда «Шүрәле» балеты өчен Фәрит Яруллинга, беренчеләрдән булып, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге премиясе бирелде.

Үлемсез «Шүрәле», иҗатчысының каберен эзләп, аның эзләреннән Европага хәтле барып чыкты — тапмады. Ләкин берәүнең дә җаны кош булып күккә ашмый, җиргә иңә. «Сугыш булып узган якларның һәр аршин җирен барлап чыкканнан соң кабере табылмый калмас»,— дип уйлады бөек Моң һәм тапты да: Фәрит Яруллин Витебск өлкәсенең Рыленки авылында туганнар каберлегенә күмелгән...

Хәтердәге прологны артиллерия канонадасы башлап җибәргән иде.

Ничәнче көн инде күңелемдәге җырның азагына нокта куя алмый азапланам. Һәм бу мөмкин эш микән соң? Чөнки эпилогны, кадерле укучым, «Шүрәле»нең соклангыч моңнары дәвам итә!

*1984—1985 еллар.*

**СӨЛӘЙМАН РӨСТӘМ**, Әзербайҗан ССРның халык шагыйре.

*Искиткеч талантка ия булган Габдулла Тукайның шигъри мирасы ул бары тик татар шагыйрьләре милке генә түгел, ул барлык тугандаш республикалар шагыйрьләре өчен дә кадерле һәм газиз...*

*Габдулла Тукай кебек искиткеч талантлар җитештергән татар халкына дан!*

# «ҖӘҮҺӘР ВӘ ЯКУТЛАРДАН ДА КЫЙММӘТЛЕ...»

### ТУКАЙ СҮЗЛӘРЕНӘ ҖЫРЛАНУЧЫ ЯҢА ТАБЫЛГАН ХАЛЫК КӨЙЛӘРЕ ТУРЫНДА

Халык җырларын Г. Тукай «җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле» хәзинә дип бәяләгән. «Белергә кирәк ки,— дип яза ул,— халык җырлары — халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәушан көзгеседер». Иҗатының башлангыч чорында ук Г. Тукай җыр мирасыбызга аеруча зур әһәмият бирергә, җырларны «югалтмаска иҗтиһад итәргә» чакыра һәм беренче үрнәкне үзе күрсәтә — кыска гына гомерендә күп кенә халык җырларын җыеп, яңадан халык күңеленә ирешт[е]рә.

Халык җырларын җыю, барлау эше күптәннән башланган булса да, аны фәнни нигездә башкаручылар дип беренче татар мәгърифәтчеләрен әйтергә мөмкиндер. Г. Тукай да дөньяви шигърият, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән иң әүвәл Каюм Насыйри хезмәтләре аша таныша, яшүсмер чакта ишеткән җыр текстларын беренче шәкерт дәфтәрләренә теркәп барган. Бу хакта И. Нуруллин болай яза: «Ул XIX гасырның ахырында халык иҗаты әсәрләрен эченә алган җыентыкларны кызыксынып укый, кешедән ишеткән җырларны хәтерендә калдырырга тырыша, соңрак исә җырларны дәфтәргә терки башлый. Мәдрәсәдә оста җырчы булып танылган Габдуллага бу баштарак, әлбәттә, мөмкин кадәр күбрәк җыр белү, «репертуар»ны баету өчен кирәк булган. Тора-бара исә аңарда, һичшиксез, җырларны матбугатка чыгару һәм аларның тәэсир көченең серен аңларга тырышу теләге туган».

Шагыйрь үзенең байтак шигъри җәүһәрләрен теге яки бу көй вәзененә, калыбына яраклаштырып иҗат итә. Шуңа күрә дә алар бик тиз халыклашып китәләр, халык күңеленә үтә якын һәм гаҗиз «Әллүки», «Тәфтиләү», «Зиләйлүк» кебек көйләргә җырлана башлыйлар. Тора-бара боларга «Туган тел», «Пар ат» кебек энҗе бөртекләре өстәлә. Шулай итеп, халык үзенең сөекле җырчысы язган шигырьне, алтын җыр фондының йөзек кашына әверелдерә.

Г. Тукай халык җырларының киләчәк «әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез» булачагын алдан белгән. Алар бөек шагыйрьнең күңел кылларын тибрәндереп, яңа әсәрләр иҗат итәргә рухландырган.

«Бу җырулар,— дип яза ул,— минем күңелемнең иң нечкә кылларына тукыналар иде. Шуннан соң мин дә аларныкы шикеллерәк итеп, алар вәзене белән, алар көен үк салып, үз хисләремне мәйданга чыгара башладым». Чыннан да, шагыйрь кайбер шигырьләренең нинди көйгә көйләнергә тиешлегенә хәтле искәртеп куя. Тора-бара «Әллүки» кебек көйләр тулысынча аның сүзләре белән җырлана башлыйлар. Шулай итеп, Г. Тукай үзе генә түгел, замандашларын да халык җырыннан туктаусыз өйрәнергә, җырга «тәкълид итәргә», ягъни ияререгә чакыра. «Пушкин вә Кольцов,— ди ул,— халык җырларына тәкълид итеп, бертөрле «искусственные песни», ягъни сонгый җырлар яздылар». «Халыкның үз көе, үз вәзене, үз формасы илә язылганга», алар «халык күңеленә бигрәк тә тәэсир итә вә урынлашадыр».

Татар халкы олы шагыйрьләрен беркайчан да истән чыгармаган, алай гына да түгел, аларның иң матур шигъри үрнәкләрен көйгә салып җырлаган. Кол Галиның «Кыйссаи Йосыф»ын гына алыйк. Бу мәшһүр әсәрнең уннан артык көе бар[1]. М. Колый,

[1] Хисамов Н. Бөек язмышлы әсәр. Казан, 1984, 319—334 бб.

Г. Утыз-Имәни, Һ. Салихов кебек шагыйрьләрнең әсәрләре дә көйгә салынып, мөнәҗәт итеп көйләнеп йөргән. Соңгы елларда мәшһүр мәгърифәтче шагыйребез Мифтахетдин Акмулланың шигырьләре дә халыкта көйле мөнәҗәт булып яшәгәнлеге ачыкланды [1].


Профессиональ композиторлары әле өлгереп җитмәгән халык яраткан шагыйрьләренең киң таралган шигъри әсәрләрен көйләргә әнә шулай әзер торган. Яңа гасыр башында бу процесс тагын да җанлана төшә. Г. Тукай үзе дә замандашы һәм каләмдәше Зыя Ярмәки язган «Ак каен» шигыренең җырга әверелү фактын хуплап каршы ала. Бу елларда мәдрәсә фольклорындагы күп кенә шигырьләр көйгә салына. Дистәләгән дәреслекләрдә дөнья күргән шундый өндәү шигырьләренең көйле назымга әверелеп китүе дә кызыклы. Һичшиксез, Г. Тукай шигырьләренең дә җыр булып киткән булуы ихтимал. Әмма аларның күбесе бүгенге көн җыр репертуарыннан, төрле сәбәпләр аркасында, төшеп калган.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты оештырган фольклор экспедицияләре ел саен туган илебезнең төрле төбәкләреннән яңа табылган халык җырларын алып кайта. Бу үзе генә дә җыр мирасыбызның шактый өлеше үз тикшерүчесен көтеп ятуы хакында сөйли. Бу юлларны язучыларга, җыр, шигырь, бәет, мөнәҗәт эзләп, байтак өлкәләрдә булып кайтырга туры килде. Иң куанычлысы шул: арада Г. Тукай сүзләренә иҗат ителгән халык җырлары да очрый. Димәк, халык хәтере гасыр башында туган җырларны әле һаман пөхтәләп саклый. Түбәндә без Г. Тукай шигыренә җырлана торган өч җырга тукталмакчы булабыз.

Беренче җыр «Бар күңеллелек...» дип атала. Ул Г. Тукайның «Бәйрәм бүген» шигыренә нигезләнә. Беренче тапкыр бу шигырь «Әльислах» газетасының 1908 елгы 13 октябрь (48) санында дөнья күрә. Бу шигырьгә композитор Җәүдәт Фәйзи 1946 елда «Бәйрәм бүген» исемле җыр яза. Дини бәйрәм уңаеннан язылган бу шигырьдән композитор бишенче строфаны төшереп калдыра. Менә ул:

Бер теләнчене кочаклашкан күреп бер бай белән:
Күңле нечкәргән! дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Нечкә ирония, сарказм белән әйтелгән бу сүзләр, әлбәттә, үз чоры өчен гаять актуаль яңгыраган. Нәкъ шушы строфа шигырьнең язылу чорына ишарә ясый. Ә Җ. Фәйзи язган җыр, гомумән, бәйрәм турында. Ул җиңел агылышлы, дәртле һәм якты яңгырашлы бәйрәм җыры итеп иҗат ителгән. Ә «Бар күңеллелек...» исемле җыр исә Җ. Фәйзинекеннән бөтенләй аерылып тора. Көй төзелешендә бәйрәм хисе, бәйрәм тантанасы гына түгел, бәлки ул елларның революцион пафосы, рухы да ачык сизелә. Беренчедән, көйдә басым һәр тактта беренче чиреккә туры килә. Бу исә татар көйләренә хас нәрсәгә — басымның фраза азагына туры килүенә каршы төшә. Шулай итеп көй революцион маршка якыная төшә, күмәк җыр төсмере ала. Икенчедән, көй ике җөмләле периодтан тора һәм, икенче җөмлә беренчесенә җавап кына булып калмыйча, ярым тонлы хәрәкәтләр аша гомум үсешкә ирешә. Җыр өндәү, чакыру пафосы белән сугарылган. Пермь өлкәсе, Уинск районы, Түбән Сеп авылында яшәүче Ягафәр ага Галәветдиновтан (1902 елда туган) 1977 елның 9 июлендә язып алынган җыр текстында Г. Тукай шигырендәге 7 нче строфа төшеп калган, ә 3 нче һәм 4 нче строфада сүз тәртибе бутала төшкән. Гомумән алганда, «Бар күңеллелек...» җырында халкыбызның авыр тормышта яшәп тә, киләчәк якты көннәр килүенә, азатлык бәйрәме якынлашуына тирән ышаныч, якты өмет баглавы чагылыш тапкан. Бу җыр яңа революцион күтәрелеш елларында туганга охшый.




[2] Хәснуллин К. Халык күңелендә моң булып.— Китапта: Поэт-просветитель Акмулла. Казань, 1983. 173—180 бб.

## «БАР КҮҢЕЛЛЕЛЕК...»

(«Бәйрәм бүген»)

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? — Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Икенче җыр «Өзелгән өмид» дип атала, ягъни Г. Тукайның мәшһүр шигыре исемендә. Шагыйрь тетрәндергеч бу әсәрен 1910 елның 29 ноябрендә «Вакыт» газетасының 700 нче санында бастырып чыгара. Күп тә үтми, бу шигырь «Тәфтиләү» көенә җырлана башлый. «Тәфтиләү» көенең, үз чиратында, шулай ук дәвамлы, бай тарихы бар. Гасырлар буе җырланып килгән «Мәхбүс» бәетенең көе, тора-бара үзенең лирик чагылышын үзгәртеп, бай орнаментлы озын көйләр рәтенә керә һәм без белгән «Тәфтиләү» көе рәвешендә җырлана башлый.

Г. Тукайның вакытсыз вафатыннан соң бу яңа туган җыр шагыйрьнең үзенчәлекле моң һәйкәленә әверелә. Шунысы характерлы: борынгы «Тәфтиләү» көе моңлы, сагышлы яңгырашы белән Тукай шигыренең рухына ятышлы тоелса да, бу үлемсез әсәрнең бөтен тирәнлеген, фаҗигале шагыйрь язмышындагы көрәш мотивын, ничектер, әйтеп бетерми төслерәк. Рәхимсез язмыш, гаделсез тормыш белән йөзгә-йөз очрашкан шагыйрьнең күркәм образы, нигездә, лирик планда ачыла. Без язып алган җыр исә, киресенчә, киеренке маршка тартымрак. Аның музыкаль тукымасында көрәш төсмерләнә. Интонацион яңгырашы белән ул XX йөз башында киң таралган шәкерт җырларын («Сада»ларны) хәтерләтә. Җыр Тукай белән мәңгегә хушлашу көннәрендә барлыкка килгән булса кирәк. Югалтуны авыр кичерсә дә, халык бөек шагыйрьнең олы җанлы шәхес булуын, ахыр чиктә, дөньяга, киләчәккә өмет белән карап яшәвен раслый. Бу җыр Пенза өлкәсе, Каменка районы, Кикино авылында яшәүче Сабир ага Патеевтан (1912 елда туган) язып алынды.

### ӨЗЕЛГӘН ӨМИД

Күз карашымда хәзер үзгәрде әшьялар төсе;
Сизлә: үтте яшь вакытлар, җитте гомрем яртысы.




Г. Тукай сүзләренә җырлана торган тагын бер җыр шулай ук шигырь исемен саклап калган. Ул «Көзге җилләр» дип атала. Шагыйрь аны 1910—1911 елларда Урта Иделдә булган ачлык фаҗигаләре тәэсирендә иҗат иткән. Әсәр тирән өзгәләнү, ачыну, сыйнфый ризасызлык рухы белән сугарылган. Кара реакция чорында халыкның коточкыч мохтаҗлыкта, караңгылыкта яшәвен чагылдырган бу шигырь үзе үк җырга соралып тора сыман. Шигырьнең буеннан-буена үстерелеп килгән көзге, шыксыз җил образы үзе генә дә халык җырларындагы традицион образларны иҗади файдалану һәм баетуны раслый. Яраткан шагыйрьнең бу шигырь белән ни әйтергә теләгәнен халык яхшы аңлаган.

«Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен; Ядыма таңрем төшә, бәхтем кара булган саен...» Җыр русчадан тәрҗемә ителгән әнә шундый эпиграф белән башланып китә. «Яктырак йолдыз» образы көйдә дә чагылыш таба, ул күтәренке рухтарак башланып китә. Әмма алга таба көйдә күтәренкелек сүнә, сүлпәнәя бара, киресенчә, киеренкелек арта төшә. Авыр тойгылар, хәсрәтле моң, «бер чылбыр»га тезелеп, көзге җил кебек, төп тонга, әйдәп баручы лейтмотивка әверелә.

Көй үзе 3/4 үлчәмендә иҗат ителгән, әмма һәр тактта басым 2 нче һәм 3 нче чирекләргә туры килә. Аерым басымлы бу иҗекләрдәге тавышлар исә кечкенә генә орнаментлар, мелизматика белән чолгап алынган. Бай орнаментлы һәм аерым басымга ия булган әлеге 2 нче һәм 3 нче чирекләрнең, ягъни төп музыкаль интонациянең кабатланып килүе җырга фаҗигале яңгыраш өсти. Шуның аша шигъри фикер белән музыкаль фикернең тәңгәллегенә ирешелә. Җырның гармоник яңгырашы аның озын гомерле булуына сәбәпче булган. Бу җырны да безгә Ягафәр ага Галәветдинов көйләп күрсәтте.

## КӨЗГЕ ҖИЛЛӘР

Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен;
Ядыма тәңрем төшә, бәхтем кара булган саен.




Шулай итеп, әлеге фольклор экспедицияләре нәтиҗәсендә Г. Тукайның халык музыкасына, татар моңына никадәр нык береккән булуы тагын бер кат раслана төште. Тукай һәм халык моңының аерылгысызлыгы, димәк, Тукай иҗатының үлемсезлеге тагын бер ышанычлы дәлил тапты.

**Котдүс ХӨСНУЛЛИН,**
**Рафис ӘХМӘТОВ.**

# СҮЗ ЭЧЕНДӘ ЭНҖЕ БАР

Туган телебезнең мөмкинлекләреннән, сүзлегеннән һәм грамматик формаларыннан иркен һәм оста файдаланган бөек Тукай теленең фразеологик фонды бай һәм күпкырлы. Шагыйрь стилендә сәнгатьлелек бирүдә, аны баетуда, шагыйрьнең уй һәм тойгыларын, кичерешләрен тулырак ачуда, сөйләмен үтемлерәк, көчлерәк һәм үткенрәк итүдә ул әһәмиятле роль уйный.

Тукай фразеологиясенең үзенчәлеге тагын шунда: автор, барыннан да элек, халыкта киңрәк таралган тотрыклы фразеологик әйтелмәләрне кулланган һәм күренеш-вакыйгаларны, әйтергә теләгән фикерне калкурак итеп сурәтләү максатында алардан бик уңышлы, урынлы һәм иҗади файдаланган. Мәсәлән, **авыздан утлар чәчү** (ашыгып, тиз-тиз сөйләү, ялкынлы речь тоту мәгънәсендә), **бармак янау** (кисәтү, куркыту, янау), **җан ату** (тырышып эшләү, хезмәт итү), **күз ату** (күңел төшү, ягъни ярату, карау мәгънәләрендә), **җан алу** (куркыту, җәфалау, интектерү, каныгу), **җан бирү** (күңел бирү, күңел утырту, үлү), **тугры юлдан язу** (бозылу, начар юлга керү), **кара кан сыгу** (үз-үзеңне аямыйча эшләү, изү, кысу), **вөҗдан сату** (вөҗдансызлык, оятсызлык, намуссызлык), **күз алмасын очырту** (карау), **эчкә дәрт сыймау** (дәртләнү, очыну, талпыну), **күңел сыну** (күңелсезләнү, өмет өзелү, өметсезләнү), **фәлсәфә сату, сафсата сату** (буш сүз сөйләү, лыгырдау, юк-бар сөйләү), **күккә ашу** (шатлану), **бит-баш кызару, йөз кызару** (оялу, кыен-авыр хәлдә калу), **авыз суын корыту** (ару-талу, ялыгу), **хәттин ашу** (очыну, һавалану, әреләнү), **чәчләр үрә тору** (гаҗәпләнү, ис китү), **сүз кушу** (дәшү, сөйләшү) һ. б. фразеологик әйтелмәләр аның иҗатында еш очрый.

Тукай фразеологиясенең урынын, егәрлеген яхшылап күзаллау өчен, аның кайбер шигырь һәм поэмаларына тукталыйк. Мәсәлән, аның 1906 елда язылган «Сорыкортларга» дигән шигырен алыйк. Билгеле булуынча, Г. Тукай шундый характердагы әсәрләре белән үзен чын революционер-демократ шагыйрь итеп танытты. Ул анда изүче сыйныфны рәхимсез рәвештә фаш итте, ә изелүче хезмәт халкын аяусыз революцион көрәшкә чакырды. Тукайның шушы идея-фикерләре, әйтерсең лә, фразеологик әйтелмәләргә төрелеп, сипләнеп бирелгән:

Аристократ — сорыкортлар, калын корсак, кечек башлар;
Ашыйлар соң бирән булган кешеләр, ну гаҗәп, ай-яй!

Бу мисалдагы **«калын корсак»**, **«кечек башлар»** дигән фразеологик әйтелмәләр эксплуататор сыйныфларның бары хезмәт халкын изү аркасында гына баюларын, корсак калынайтуларын, әмма үзләренең кабахәт, миһербансыз сыйныф булуларын тәгәл һәм ачык итеп тасвирлый.

Халык батсын да бетсен, тик боларның эчләре күпсен;
Авызлары ачык бик киң, ниең бар: «Дай сюда, дай-дай!»

Күренүенчә, югарыда китерелгән юлларда сорыкорт-эксплуататорларның яшәү максаты бик дөрес, реаль итеп күрсәтелә: халык **«батсын да бетсен»**, тик боларның **«эчләре күпсен»**, ягъни хезмәт ияләре изелсен, басылсын, кысылсын, көне-төне эшләсен, ә сорыкортлар баесын һәм мул тормыш корсын. Шулай итеп, Г. Тукай шул чордагы социаль тигезсезлекне ап-ачык күргән, җаны-тәне белән янган, борчылган, аны бетерү юлларын эзләгән.

Матур булыр бу корсакларга каршы чаралар корсак;
Тотып ярсак боларны без заман үткәрми, картаймай.

Бу мисалдагы **«чаралар кору»**, **«тотып яру»** дигән фразеологик әйтелмәләр ярдәмендә Г. Тукай хезмәт халкын сорыкортларга каршы кискен **«чаралар корырга»**,

барыннан да элек, **«тотып ярырга»**, ягъни аларның үзләрен җәзаларга чакыра. Тукайча, хезмәт халкының бәхете көрәш, революция аша гына табылырга мөмкин, ә калын корсаклы эксплуататорлар аларның икъбален (якты киләчәген) йоткан, ваткан-җимергән, юкка чыгарган.

Җитәр инде, җитәр инде, давайте сызганыйк җиңне;
Салып ташлыйк киемне: һич өмид юк җиңне сызганмай.

Шагыйрь югарыдагы **«сызганыйк җиңне»**, **«салып ташлыйк киемне»** дигән фразеологик әйтелмәләр аша кыюланырга, изге тартышка, революцион көрәшкә нык-лап әзерләнергә, «гөмбә башлар»ны, сорыкортларны, ягъни изүчеләрнең барысын да тар-мар китерергә, юк итәргә, бетерергә, «Ура!» кычкырып кырып ташларга өнди. Шигырьнең төп идеясе, төп фикере — нәкъ менә шул.

Язам, юк, туктамыйм мин һич, алардан бер дә кот чыкмай.

**«Кот чыкмай»** дигән фразеологик әйтелмә Г. Тукайның беркемнән курыкмавын, революцион-демократ шагыйрь булуын тагын да бер кат исбат итә.

1907 елда көчле патриотик рухта язылган «Китмибез!» дигән шигырендә Г. Тукай кара йөзләр көчләве буенча Төркиягә китүне **«сәкарьгә (тәмугка) керү»**, **«үз-үзеңне утка илтеп терәү»** кебек фразеологик әйтелмәләр белән төгәл аңлата һәм пантюркистларга:

— Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт — хөр Русия!— дип кискен җавап кайтара. Бу юлларда шагыйрь татар халкының язмышы бары хөр Россия белән генә бәйләнгән дип, кара көчләргә, милләтчеләргә, реакционерларга дөрес отпор бирә.

Шагыйребезнең 1908 елда язылган «Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» исемле классик поэмасын күз алдына китерик. Монда иске татар җәмгыяте, аның тәртипләре, ул тәртипләрне теш-тырнаклары белән яклаучылар фаш ителә. Поэмада фразеологик әйтелмәләр, башка тел-сурәтләү чаралары белән чагыштырганда, төп урынны алып тора. Менә аларның кайберләре:

**Таңга калсын** тиречеләр, итчеләр,
Шәмчеләр дә, майчылар, кибетчеләр...
Иртә берлән **кайнамакта бу базар,**
Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр...
Мин дә чаптым шунда мөэминнәр белән,—
Мәскәүски якка **күз салсам,** күрәм...
Сакалы ак, һәм **йөзеннән нур чыкар,**
Күз камашыр — һәркем йөзенә бакар...
Башны күргәч, ихтыярсыз **җан ачый:**
Әй, җаным, бу кайсы мискиннең башый?..
Һәм дә Мәскәүдән дә маллар алмышым,
**Сумына туксан тиенне чәлмешем...**
Бу мидә **йөзләп гыйнад амбары бар,**
Бу мидә **мең пот сыраның пары бар.**
Бу мидә бардыр **җәһаләт ун вагон,**
**«Мин беләмлек» дәгъвасы — бер мең вагон...**

Күренүенчә, халык шагыйре Габдулла Тукай үзенең әсәрләрендә тел хәзинәсенең мөһим һәм кыйммәтле өлеше булган фразеологик әйтелмәләрдән мөмкин кадәр нәтиҗәле файдаланган, күренеш һәм вакыйгаларны ачуда аларны новаторларча кулланган. Әмма шагыйрьнең бу кыйммәтле тел байлыгы, кызганычка каршы, аз өйрәнелгән, аз тикшерелгән әле.

**Габделхәй ӘХӘТОВ,**
филология фәннәре докторы, профессор.

# ТУКАЙНЫҢ ТОРМЫШ ҺӘМ ИҖАТ ХРОНИКАСЫ

Бөек шагыйрьнең тормышын «инәсеннән җебенә кадәр» тикшерү җиңел эш түгел. Биографик материалларның еш кына очракта конкрет булмавы, аерым елларга бөтенләй очрамавы өстәмә кыенлык тудыра. Шуңа күрә шагыйрь тормышына кагылган кайбер даталарны, вакыйгаларны башка кешеләр биографиясендәге, истәлекләрендәге аерым моментларны ачыклап, аларны язучыга бәйле вакыйгалар эченә куеп, төрле яктан чагыштырып эзләргә, билгеләргә туры килә.

Журнал укучыларга «Хроника»ның кыскартылган варианты тәкъдим ителә.

**1886 ел**

**26 апрель**

Габдулла дөньяга килә. Бу турыда метрика кенәгәсендә мондый юллар бар: «Баланың исеме — Габдуллаҗан; каю айда вә көндә туган — 14 апрельдә (иске стильдә), атасы — маншүрле (указлы) имам Мөхәммәтгариф мелла Мөхәммәтгалим угылы; анасы — Миңсафа Зиннәт кызы. Казан өязе. Кушлавыч. Кушлавычта указный имам Мөхәммәтгариф мелла Мөхәммәтгалим угылы кулым куйдым». (ТАССР Үзәк дәүләт архивы. *Алга таба* — ТАССР ҮДА. 4 ф., Коллекцияләр тасвирламасы, 237 эш, 353 б.)

**10 сентябрь**

Габдулланың әтисе Мөхәммәтгариф үлә. «Мелла Мөхәммәтгариф бине мелла Мөхәммәтгалим угылы август 29 ында (иске стильдә) 44 яшендә кату зәхмәте илә вафат булды. Казан өязе Кушлавычта дәфен улды (күмелде)». Әтисе үлгәндә Габдуллага дүрт ай ярым була. (Шул ук эш, 237 б.)

**1887 ел**

**Көз**

Ире үлгәннән соң бер ел чамасы үткәч, Мәмдүдә, нәни Габдулланы алып, Өчилегә атасы Зиннәтулла өенә кайта. (Тукай турында хатирәләр. (*Алга таба «Хатирәләр» дип кенә күрсәтеләчәк.*) Казан, 1975, 23 б.)

**1889 ел**

**3 январь**

Иске стиль белән 22 декабрьдә Өчиледә Габдулланың әнисе Мәмдүдәнең Сасна пүчинкәсе указсыз мулласы Мөхәммәтшакир Фәйзуллин белән никахлары була. Никах турындагы документта Тукай әнисенең исеме Бибимәмдүдә дип күрсәтелә. Габдулланың тууы турындагы таныклыкта әнисенең исеме Миңсафа диелгән иде. Элек татарларда кешене кушылган исеме белән түгел, ә башка исем белән атап йөртсәң, ул кешене чир таба алмый дигән ышану булган. Тукай әнисенең исеме дә шушы йола нигезендә үзгәртелгән булырга тиеш.

**3 январьдан соң.**

Никахтан соң Мәмдүдә Габдулланы яңадан Кушлавычка алып кайта һәм Шәрифә исемле карчыкка вакытлыча тәрбияләргә калдыра. Бу вакытта балага ике яшь тә сигез ай ярым чамасы. (Тукай Г. Әсәрләр, биш томда. Казан, 1986, 5 т., 10 б. *Алга таба җәяләр эчендә том һәм бит саннары гына күрсәтеләчәк.* ТАССР ҮДА, 4 ф., Коллекция тасв., 359 эш, 2 т., 267 б.)

**Ел башыннан язга кадәр**

Габдулла Кушлавычта Шәрифә карчыкта яши. (5, 11.)

**Март — апрель**

Габдулланы әнисе Сасна пүчинкәсенә алып кайта. (5, 11.)

**1890 ел**
**30 январь** Иске стиль белән 18 январьда Габдулланың әнисе Мәмдүдә 26 яшендә вафат була һәм Күчкән Сасна авылы зиратына күмелә. Габдуллага бу вакытта 3 яшь тә 9 ай булган. (5, 11; ТАССР ҮДА, 4 ф., 1 тасв., 68 эш, 160 б.)

**Февраль — март** Зиннәтулла үзенең оныгы Габдулланы Өчилегә алып кайта. (5, 12.)

**Ел ахыры (?)** Зиннәтулла Габдулланы, Өчиледән Казанга бара торган бер ямщикка утыртып, Казанга озата. Казанда аяк киемнәре тегеп сату белән көн күргән һөнәрче Мөхәммәтвәли баланы өенә алып кайта. (5, 12.)

**1891—1892 еллар** Казанда Мөхәммәтвәли белән Газизә гаиләсендә Габдулланың тамагы тук, өсте бөтен була. Әтисе Мөхәммәтгариф ягыннан бертуган апасы Газизә белән очрашып тора. (5, 13; «Хатирәләр», 17 б.)

**1892 ел**
**Яз ае** Мөхәммәтвәли белән Газизә авырып китәләр һәм, баланы Казанга китергән ямщикны табып, Габдулланы янә Өчиле авылына, Зиннәтулла бабасына кайтарып җибәрәләр. (5, 14.)

**Июнь урталары** Габдулла Сәгъди арбасына утырып Өчиледән Кырлайга килә. (5, 14—16.)

**Җәй** Габдулла җәйне малайлар белән уйнап, су коенып, хозурлыкта уздыра. 30 июльдә урактан авырып кайтып, Сәгъдинең кызы Бибисабира үлә. (5, 16.)

**Көз** Сәгъдинең хатыны Бибизөһрә Габдулланы әтисе (Мөхәммәтгариф) белән бергә Кышкар мәдрәсәсендә укыган Кырлай имамы һәм мөгаллиме Фәтхерахман Гобәев өенә алып бара. Бу кышны Габдулла кызлар белән бергә Фәтхерахманның хатыны Маһруйбикә абыстайда укый. (5, 19; Г. Г[illegible]айдуллин истәлеге. СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивында саклана. 9 ф., 4 тасв., 55 эш.)

**1893 ел**
**Җәй** Бу җәйдә кечкенә Габдуллага Сәгъди абзыйның узган елның 28 декабрендә (иске стильдә) туган Садретдин исемле улын юатып, тирбәтеп утырырга туры килә. Урак вакытында аны, кечкенә Садрины арбада тартып йөрер өчен, кырга да алып чыгалар. «Бу бала тугач... мин үз өлешемә төшкән аз гына мәхәббәттән дә коры калдым», — ди соңыннан Тукай. (5, 21; ТАССР ҮДА, 4 ф., Коллекция тасв., 419 эш, 348 б.)

**Көз** Габдулланы мәдрәсәгә укырга бирәләр. Башта ул Гатауллин Хәбибрахман хәлфәдә укып йөри. «Озак тормыйча Фәтхерахман мулла аны үзе укыта башлады. Фәтхерахман мулланың ...аны алай үзен генә аерып укыта башлавына без көнләшә башладык. Аның бик тиз арада гына «Һәфтияк» иҗеген укып бетереп, сүрәгә күчүе, язга кадәр «Һәфтияк» сүрәсен бетереп, Коръән укырга башлавы безне бераз кытыкландыра иде. Чөнки башка балалар тик ике-өч ел эчендә генә алай укый алалар иде». Габдулла бу мәдрәсәдә «Бәдәвам», «Кисекбаш» китапларын укый. Аңа өйрәтергә дип надан шәкертләрне дә бирә башлыйлар. (5, 21; Тукай турында замандашлары. Казан, 1960, 31—33 б; *алга таба «Замандашлары» дип күрсәтеләчәк.)*

**25 декабрь** Өчиледә Габдулла әнисенең сеңлесен — Сәҗидәне кияүгә бирәләр. Шул уңай белән Габдулланы да Кырлайдан Өчилегә кунакка алып кайталар. (5, № 2. *Хатлар номер белән күрсәтелә.* Рәсүлева З. Тукай эзләреннән. Казан, 1985, 14 б., Р. Якупов искәрмәсе.)

**1894 ел**
**13 апрель** Иске стиль белән 30 майда 15 яшендә, чахотка белән газаплы озак авырудан соң, Сәгъдинең кече кызы Бибисаҗидә үлә. (ТАССР ҮДА, 4 ф., Коллекция тасв., 489 эш, 597 б.)

**Көз** — Кушлавыч кешесе Бәдретдин Габдулланы Кырлайдан алып китә. Кушлавычка барышлый Өчиле авылына, Габдулланың бабасы Зиннәтулла янына да кереп чыгалар.

Кушлавычта Габдулла берничә ай тора. Бәдринең улы Камалетдин белән бергә авыл мәдрәсәсенә укырга йөри. Ниһаять, Бәдри, Уральскига озату нияте белән, малайны Казанга алып бара. Биредә Габдулла Казандагы әти-әнисе Мөхәммәтвәли һәм Газизә белән очраша. (5, 25—27; «Хатирәләр», 25 б.)

**1894 ел ахыры яки 1895 ел башы** — Габдулла Алты-Биш Сапый (Сафый)ның өсте ябулы чанасында 18 көн барып, әтисенең бертуган сеңлесе Газизә апасы белән җизнәсе Галиәсгар Госмановлар яшәгән Уральск каласына барып җитә. Габдуллага бу вакытта сигез яшь ярымнан артыграк була. (5, 27; Тукай эзләреннән, 14 б.)

**1896 ел** — Габдулла Уральскида «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укый башлый.

**Көз** — Башта ул «Мотыйгыя» мәдрәсәсе каршындагы рус классына йөри. Анда аны Әхмәтша Сираҗетдинов укыта. Пушкин, Лермонтов, Крылов һәм башка рус язучыларының әсәрләрен Габдулла беренче тапкыр Әхмәтша учительдән алып укый.

**1900 ел** — Иске стиль белән 30 июльдә Габдулланың җизнәсе Галиәсгар Госманов вафат була. Габдулла Газизә апасы йортыннан китеп, мәдрәсәдә торып укый башлый. Ул укуын тәмам иткәч тә бер ел чамасы мәдрәсәдә яши. («Хатирәләр», 35 б.)

**1902—1903 еллар** — «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә Истанбулда укыган төрек шәкерте шагыйрь Габделвәли килә һәм биредә бер кыш укый. Мотыйгулла хәзрәттән гарузны — шигырь төзелешен өйрәнеп йөргән Габдулла аның белән бик тиз дуслашып китә.

Тукай Казандагы иптәшләренә бу егетнең бик гыйлемле булуы, үзенең мәдрәсә тормышында аның уңай роль уйнавы турында сагынып сөйли. («Хатирәләр», 82 б.)

Мәдрәсәдә атна саен җыр кичәләре оештырыла. Габдулла кичәләрдә иң оста җырчылардан санала.

1903 елда мәдрәсәдә «Мәгариф» исемле стена газетасы чыгарыла. Бу газета 1904 елда «Әлгасрелҗәдит» исемендә кулъязма журнал булып чыга башлый. Тукай аларны оештыручы һәм иң актив язышучыларыннан була. (Татарстанның Берләштерелгән үзәк дәүләт музее. Сирәк очрый торган кулъязмалар бүлеге, № 124390.)

**1904 ел** — Габдулла «Уралец» типографиясенә хәреф җыючы өйрәнчеге булып керә. Шунда ул рус эшчеләре белән таныша. («Хатирәләр», 30 б.) Тукай турыдан-туры социал-демократик өндәмәләр тарату эшенә тартыла. Типографиядә социал-демократларның ячейкасы оештырылган була. Тукай большевиклар белән аралашып, тыелган әдәбият укылган җыелышларда катнашкан, хәреф җыючы булып эшләүче большевик А. А. Коканов белән дуслык мөнәсәбәтләрендә булган. Типографиядә төрле вазифаларны үтәүче А. М. Сенькин, П. П. Зуев, И. Д. Хвостов кебек большевиклар белән аралашкан.

Тукай сәүдәгәр Додоновның кирпеч заводында да булган, анда эшләүче рус һәм татар эшчеләренә үзенең журналларын, шулай ук тыелган әдәбият тараткан. (Нәфиков Р. Тукайның иптәшләре һәм танышлары.— «Казан утлары», 1984, 5 сан.)

**1905 ел 15 сентябрь** — 1906 ел башында чыга башлаячак «Әлгасрелҗәдит» журналының игъланын, программасын, шул чордагы күренекле әдәбият-культура әһелләренең тәбрик-теләк хатларын эченә алган 16 битле брошюраны чыгарырга цензура рөхсәте алына. Брошюрада булачак журналның редакторы Камил Мотыйгый Төхфәтуллинга Тукайның мөрәҗәгать хаты һәм «Гөлүмең бакчасында...», «Чөнанча бездә...» дип башлана торган исемсез шигырь-мәдхияләре басылып

чыга. Болар Тукайның беренче басма шигырьләре. Брошюра Оренбургта басыла.

**Октябрь** Габдулла типография эшчеләре белән бергә демонстрациягә чыга. Эшчеләр 8 сәгатьлек эш көне таләп итәләр. Демонстрация шәһәр уртасындагы митинг белән тәмамлана. («Хатирәләр», 31 б.)

**22 октябрь** Хәбәр басылып чыга: «Якшәмбе көн 15 октябрьдә... «Казан миһманханәсендә якында ачылачак җәмгыяте хәйриянең уставларын тәртип өчен хосуси бер җәмгыять булды. Җәмгыять шул кешеләрдән гыйбарәт иде: мөхәррир К. М. Төхфәтуллин, М. Ф. Мусин, Г. Коләхметов, К. Бахтюзин, Г. Тукаев, М. Мамашев, С. Сабитов, Х. Сөләйманов, В. Хәмидуллин, С. Гобәйдуллин» («Фикер», № 39.)

**27 ноябрь** Уральскида К. Мотыйгый редакторлыгында һәм наширлегендә демократик юнәлештәге «Фикер» газетасы чыга башлый. Тукай секретарь буларак та, иҗаты белән дә газетада бик актив катнаша.

**1906 ел**

**15 январь** Уральскида К. Мотыйгый редакторлыгында һәм наширлегендә әдәби, фәнни һәм иҗтимагый журнал — «Әлгасрелҗәдит» чыга башлый. Тукай журналның фактик редакторы була һәм һәр санында берничәшәр шигъри һәм чәчмә әсәрләрен бастыра.

**1 май** Уральскидагы типография эшчеләре демонстрациягә чыгалар. «Без Апуш белән икәү киттек. Демонстрациягә тимер юл эшчесе Николай Покатилов җитәкчелек итте... Казаклар безне кудылар... Өлкән иптәшләрнең кушуы буенча, прокламацияләр, революцион җырлар таратып йөрдек («Карт вахмистр» дигән листовка, «Варшавянка», «Смело, товарищи, в ногу» җырлары)». («Хатирәләр», 31 б.)

**6 май** «Матбугате исламия» рубрикасы астында хәбәр басылып чыга: «Уральск» «Әлгасрелҗәдит»нең № 4 килде. «Гыйшык бу, йа...» вә... «Мөридләр каберстаныннан бер аваз»... шигырьләре бәхак (чын) гүзәл вә журналның чичәгедер» («Вакыт», № 22.)

**15 июнь** Уральскида К. Мотыйгый редакторлыгында демократик юнәлештәге, татар телендә беренче айлык рәсемле сатирик журнал — «Уклар» чыга башлый. Мотыйгый журналны тулысынча Тукайга тапшыра. Тукай, журналга яраклы материал бирүчеләр аз булганлыктан, аны нигездә үзе язып тутыра.

**27 июнь** «Әлгасрелҗәдит»нең 6 нчы саны чыгу уңае белән хәбәр басылып чыга. «Ошбу журналның һәр номерында диярлек Г. Тукаев намында бер затның күпме-азмы... әсәрләре булыныр... Бу кемсәнең иң элек күрелмеш (шигырьләре) ләззәтле вә күңелләргә сөекле тоелмыш (иде)... Милли шагыйрьләремезнең даһиларыннан улачагына өмид идәрез». («Вакыт», № 42.)

**5 июль** Уральскида аяк киемнәре тегү мастерское тоткан сәүдәгәр Шәрәфетдин Галиуллин өендә яшерен мәҗлес җыела. Уральск миллионеры Хәйрулла Гаделшин мәҗлестәгеләрне «Фикер» газетасы идарәсенә һөҗүм итеп, машиналарны, кассаларны ватарга, идарә хуҗасы К. Мотыйгыйның үзен, балаларын кыйнарга, «Фикер»нең шагыйрен (Г. Тукайны) «эләктерсәңез аны да кыйнагыз» дип котырта. Бу погромны башкару өчен Гаделшин 40 кеше, Гайнетдин Җәләлетдинов 20 кеше табарга булалар. («Фикер», № 25.)

**24 сентябрь** Диния назаратына хат языла. Хатта моннан ун ел элек үлгән Гайнулла Гаделшинның мәчет файдасына дип калдырган ике таш пулатыннан доход бармы, без ул пулатларда Укытучылар институты ачар идек, диелә. Хатка кырык кеше кул куйган, алтынчы кул — Габдулла Тукайныкы. («Фикер», № 36.)

**1 октябрь** «Казан» кунакханәсендә Уральскида Укытучылар институты ачу хакында җыелыш була. «Безгә шул борынгы мәдрәсәләремез дә җитәр» дип, институт ачуга каршы чыккан Ф. Шәриповка Тукай болай ди: «Юк, Фатих абзый! Безнең ул мәдрәсәләремез генә җит-

ми. Башка милләтләрдәге кеби безгә дә 3—4 этажлы мәдрәсәләр кирәк. Син, Фатих абзый, әле күптән түгел генә ярлы идең. Син шул ярлылыгым җитәр дип тормадың, кибет ачтың, сәүдә иттең, һәр ничек баерга тырыштың. Инде мәдрәсә ачу хосусына килгәндә, җитәр дип әйтәсең... Юк, җитмәс. Җитәр дип әйтмә. Безнең мәдрәсәләремез руслар мәдрәсәсенең таһарәтханәсеннән дә шакшырак. Китабез алга! Китабез, канәгать итмибез бу мәдрәсәләргә!» («Фикер», № 37.)

**9 декабрь**

«Әлгасрелҗәдит»нең 11 нче саны чыгу уңае белән хәбәр басыла. «Бу журналның һәрбер нөсхәсенә махсус бер зиннәт биреп килмәктә улан борадәремез Тукаевның гүзәл шигырьләре бу нөсхәдә һәм бар. «Сөеклемнең кабер ташына» сәрләүхәле (исемле) улан һәм дә «Үз-үземә» сәрләүхәле... шигырьләре иң гүзәл улып, безем татарлар агызыннан беренче дәфга (тапкыр) ишетелмәктәдер». («Вакыт», № 108.)

## 1907 ел

**6 январь**

Тукай үзенең «Мотыйгыя» мәдрәсәсеннән чыгуы, «Казан» кунакханәсендә яшәве турында хәбәр итә. («Фикер», № 1.)

**14 март**

«Казан» кунакханәсе залында концерт була. «Халык күп иде. Күбрәк татарлар вә азрагы руслар иде... Тукаев илә Сираҗетдин Билюков әфәнделәр чыгып, шарык исулынча тезләнеп, милли кием илә «Кичке азан» шигырене укыдылар. 4 нче пәрдә күтәрелгәч, Г. Тукаев теләнче киеме киенгән Хәкимҗан Йосыповның өстенә карап, «Теләнче» сәрләүхәле (исемле) шигырене сөйләде... 6 нчы пәрдәдә янә Г. Тукаев чыгып, үзенә кушылырга музыка булмаганлыктан, иң әүвәл халыкка хитабән: «Я сам балалайка, сам гитара» дип кычкырып, «Турецкий марш»ны җырлады». («Фикер», № 11.)

**Май**

«Фикер» газетасы һәм «Әлгасрелҗәдит» журналы чыгудан туктый.

**3 октябрь**

Казанда демократик яшьләр тарафыннан «Әльислах» газетасы чыга башлый. Тукай бераздан бу газетада әсәрләрен бастырачак, шулай ук әдәбият бүлеген алып барачак.

**Октябрь башлары (?)**

Тукай Казанга килә. «Болгар» кунакханәсенә урнаша. Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Сәгыйть Рәмиевләр белән таныша. Берничә көннән солдатка каралырга дип туган ягына кайтып китә. Каенсар, Яңа Кырлай, Кушлавыч, Олы Мәңгәр авылларында була, туганнарын, якыннарын күрә. (Нуруллин И. Габдулла Тукай. Казан, 1979, 124 б.)

**26—27 октябрь**

Әтнәдә рекрутларның комиссия көне. Габдулла врачлар яныннан «ак билет» алып чыга. (Шул ук китап, 127 б.)

**Ноябрь башлары**

«Авылдан килгәч, Тукай бераз вакыт «Шәрәфләргә — «Мәгариф» көтепханәсенә саткан шигырьләреннән алган гонорары белән җан асрап килә... «Әльислах» чыга башлагач, Тукай шунда җиң сызганып эшләргә тотынды. Ләкин ярлы оешманың барлы-юклы гына акчасына чыгарыла торган «Әльислах»тан алган чирек-чорык гонорарлар гына Тукайның тормышын тәэмин итә алмыйлар». («Хатирәләр», 63 б.)

**Ноябрь башлары**

Тукай «Китап» нәшриятына, Габдерахман Дәүләтшин янына, аена 25 сум эш хакы белән экспедитор булып урнаша, эшләгән җирендә куныл та йөри. («Хатирәләр», 64 б.)

**14 ноябрь**

«Г. Тукаев шигырьләре» басылып чыга («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр)[1]. Беренче кыйсем. Казан, Шәрәф матбагасы. «Әльислах» газетасының 1907 елгы 3 декабреннән 1908 елгы 21 январена кадәр булган саннарның һәрберсендә бизәкле рам эчендә бу китап турында белдерү басылып бара.

---

[1] Тукай әсәрләренең дөньяга чыгу вакыты ТАССР Үзәк дәүләт архивындагы Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының басылып чыккан барлык китапларны теркәү дәфтәре буенча куелды. 420 ф., 1 тасв.

**1 декабрь** «Яңа китаплар» рубрикасы астында хәбәр басылып чыга. «Г. Тукаев шигырьләре». «Ушбу исем илә Габдулла әфәнденең шигырьләре... басылып чыкты... Бик күп кемсәләр ялгыз назыйм (тезмә әйберләр язучы, рифмачы) гына улдыклары хәлдә, Габдулла әфәнде һәм назыйм һәм шагыйрьдер. Укучылар боны гүзәл белерләр. Гарифә тәгъриф (аңлатып тору) кирәкмәс». («Вакыт», № 251.)

«Болгар» номерларында «Шәрык» клубы эшли башлый. Аның программасына әдәби-музыкаль кичәләр үткәрү, спектакльләр кую, китаплар, газеталар алдыру, шулай ук фәннең төрле тармаклары буенча белгечләр белән очрашуларны оештыру керә. Клубта татар, рус спектакльләре, татарча-русча берләштерелгән концертлар да куела.

Тукай бу кичәләрне оештыручыларның иң активларыннан була.

Кичәләрдән килгән акча большевикларның шәһәр комитеты кассасына тапшырыла, ә бер өлеше исә үзәк большевистик матбугат органнарына, шул исәптән «Правда» газетасына язылу өчен тотыла. (Нафигов Р. Тайны революционного подполья. Казань, 1981, 174 б.)

**1908 ел**

**6 январь** «Габдулла Тукаев шигырьләре» басылып чыга («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр). Икенче кыйсем. Казан, Шәрәф матбагасы.

**Февраль** Охранканың Чистай шәһәрендәге агенты «Персий» «Габдулла Тукаев шигырьләре» (4 нче дәфтәр) китабын һәм андагы шигырьләргә карата үзенең аңлатмаларын Казан губернасы жандармерия идарәсенә җибәрә: «...Это враждебного содержания, против правительства...» (ТАССР ҮДА, 199 ф., 1 тасв., 3458 эш, 43 б.)

**28 март** «Әльислах» газетасы редакциясе яшьләре әдәби-музыкаль кичә оештыралар. Тукай кичәдә үзенең «Утырышу» шигырен укый. Аны С. Рәмиев Г. Коләхметовлар алыштыра.

Ф. Әмирхан «Әдәби кичә» исемле мәкаләсендә Г. А. Трейтер ханымның татарча җырлавы, ул оештырган кызлар хоры чыгышы турында сокланып язган.

Тукай 1908 елда Г. А. Трейтер ханымга немец телен өйрәнергә йөргән. Алар кичәләрдә, шул исәптән рус-татар кичәләрендә дә очрашканнар. (Нәфиков Р. Тукайның дусты, партия солдаты.— «Казан утлары», 1986, 2 сан.)

**3 август** Г. Камал редакторлыгында «Яшен» журналы чыга башлый. Тукай журналның секретаре булып тора. Эшнең зур өлешен үз өстенә ала, аның рухы һәм җаны була. Журнал барлыгы 10 сан чыга.

**5 август** Г. Тукай Галиәсгар Камал белән бергә Нижний Новгородка Мәкәрҗә ярминкәсенә бара. Тимерша Соловьевның «Двухсветная» кунакханәсендә торалар. Г. Кариев, шулай ук «Сәйяр» труппасының башка артистлары белән бергәләп кунакханә залында җыр кичәләре оештыралар. Тукайның Мәкәрҗәдә булуы турында хәбәр басылып чыга: «Гәзитәмезнең даими язучыларыннан Г. әфәнде Тукаев 5 августтан бирле Нижнийда торып, августның 18 ләрендә Казанга кайтачак». («Хатирәләр», 85—88. «Әльислах», 1908, № 41).

**22 октябрь** «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» китабы басылып чыга. (Шигырьләр көтепханәсе»ннән 7 нче дәфтәр.) Казан, И. Н. Харитонов лито-типографиясе.

**8 ноябрь** «Җуаныч» җыентыгы басыла («Мәктәп мөкяфәте»ннән беренче китап). Казан, «Сабах» көтепханәсе.

**14 ноябрь** «Алтын әтәч» әкият-поэмасы басыла («Мәктәп мөкяфәте»ннән икенче китап). Казан, «Сабах» көтепханәсе.

**Декабрь** «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» китабының икенче басмасы чыга. И. Н. Харитонов лито-типографиясе.

| | |
|---|---|
| **1909 ел** 14 январь | «Габдулла Тукаев диваны» басыла (Шигырьләр көтепханәсе»ннән 8 нче дәфтәр). 3 нче кыйсем. Казан, «Гасыр» көтепханәсе, «Үрнәк» матбагасы. |
| Февраль | «Алтын әтәч» әкият-поэмасының икенче басмасы чыга. «Сабах» көтепханәсе. |
| 6 март | «Габдулла Тукаев шигырьләре»нең икенче басмасы чыга. (Шигырь көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр.) Казан, «Үрнәк» матбагасы. Бу басма 1907 елгы басмадан үзгәрәк эчтәлек белән чыга: элекке җыентыкта булган кайбер шигырьләр кертелмәгән, шулай ук беренче басмада күренмәгән шигырьләр соңгы басмада бирелгәннәр. |
| 11 март | «Габдулла Тукаев» шигырьләренең икенче басмасы чыга. («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр) 2 нче кыйсем. Казан, «Үрнәк» матбагасы.<br>Беренче басмадагы «Китмибез!» шигыре цензура тарафыннан соңгы басмадан төшереп калдырылган. |
| 26 март | «Энҗе бөртекләре» исемле мәсәлләр җыентыгы басыла. Казан, «Мәгариф» көтепханәсе, «Үрнәк» матбагасы. |
| 3 сентябрь | Тукайның «Яңа кыйраәт» исемле дәреслек-хрестоматиясе басыла. Казан, «Үрнәк» матбагасы. |
| 27 октябрь | «Әдәбият» басыла. («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 10 нчы дәфтәр). Казан, «Үрнәк» матбагасы. |
| 12 ноябрь | «Исемдә калганнар»ы басыла. Казан, «Үрнәк» матбагасы. |
| 23 ноябрь | «Балалар күңеле» басыла. Беренче җөзә. Ибтидаи мәктәпләр өчен шигырьләр мәҗмугасе. Казан, «Сабах» көтепханәсе. |
| 1910 елларга кадәр | Каванда Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камаллар әйдәвендә барган әдәби хәрәкәт татар әдәбиятының төп магистрале санала һәм татар революцион демократиясе юнәлешендә барган бу куәтле өчлек үзәге белән татар большевиклары Ямашев, Дулат-Алилар дусларча мөнәсәбәттә булганнар. 1909—1910 елларда Тукайның вакыт-вакыт кеше күзеннән югалып яши торган бер почмагы нәкъ шушы Яңа Бистәдәге Дулат-Алилар йорты булган. (Исәнбәт Н. Г. Тукайның мәгълүм булмаган бер шигыре һәм Мәхмүт Дулат-Али хакында. «Казан утлары», 1976, 4 сан.) |
| **1910 ел** 15 март | Казанда Э. Урманчиев редакторлыгында һәм наширлегендә рәсемле сатирик журнал «Ялт-Йолт» чыга башлый. «Яшен» журналы 1909 елның июнендә чыгудан туктагач, Тукай «Яшен» мәрхүм» исемле юмористик язмасында: «Сез бу «Ялт-Йолт»ны кайдан ялтырый дип беләсез? Ул һаман шул яңадан терелгән «Яшен» нурыннан ялтырый», ди. Тукай бу журналның да җаваплы секретаре була. («Ялт-Йолт», № 2). |
| 12 апрель | «Күңелле сәхифәләр»е басыла. («Мәктәп» мөкафәтеннән 4 нче китап). Казан, «Сабах» көтепханәсе. «Милләт» матбагасы. |
| 15 апрель | «Шагыйрьләремездән Габдулла Тукаев җанабләре «халык әдәбияты һәм милли көйләр вә шигырьләр» хакында лекция укыды. Лекциядә нинди хикәя вә шигырьләрнең халык әдәбияты дип аңлаганлыгын, татар көйләрендән бәгъзеләренең нинди мөнәсәбәт илә чыкканлыгын... мисаллар илә күрсәтте. Мисаллар арасында көлдергеч шигырьләрнең булуы тыңлаучыларның һушына килде. Алар (бик канәгать булып) лекция укылып беткәч кул чабып Тукаев җанабларын тәбрик кылдылар». («Йолдыз», № 529.) |
| 29 апрель | «Халык моңнары» басыла. Җыючысы: Шүрәле. Казан, «Сабах» көтепханәсе, «Милләт» матбагасы. |
| 20 июнь | «Халык әдәбияты» басыла. Казан, «Сабах» көтепханәсе. |

| | |
|---|---|
| 9 июль | «Әдәбият»ның 2 нче басмасы чыга. («Шигырьләр көтепханәсе»нән 10 нчы дәфтәр). Казан, «Мәгариф» көтепханәсе. |
| 5 октябрь | «Яңа кыйраәт» басыла. (Үзгәртелгән, өстәлгән 2 нче басма). Казан, «Үрнәк» матбагасы. |
| 18 декабрь | «Балалар күңеле» басыла. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Казан, «Мәгариф» көтепханәсе, «Үрнәк» матбагасы. |
| **1911 ел** | |
| 26 март | «Күңел җимешләре» басыла. Казан, «Сабах» көтепханәсе, И. Н. Харитонов лито-типографиясе. |
| 23—24 апрель | Тукай пароходта Казаннан Әстерханга бара. «Люкс» кунакханәсенә төшә. Соңыннан Сәгыйть Рәмиев белән бергә Даут Мөхәммәдиев өендә яши. «Идел» газетасы редакциясенә килеп йөри. Май ае башында Сәгыйть Рәмиев һәм газетаның башка хезмәткәрләре белән Сәмәк авылына маевкага бара. Маевкада әзербайҗан халкының атаклы драматургы һәм җәмәгать эшлеклесе Нариман Нариманов та катнаша.<br>Калмык Базары исемле авылга китеп Шәһит Гайфетдинов өендә тора. Иҗат белән шөгыльләнә, кымыз эчеп дәвалана. Әстерханда эшчеләр бистәсе — Тияктә, шулай ук шагыйрь Әстерханнан китәр алдыннан аның хөрмәтенә шәһәрнең Кышкы театрында әдәби кичәләр уздырыла. (5, 29—31; «Замандашлары», 116—123 б.) |
| 25 май | Казан университеты типографиясе эшчесе Әхмәтвәли Әхмәдуллин өендә тентү була. Донос кәгазендә Әхмәдуллинның тыелган китаплар саклавы турында әйтелгән. Беркетмәдә тасвирланган 88 басма китапның беренчесе итеп «Габдулла Тукаев шигырьләре» (4 дәфтәр) язылган. (ТАССР ҮДА, 199 ф., 2 тасв., 1237 эш.) |
| 6 июнь. | Тукай Әстерханнан Казанга кайтып китә. (Нуруллин И. Габдулла Тукай, 238 б.) |
| 12 июнь | «Мияубикә» басыла. («Мәктәп көтепханәсе»ннән 1 нче китап). Казан, «Сабах» көтепханәсе. |
| 23 июль. | Жандармерия подполковнигы Добродеев тәрҗемәче ярдәмендә Әхмәдуллиннан алынган китапларны тикшерә, һәм берничә китапны, шул исәптән «Габдулла Тукаев шигырьләре»н дә «китаплардагы аерым тенденциоз урыннарны тәрҗемә итеп, эчтәлектәге политик юнәлешләрне билгеләү өчен» жандармерия идарәсенең начальнигы аша Казан Матбугат комитетының (цензураның) председателенә җибәрү турында отношение яза. Шулай итеп, 1908 елда жандармерия агенты «Персий»нең доносыннан соң сүрелеп торган «эш» яңадан калкып чыга. (ТАССР ҮДА, 199 ф., 2 тасв., 1237 эш.) |
| 1 август | «Яшен ташлары» басыла. Беренче җөзә. (Авторы: Шүрәле.) Нашире: Су анасы. Казан, «Өмид» матбагасы. |
| 23 ноябрь | «Балалар күңеле» басыла. Беренче кыйсем, 2 нче табгы, Казан, «Сабах» көтепханәсе. |
| 26 ноябрь | Казан Матбугат эшләре комитеты «Габдулла Тукаев шигырьләр»ен (4 дәфтәр) тәрҗемәсе белән бергә теркәп, Казан суд палатасына отношение җибәрә: аерым шигырьләрдә җинаять билгеләре табылуын һәм Комитет тарафыннан китапка арест салынуын хәбәр итә һәм Суд палатасыннан арестны раславын, җыентыкның авторын хөкемгә тартуын үтенә. (ТАССР ҮДА, 420 ф., 1 тасв., 179 эш.) |
| 28 ноябрь | Казан Матбугат комитеты Петербургтагы Матбугат эшләре буенча Баш идарәгә «Габдулла Тукаев шигырьләре»нә (4 нче дәфтәр) арест салу һәм авторын хөкемгә тарту турындагы фикерен һәм Казан Суд палатасына киткән отношениенең күчермәсен җибәрә. (ТАССР ҮДА, 420 ф., 1 тасв., 179 эш.) |
| 16 декабрь | Казан Суд палатасыннан Казан Матбугат эшләре комитетына отношение китә: Суд палатасы Комитетның 26 ноябрьдә җибәр- |

гән отношениесендәге фикер белән килешми. «Габдулла Тукаев шигырьләре»ндә (4 дәфтәр) җинаять билгеләре юк дип саный һәм китапка арестны расламый.

Шулай итеп, прогрессив кешеләрнең ярдәме белән, озак вакытлардан кабарып килгән «эш» юкка чыга. (ТАССР УДА, 420 ф., 1 тасв., 179 эш.)

**18 декабрь**

Казан Суд палатасы Петербургтагы Матбугат эшләре буенча Баш идарәгә үзенең «Габдулла Тукай шигырьләре»нә (4 нче дәфтәр) арестны расламау турында 16 декабрьдәге карарын җибәрә. (ТАССР УДА, 420 ф., 1 тасв., 179 эш.)

**Декабрь ахыры.**

Тукай Өчилегә китә. Габдулла әнисе Мәмдүдәнең ата бер, ана башка булган энесе Кәшфелкәбир белән аның хатыны Рабига тәрбиясендә яши. «Ялт-Йолт»ка үзенең әсәрләрен җибәреп тора. Ләкин иптәшләренә авылдагы адресын беркемгә дә бирмәскә куша. Туганнарыннан, үзен тикшерәләр дип, өйгә килгән кешеләргә аның кайтуын белгертмәскә үтенә. (5, 34, «Хатирәләр», 124 б.)

**1911—1912 еллар.**

Х. Ямашев студентларның әдәби-политик түгәрәге җитәкчеләренең берсе була. Аның белән бергә түгәрәктә укытучы Г. Коләхмәтов, шагыйрь Г. Тукай, наширләр һәм редакторлар, язучылардан — Г. Хәсәнов, Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Дулат-Али, Г. Сәйфетдинов һ. б. эшлиләр. Жандармерия аларны бертуктаусыз, яшерен күзәтү астында тота. (Нафигов Р. Тайны революционного подполья, 131 б.)

## 1912 ел

**Ел башы (?)**

«Яшен ташлары» басыла. Икенче җөзә. (Авторы: Шүрәле). Нашире: Су анасы. Казан, «Өмид» матбагасы.

**11 февраль**

«Балалар күңеле» басыла. Икенче кыйсем. Казан, «Өмид» матбагасы.

«Яшен ташлары» басылып чыга. Беренче җөзә. 2 нче басма. (Авторы: Шүрәле). Нашире: Су анасы. Казан, «Өмид» матбагасы.

**Февраль ахыры**

Тукай Өчиледән Казанга кайта. Бераз вакыт квартирада торып ала, аннары «Свет» кунакханәсенә күчә. (5, 37—45.)

**14 апрель**

Тукай «Фультон» пароходында Уфага китә. Беренче тукталышта — Самарада пароходтан төшә һәм «Бристоль» кунакханәсенә урнаша. «Икътисад» исемле журналның редакторы Фатих Мортазин белән очраша. (5, 47—49.)

**15 апрель**

Тукай поездга утырып Уфага китә. Уфада ул «Сабах» ширкәтендә була. Мәҗит Гафури белән очраша. (5, 52—56; «Хатирәләр», 135 б.)

**Апрельнең 18-20 ләре**

Тукай Уфадан Петербургка китә. Биш көн Муса Бигиев квартирасында яши. Соңыннан кунакханәгә күчә. «Нур» газетасында була. К. Бәкер, К. Сәгыйть, С. Баязитов, Ш. Мөхәммәдьяровлар белән очраша. Университет докторы Александр Робертович Польга күренә. Доктор Тукайның иптәшләренә: «Туберкулезның соңгы дәвере... тын ала торган әгъзаларының дүрттән бере белән генә сулап тора»,— ди. Тукайга Петербургтан тизрәк китәргә, санаторийга барып дәваланырга киңәш итә. (5, 57—62; «Хатирәләр», 140—163.)

**2 май**

Тукай поезд белән Уфага китә. Кәбир Бәкер аны Мәскәүгә кадәр озата бара. («Хатирәләр», 162—163).

**4—5 май**

Тукай кабат Уфага килә. Танышлары аны шактый йончыган кыяфәттә күрәләр. Уфада ул атнадан артык тора, М. Гафури белән очрашып йөри. (5, 62; «Хатирәләр», 138 б.)

**Май урталары**

Тукай Троицкига юл тота. Ул бирегә мулла Габдрахман Рахманкулов чакыруы буенча, кымыз белән дәваланырга килә. Троицкида берничә көн торгач, шагыйрьне шәһәрдән 25 чакрым җиргә, сахрага алып китәләр, аның өчен махсус чатыр коралар. «Ялт-Йолт»

идарәсенә. Урманчиевка хатлар, үзенең әсәрләрен почта аша җибәреп тора. (5, 63—64.)

| | |
|---|---|
| **17 май** | «Сабитның укырга өйрәнүе» чыга. Казан, Н. И. Харитонов типографиясе. |
| **25 май** | «Халык моңнары» басыла. Икенче табгы. Җыючысы: Шүрәле. Казан, «Сабах» көтепханәсе.<br>«Халык әдәбияты» басылып чыга. Икенче табгы. Казан, «Сабах» көтепханәсе, «Өмид» матбагасы. |
| **Июльнең 20 ләре** | Тукай Троицкидан Казанга кайта. «Свет» кунакханәсендә яши башлый. «Җан азыклары» җыентыгы өстендә эшли. (Нуруллин И. Габдулла Тукай, 283 б.) |
| **26 июль** | Евангелическая (хәзерге Татарстан) урамындагы Хәсәнов йортында татар яшьләренең революцион түгәрәге чираттагы җыелышын уздыра. Бу түгәрәккә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Коләхмәтов, И. Аитов һ. б. кергән. (Саратов өлкәсе дәүләт архивы, 55 ф., 44 эш, 59 б.) |
| **10 декабрь** | Казанда «Кояш» исемле демократик юнәлештәге газета чыга башлый. Ф. Әмирхан җаваплы секретарь итеп билгеләнә. Тукайны, 40 сум айлык биреп, газетага язышучы итеп билгелиләр. Яңа газетаның идарәсе «Амур» кунакханәсенә урнаша. Ф. Әмирхан да, Тукай да «Амур»га күчеп (Тукай — тугызынчы бүлмәдә, Ф. Әмирхан — унберенчедә) тора башлыйлар. (Нуруллин И. Габдулла Тукай, 285 б.) |
| **17 декабрь** | Казанда «Аң» исемле әдәби-иҗтимагый журнал чыга башлый. Редакторы һәм нашире Әхмәтгәрәй Хәсәни. Журналга исемне Тукай тәкъдим итә. Беренче санында журнал чыгу уңае белән язылган «Аң» исемле шигыре басылып чыга. |
| **30 декабрь** | «Җан азыклары» басыла. Казан, «Мәгариф» көтепханәсе. Бу китап — шагыйрьнең үзе исән чакта чыккан иң соңгы җыентыгы. |
| **1913 ел**<br>**Ел башы** | Сәламәтлегенең көннән-көн начарлана баруына карамастан Тукай күп эшли, «Ялт-Йолт», «Аң» журналларында, «Кояш» газетасында әледән-әле аның әсәрләре чыгып тора. Басылачак «Мәҗмугаи асарен» хәзерли. («Хатирәләр», 174 б.) |
| **26 февраль** | Иптәшләренең киңәше белән, айга 150 сум хак түләү турында килешеп, Тукай Казанда Клячкин шифаханәсенә керә. Биредә шагыйрьне врач Р. А. Лурия дәвалаган. (Фәйзуллин М. Тукайны кем дәвалаган? — «Социалистик Татарстан», 1985, № 226. «Хатирәләр», 174 б.) |
| **Март** | Тукайның хәле начарая бара, температурасы гел югары тора. Үзе һаман көндәлек матбугатны күзәтеп, укып бара. («Хатирәләр», 173—180 б.) |
| **18 март** | Ф. Әмирханга хат яза. «Кояш»ның тәртипсез килүен, соңгы санын тизрәк үзенә җибәрүне үтенә. (5, № 32). |
| **20 март** | «Аң» журналы редакторы Ә. Хәсәнигә хат яза. «...7 нчегә өстәргә материал алып китсәң, ярыйдыр иде, ...8 нчедән дә гафил калмам». (5, № 33.) |
| **28 март** | Зәйнәп Хәсәниягә хат яза. «8 нче санга бар кадәремне җибәрдем. Беренче корректурасын үземә күрсәтсәңез иде». («Аң»ның 8 нче саны Тукай үлгәч, 10 апрельдә чыга, анда Тукайның 3 шигыре басыла). Бу — Тукайның соңгы хаты. (5, № 34). |
| **31 март** | «Бердән авыраеп, ашау-эчүдән вә йокыдан тәмам киселде... хәлен белергә килүчеләр белән бәхилләшә, аз сөйләшә вә сораган сөальләргә дә бер сүз яхуд баш ишарәсе илә генә җавап бирә башлады». («Хатирәләр», 175 б.) |

| | |
|---|---|
| **1 апрель төштән соң** | Тукайның рөхсәте белән фотограф чакырыла һәм утырган, һәм яткан көенчә рәсемгә төшерелә. («Хатирәләр», 175 б.) |
| **2 апрель кичке сәгать 6** | Тукай янына «Аң» журналы редакторы Ә. Хәсәни килә. Тукай аңардан: «Актык корректура кайчан?» — дип сорый. Хәсәни, ул сораган корректура янында булса да: «Иртәгә була»,— дип җавап бирә. («Хатирәләр», 178 б.) |
| **Кичке 8 сәгать 15 минут** | Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның йөрәге тибүдән туктый. |

«Хроника»ны СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре Лена **ГАЙНАНОВА** төзеде.

---

КАМЧЫ ҖУНУСОВ, кыргыз язучысы.

*...Тукайның әсәрләре кыргыз халкына бик күптәннән таныш инде... Кыргыз әдәбиятының аксакалы өлкән акыныбыз академик Аалы Токомбаев, күренекле әдипләребез К. Баялинов, У. Абдукаимов, Н. Җантөшев, М. Токобаев, К. Маликов, М. Абдукаримов, Т. Өметалиев һәм башкалар әле гарәп хәрефләре белән чыккан басмаларыннан Тукай әсәрләрен укып өйрәнгәннәрен сөйлиләр...*

ГАФУР ГОЛӘМ, үзбәк халык шагыйре.

*Габдулла Тукай — татар халкының бөек шагыйре, сөекле улы. Ләкин Габдулла Тукайны фәкать татар халкының шагыйре дип әйтү генә җитми. Ул татар халкының горурлыгы, әмма шуның белән бергә Тукай — Россиядә яши торган күп кенә башка төрки халыклар арасында, иң элек аларның укымышлылары арасында киң танылган, яратып укыла торган зур әдип тә.*

*Габдулла Тукайның исемен телгә алгач ук, татар әдәбиятының үзбәк әдәбияты белән элемтәсе, алай гына да түгел, гомуми татар халкы белән үзбәк халкының тарихи элемтәсе күз алдыбызга килә.*

---

## МУСА ҖӘЛИЛ ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАНГАН ТАНТАНАЛЫ ҖЫЕЛЫШ

14 февральдә герой-шагыйрь исемен йөрткән Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында М. Җәлилнең 80 еллык юбилеена багышланган тантаналы җыелыш булды. Анда партия, совет, профсоюз һәм комсомол органнары, Казан һәм республикабызның хезмәт коллективлары вәкилләре, М. Җәлилнең көрәштәшләре һәм туганнары, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре, галимнәр, Мәскәүдән, Ленинградтан, союздаш һәм автономияле республикалардан, край һәм өлкәләрдән килгән кунаклар җыелды.

Президиумда — КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ә. Б. Баһаветдинов, КПСС өлкә комитетының икенче секретаре Л. М. Смагин, КПССның Казан шәһәр комитеты беренче секретаре М. М. Сухов, КПСС өлкә комитеты һәм Казан шәһәр комитетының бюро членнары һәм членлыкка кандидатлар, иҗат союзлары вәкилләре, партия, совет, профсоюз һәм комсомол органнарының җитәкче работниклары, производство алдынгылары, М. Җәлилнең бертуган сеңлесе Х. Җәлилова, тормыш иптәше Ә. Җәлилова һәм кызы Чулпан.

Тантаналы җыелышны Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ә. Б. Баһаветдинов ачты.

Муса Җәлилнең гражданлык һәм иҗат батырлыгы, аның совет кешеләрен коммунистик рухта тәрбияләүдәге роле турындагы доклад белән КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев чыкты.

М. Җәлилнең тууына 80 ел тулуны үткәрү буенча Бөтенсоюз юбилей комиссиясе председателе, «Новый мир» журналының баш редакторы, Советлар Союзы Герое язучы В. В. Карпов патриот-шагыйрь иҗатының күпмилләтле совет әдәбиятында тоткан урыны, бүгенге әһәмияте турында сөйләде.

Татар поэзиясе аксакалы, РСФСР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты Сибгат Хәким, М. Җәлилнең көрәштәше Р. Б. Хисаметдинов, КамАЗның слесарьлар бригадиры Ш. Х. Хөснетдинов, Бөгелмә районының «Восточный» совхозы сыер савучысы Р. Г. Лотфуллина, Чувашия АССР Язучылар союзы идарәсе председателе П. В. Афанасьев, Казан дәүләт университеты студенткасы А. Качкаева үз чыгышларында Җәлил иҗатының үлемсезлеге, аның буыннан-буынга күчеп яшәвечәге турында сөйләделәр.

Тантананың икенче өлешендә Татарстан сәнгать осталары катнашында музыкаль-шигъри спектакль күрсәтелде.

## БӨТЕНСОЮЗ ЮБИЛЕЙ КОМИССИЯСЕ ТӨЗЕЛДЕ

СССР Язучылар союзы идарәсе секретариатында «Атаклы татар шагыйре, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулуны билгеләп үтү турында» карар кабул ителде һәм бу уңай белән Бөтенсоюз юбилей комиссиясе составы расланды. Бөтенсоюз юбилей комиссиясе председателе итеп «Новый мир» журналының баш редакторы, Советлар Союзы Герое язучы В. В. Карпов билгеләнде.

## ҖЫР КӨРӘШКӘ ЧАКЫРА

Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең туган көне алдыннан политик поэзия бәйрәме уздыру матур бер традициягә әверелде. Быел бу чара В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының Мәрмәр залында политик митинг-реквием рәвешендә үткәрелде. Анда университет студентлары һәм укытучылары, Җәлилнең көрәштәшләре Р. Хисаметдинов һәм Ф. Солтанбеков, шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүче И. Зәбиров (Ташкент), В. Альтов (Оренбург) һәм Р. Мостафин, Бөтенсоюз юбилей комиссиясенең җаваплы секретаре, шагыйрь Г. Рәхим, язучылар һәм журналистлар катнашты.

Шигъри митингны Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, шагыйрь Р. Харис кереш сүз белән ачты. Митингта фронтовик шагыйрь З. Нури, Ә. Баянов, Г. Рәхим, Р. Әхмәтҗанов, Р. Гатауллин, Ә. Рәшитов, К. Булатова, Ш. Маннапов, Зөлфәт, Р. Миңнуллин һәм яшь шагыйрьләр үз әсәрләрен укыдылар. Казан дәүләт университетында белем алучы Куба, Вьетнам, ГДР студентлары М. Җәлил шигырьләрен, үз шагыйрьләренең тынычлыкка, дуслыкка чакырган әсәрләрен укыды, үзешчән автор һәм башкаручы Ф. Еникеев үзенең «Набат» дигән җырын башкарды.

Политик шигырь бәйрәмендә катнашучылар тынычлыкны яклап, «Әлегә соң түгел!» дип аталган Өндәмәгә кул куйдылар.

Шигъри митинг Казан телевидениесе тарафыннан республикабыз хезмәт ияләренә күрсәтелде.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

13—14 февральдә Казан дәүләт университетында М. Җәлилнең тууына 80 ел тулуга багышланган фәнни конференция булды. Аның эшендә Мәскәү шәһәре, союздаш һәм автономияле республикалар язучылары, әдәбият белгечләре катнашты. «М. Җәлил һәм хәзерге совет әдәбиятында героик һәм пат-

риотик традицияләр» дигән темага Казан дәүләт университеты һәм Татарстан Язучылар союзы оештырган бу конференцияне КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев ачты.

Пленар утырышта М. Җәлил иҗатындагы героик характер сыйфатлары, интернационалистик үзенчәлекләр, хәзерге әдәбиятта аның героик-патриотик традицияләре турында Казан дәүләт университеты һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре докладлар белән чыктылар. Конференциядә язучылар С. Хәким, И. Юзеев, Р. Харис, Д. Вәлиев, Ф. Мусин, Н. Юзиев, А. Әхмәдуллин, Р. Мөхәммәдиев һ. б. чыгыш ясады. Фашизм тоткынлыгында М. Җәлил белән бергә көрәшкән Р. Хисаметдинов үзенең истәлекләрен сөйләде.

Аннары конференция секцияләргә бүленеп эшләде. Аның эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире Р. И. Әдһәмов катнашты.

### МЕМОРИАЛЬ ТАКТА АЧЫЛДЫ

14 февральдә Казанның Бауман урамындагы Матбугат йорты бинасында (19 нчы йорт) Муса Җәлил исталегенә мемориаль такта ачу тантанасы булды. Шушы уңай белән үткәрелгән митингны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин ачты. Анда М. Җәлилнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүче әдәбият белгече Р. Мостафин, Казанның 80 нче мәктәбе укытучысы В. Чеканова, Казан дәүләт университетының өлкән фәнни сотрудникгы, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Н. Зәбиров, язучы Г. Ахунов, шагыйрь Р. Гатауллин һ. б. чыгыш ясады.

Мемориаль тактага рус һәм татар телләрендә: «Бу бинада 1939—1940 елларда Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, шагыйрь Муса Җәлил эшләде», — дип язылган. Мемориаль тактаның авторы — РСФСРның атказанган художнигы, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт һәм республика комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләре лауреаты скульптор В. Маликов.

Мемориаль тактаны ачу тантанасында М. Җәлил юбилеен үткәрү буенча Бөтенсоюз комиссиясе председателе, Советлар Союзы Герое В. В. Карпов, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, М. Җәлилнең тормыш иптәше Әминә Җәлилова, кызы Чулпан катнашты.

Шул ук көнне республикабыз язучылары һәм Муса Җәлилнең юбилей тантаналарында катнашучы кунаклар В. И. Ленин, А. С. Пушкин, Г. Тукай һәм М. Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр куйдылар.

### ҖӘЛИЛ ҺӘМ ҖӘЛИЛЧЕЛӘРДӘН ИЛҺАМ АЛЫП

Тормышы һәм иҗаты белән үлемсез батырлык үрнәге булган Муса Җәлил үзе дә әдәбият һәм сәнгатьтә героик образга әверелде. Татарстан Художниклар союзының Күргәзмәләр залында шагыйрь юбилеена багышлап оештырылган күргәзмә — әнә шуның матур бер чагылышы.

14 февральдә күргәзмәне ачу тантанасы булды. Анда республикабыз башкаласының партия, профсоюз, комсомол оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, шәһәр җәмәгатьчелеге, мәктәп укучылары, шагыйрьнең туганнары, көрәштәшләре килгән иде.

Күргәзмәгә 40 художникның 70 кә якын әсәре куелган. Алар арасында Х. Якуповның «Хөкем алдыннан», В. Кудельскийның «Муса-политрук», Ә. Китаевның (Мәскәү) «Фашистлар тоткынлыгында», В. Скобеевның «Яңа опера туганда», Ф. Якуповның «Шагыйрь һәм палач» һ. б. талантлы иҗат җимешләре бар...

Күргәзмәне ачу тантанасында М. Җәлилнең көрәштәшләре Р. Хисаметдинов һәм Ф. Солтанбеков, шагыйрь Р. Харис һәм Казан медицина институты ассистенты М. Ситдикова һ. б. чыгыш ясады.

Күргәзмәгә керү юлындагы ал тасманы өлкән әдип, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Г. Бәширов кисте.

### «ТӨП НӘСХӘНЕ КАРАУ КӨНЕ»

Мәгълүм булганча, М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» Татарстан дәүләт музее фондында саклана. Герой шагыйрьнең кул җылысын, йөрәк кайнарлыгын туган илгә алып кайткан бу кадерле дәфтәрләр алты елдан бирле инде бөтенхалык күрсәтелүенә чыгарыла. «Төп нөсхәне карау көне» дип аталган бу чара быел 16 февральдә 11—16 сәгатьләрдә уздырылды. Анда күпсанлы поэзия сөючеләр, герой шагыйрьнең туганнары, көрәштәшләре һ. б. килгән иде.

«Моабит дәфтәрләре»н почетлы каравыл һәм кунаклар озатуында, барабан һәм быргы тавышлары астында Советлар Союзы Герое Б. К. Кузнецов алып чыкты. Музейның генераль директоры Л. Г. Вәлиеваның кереш сүзеннән соң, «Сугышчылар хәтерли», «Халык хәтерендә», «Муса Җәлил — герой шагыйрь», «Якташларыбыз — Советлар Союзы Геройлары», «Татарстан — Бөек Ватан сугышы елларында», «Өзелгән җыр эзеннән» дигән кызыклы чаралар, очрашулар, экскурсияләр уздырылды. Аларда М. Җәлил эшләгән фронт газетасы «Отвага» редакциясенең җаваплы секретаре В. А. Кузнецов, герой шагыйрьнең көрәштәшләре Ф. Солтанбеков, Р. Хисаметдинов, М. И. Иконников, язучылардан Р. Мостафин, Р. Харис, әзербайҗан шагыйре С. Рөстәмханлы, каракалпак шагыйре М. Карабаев, Казан театр училищесы студентлары, Казанның 124 мәктәп укучылары һ. б. чыгыш ясады. Укучыларны ВЛКСМ сафына кабул итү булды.

Шундый ук тантаналы шартларда «Моабит дәфтәрләре»н Советлар Союзы Герое С. М. Ильченко янадан Татарстан дәүләт музее фондына кайтарды.

### ШАГЫЙРЬНЕ ЯКТАШЛАРЫ ЗУРЛЫЙ

Оренбург якларында Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулу уңаеннан зур тантаналар булып узды. Анда шагыйрьнең сеңлесе Хәдичә Җәлилова, туганы Таһир Корбанов, кө-

рәштәшләре Р. Хисаметдинов һәм Ф. Солтанбеков, шагыйрьләр Ш. Галиев һәм Р. Харис, Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүчеләр В. Альтов (Оренбург), И. Зәбиров (Ташкент) һәм Ш. Хамматов (Казан) катнашты.

Оренбургтагы «Россия» культура сараенда, Шарлык район үзәгендә, шагыйрьнең туган авылы — Мостафада тантаналы кичәләр үткәрелде. Оренбург туган якны өйрәнү музеенда шагыйрьнең гражданлык һәм әдәби батырлыгына багышланган даими экспозиция ачылды. Мостафа авылында Муса туган нигезгә мемориаль такта кую уңаеннан митинг булды.

Оренбургның Н. К. Крупская һәм Х. Ямашев исемендәге китапханәләрендә һ. б. урыннарда юбилей тантанасына килгән кунаклар белән очрашулар үткәрелде.

М. Җәлилнең 80 еллык юбилеена килүчеләрне Халык депутатларының Оренбург өлкә Советы башкарма комитеты председателе урынбасары В. Ф. Голубничий кабул итте.

## СВЕРДЛОВСКИДА ЮБИЛЕЙ ЧАРАЛАРЫ

Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулу көннәренә багышлап, Свердловск шәһәрендә дә чаралар үткәрелде. В. Г. Белинский исемендәге өлкә китапханәсендә шагыйрьнең төрле елларда, төрле телләрдә басылып чыккан әсәрләре һәм аның үз иҗатына багышланган хезмәтләрнең зур күргәзмәсе оештырылды. Шундый ук күргәзмәләр шәһәр һәм өлкә мәктәпләрендә, китапханәләрендә дә булды. Өлкә газеталары — «Уральский рабочий», «На смену», «Вечерний Свердловск» һ. б. көндәлек матбугатта М. Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын яктырткан мәкаләләр, шагыйрьнең әсәрләре басылды.

21 февральдә шәһәрнең Автомобилистлар культура сараенда Бөтенроссия китап сөючеләр җәмгыятенең өлкә оешмасы идарәсе тарафыннан кичә үткәрелде. Анда М. Горький исемендәге Свердловск дәүләт университеты доценты, филология фәннәре кандидаты В. В. Химич герой шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында сөйләде, Урал ягы язучысы, «Яшь Муса» исемле китапның авторы С. Б. Шмерлинг шул әсәрне язгандагы тәэсирләре белән уртаклашты. Аннары Свердловск дәүләт филармониясенең нәфис сүз остасы, РСФСРның атказанган артисты Дауд Бикбов татар һәм рус телләрендә Муса Җәлил әсәрләрен укыды.

Җәлил юбилее уңаеннан уздырылган әлеге чаралар Свердловск шәһәре культура тормышында зур вакыйга булып әверелде.

Бу хакта безгә Ф. Шәнгәрәев хәбәр итте.

## «ЛЕГЕНДАГА ТИҢ ГОМЕР»

Уфа шәһәренең Химиклар культура сараенда Муса Җәлилгә багышлап, әнә шул исемдәге күргәзмә оештырылды. Ут күршеләребез М. Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын яктырткан материалларны, аңа атап язылган әсәрләрне, шагыйрьнең туганы Ибраһим Җәлилов истәлекләрен зур кызыксыну белән карадылар. Бу күргәзмәгә материаллар җыюда шәһәр мәктәпләренең эзтабарлары күркәм эш башкарды.

## ЮБИЛЕЙГА БАГЫШЛАП

Муса Җәлил юбилее илебезнең культура тормышында зур вакыйга буларак зурлап билгеләп үтелде. Үзәк, союздаш һәм автономияле республикалар нәшриятлары Җәлилнең әсәрләре тупланган яки аның тормышына, иҗатына һәм фашистларга каршы көрәшенә багышланган китаплар, альбомнар, җыентыклар бастырып чыгардылар. Татарстан китап нәшриятында герой шагыйрьнең үз әсәрләре, аңа багышланган фотоальбом һәм зур форматлы плакатлар сериясе басылды. Илебездәге күпләгән газета-журналлар, радио һәм телевидение тапшырулары герой шагыйрь истәлегенә багышлап материаллар бирделәр.

Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулу алдыннан патриот шагыйрьгә багышланган почта басмалары коллекциясе янә баетылды: шагыйрьнең портреты төшерелгән бизәкле конверт чыгарылды. Юбилей көнендә Казан почтампты аша үткән корреспонденцияләргә махсус штемпель басылды.

## ҖӘЛИЛГӘ — ЧӘЧӘКЛӘР

Көнбатыш Берлин. Фашистларның Плетцензее төрмәсендә Европаның бик күп иленнән меңләгән патриотлар — гитлеризмга каршы көрәшүчеләр җәзалап үтерелгән иде. Алар арасында — коммунист шагыйрь, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре дә бар. Хәзерге вакытта Плетцензеада фашизм корбаннары истәлегенә куелган мемориаль комплекс эшли. Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулган көннәрдә бирегә, татар халкының каһарман улына Көнбатыш Берлин кешеләре веноклар һәм чәчәк бәйләмнәре алып килделәр. Килүчеләр арасында Көнбатыш Берлинның Бердәм социалистик партиясе правлениесе, Герман — Совет дуслыгы җәмгыяте вәкилләре, нацизм вакытында эзәрлекләнүчеләр берләшмәсе — Антифашистлар союзы членнары бар иде.

Чыгыш ясаучылар күзләренә үлем карап торган зинданда фашизмны җиңүгә какшамас ышаныч белән ялкынлы шигырьләр язуын дәвам иткән совет коммунистының рухи ныклыгы турында сокланып сөйләделәр, Муса Җәлилнең немец хезмәт ияләренә карата йөрәгендә дуслык хисләре саклангалыгын әйттеләр. («Правда» газетасының 1986 елгы 18 февраль санынан).

# МӘҢГЕЛЕК ЯЗ ЮЛДАШЫ

Күңелемдә көн һаман аяз — һаман да яз...

Татарстанның халык рәссамы Мәснәви Хәйретдиновның «Габдулла Тукай» портреты ирексездән әнә шундый шигырь юлын хәтергә төшерә. Яз!.. Табигать яңарыш кичерә. Һәр тарафта яшеллек тантана итә.. Мәңгелек яз тантанасы...

Тукайның шундый җирлектә гәүдәләндерелүе бөтен яктан да аклана. Тукайны яздан аерып булмый: ул язда килгән, язда янган... Һәм үлемсез Тукайның гомере мәңгелек язларга кушылып дәвам итә. Портретка менә шундый тирән мәгънә салынган.

Эчтән янып торган шагыйрь сынының күрер күзгә «чәчрәп» тормаган силуэты Тукайны үлемсезлеккә озатып калган туган җир пейзажына органик төстә кушылып киткән. Шагыйрь биек елга яры өстендә утыра. Бәрәкәтле туган җир туфрагы аны әнә шулай югары күтәргән. Бихисап төстәге чәчәк һәм үләннәр катлаулы тормыш «корамасы»ның төрлелегенә ишарәли шикелле. Картинада ерак киңлекләр колачлана. Күренмәс җепләр шагыйрьне нәкъ менә шушы чиксезлеккә тоташтырган.

Җирдә яз тантана итә. Кара реакция елларында туңа-туңа халык йөрәген җылыткан Тукай күңеленә күптән көтеп алынган җылы яз иңә. Галибанә ябтырып яткан яз таңы яктыга һәм җылыга сусаган җирне нурга коендыра. Шагыйрь кулындагы шомырт чәчәгеннән ниндидер салкынлык бәреләшикелле. Монысы да ишарә. Гомере буе туңа-туңа халык җанын җылыткан Тукай, әнә шулай иртә чәчәк атучы шомыртның ап-ак таләгәшләрен тотып, мәңгелек яз белән бергә киләчәккә баруын дәвам иттерә.

**Вера ЦОЙ,**
ТАССР сынлы сәнгать музееның
бүлек мөдире.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Арча районының Тукай-Кырлай авылында Габдулла Тукай музее күренеше.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.

Тукайның 100 еллыгына

# Тукай көне

Гәрәй РӘХИМ шигыре

Рәшит ГОБӘЙДУЛЛИН музыкасы

Урманнарда язгы яфрак яра,
Яшелләнә илем, яшәрә.
Язлар саен бөек Тукай көне
Дәртләндерә безне яшәргә,
Дәртләндерә мәңге яшәргә.

Татарстан, сиңа язлар саен
Төрле җирдән дуслар җыела.
Шундый чакта туган Кырлаена
Тукай кайткан сыман тоела,
Үзе кайткан сыман тоела.


Арыслапдай ирләр бирдең илгә,
Рәхмәт сиңа, әй, туган халкым!
Ил күгендә мәңге балкып янар
Иөрәгеңнән чыккан ул ялкын,
Тукай дигән якты ул ялкын.






Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)